ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2007





**Кәрим Тинчурин**
**(1887–1938)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

# 9

(1019)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсният**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Күзге моңнар. *Шигырьләр.* ..... 5
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Тансык язлар, тансык назлар. *Сигезьюллыклар.* .. 26
Мәдинә МАЛИКОВА. Тылсым. *Роман.* ..... 29
Әхмәт ГАДЕЛ. Ватаным. *Шигырьләр.* ..... 95
Асия ЮНЫСОВА. Кое күзләреннән су алдым... *Шигырьләр.* ..... 98
Марат ӘМИРХАНОВ. Убыр уты. *Хикәя.* ..... 103

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Алты кызга бер кияү. *Моңсу комедия.* ..... 9

**КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Кәрим ТИНЧУРИН. ..... 116

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Индус ТАҺИРОВ. Тел вә моң – миллилек чыганаклары. ..... 120
Эльмира ГАЛИЕВА. Бай тарихлы гали мәдрәсә. ..... 126

**ФӘН**

Ринат СОЛТАНОВ. XVI-XVII гасырларда Казан тирәсендәге авыллар. ..... 134
Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Гаспралы мирасы кайта. ..... 142
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 146
Фәнис ИСЛАМОВ. Шифалы йогынты. ..... 167
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 172

**СӘНГАТЬ**

Филүсә АРСЛАН. Татар җанлы рус кешесе... ..... 151

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Бикә РӘХИМОВА. Халык китабы. ..... 156
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. «Моңлы ядкарь». ..... 159

**СӘГЫЙТЬ ХӘЛФИННЕҢ ТУУЫНА 275 ЕЛ**

Әхмәтзәки ВӘЛИДИ. Сәгыйть Хәлфин. ..... 164

**ҖӘМАЛ ВӘЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Җәмалетдин ВӘЛИДЕВ. Кавем вә кабиләбез арасында. ..... 176

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 182
Котлыйбыз! ..... 183
Укучы сүзе. ..... 184
Берлекнең яңа әгъзалары ..... 185
«Казан утлары» архивыннан. ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман М. МАЛИКОВОЙ «Очарование» (окончание); рассказ М. АМИРХАНОВА «Блуждающие огни»; стихи Р. ИДИЯТУЛЛИНА, Г. МУХАМЕТШИНА, А. АДИЛЯ, А. ЮНУСОВОЙ.
«Драматургия»: Т. МИННУЛЛИН. Комедия. «Один жених на шесть невест».
«Публицистика»: И. ТАГИРОВ. «Два источника национального»; статья Э. Галиевой о знаменитой медресе «Галия».
«Наука»: Ф. СУЛТАНОВ. «Деревни в окресностях Казани в XVI—XVII веках»; А. СИБГАТУЛЛИНА. «Возвращается наследие Гаспралы»; Ф. ИСЛАМОВ. «Благотворное влияние»; Ф. Гарипова «История наших деревень» (продолжение); А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение).
«Искусство»: статья Ф. АРСЛАН о композиторе А. Ключареве.
«Книжное обозрение»: рецензии Б. РАХИМОВОЙ на книгу Р. Муллануровой «Одинока, как береза...» и А. ЗАКИРЗЯНОВА на книгу Амануллы «Грустная память».
В номере отмечаются 275-летие С. Халфина, 120-летие К. Тинчурина и Дж. Валиди.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Слово читателя
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Золотая осень; писатель Дания ГАЙНУТДИНОВА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by M. MALIKOVA «Charm» (termination); story by M. AMIRHANOV «Wandering fires»; verses by R. IDIYATULLIN, G. MUHAMETSHIN, A. ADIL, A. YUNUSOVA.
«Dramatic art»: T. MINNULLIN. Comedy. «One groom for six brides».
«Publicism»: I. TAGIROV. «Two sources of national»; article by E.Galieva about well-known medrese «Galia».
«Science»: F. SULTANOV. «Villages in suburbs of Kazan in XVI-XVII centuries»; A. SIBGATULLINA. «Gasprala's heritage comes back»; F. ISLAMOV. «Beneficial influence»;
F. GARIPOVA «History of our villages» (continuation); A.TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation).
«Art»: article by F. ARSLAN about composer A.Klucharev. «Book review»: reviews by B. RAHIMOVA on book by R. Mullanurova «Lonely as a birch...» and A. ZAKIRZYANOVA on book by Amanulla «Sad memory».
In number are celebrated 275th anniversary of S.Halfin, 120th anniversary of K.Tinchurin and G. Validi.
Pages from «Tatar encyclopedia».
Word of reader.
New members of Union of writers. From photoarchive of magazine.
Diary of socially-cultural life.
On our covers: Mellow autumn; writer Dania GAYNUTDINOVA.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.08.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–1017 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.



Рим
Идиятуллин

# КӨЗГЕ МОҢНАР

## Карлар яуганда

**Күрәсеңдер ич!—Күкләрдән Ходай
Кушучлап сибә өмет бөртеген;
И Алма әби!—
Күзеңнән һаман яшь койдырамы
Картайган мичтән бөркелгән төтен?**

**Җем-җем кар ява,—җилферди җилдә
Зәңгәр каймалы ап-ак ашъяулык;
И Чибәр әби!—
Ятасың, беләм, сызланган килеш
Безләргә теләп гомерлек саулык.**

**Иркә кар ява,—алчак кунактай
Томса күңелнең түрен балкыта;
И Ерак әби!—
Чеметеп пәрдәң, ник син зиратка
Күз саласың еш соңгы вакытта?!**

**Чабыша карлар,—сабантуйларда
Узышка чыккан малайлар сыман;
И Кендек әби!—
Шылт тавыш та юк кысыр авылда
Кылып яшисең, әйт, нинди гөман?!**

**...Ә көн ачылган... Ник ачылмаган
Ыңгыр-шыңгырлы кече капкагыз?!
Ак әбиләрем!—
Яшьлек төседәй яшь-яшь карларга
Кем кот кундырыр, тормый ятсагыз?!
Аһ, әбиләрем...**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940)—*шагыйрь; «Хәерле иртә», «Хәерле көн» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Уфа шәһәрендә яши.*

## Халык артисткасының соңгы роле

*Кызым Резедага*

Пәрдә төште. Сүнде гөр алкышлар...
Утырып ул көзге каршына,
Кайтты кабат чын үз төсенә:
Йөзен тирән сырлар сарган карчык
Карап тора яшьле күзенә...

Их, хушыгыз, былбыл Асылъярлар,
Ак калфаклы Галиябанулар,
Нафталинлы кофта исләре...
Сәхнәләргә сеңеп калгандыр ла
Мең-мең баскан аяк эзләре?!

...Ә иртәсен күрше Гайни белән
Базарларны урый башларлар,
Сорый-сорый сөт йә ит хакын;
Көн авышкач, ирен күреп килер...
Татар зиратында... бик якын.

Әле тын урамнан атлый, сүзсез
Бер Узгынчы ролен башкарып;
(Хас—ялгыз каз, җуйган бәбкәсен...)
Нигә атмый чүпкә тынчу кичтә
Төсе качкан соңгы чәчкәсен?!

Килеп җитте йорты каршысына;
Пәрдә төшкән җансыз тәрәзгә
Күз атарга курка карашлар;
...Тәтемәде бәхет: аягүрә
Үләлмәде—залда алкышлар
Күкрәгәндә...

## Кызу учак каршындагы салкын уйлар

Мин күнектем, бугай, ялгызлыкка,—
Җансыздан да җанга иш табам:
Тын кичләрдә җәйге челләдә дә
Бакча-йортта тимер мич ягам,
—Сердәш булсынга.

Әнә,
Япь-яшь утын яшен сыга-сыга
Калтыранып яна карт мичтә;
Уй-учагым өреп сүндерәлсәм,
Их, уйланмас идем мин һич тә!—
Уйландыра-а...

Ярка утын һәм дә ялгыз бәндә...
Арабызда нинди аерма?
(Ул төтенләп яна, мин—төтенсез...)

Җавап булып микән, кан төере
Суга, каһәр, чигә тамырга.

Үсмер каен, күктән күз яздырмый,
Ауган чакта йөзе караеп,
Уйлаганмы: «Авалмадым җиргә,
Балталылар кебек, картаеп».
Уйлагандыр!

...Ә менә,
Инквизитор атлап килгән мәлдә
Утлы кисәү тотып кулына,—
Галәмнәрне кочып өлгергәнме,
Чиксезлеккә гашыйк Бруно?—
Кем белә?!

Чиксезлекне сөю сеңәдер ул
Карында ук адәм канына;
Тик кара!—
Берчак җырлап кискән мәрхүм каен
Төпсәсенә «гөрс» абына...—
Бичара!

Дөрестән:
Хак балчыгы, сабый сыйфаттан ук,
Шуып төшү белән бишектән,
Кулга капкан җисми һәр матдәне
Сыткан, кырган, теткән, көл иткән
(Менә минем кебек,—мич ягып)...

Ышанам,—
Кеше—бөек: көчлелеген җиңеп,
Гыйфритлекнең ертып пәрдәсен,
Кечтек бөҗәк, терек күзәнәктә
Таный алса якын кардәшен.

...Юк, күнегә алмыйм ялгызлыкка,
Таба алмыйм аңа һич дәва;
Гөнаһларым күптер: янгыр түгел,
Күк катыннан башка таш ява,
—Кап-кара...

## Шагыйрь яше

Сабый чакның күз яшьләре ачы,—
Апуш моңын тоеп үскәнгәдер;

Шат яшьлекнең күз яшьләре ширбәт,—
Сөйгәнеңне кочып үпкәндәдер;

Җирнең битен көйдерердәй кайнар,—
Әнкәң каберенә чүккәндәдер;

Джордано Бруно—урта гасырда чиксезлек тәгълиматын яклаган өчен инквизиция тарафыннан терелә́й утта яндырылган итальян философы һәм шагыйре.

**Гүре дөрләр кебек—яшьләреңне**
**Балаң туфрагына түккәндәдер;**

**Җанны бозга катырырдай салкын.—**
**Мең сырхаулы картлык килгәндәдер;**

**Шагыйрь яше җылы,—илдә Тукай**
**Калганлыкны күреп үлгәнгәдер...**

***

**...Шәмсетдин Суфый Зәки,**
**Илһам тамар дип, бәлки,**
**Кояш күтәрелгәч,**
**Шәм яндырып куйды**
**Шигырь валчыклары өстенә.**

**—Нидән Суфый, балкыш баккач,**
**Ут тергезеп утыра?!**
**Җан түрендә сүнде мәллә**
**Илаһ сипкән яктылык?!**
**—Җир өсләрен томан булып**
**Каплап ятты шакшылык;**
**Шәйләми акны күзләрем,—**
**Сарды дөнья карасы.**
**—Өч көнлекне Мәңгелеккә**
**Тиңләр Адәм баласы;**
**Кичмәк булыр Сиратны да**
**Какмый гөнаһ тузанын.**
**—Гавам таптап чыкты тәмам**
**Изгелекнең ызанын;**
**Иман сатып, әсир төште**
**Нәфес ташкан Иблискә.**
**—Бәндә Җирдә бер тоткындыр,**
**Күз терәмәсә Күккә;**
**Күләгәсен сагынып елар,—**
**Илаһ шәмен сүндерсә.**
**—Яктыда шәм яндырсам да**
**Күрмим: кай юлда инсан?!**
**—Сукыр шагыйрь күрмәс булгач,**
**Күзле сукырга ни сан!..[1]**

♣

[1] XIX йөздә яшәгән тома сукыр, үткен, фәлсәфи акыллы шагыйрь Ш. Зәки шәүләләрне, яктылыкны бераз аерган дип фаразлый күренекле татар галиме Хатыйп Миңнегулов. Бу шигырьдә шуңа ишарә (Р.И.).



Туфан
Миңнуллин

# АЛТЫ КЫЗГА БЕР КИЯҮ

МОҢСУ КОМЕДИЯ

**Катнашучылар:**
Рәхмәтулла Хөрмәтуллович—59 яшьтә
Гөлчирә—42 яшьтә
Фаягөл—39 яшьтә
Рузалия—19 яшьтә
Нурзидә Мөбарәковна—45 яшьтә
Хәдичә—40 яшьтә
Нина Васильевна—42 яшьтә

*Вакыйга бухгалтериядә бара.*

## I ПӘРДӘ

*Бер бүлмәдә алты өстәл. Бөтен өстәлләрдә дә компьютер. Пәрдә ачылганда Рәхмәтулла үз өстәле артында эшләп утыра. Әкрен генә көйли.*

Заманалар авыр, еллар ябык —
Дус-иш кирәк гомер итәргә...
Заманалар авыр, еллар ябык...
Заманалар авыр, еллар ябык...

*Хәдичә керә, Рәхмәтулла өстәленә тастымалга төрелгән ризык куя.*

Хәдичә. Суынганчы капкалап алыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Рәхмәтулла. Ач түгел мин, Хәдичә. Нигә инде син?.. *(Хәдичә сүзсез генә үз өстәле янына барып утыра. Күзгесенә карап төзәтенә. Рәхмәтулла аны күзәтә).* Сиңа чәчне кыектан ачу килешә, Хәдичә. *(Янына килеп).* Менә бу яктан ач, бу ягын күпертебрәк җибәр. Синең йөзең тулган ай кебек түгәрәк, күпертебрәк җибәрсәң, тагын да чибәрләнәсең. Чын татар кызының чибәрлеге синдә. *(Хәдичәнең аркасыннан чәбәкли дә өстәле янына бара).*

Фаягөл *(керә).* Шушы трамвайларның тәгәрәп җан биргәннәрен генә күрсәм иде. Троллейбусларын үләт себереп китсен иде. Маршруткалары мәталеп үлсен иде.

Рәхмәтулла. Соңга калмадың ич, Фаягөл.

Фаягөл. Калмаса ни. Үләрдәй булып чаптым. Үпкәм бугазыма килде.

Туфан МИҢНУЛЛИН (1935)—*драматург, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы; күпсанлы китаплар, сәхнәләштерелгән күп пьесалар авторы. Казанда яши.*

Рәхмәтулла. Җәяү йөрү сиңа файдалы ул, Фаягөл. Билең әз генә калыная башлады. Кызлар биле 60 сантиметр булырга тиеш.

Фаягөл. Кызлар биле бит ул.

Рәхмәтулла. Синең кай җирең кызлардан ким? Синең атлап йөрүләреңә карап торам да яшь чагым искә төшә.

Фаягөл. Сезнең аркада ашыгам мин. Кайчан килсәң дә сез тасраеп утырасыз. Сезгә карап мин чабам.

Рәхмәтулла. Яшьрәк булсам, мин синең арттан чабар идем. Алданрак туарга ашыкканмын шул. Яңа туфли алгансың икән.

Фаягөл. Шул аякларымны кырып бетерде инде.

Рәхмәтулла. Аякларың кырып ясалган кебек шул.

Фаягөл. Күз тидермәгез тагын. Без бит исәнләшмәдек тә. Исәнме, Рәхмәтулла абзый. *(Рәхмәтулланың битеннән үбеп ала.)* Исәнме, Хәдичә. *(Урынына барып утыра).*

Рузалия *(керә).* Исәнмесез.

Рәхмәтулла. А-а-а, Рузалия!... Безнең яраткан кызыбыз да килде.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Рузалия:
Шул Рузалияне күрсәм,
Йөрәгем сикерия.

Мәхәббәт өлкәсендә уңышлар ничек, Рузалия?

Рузалия. Окей.

Рәхмәтулла. Их миңа унтугыз яшь булса...

Фаягөл. Нишләр идегез, Рәхмәтулла абзый?

Рәхмәтулла. Рузалияне үземә каратыр идем.

Рузалия. Мин болай да сезгә карыйм, Рәхмәтулла бабай.

Фаягөл. Бабай димә, безне картайтасың.

Нина *(керә).* Исянмесез. *(Рәхмәтуллага).* Привет, жених. Килегез әле, аракы исе килмәгән бер егетне кочаклыйм әле. *(Рәхмәтулланы кочаклап алганнан соң).* Привязался бер алкаш трамвайда. Зараза. С утра тыгынган, сволочь. Дөрес әйтәмме, Рахматулла Хурматуллович? Тыгынган—налакался бит, да?

Рәхмәтулла. Син әйтсәң дөрес, Ниночка. Ты всегда истину глаголишь. Как спали, Нина Васильевна?

Нина *(кәефсез генә).* Бик яхши.

Рәхмәтулла. Вы Шекспира читали, Нина Васильевна?

Нина. Какого Шекспира?

Рәхмәтулла. Был такой англичанин. Он писал гениальные трагедии. «Отелло», например. Так вот Отелло говорит своей возлюбленной: «Молилась ли ты на ночь, Дездемона?».

Нина. Ну и что?

Рәхмәтулла. Задушил Отелло Дездемону.

Нина. Причем здесь я?

Рәхмәтулла. При том, Ниночка, улыбаться надо. Улыбка делает женшину прекрасной.

Нина. Ну и улыбнитесь. Кстати, почему сез минем белән урысча сөйләшәсез. Мин татарча өйрәнәм. Мин сине яратам—приходи к воротам.

Гөлчирә *(керәп).* Капиталистик хезмәт алдынгыларына ялкынлы сәлам. Рәхмәтигә аерым сәлам. *(Рәхмәтулла янына килеп).* Нихәл. (Рәхмәтулланың пеләшен үбеп ала). Пеләш башны үбүе җайлы, авызга чәч керми. Кара утырып торуын. Тор һәм кочакла. *(Үзе Рәхмәтулланы кочаклап ала).* Утыр һәм эшлә.

Фаягөл. Әгәр дә Зөһрә Таһирны шулай кочаклаган булса, мәхәббәт турында гениаль әсәр язылмый калган булыр иде.

Гөлчирә. Көнләшмә. Шул җиткән аңа. Югыйсә азына башлый. Шунысын да онытмагыз, Таһир пеләш башлы булмаган.

Рәхмәтулла. Пеләш башлы ирләр бүгенге заманда файдалы, Гөлчирәкәй. Парикмахерскаяда бәяләр көн саен арта.

Гөлчирә. Сөйләштермә, эшем күп. *(Берара тыныч кына эшлиләр).*

Рәхмәтулла. Ишетмим. Бүген кем чираты? Рузалия, синме?

Рузалия. Мин кичә көйләдем. Бүген Нина Васильевна көне.

Рәхмәтулла. Ниночка, начинай. Эшләп булмый.

Нина. Не умею я мурлыкать. Белмим.

Рәхмәтулла. Бүтән көннәрне белә идең.

Нина. Бүген нет у меня настроения.

Рәхмәтулла. Настроение жырлаганда килә.

Нина. Прямо как надзиратель сез, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Не надзиратель, а петух в курятнике.

Гөлчирә. Ah! Петух! Карт әтәч.

Рәхмәтулла. Сез дә чебиләр түгел. Нина, котәм. Жду. *(Нина авыз эченнән бер көйне көйли. Ул көй салмак кына яңгырый).*

Гөлчирә *(кычкырып жибәрә).* Сабакы! Тагын глюк башланды.

Рузалия. Нәрсә карый Президент?!

Нина. Куда смотрит Правительство?!

Фаягөл. Нигә Дәүләт Советы дәшми?!

Гөлчирә. Көлмәгез. Мина иске шайтан машинасы бирделәр дә... Рәхмәти, кил кара.

Рәхмәтулла. Гел синеке генә кәжәләнә, Гөлчирә.

Фаягөл. Компьютеры да үзенә ошаган.

Гөлчирә. Молчи, морду набью.

Рәхмәтулла. Матур гына сөйләшегез. *(Компьютерны карый)*

Нина. Тихо! Рузалия с кавалером будет говорить. *(Рузалия кесә телефонын колагына куеп, чыгып йөгерә).*

Фаягөл. Их! Сотовыең булсын иде дә шалтыратсыннарые.

Рәхмәтулла. Булды бу, Гөлчирәкәй.

Гөлчирә. Маладис! Безнең ишан хәзрәтнең белмәгәне юк. *(Көйләп).*

Ишан хәзрәт, бар утыр,
Син бит безнең компьютыр.

*Нурзидә Мөбарәковна керә.*

Нурзидә. Хәерле иртә.

Рәхмәтулла. Иртә түгел, Нурзидә Мөбарәковна. Иртә ул эшкә килгәнче генә була. Котлы булсын яна күлмәгегез.

Нурзидә. Мин күлмәк күрсәтергә кермәдем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Иртәгә отчет әзер булырга тиеш. Шеф ашыктыра.

Фаягөл. Башта акчасын вакытында түләсен.

Гөлчирә. Сина нәрсәгә акча, ирең «мерседес»та йөртсен.

Фаягөл. Авыз чайкама минем ирем белән.

Рәхмәтулла. Әй, сез! Кисәм телегезне. Бәхет акчада түгел. Бәхет баш бухгалтерыбыз Нурзидә Мөбарәковнаның исәнлегендә. Утырып ял итегез, Нурзидә Мөбарәковна, арыгансыздыр.

Нурзидә *(Рузалия урынына күрсәтеп).* Бу кыз кайда?

Нина. Решает любовные проблемы.

Гөлчирә. Туалетта бикләнеп, сөйгән егете белән сөйләшә. Кесә телефоныннан.

Рузалия *(Керә. Йөзе балкыган).* Исәнмесез, Нурзидә Мөбарәковна.

Нурзидә. Бухгалтерия утырып эшли торган эш. *(Чыгып китә).*

Гөлчирә. Ах, нинди афоризм әйтте! Бухгалтерия—утырып эшли торган эш. Ә менә мин юри утырмыйм. *(Рәхмәтулла өстәле каршына килеп баса).* Сөйлә мәзәгеңне, Рәхмәти.

Рәхмәтулла. Бер карт үгез су буенда ята икән. Аның янына яшь үгез чабып килгән. «Абый, көтүгә яна таналар китерделәр, әйдә» дигән. «Эч пошырып йөрмә» дигән карт үгез. Бераздан яшь үгез тагын чабып килгән. «Әйдә инде, абый, таналары шундый сылу, сокланып туймассың» дигән. «Нигә мина анда барып йөрергә, су эчәргә үзләре монда киләчәкләр» дигән карт үгез.

Гөлчирә. Ах оятсыз! Ах, азгын! Әле син таналар көтеп утырасыңмыни? Килегез әле монда, таналар. Нишләтергә жыена икән ул безне. *(Янына хатыннар жыелгач).* Йә, нишләтәсең безне? Менә сина сөлек шикелле таналар. Нишләтәбез бу карт үгезне, кызлар?

Нина. Хәзер без аны разденем и стриптиз устроим.

Рәхмәтулла. Пажалысты, пажалысты...

Фаягөл. Болай эшлибез. Без аның башына бармак белән сүзләр язабыз. Белмәсә, нишләтәбез?

Гөлчирә. Печәбез. *(Туктаусыз көлеп торган Рузалиягә).* Башла, Рузалия.

Фаягөл. Ул тана түгел, бозау гына. Куегыз әле башыгызны, иптәш үгез. *(Рәхмәтулла башына бармагы белән*

*яза).* Ни яздым?

Рәхмәтулла. Яратам...

Фаягөл. Дөрес!

Нина. Дай-ка сюда. *(Рәхмәтулла башына яза).* Нәрсә яздым?

Рәхмәтулла. Я вас люблю.

Нина. Дөрес!

Гөлчирә. Хәзер минекен белеп карасын ул. *(Яза.)* Әйтеп бир.

Рәхмәтулла. Яратам.

Гөлчирә. Алдаша. Яратмыйм дип яздым.

Рәхмәтулла. Син үзең алдашасың. Нигә яраткан килеш яратмыйм дип яздың?

Рузалия. Мин дә языйм инде.

Фаягөл. Сиңа әле иртә. Телефоныңнан сөйләш.

Рәхмәтулла. Әй кулларыгыз да кулларыгыз, кызлар. Шундый йомшаклар. Шундый рәхәт. Карагыз әле, чәчем үсмәдеме?

Нина *(Рәхмәтулланы кочаклап).* Шевелюра, Рахматулла Хурматуллович?

Гөлчирә. Кочакламагыз, ул минеке генә. *(Хатыннар шау-гөр килеп, көлешә-көлешә Рәхмәтулланы бүлешәләр. Нурзидә Мөбарәковна кереп карап тора. Хатыннар аны күреп тиз генә урыннарына утыралар).*

Нурзидә. Нишлисез соң сез? Ишегегез яныннан үтеп булмый.

Рәхмәтулла. Гафу итегез, Нурзидә Мөбарәковна, мин гаепле.

Нурзидә. Мин гаеплене эзләп йөрмим. Болай ярамый бит инде *(чыгып китә).*

Гөлчирә. Син нәрсә маңка малай шикелле мин гаепле дип торасың ир кеше башыңнан?

Рәхмәтулла. Начальствога каршы әйтергә ярамый, Гөлчирә. Артында ныклы терәк булмаса, начальствога каршы сүз әйтмәскә кирәк.

Гөлчирә. Ә мин әйтәм. Мине терәп торучы кеше бар. Нигә кем дип сорамыйсыз? Менә Рәхмәтулла абый. Куып чыгарсалар, бер Гөлчирәсен генә ашатыр әле.

Нина. Аның үз хатыны бардыр.

Гөлчирә. Булмагае. Гөлчирә исемле түгелдер әле.

Нина. Кстати, хатыныгызны как зовут, Рахматулла Хурматуллович? Вы ни разу не говорили о ней.

Гөлчирә. Төпченмә. Әйтми икән— ярамый. Безгә аның хатыны түгел, үзе кирәк. Булды—шаярдык. Әйдә эшләргә. *(Тыныч кына бераз эшләп алалар).*

Рәхмәтулла. Ишетмим. Кем чираты? Фаягөл!.. *(Фаягөл авыз эченнән генә көй көйли. Шул көй астында ут сүнә. Ут янганда бүлмә уртасына өстәл куелган. Анда савыт-саба, ризыклар, өстәл тирәсендә Рәхмәтулла кайнаша).*

Рәхмәтулла. Кызлар, чәй әзер, утырып садисыгыз.

Гөлчирә.

Утырып садисыгыз:  
Кеше ярларын сөяргә  
Җитәрме сависыгыз.

Рәхмәти, яса чәйләренне.

Хәдичә. Үзем.

Гөлчирә. Утыр урыныңа. Матриархат заманы, ирләр изелсен. Рәхмәти, ач вәринҗә капкачын.

Фаягөл. Рәхмәтулла абзый, шикәрең кайда?

Нина. Рахматулла Хурматуллович, минем кашыкны бир. *(Рәхмәтулла официантларга охшатып йөренә).*

Гөлчирә. Безнең күңелебезне күреп җырлап тор.

Рәхмәтулла. Баш өсте. Кайсы көйне телисез, галиҗәнаббикә Гөлчирә?

Гөлчирә. «Алма турыйм»ны.

Рәхмәтулла.

Алма турыйм, алма турыйм,  
Алманың түгәрәген.  
Инде ниләр уйлыйм икән  
Мәхәббәт күбәләгем.

Алма турыйм, алма турыйм,  
Алмаларның кызылын.  
Сине сөйгәч кенә белдем  
Бу дөньяның кызыгын.

Алма турыйм, алма турыйм,  
Алмаларның яшелен,  
Мине сөйми дип уйлама,  
Сөюләрем яшерен.

Тагын ниләр телисез, бикәкәйләрем?

Гөлчирә. Миңа осетрина!

Нина. Миңа ананас!

Фаягөл. Миңа... Миңа... Кыздырылган фил борыны.

Рәхмәтулла. Сиңа нәрсә, Хәдичә.

Хәдичә. Миңа берни дә кирәкми.

Фаягөл. Сүз әрәм итеп сөйләшмә аның белән, Рәхмәтулла абзый.

Рузалия. Мина шоколад.

Рәхмәтулла. Калганнарын табарга тырышырбыз. Ә шоколад—хәзер үк *(түш кесәсеннән шоколад алып Рузалиягә суза).*

Гөлчирә. Ах син, ә. Кара моны нишли.

Рәхмәтулла. Аның шоколад ашый торган чагы.

Рузалия. Рәхмәт, рәхмәт *(Рәхмәтулланың битеннән үбеп ала).*

Гөлчирә. Булды, Рәхмәти. Бик әйбәт хезмәт күрсәткәнең өчен синең дәрәҗәңне күтәрәбез—Солтан ясыйбыз. *(Бер урындыкка папкалар өеп тәхет ясыйлар. Ана Рәхмәтулланы утыртып куялар).*

Гөлчирә. Хәдичә, син Солтанга чәй ясап тор. Без шәрекъ биюен биибез. Без аның жарияләре.

Рәхмәтулла. Шәрекъ биюендә кендек күрсәтеп бииләр.

Гөлчирә. Кендек күрәсең килсә, Бауман урамына чык.

Рузалия. Минем бабай әйтә әбигә: пилмән яса, пилмәнең кызлар кендеге кебек матур булсын, ди.

Фаягөл. Картлар бөтенесе азгын алар. Башладыкмы, Гөлчирә? *(Шәрекъ биюе бииләр. Нурзидә Мөбарәковна керә).*

Рәхмәтулла. Безнең әбәт вакыты, Нурзидә Мөбарәковна.

Нурзидә. Обед булса, бу бит ресторан түгел.

Гөлчирә. Ашханәгә акча житмәгәч ресторан ясыйсың инде.

Нурзидә. Үз өстегезгә күпне аласың, Гөлчирә Нәжиповна.

Гөлчирә. Алам икән, димәк, күтәрерлек көчем бар.

Нурзидә. Ә мин сез күтәргән йөкне һәм үзегезне берьюлы күтәрә алмасам?

Гөлчирә. Андыйларга татарлар серкәсе су күтәрми диләр.

Рәхмәтулла. Гөлчирә, усалланма.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, минем янга кереп чыгыгыз әле. *(Чыгып китә. Ана Рәхмәтулла иярә).*

Рузалия. Эләгә Рәхмәтулла абыйга.

Нина. Нәрсә, ул виноват что ли. Безнең обеденный перерыв.

Гөлчирә. Кеше ашаганда кереп иснәнеп йөри.

Нина. Син тоже, Гуля...

Гөлчирә. Нәрсә, мин тоже?

Нина. Нурзидә Мубараковна белән... перерекаешься.

Гөлчирә. И, ачуым китереп торма әле, маржа башың белән.

Нина. Че ты? Марзя, марзя... Үзең кем? Әйтәсең, бисмилла, бисмилла, а сама вешаешься на шею мужчин.

Гөлчирә. Кайчан минем ирләрнең муенына асылынганым бар, ә?

Нина. Рахматулла Хурматуллович не мужчина что ли?

Гөлчирә. Ай-ай-ай. Ревнуешь, да? Может я его люблю.

Фаягөл. Арттырып жибәрәсең инде анысы. Яратканыңны бөтен кешегә күрсәтергә димәгән.

Гөлчирә. Син тик тор. Минем бит өемдә синеке кебек мужыгым юк.

Фаягөл. Ал кирәк булса, бирәм.

Гөлчирә. Төкердем мин синең өч тиенлек үләтенә.

Хәдичә. Житте инде, кызлар.

Фаягөл. Ә син оянда тик кенә утыр.

Рузалия. Ә мин сезне Рәхмәтулла абыйга әйтәм.

Фаягөл. Нәрсә дип әйтәсең?

Рузалия. Алар сез булганда гына әйбәт, сез чыгып киткәч ызгышалар дим.

Гөлчирә. Кем ызгыша, әйт әле, кем ызгыша?

Рузалия. Әнә бит, ямьсез сүзләр әйтешәсез.

Нина. А ты не вмешивайся. Говори по своему телефону.

Гөлчирә. Әгәр дә Рәхмәтулла абыйга берәр начар сүз әйтсә, бәреп үтерәм мин ул хатынны. *(Башын түбән иеп Рәхмәтулла керә. Урынына сүзсез генә барып утыра. Шомлы тынлык. Хәтта Хәдичә дә торып Рәхмәтуллага карап тора).*

Гөлчирә *(сакланып кына Рәхмәтулла янына килә).* Рәхмәтулла абый. *(Рәхмәтулла кулын селтәп кенә жавап бирә. Бүтән хатыннар, Рузалия Рәхмәтулла янына жыелалар. Хәдичә генә тораташтай үз урынында басып тора).*

Рәхмәтулла. Бетте...

Фаягөл. Нәрсә бетте, Рәхмәтулла абый?

Рәхмәтулла. Мин китәм.

Нина. Куда, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. На пенсию отправляют, Ниночка.

Нина. Как? Сезгә әле алтмыш юк.

Рәхмәтулла. Досрочно, Ниночка.

Фаягөл. Чынмы, Рәхмәтулла абзый?

Рәхмәтулла. Чын, Фаягөл, чын.

Гөлчирә. Безобразие! Шеф янына керәбез. Шефтан узарга аның ни хакы бар.

Рәхмәтулла. Соң инде, Гөлчирәкәй. Шеф янына алып керде Нурзидә Мөбарәковна. Рәнҗемәгез, кызлар, төрле чакларым булгандыр. Миннән башка тату гына эшләгез, тату гына яшәгез. Әйтәсе сүзләремне бүген әйтеп калыйм. Рузалия, кызым, синнән башлыйм. Бәхетле бул, ярыймы.

Рузалия. Ярый, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Фаягөл, бәхетле бул, ярыймы. *(Фаягөлне кочаклый).*

Фаягөл *(еларга житешеп).* Рәхмәт, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Будь счастлива, Ниночка. *(Нинаны кочаклый).*

Нина. Спасибо! Рәхмәт, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Гөлчирәкәй. *(Гөлчирәне кочаклап бит уртасыннан үбә.)* Син үзең дә кочаклап үп инде, Гөлчирәкәй.

Гөлчирә *(кычкырып).* Хәшәрәт! Алдаша! Алдаша, кызлар. Күзенә карагыз, күзенә карагыз, елмая. *(Рәхмәтуллага очып куна, тукмый, кочаклый).* Үтерәм! *(Рәхмәтулла көлә, шау-шу).*

Рузалия. Арти-и-ист...

Рәхмәтулла. Утырыгыз урынныгызга. Бүгеннән башлап шаярулар бетте. Эшкә вакытында киләсез, эшлисез, шыпырт кына чәегезне эчәсез, шыпырт кына кайтып китәсез. Нурзидә Мөбарәковна мине бу бүлмәнең старостасы итеп билгеләде. Мин шаярмыйм, кызлар. Утырышыгыз. *(Барысы да үз урыннарына утыргач та).* Ишетмим? Кем чираты? Минем чират. *(«Әпипә» көенә көйли. Ут сүнә).*

*Ут янганда Рәхмәтулла компьютерда эшләп утыра. Әлеге дә баягы үзенең жырын көйли.*

Рәхмәтулла.

Заманалар авыр, еллар ябык —
Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Хәдичә *(керә).* Исәнмесез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Менә жылы өчпочмаклар.

Рәхмәтулла. Ничек жылы килеш алып килеп житкерәсең син аларны?

Хәдичә. Мин аларны кайнар килеш төрәм дә суынып өлгермиләр.

Рәхмәтулла. Бик күпкә китте бит инде бу, Хәдичә.

Хәдичә. Юк, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, миңа рәхәт кенә. Сез шундый тәмле итеп ашыйсыз, рәхмәт.

Рәхмәтулла. Синең белән бер утырып сөйләшәсе бар әле, Хәдичә.

Хәдичә. Нәрсә турында, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович?

Рәхмәтулла. Ташла әле шул Хөрмәтулловичны. Абый, диген.

Хәдичә. Ияләшкән инде. Нәрсә турында сөйләшергә жыенасыз Рәхмәтулла... Абый...

Рәхмәтулла. Бар сөйләшәсе сүзләр.

Хәдичә. Әйтерсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Кичә кульяулыгыгыз төшеп калган булган. Югач чистарды. *(Таслап бөкләнгән кульяулыкны Рәхмәтулла өстәленә куя.)* Берәр әйберегез каралса, әйтерсез.

Рәхмәтулла. Син нәрсә инде, Хәдичә... Әллә исләмәй да сөрткән инде.

Хәдичә. Ирләрнеке ул. Кибеттә әйттеләр. *(Урынына барып утыра.)* Рәхмәтулла абый, әйткәнгә ачуланмагыз. Нигә сез үзегезне мыскыл иттерәсез? Сез олы кеше. Алар сезне бала-чагага саный.

Рәхмәтулла. Алар көлмиләр, шаяралар гына, Хәдичә.

Хәдичә. Шаяралар дип инде...

Рәхмәтулла. Менә бүген чәченне дөрес ачкансың. Шулай йөрт. Бик килешә.

*Рузалия керә дә тәрәзәгә чаба. Карап тора. Урынына килеп утыра.*

Рәхмәтулла. Киттеме?

Рузалия. Уһу...

Рәхмәтулла. Әйбәт егетме?

Рузалия. Уһу...

Рәхмәтулла. Әйбәт булгач, бик әйбәт. Шулай да син исәнләшергә оныттың инде.

Рузалия. Әллә исәнләшмәдемме?

Рәхмәтулла. Юк шул.

Рузалия. Ай, гафу итегез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Исәнмесез, Хәдичә апа. *(Нина керә. Кәефсез генә исәнләшеп,урынына узып утыра).*

Рәхмәтулла *(анын янына килеп).* Успокойся, Нина Васильевна.

Нина. Я спокойна, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Успокойся, все будет хорошо.

Нина. Спасибо, Рахматулла аби.

Фаягөл *(керә).* Исәнмесез. *(Рәхмәтулла янында туктап).* Рәхмәтулла абый, бүген мине көйләтмәгез яме. Кәефем юк.

Рәхмәтулла. Кәеф булмаганда көйләргә кирәк тә инде ул, Фаягөл. Кәефле чакта исерек тә жырлый.

Фаягөл. Чынлап әйтәм, Рәхмәтулла абый. Чынлап та кәефем юк.

Рәхмәтулла. Ярый, синең өчен үзем көйләрмен.

Фаягөл. Соң, куйыйк берәр музыкальный центр. Торсын көйләп.

Рәхмәтулла. Әнә шул центрлар кубәйгәнгә кешеләрнең кәефе юк инде, Фаягөл. Ярый, бар утыр. Тынычлан. Барысы да җайланачак.

Гөлчирә *(керә).* Бетте. Көннең рәте-чираты булмаячак. Өйдән чыккач кара мәче очрады, коридорда Мөбарәковна каршыга килеп чыкты.

Рәхмәтулла. Анын каравы, монда мин көтеп торам. Нихәл!

Гөлчирә. Әй, сине дә күрәсе килеп тормый әле. Нихәл. Бүген магнитлы көн мәллә? Нәрсә, берегез дә сөйләшмисез?

Рузалия. Исәнмесез, Гөлчирә апа.

Гөлчирә. Исәнме, матурым. Әле дә син бар, бәгырькәем.

Рузалия. Сез зря Рәхмәтулла абыйга алай әйттегез.

Гөлчирә. Нәрсә дип әйттем?

Рузалия. Күрәсем килми дидегез.

Гөлчирә. Һай, берәүнең адвокаты табылган. *(Рәхмәтулла янына килеп).* Кил! *(Бер кулы белән кочаклап ала).* Булдымы?

Рузалия. Кайчан сез Рәхмәтулла абыйны кочаклыйсыз, миңа бик ошый.

Гөлчирә. Ярый, аллага тапшырдык. *(Урынына утыра. Тын гына эшлиләр. Фаягөл көй көйли башлый. Ана Рәхмәтулла кушыла).*

Рәхмәтулла. Их, кызлар! Ун яшьтә мин райком секретаре кызына гашыйк булган идем. Ана тугыз яшь иде. Аларнын чия бакчасы бар иде. Шунда чия агачлары арасында үбешә идек. Бервакыт безнең үбешкәнне анын әнисе күргән. Шунын өчен мәхәббәтемнең әтисе мине кычыткан белән сыйлады. Мәңгелек сабак булды. Ун яшьтә чия агачлары арасында райком секретаренын тугыз яшьлек кызын үбәргә ярамый икән.

Гөлчирә. Син ул чакта ук азгын булган инде.

Рәхмәтулла. Хатын-кызлар ни өчендер азгын ирләргә кызыгалар.

Нина. Неправда. Кызыкмыйлар, алданалар. Бабники умеют находить ключ к женскому сердцу.

Гөлчирә. Карале, Рәхмәти. Син сөйләмәдең бит әле ни булганын баш бухгалтер кабинетында. Син, әйдә, шыттырма, сөйлә.

Рәхмәтулла. Без мәхәббәт аңлаштык. Мин аңа багышланган шигыремне укыдым.

Рузалия. Шигырь?! Әллә сез шагыйрь дәме, Рәхмәтулла абый?

Гөлчирә. Аның булдырмаган эше юк. Укы безгә дә шигыреңне, Рәхмәти.

Рәхмәтулла.

Гүзәлләрдән гүзәл баш бухгалтер!
Ничәнче размер икән сезнең бюстгалтер?

*Дәррәү көлешәләр.*

Гөлчирә. Нәрсә ди Мөбарәковна?

Рәхмәтулла. Гөлчирәнекеннән зуррак ди.

Гөлчирә. Үтерәм мин сине, оятсыз.

Нина. Бюстгалтернын татарчасы ничек.

Гөлчирә. Юк анын татарчасы. Элек татар хатыннары аны кимәгән.

Фаягөл. Ә күкрәкчә нәрсә?

Гөлчирә. Ул бюстгалтер түгел.

Рәхмәтулла. Бар аның татарчасы. Имидж дип атала ул. Шунын зурлыгына карап хатын-кызның кемлеге бәяләнә.

Гөлчирә *(Рәхмәтулла янына атылып килеп).* Нишләтим мин моны, әйтегез. Чәчен йолкыр идем, чәче дә юк бит әй... Карагыз әле, Рәхмәтулла абыйның

башы глобуска охшаган икән. Менә Африка, менә Татарстан. *(Рәхмәтулланың борынын кысып).* Менә Кавказ тавы.

Нина. Ульяновский область кайда?

Гөлчирә. Әйләндер, теге яктадыр. *(Рәхмәтулланың башын боргалыйлар).*

Рәхмәтулла. Үтерәсез. Әйтәм Нурзидә Мөбарәковнага.

Гөлчирә. Әле син әләкче дәмени? Фаягөл, биклә ишекне, күрмәгәнен күрсәтәбез.

Рәхмәтулла. Рузалия кызым! Үтерәләр болар, коткар.

Рузалия. Тимәгез Рәхмәтулла абыйга.

Рәхмәтулла. Тисеннәр, тик үтермәсеннәр генә.

Гөлчирә. Нина, бир косынкаңны, кулларын бәйлибез. *(Косынка белән Рәхмәтулланың кулларын артка каерып бәйлиләр. Рәхмәтулла, әлбәттә, карышмый.)*

Фаягөл. Булды, нишләтәбез?

Гөлчирә. Печәбез.

Нина. Кастрировать что ли? Что ты, Гуля! Такого старого бугая. Бирегез аны миңа.

Гөлчирә. Бирәүгә дә булмасын. *(Рәхмәтуллага).* Бас әле монда. Тәк. Башта ул безнең сорауларга җавап биреп карасын. Сорауларыгызны әзерләгез. Җавап бирә алмаса, җәзасын үзегез билгеләрсез. Тәк, иптәш Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! Беренче сорау: Син, җанбиздергеч адәми зат, ни өчен дип кылчыклы арпа башагы кебек кашларың астындагы ике пыяла кисәген күз дип атыйсың?

Рәхмәтулла. Ә син, сөйкемлеләрдән сөйкемле, аккоштан да сылурак бөек зат, ни өчен энҗе сыман тешләреңне каплап торучы ике карбыз телемен иреннәр дип атыйсың?

Фаягөл. Син, дию пәриеннән дә кошпәтсез адәми зат, ни өчен тау куышыдай авызың эчендә боргаланучы җыланны тел дип атыйсың?

Рәхмәтулла. Ә менә син, алма кисәгем, урман күле сыман серле күзләреңдә урын алган камышларны ник керфекләр дип атыйсың?

Гөлчирә. Нина, синең чират.

Нина. Я потом..

Гөлчирә. Рузалия кил, бир соравыңны.

Рузалия. Мин белмим, Гөлчирә апа. Минем өчен син әйт.

Гөлчирә. Фаягөл, әйт Рузалия өчен.

Фаягөл. Әйт әле, килбәтсезем, син нигә мунча морҗасыдай муеның өстендәге кабакны баш дип йөртәсең?

Рәхмәтулла. Ә син, фәрештәләр фәрештәсе, нигә таң алсулыгы кунган битләрең уртасындагы фәрештә үпкән сөйдергеч урыннарны чокыр дип йөртәсең. Нигә син, алтын кисәгем, күл өстенә иелгән бөдрә талны иркәләүче йөгерек дулкыннарны чәч дип йөртәсең?

Гөлчирә. Кара син мутны, кызларга икешәрне әйтә. Хәдичә, синең соравың бармы?

Хәдичә. Юк.

Гөлчирә. Нина, давай.

Нина. Не могу я плохое сказать про Рахматулла Хурматулловича.

Гөлчирә. Можешь. Смотри, какой он безобразный. Давай...

Нина. Ну, если давай... Рахматулла Хурматуллович, почему... Почему вы такой... Но не могу я... Ну почему вы такой?

Рәхмәтулла. Потому что ты такая милая.

Нина. Ну разве можно такого симпатичного... Лучше я поцелую его. *(Рәхмәтулланы ике яңагыннан да үбеп ала).*

Гөлчирә. Ай-яй-әй. Монысы рөхсәт ителми. *(Үзе Нина шикелле үбеп ала. Аңа Фаягөл кушыла).*

*Шул вакыт ишек шакыйлар.*

Фаягөл. Бетте баш.

Гөлчирә *(шыпырт кына).* Ачмагыз.

Нурзидә тавышы. Ачыгыз!

*Хатыннар тиз генә урыннарына утыралар. Нина Рәхмәтулланың кулларын чишәргә өлгерә. Рәхмәтулла барып ишекне ача.*

Нурзидә. Нигә бикләнеп утырасыз?

Нина. Чтоб не мешали работать, Нурзида Мубараковна.

Нурзидә. Ой ли. Такой шум стоял.

Гөлчирә. Рузалия бюстгалтер алган да, шуны үлчәп карадык.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтул-

лович, сез дәме? *(Рәхмәтулланың иреннәрдән кызарып чуарланган йөзен күреп).* Ни булды сезнен белән?

Гөлчирә. Оялудан шулай кызарган ул. Бюстгалтер күргәне юк икән.

Нурзидә. Гөлчирә Нәҗиповна, һәр нәрсәнең чиге була.

Гөлчирә. Ә мин чик белмим.

Нурзидә. Кызганыч.

Гөлчирә. Нурзидә Мөбәраковна!..

Рәхмәтулла. Гөлчирә...

Гөлчирә. Гафу итегез.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! Иртәгә бүтән бүлмәгә күчәсез. *(Чыгып китә).*

*Пәрдә*

## II ПӘРДӘ

*Аерым бүлмәдә Рәхмәтулла эшләп утыра. Шакымый-нитми Гөлчирә килеп керә. Керә дә бүлмәне карап-тикшереп чыга.*

Гөлчирә. Ай-яй, оялаган берәүләр тыныч урынга. *(Җырлап).*

Уңга каерылгач та...
Әй дускаем рәхәт яшә
Бездән аерылгач та.

Бездән аерылгач рәхәтме?

Рәхмәтулла. Мин бит үзем аерылмадым, аердылар.

Гөлчирә. Хатын-кызга буйсынып яшәгән иргә ни әйтим. Әйтергә иде! Юк, Нурзидә Мөбәраковна, хатыннарымнан аерылып башка чыкмыйм диярга иде. Җибәргән. Беләм инде, миннән качтың. Барыбер үзеңне генә калдырмыйм. Минутына ун керәчәкмен. Аңладыңмы?

Рәхмәтулла. Аңладым.

Гөлчирә. Аңласаң шул. *(Кулын сузып).* Нихәл! *(Рәхмәтулла күрешергә кулын сузгач).* Ах, оятсыз! Бер тәүлек буе күрешмәдек, ә ул күрешергә кулын суза. Тор урыныңнан, җир бит. *(Урындыгыннан торып баскан Рәхмәтулланы кочаклап алып).* Утыр. *(Рәхмәтулла каршысына утырып)* Нихәл соң?

Рәхмәтулла. Үзең нихәл.

Гөлчирә. Начар.

Рәхмәтулла. Ни булды?

Гөлчирә. Син юк. Килеп кердем эшкә—син юк.

Рәхмәтулла. Менә ич мин.

Гөлчирә. Мине мондагысы канәгатьләндерми.

Рәхмәтулла. Нишләп?

Гөлчирә. Мондагысың кочаклап булмый.

Рәхмәтулла. Кочакладың ич.

Гөлчирә. Монысы аның формальне гына кочаклау. Кызлар карап торганда шаярган булып чынлап кочаклый идем. Монда оялам.

Рәхмәтулла. Кемнән?

Гөлчирә. Үземнән.

Рәхмәтулла. Кызык икән.

Гөлчирә. Кызык түгел. Чөнки мин сине чынлап яратам.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Гөлчирә. Ахмак сорау биреп үзеңнән биздермә. Син дә бит мине яратасың. Мин ни өчен дип сорамыйм.

Рәхмәтулла. Минем яратканымны каян беләсең?

Гөлчирә. Белмим, сизәм. Мин бит тиле-миле. Андыйларны ирләр ярата. Фәритем дә, сине тиле булганың өчен яратам, дия иде. Күзгә карап торма, оялтасың. Әйт, яратырлык хатынмы мин? Ник дәшмисең?

Рәхмәтулла. Яратмаслык түгел инде.

Гөлчирә. Җәбриләр кебек алдын артка куеп сөйләшмә. Өзеп әйт, яратырлыкмы?

Рәхмәтулла. Яратырлык. Мин яратырлыкны гына яратам.

Гөлчирә. Әйтмә яратам дип. Кызыгы бетә. Яратканыңны мин генә сизим! Минем чибәрлегем әле бетмәгән. Чибәр хатынга яратам дип еш әйтәләр. Чибәр хатынны ахмак дип уйлыйлар. Яратам диюгә—яннарына ятар дип өметләнәләр. Син өметләнмә, яныма яткызмаячакмын. Өзелеп яратсам да яткызмаячакмын. Чөнки яратканымның берсе ятты инде. Ятты да мәңгелеккә китеп барды. Синең китүеңне теләмим. Сине яшәтәсем килә. Син, бәлки, минем соңгы мәхәббәтемдер. Карап торма алай. Нигә алай караганыңны беләм мин. Их шуны бер кочаклап үбәргә дип карап торасың. Кочаклаттырам, әмма үптермим. Үптерсәм дәртем кузгалыр дип куркам. Үземне тыеп кала алмам-

дыр шикелле. Елмайма. Нигә елмайганыңны беләм. Кая инде миндәй картка дәрт кузгатырлык куәт дип уйлыйсың. Илле тугыз яшьтә бит инде дисең, пенсия яшенә җитәм дип уйлыйсың. Мин беләм, синдәге дәртнең әле чик-чамасы юк. Син дәртеңне минем өчен саклап тоткансың. Янымa яткыза алмаганга кызганам да мин сине. Нишлим, яраткан ирем бар иде шул. Аерылып, ташлап китсә дә авыр булмас иде, бакый дөньяга китеп барды. Яшәүнең кызыгы беткән иде, син очрадың. Кил, чынлап бер кочаклыйм әле үзеңне кеше юк чакта. Утырып кына тор, үзем кочаклыйм. *(Рәхмәтулланы кысып кочаклый да ишеккә таба атлый).* Кара аны, бүтәннәргә кочаклаттырма, көнләшә торган әшәке гадәтем бар. *(Чыгып китә. Рәхмәтулла эшкә тотынгач кына Фаягөл ишекне ача).*

Фаягөл. Кирәргә ярыйдыр бит, Рәхмәтулла абзый.

Рәхмәтулла *(урыныннан торып Фаягөлне каршылый).* Кер әйдә, кер. Әйдә, уз, утыр.

Фаягөл. Узып тормыйм. Эшкә килдем, нәрсәдер җитми. Нәрсә җитми дисәм, сез юк икән. Шушында күчерделәрмени инде сезне? Бергә утырсак ни була иде инде. Сезнең белән бергә утырганда рәхәт иде. Күрше өстәлдә сез барын тою рәхәт иде. Гөлчирә кереп өлгергәндер инде.

Рәхмәтулла. Кереп болганып чыгып китте.

Фаягөл. Сезгә гашыйк ул. Шуны яшерер өчен кыланган була. Мин дә яратам сезне, Рәхмәтулла абый. Беләсезме, ни өчен яратам сезне?

Рәхмәтулла. Белмим инде, Фаягөл. Шундый чибәр хатын яратырлык нием бардыр. Бигрәкләр дә чибәр бит син. Тулып пешкән алма кебек.

Фаягөл. Шундый сүзләрегез өчен яратам бугай мин сезне, Рәхмәтулла абый. Беләм инде, минем күңелемне күрер өчен генә әйтәсез чибәр дип. Сез иң олы җанлы, җылы күңелле кеше, Рәхмәтулла абый. Шуңа күрә дә сезнең янда миңа җылы.

Рәхмәтулла. Юк, син чыннан да чибәр, Фаягөл. Ходай тәгалә дөньяга ямьсез хатын-кызны яратмый. Хатын-кызны Ходай карап сокланыр өчен ярата. Син, беләсең килсә, арагызда иң чибәре. Кемдер синең чибәрлегеңне күрә белми икән, ул—ахмак, ул—утын агачы.

Фаягөл. Беләм инде, Рәхмәтулла абзый, юатыр өчен генә әйтәсен. Шулай да рәхмәт сезгә. Нишләтәсең, хатын-кызның холкындадыр инде, алдаганны өнәп бетермәсәк тә алданасы килә. Кайсыдыр шагыйрь шулай әйткән бугай.

Рәхмәтулла. Алдамыйм, Фаягөл бәгырькәем. Кил әле, бас әле каршыма. Хәзер мин сиңа чибәрлегеңне дәлилләп исбатлыйм. Әйтик, менә синең күзләрең...

Фаягөл. Кирәкми, Рәхмәтулла абый. Миңа хәзер инде барыбер—чибәр булдым ни, булмадым ни. Уңсигез яшьлек кияүгә чыгасы кыз түгел. Кырык тула.

Рәхмәтулла. Алай димә, Фаягөл. Кырык яшь ул хатын-кызның чәчәк аткан вакыты.

Фаягөл. Җимеше булмагач чәчәк атудан ни мәгънә, Рәхмәтулла абзый. Бер сүз әйтсәм, ачуланмыйсызмы?

Рәхмәтулла. Нишләп ачуланыйм ди, Фаягөл.

Фаягөл. Мин ир белән егерме ел яшим. Балабыз юк, беләсеңме шуны.

Рәхмәтулла *(паузадан соң).* Беләм.

Фаягөл *(аптырап).* Каян беләсез? Әйткәнем юк. Гөлчирә әйттеме?

Рәхмәтулла. Юк.

Фаягөл. Шулай да... каян белдегез? Мин ул турыда берәүгә дә әйткәнем юк. Киресенчә, ике балам бар дип сөйләп йөрим.

Рәхмәтулла. Хатын-кыз алдашса да алдаша белми. Хатын-кызның дөрес сүзе телендә түгел, йөзендә, Фаягөл.

Фаягөл. Сез сихерчедер, Рәхмәтулла абзый. Ярый, чишелә башлаганмын икән, чишелеп бетим инде. Чишеләсем килә, Рәхмәтулла абзый. Шундый да чишеләсем килә. Күңелемдә җыелган бөтен серләремне кемгәдер сөйлисем килә. Мине тыңлый алырлык кеше юк дөньяда. Сез очрадыгыз. Ничә ел инде сезгә сөйлим-сөйлим дим, һич кенә дә җае чыкмый.

Рәхмәтулла. Мин сине сөйләмәсәң дә аңлыйм, Фаягөл сеңелем.

Фаягөл. Аңлаганыгызны беләм. Ләкин миңа бушанырга кирәк. Рөхсәт итегез. Яратып чыктым мин кияүгә. Ул нигә өйләнгәндер, белмим. Яратам дигән сүзен хәтерләмим. Ни өчен ярат-

канмындыр. Эчми, тартмый, сүгенә белми, күп сөйләшми, шул ягы ошагандыр инде. Мин гомерем буе исерекләрдән жирәнеп яшәдем. Бу шундый тәртипле. Ничек яратмыйсың. Тик менә үзем яратсам да яраттыра алмадым. Яратып түгел, өйләнергә кирәк булганга гына өйләнгән булып чыкты. Балабыз булмады дидем. Булмады шул. Булган булса, тун жаны бәлки эрегән булыр иде. Бала булмаганга мин өзгәләндем, анын исе дә китмәде шикелле. Унбиш ел гомер шулай үтте дә китте. Бервакытны әйтә бу: «Синен бала тапмавын әйбәт, ди, югыйсә үзен кебек ямьсез бала табып, бәхетсез итәр иден» ди. Тыныч кына әйтә, елмаеп әйтә. Ышанасызмы, Рәхмәтулла абзый? Йөрәгемә боз булып төште шул сүзләр. Бөтен яратуларым нәфрәткә әйләнде. Янына яту түгел, янышнан үтеп китәсем дә килми. Шул килеш ничә ел яшибез бит, Рәхмәтулла абый, жан кисәгем. Кайвакытларда башымны әлмәккә тыгарлык булам. Яшәү түгел бит инде бу, Рәхмәтулла абый. *(Рәхмәтулланын күкрәгенә башын куеп елый).*

Рәхмәтулла. Тулган күнелен бушансын. Нишлим соң инде, жыла... Булдымы инде? Инде хәзер күз яшьләренне сөртик... Менә шулай. Кара син бу күзләргә, алар бит көләр өчен генә яратылган.

Фаягөл. Бирегез берәр кинәш мина, Рәхмәтулла абзый. Нишлим?

Рәхмәтулла. Нинди кинәш бирим инде сина, бәгырькәем. Кинәш бирү жинел түгел бит.

Фаягөл. Ташламагыз мине, Рәхмәтулла абый. Гафу итегез мине.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Фаягөл. Менә бит... Әллә ниләр сөйләдем. Елаганымны кешегә әйтмәгез инде, Рәхмәтулла абзый. Сез шундый итеп карап торасыз мина, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Ничек итеп?

Фаягөл. Сокланып.

Рәхмәтулла. Сокланырлык бит.

Фаягөл. Рәхмәт сезгә. Мин кызганып карауларыннан куркам, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Кызганып карарга ярамый кешегә. Ул аны түбәнсетә.

Фаягөл. Мин бит матур жырлый идем яшь чакта. Үз туемда жырлаган жырымны жырлыйммы? Тик ачуланмагыз, ярыймы, Рәхмәтулла абый. *(Жырлый.)*

Туйда жырлар өчен нигә шул жырны сайладым икән, Рәхмәтулла абый. Ярый, чыгыйм инде, Рәхмәтулла абый. Гаеп итмәгез зинһар. Ташламагыз мине *(чыгып китә).*

Гөлчирә *(кереп).* Фаягөл нигә кергән?

Рәхмәтулла. Сагындым ди.

Гөлчирә. Анын сагынырга хакы юк. Чөнки анын ире бар.

Рәхмәтулла. Алай димә инде, Гөлчирә.

Гөлчирә. Нәрсә, аны яклыйсынмыни?

Рәхмәтулла. Якламыйм да.

Гөлчирә. Якламагач нигә алай сөйләнәсен?

Рәхмәтулла. Ничә ел бергә утырдык, бергә эшләдек. Бергә эшлибез.

Гөлчирә. Синен бик әйбәт һәм дә бик начар гадәтен бар—син бөтен хатын-кызны да яратасын.

Рәхмәтулла. Нишлим соң инде, барыгыз да яратырлык бит.

Гөлчирә. Ә мин?

Рәхмәтулла. Син—син бит инде ул.

Гөлчирә. Сөйләп тора Фаягөл: Рәхмәтулла абзыйнын хатынына рәхәттер Рәхмәтулла абзый белән яшәве, ди. Беренчедән, нигә ул сина абзый ди. Нинди абзый син. Абый дисә ярамыймы? Икенчедән, ни эше бар анын синен хатынында. Мина булды ни синен хатынын, булмады ни. Мина син булгач житкән. Мин анын өлешенә керергә жыенмыйм, мин бары тик яратам гына. Мин кочаклаганнан гына Рәхмәтулла хатынынын иренә мөгез чыкмас. Рәхмәтулланын хатынына Рәхмәтулла кочаклап ятар өчен, мина яратыр өчен генә. Нигә шулай карап торасын?

Рәхмәтулла. Әллә нинди син. Көнгә әллә ничә төрлегә керәсен.

Гөлчирә. Кермим, үзем шундый мин. Мине Ходай шундый итеп яраткан. Шуна күрә син мине яратасын. Фәрит тә мине шунын өчен ярата иде. Ләкин мин мәхәббәт мәсьәләсендә генә үзгәрмим. Яратам икән мәнгелеккә яратам. Фәритне мәнгелеккә яраттым. Аны син алыштырдын, сине дә мәнге яратачакмын. Ләкин Фәрит хисабына түгел. Синен минем жанымда үз урынын бар.

Мин күп сөйлим, әйеме?

Рәхмәтулла. Әйе.

Гөлчирә. *(Рәхәтләнеп көлеп).* Менә шуның өчен яратам да мин сине. Син минем җанымны аңлыйсың. Мин күзәтеп торам бит, син хатын-кызның үзләре дә белмәгән серләрен беләсең. Син кеше кыяфәтендәге Хозер Ильяс бит, бәгырькәем. Шуңа күрә бөтен бәхетсез хатыннар сиңа елышалар. Тыңлавы рәхәтме мине?

Рәхмәтулла. Рәхәт. Сиңа карап торуы да җан рәхәте. Яраттыра торган сихерең, сөйкемле сөягең бар синең. Мин синең биегәнеңне карап торырга яратам. Биегәндә син җирдә яшәгәнне дә онытасың шикелле. Дөньяда өлкәнәю килешми торган кешеләр була. Син шуларның берсе, Гөлчирәҗан.

Гөлчирә. Шуларның берсе димә, бердәнбере диген.

Рәхмәтулла. Бердәнбере.

Гөлчирә. Кил, кочакла шуның өчен. Тик үбәргә үрелмә, ярыймы. *(Рәхмәтулланы кочаклап).* Әй бу Фаягөлне. Хатыны дигән була, хатынының монда ни катнашы бар. *(Рәхмәтулланы этеп җибәреп).* Утыр, эшлә. Эшләгәндә мине уйлама, саташуың бар. Сау бул. *(Бөтерелеп бии-бии чыгып китә. Рәхмәтулла эш өстәле артына утырырга өлгерми, ишектә Хәдичә күренә).*

Хәдичә. Мөмкинме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Сөйләшәсем бар дигән идегез.

Рәхмәтулла. Кер әйдә, Хәдичә, нигә рөхсәт сорап торасың. Уз, утыр.

Хәдичә. *(Полиэтилен пакеттан тастымалга уралган тәлинкә ала. Тастымалны сүтеп тәлинкәне өстәлгә куя).* Суынып үк өлгермәгәндер әле...

Рәхмәтулла. Син мине азындырып бетерәсең, Хәдичә. Мин инде өйдә иртәнге ашны ашамый башладым. Хәдичә алып килер әле дим.

Хәдичә. Сез бит тәмле итеп ашый беләсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Күп итеп пешерергә яратам мин. Минем берүземә күпме кирәк. Әле дә ярый сез бар. Ашагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. *(Рәхмәтулла ашаганда күзләрен дә алмый аңа карап тора. Аннан торып ишеккә юнәлә).*

Рәхмәтулла. Туктале, Хәдичә. Нишләп әле алай, бик тиз генә.

Хәдичә. Чыгам...

Рәхмәтулла. Утыр инде бераз. Синең белән утырып сөйләшкән дә юк.

Хәдичә. Нәрсә турында сөйләшәсең инде.

Рәхмәтулла. Тормышларың ничек?

Хәдичә. Тормышым юк минем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Рәхмәтулла. Хөрмәтулловичын әйтеп торма дидем бит инде.

Хәдичә. Мин бит Гөлчирә түгел, сезнең яшьтәге кешегә Рәхмәти дип әйтә алмыйм. Килешми.

Рәхмәтулла. Гөлчирәгә килешә.

Хәдичә. Аңа да килешми. Сез бит бала-чага түгел. Ул да бала-чага түгел.

Рәхмәтулла. Син һәрвакыт җитди, Хәдичә. Дөньяга бераз көлеп карарга кирәк.

Хәдичә. Көлеп карый алмыйм мин, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Яшәве кызык түгел миңа. Яшисем килми генә яшим. Кайвакытларда үкереп-үкереп җылыйсым килә. Юатучы булмаганга җыламый түзәм. Кырык яшь бит инде миңа. Һаман бер ялгызым.

Рәхмәтулла. Шулайдыр инде. Ялгызлык бәхет түгел. Нишләп соң болай? Чибәр дә үзең. Арагызда иң чибәре син. Эшкә уңган. Пешергән ризыкларың ашап туймаслык.

Хәдичә. Шулар харап итте дә бугай инде. Сайландым шул. Күңелем ятардае очрамады. Очраганда инде соң иде.

Рәхмәтулла. Соң түгел, Хәдичә. Яратырга беркайчан да соң түгел.

Хәдичә. Соң, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Аннан инде минем яшьтә ярату, мәхәббәт дип сөйләнү дә килешми.

Рәхмәтулла. Очрады диден бит.

Хәдичә. Очрады. Ләкин ул ярату түгелдер, хөрмәт итү генәдер.

Рәхмәтулла. Хөрмәт итмичә ярату булмыйдыр, Хәдичә.

Хәдичә. Кем белә инде анысын. Сезнең яшисегез килмәгән чагыгыз булгалыймы, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Карап торсаң, сезнең бәхетегез тулып ташкан кебек. Уен-көлке, мәзәк. Бер кайгыгыз юк кебек.

Рәхмәтулла. Мин дә адәм баласы бит, Хәдичәкәй. Ләкин яшәргә кирәк бит. Ходай биргән гомер бит. Бүләк итеп биргән. Мә, яшә, бу дөньяның да рәхәтен күр дигән.

Хәдичә. Авыр бит, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Авыр билгеле. Сиңа

гына авырмы? Авырайтсаң, ашый торган кашыгын да авырая. Сөйләш син кешеләр белән. Син гел үз-үзенә йомылып утырасың. Гөлчирәгә җинелме? Нинага, Фаягөлгә җинелме? Тиле булганга көләләрме алар? Җилбәзәк булганга шаяралармы? Синең яшен яшьнәгәнен, күк күкрәгәнен күргәнең бармы?

Хәдичә. Ничек инде булмасын.

Рәхмәтулла. Ни өчен яшен яшьни? Ни өчен күк күкри? Алар күккә кара болытлар җыелгач яшьниләр, күкриләр. Кара болытлар сыеша алмагач, яшен яшьни, күк күкри дә коеп яңгыр ява башлый. Яңгыр ул болытларның күз яше. Ә күк күкрәү табигатьнең кычкырып көлүе. Табигать кычкырып көлә дә, болытлар яңгыр булып яугач, дөнья бушанып кала. Әгәр дә ул бушанмаса, дөнья җыелган кайгысыннан шартлар иде. Дөрес сөйлимме?

Хәдичә. Сез һәрвакыт дөресен сөйлисез. Ләкин сезнең бөтен сүзләрегез дә әкият. Тормыш әкият түгел.

Рәхмәтулла. Әкият, Хәдичә җанкисәгем, әкият. Әйт әле миңа, нигә дип син миңа иң тәмле ризыклар пешереп киләсең? Нигә син минем төшеп калган кульяулыгымны табып юып алып килдең? Нигә бүген яныма кердең? Үзем әйтимме? Яшисем килми диден. Юк, Хәдичә бәгырькәем, яшисең килгәнгә кердең яныма. Чөнки мин әкият. Мин әкияттәге маймыл. Мин әкияттәге таз малай. Карале миңа. *(Төрле мимикалар ясап кылана. Бака булып сайрый, әтәч булып кычкыра, үгез булып мөгри).* Йә, ничек? Нигә елмаясың? Кызык бит, әйеме. Көлке бит. Алтмыш яшьлек карт ничек тилерә.

Хәдичә. Сезгә алтмыш түгел әле. Илле тугыз яшь тә ике ай гына.

Рәхмәтулла. И-и-и, сабый гына икәнмен әле. Алайса, мин сиңа миңа дигән кияү егете. Эзләгәнемне таптың дигәнең әллә минме?

Хәдичә. Шаяртмагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Әйе—сез.

Рәхмәтулла. Пәрәмәч... Алайса, гафу ит шаяртканым өчен.

Хәдичә. Соңгарак калып очрадыгыз шул. Ләкин мин барыбер бәхетле. Сезнең бүлмәгә кучеп утырсам, сез каршы түгелме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Бер бүлмәдә утырсак, миңа артыгы кирәкми...

Гөлчирә *(кереп, карап тора да).* Бәтәч... Нишләп утырасыз? *(Хәдичә чыгып китә).* Кара син боларны, мыштым гына. Нигә ташып ашата дисәм, кулга ияләштерә икән.

Рәхмәтулла *(кискен итеп).* Узынма, Гөлчирә.

Гөлчирә *(каушап калган).* Син усал да була беләсеңмени, Рәхмәтулла абый?

Рәхмәтулла. Беләм.

Гөлчирә. Гафу ит инде алайса. Йомыш белән генә кергән идем. *(Чыгарга борыла)*

Рәхмәтулла. Йомышыңны әйт.

Гөлчирә. Ярый инде. Фәритем дә баудан ычкынып китсәм, узынма дия иде. Зинһар гафу ит, Рәхмәтулла абый. Мин чыннан да йомыш белән кергән идем. Рузалия җылый.

Рәхмәтулла. Ни булган?

Гөлчирә. Ни булсын, йөргән егете шалтыратмый.

Рәхмәтулла. Ә минем ни катнашым бар?

Гөлчирә. Кара бу оятсызны, ни ди. Ана җылый дип әйтеп торалар. Ул ни катнашым бар ди. Син бит аның әтисе урынына калган кеше. Ул бит синең һәр сүзеңне йотып утыра. Аның тома ятим үскәнен белмисеңмени?

Рәхмәтулла. Беләм.

Гөлчирә. Белмәсәң бел. Детдом баласы ул. Әрәм булмаганына рәхмәт әйт. Эшли, тәртипле.

Рәхмәтулла. Егете нигә шалтыратмый?

Гөлчирә. Каян белим. Белеп буламыни сезне. Яраттырасыз да качасыз.

Рәхмәтулла. Кайчаннан бирле шалтыратмый?

Гөлчир. Ике көн ди инде.

Рәхмәтулла. Ике көн күп түгел, шалтыратыр.

Гөлчирә. Кара моны... Ике көн синең белән миңа күп түгел. Ана бит унтугыз гына яшь. Аңлыйсыңмы—унтугыз.

Рәхмәтулла. Миңа нишләргә кушасың?

Гөлчирә. Менә ул егетнең телефон номеры. Шалтырат.

Рәхмәтулла. Ни дип?

Гөлчирә. Нәрсә, мин өйрәтер көнгә калдыңмыни?

Рәхмәтулла. Нигә үзең шалтыратмыйсың?

Гөлчирә. Ярамый. Мин хатын-

кыз. Хатын-кыз чәрелди башлый. Чәрелдәгән хатын-кызны кем тынласын. Шалтырат, Рәхмәти. Рузалия шалтыраткач, «номер не отвечает» дигән язу чыга ди. Юри алмый инде. Кесә телефоныңны бир әле. *(Рәхмәтулла кесәсеннән телефонын алып, номерлар җыя).* Мә, Рәхмәти, мә, җаным. Әйбәт бит син. *(Кесә телефонын Рәхмәтулланың колагына куя).*

Рәхмәтулла. Исеме ничек егетнең?

Гөлчирә. Әй, алла. Сорарга онытканмын. Хәзер. *(Атылып чыгып китә. Ул арада Рузалиянең йөргән егете телефонны ала).*

Рәхмәтулла. Алло. Исәнмесез. Рәхмәтулла абыегыз бу. Хәзер белерсез. Ә сез Рузалия исемле кызны беләсезме?.. Безнең бухгалтериядә эшли. Искиткеч акыллы һәм искиткеч чибәр кыз. Арада иң чибәре. Беләсезме андый кызны?

Гөлчирә *(атылып керә).* Тимур. Тимур аның исеме.

Рәхмәтулла. Тимур бит әле сезнең исемегез. Бик матур исем. Рузалия әйтмичә кем әйтсен. Мин аның әтисе урынына калган кеше. Ул сезнең турыда гына сөйли. Сезне очратуын зур бәхет дип саный. Ул сезнең бәхетегез, Тимур улым. Кулдан ычкындырмагыз. Андыйлар хәзер еш очрамый. Нигә шалтыратаммы? Нигә сез аңа шалтыратмыйсыз, шуңа шалтыратам. Рузалия кушмады, үзем шалтыратам. Телефон номерын ул бирмәде, үзем сорап алдым. Энекәш, сез көлмәгез әле. Көлмә әле син. Кеше җылаганда көлү килешми. Рузалияң җылый. Кызларның күз яшеннән куркырга кирәк, Тимур энекәш. Шалтырат син аңа. Сүзгә килгән булсагыз, очрашып аңлашыгыз. Хатын-кыз кәпризле була ул. Чөнки аларның күңелләре нечкә. Скрипкә кылы кебек. Көйләмәсәң, әче тавыш чыгара. Аңладыңмы? Көлмә син. Минем яшькә җиткәч, көлмәссең.

Гөлчирә *(Рәхмәтулланы кочаклап алып).* Менә, ничек яратмыйсың инде сине. Әле дә син бар әле дөньяда. Килешсәләр ярар иде инде. Бәхетле булсыннар иде. Минем кебек бәхетле булсыннар иде. Сине яратканымны кызым да белә. Элек мин аңа әтисе турында гына сөйли идем. Әтисен хәтерләми бит ул—яшь ярымлык кына иде. Хәзер синең исем дә ычкынгалый икән. Бервакыт әйтә, Рәхмәтуллаң ни хәлләрдә яши ди. Егылыплар китә яздым. Синең исемгә ияләште инде. Яратканымны сизә, кунакка чакырыйк, ди. Чакыра алмыйм шул. Чыгарып җибәрмәм дип куркам.

Кызыбызны нишләтербез икән, Рәхмәтулла?

Рәхмәтулла. Ничек кызыбызны?

Гөлчирә. Хәзер синең кыз да инде ул. Мәктәпне тәмамлый, кая укырга кертербез икән... Нигә алай карап торасың, Рәхмәтулла, әллә ярамаган сүз әйттемме? Узынма дип әйтергә җыенасыңмы? Ник дәшмисең, Рәхмәтулла? Ни уйлыйсың?

Рәхмәтулла. Юк, юк, сөйлә, сөйлә...

Гөлчирә. Юк инде, сөйләмим, ошатмадың. Сау бул. Рузалия өчен рәхмәт.

Рузалия *(атылып кереп Рәхмәтуллага ташлана, кочаклый).* Рәхмәтулла абый! Рәхмәтулла абый...

Гөлчирә. Кысыбрак кочакла. Ике яңагыннан үп. Булды. Инде мине кочакла.

Рузалия. Гөлчирә апа!..

Гөлчирә. Менә шундый инде без, Рәхмәтулла абый. Ә син безне әллә кем дип уйлыйсың. Күктәге йолдыз! Тулган ай! Фәлән-төгән, өч тиенлек бер дурак өчен акылдан шашучылар димисең.

Рузалия. Өч тиенлек түгел, Гөлчирә апа. Дурак та түгел. Рәхмәтулла абый кебек әйбәт егет ул.

Гөлчирә. Нәрсә, Рәхмәтулла абыең шулай бик әйбәтмени?

Рузалия. Искиткеч! Чудо!

Гөлчирә. Нәрсәсе чудо инде?

Рузалия. Мин каян белим инде. Кызык бит аның белән, күңелле.

Гөлчирә. Нәрсәсе күңелле инде?

Рузалия. Ну, Гөлчирә апа. Сез беләсез бит инде.

Гөлчирә. Нәрсәне беләм?

Рузалия. Ну, сез Гөлчирә апа. Үзегез дә яратасыз ич инде Рәхмәтулла абыйны.

Гөлчирә. Ни өчен яратам соң мин аны?

Рузалия. Ну, Гөлчирә апа.

Гөлчирә. Бар, чәй куя тор, мин хәзер чыгам. *(Рузалия чыгып киткәч).* Рәхмәт сезгә, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Нишләп әле сез дип сөйләшә башладың?

Гөлчирә. Гаебем бар синен алда. Син миңа шулай әйткәләп тор ярыймы, Рәхмәтулла абый. Ә миңа шундый рәхәт булды, син узынма дип әйткәч. Ирләр сүзе житми шул безгә, Хәдичәгә дә ирләр сүзе житми. Күпме әйттем сайланма дип. Әллә кемне эзли. Син аның ризыкларын тәмле дип аша, Рәхмәтулла абый, күңеле булсын. Ир кирәк шул хатынкызга, ир кирәк. Хәзер кочаклаттырмассың инде, әйеме?

Рәхмәтулла. Син миннән уенчык ясап бетердең. Рәхәтләнеп уйныйсың.

Гөлчирә. Уйныйм, Рәхмәтулла абый. Уйнарлык уенчык барында нигә уйнамаска. Әгәр дә бик беләсегез килсә, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, бер генә бала да яратмаган уенчыгы белән уйнамый, яраткан уенчыгы белән генә уйный. Минем сүзләрем сезләрнең баш шәрифләренә барып життеме?

Рәхмәтулла. Житте.

Гөлчирә. Менә шулай. Мин булмасам, нишләпләр бетәр идең син. Әле мин уйныйм гына, чынлап тотынсам—һу-һу-һу!.. Син дә уйна, Рәхмәтулла абый, мин яраткан уенчыгың булырга риза бит. Менә мин—синеке, теләсәң нишләт. Тездән түбән, кендектән югарысы барысы да синеке.

Рәхмәтулла. Бар чыгып кит.

Гөлчирә. Чыгып китсәм, сагынасың бит.

Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул;
Сагынасыңмы дип сорыйлар
Сагынмаган кая ул. *(Боргаланып чыгып китә).*

Рәхмәтулла *(Гөлчирә калдырган жырны дәвам итә).*

Телеграм баганасын
Санныйсым калган икән;
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

*(Кесәсеннән кесә телефонын алып саннар жыя).* Исәнме, алтыным. Борчылма, бик яхшы. Укып бетердеңме әле китабыңны. Әйе, бик яхшы язучы ул. Кит инде... Йәле, йәле укы... Искиткеч, алтыным. Тагын яз. Китап итеп чыгарырбыз. Мин дә шагыйрь ире булып мактанып йөрермен. Сау бул, кугәрченем. Борчылма.

Гөлчирә *(ишектә күренеп).* Бу мин түгел, курыкма. Әйдә, Нина. Менә Нинаның синең янга керәсе килә. Оялам, ди. Үзе маржа—үзе ирләрдән ояла. Утыр әйдә, Нина. Сөйләш туйганчы.

Нина. Балаболка син, Гуля. Исәнмисез, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Пока живой, Ниночка.

Гөлчирә. Мин чыгам, Нина. Смотри, не трогай Рахматулла абыйны. Маржаларга ир ышанып калдырсаң... Маржа күрсә, татар ире акылдан шаша бит ул.

Нина. Потому что без матурлар. Әйеме Рахматулла аби?

Рәхмәтулла. Әйе.

Гөлчирә. Кара, кара моның. Кил, башта кызыгыңны үзем күрим. *(Рәхмәтулланы кочаклап чыгып китә).*

Нина. Ә мин беләм нигә Гуля кочаклый сезне. Она вампир. Ул сездән ни ... жизненный тонус высасывает. Шуңа ул такая веселая. Ул сезгә ошыймы?

Рәхмәтулла. Ошый. Все вы мне нравитесь. Я всех вас люблю.

Нина. Сез со мной татарча сөйләшегез, Рахматулла Хурматуллович. Сез ошыйсыз миңа, кайчан татарча сөйләшәсез. Сез сөйлисез, все мне понятно. Язык наверно красив тогда, кто на нем красиво говорят. Минем ирем булды татар, аның сөйләшүе татарча меня раздражал. Раздражал ничек татарча?

Рәхмәтулла. Ачуны китерә иде.

Нина. Вот, вот ачуны китерә. Мин уйлый идем—какой грубый язык. Сез сөйлисез, ласкает слух сезнең сүзләр. Какие-то мягкие они. Сез үзегез дә такой йомшак. Вот сез прикоснетесь руками, кулыгыз белән, әйеме, и по всему телу вот такая теплота, жылы. Вроде бы вы уже не молодой. Яшь кеше түгел бит, да? Менә вот сезнең объятие... Кочакка керәсе килә. Гуля ул такая хитрая. Сез гафу итегез мине алай сөйләгәнгә. Мне вот захотелось в любви объясняться. Юк, мин бер нәрсә теләмим, сорамыйм. Сезне выгнали безнең бүлмәдән и так скучно мне стало. Откуда у вас такая положительная энергия?

Рәхмәтулла. Белмим инде, Ниночка. Сез үзегез яхшы булгангадыр ул.

Нина. Какой уж яхшы. Үзем беләм.

Правильно я говорю—үзем беләм. Кстати, не такая уж я стерва, да, Рахматулла аби?

Рәхмәтулла. Синме, Ниночка. Син арада иң чибәре, иң яхшысы.

Нина. И иң бәхетсез. Самая несчастная, наверно.

Рәхмәтулла. Алай димә, Ниночка. Бәхетне аны үлчәүгә салып үлчәп булмый.

Нина. Как, как?...

Рәхмәтулла. Ну как сказать. Счастье невозможно положить на весы и взвесить.

Нина. Интересно. Может быть. Вот мин, Рахматулла аби, дүрт иргә чыктым, да? Беренче чыктым. Любила. Яраттым. Сигез ел нормально жили. Аннан начал эчәргә. Беспробудно. Вроде бы и причина да юк. Эчә дә сугыша. Кыйный. Үз баласын да кыйный. Аерылдым. Икенче чыктым—такая же картина. Өченчегә татарга чыктым. Вроде бы трезвее народ. Ну эчте. Хуже других может. Исереп под трамвай попал. Четвертый раз за еврея вышла. Ну этот же народ абсолютно трезвый. Умный, рассудительный. Ну откуда мне попался такой экземпляр. Пьяница. Мин хәзер уйлыйм, Рахматулла аби, мы всем миром дышим перегаром. Минем дүрт иремнән өч балам бар. Как аларны уберечь. И у меня хәзер такое ощущение, что мин постоянно йокладым с бочками, наполненными водкой. Гафу итегез, что мин инде болай... Зашла вот объясниться в любви и объяснилась. Сез әйтәсез, что сез старый. Вот если сез әйтәсез миңа, Ниночка выйди за меня дип, побежала бы.

Рәхмәтулла. Читтән караганда гына шулай ул, Ниночка.

Нина. Нет, Рахматулла Хурматуллович. Юк, Рахматулла абый. Кайтыгыз безгә, вернитесь. Мы уговорим эту кикимору. *(Нурзидә Мөбарәковнаның кергәнен күреп).* Извините. *(Чыгып китә).*

Нурзидә. Сез мавзолейда яткан кебек, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Чират торып керәләр.

Рәхмәтулла. Нишләтим инде аларны. Ничә ел бергә утырдык бит, ияләшкәннәр.

Нурзидә. Ияләшү генә түгел бу. Сөйкемле сөягегез бар, күрәсең.

Рәхмәтулла. Кем белә инде аның, Нурзидә Мөбарәковна. Яратам бит мин аларны. Алар яратуга мохтаҗ. Эшли-эшли сезне дә яратырмын, мохтаҗ булсагыз.

Нурзидә. Ләкин бит эш бүлмәсе балаган түгел. Анда нindidер тәртип булырга тиеш.

Рәхмәтулла. Эш бүлмәсе төрмә камерасы да түгелдер инде. Монда бит җинаятьчеләр утырмый.

Нурзидә. Комедия театры да түгел инде бухгалтерия.

Рәхмәтулла. Үз эшләрен эшлиләр бит алар. Мин дә калышмыйм.

Нурзидә. Сез өлкән яшьтә бит инде. Алар сезне уенчык итеп уйныйлар.

Рәхмәтулла. Уйнасыннар. Сез баскетбол дигән уенны беләсезме? Мин аны яратам. Менә шул уенда уйнаучылар бар, туп бар. Уйнаучылар әллә нинди булсалар да тупсыз уйный алмыйлар. Мин—шул туп. Уйнасыннар, аннан кемгә зыян. Нигә алай карап торасыз? Бу абзый акылында микән дипме?

Нурзидә. Нигә минем турыда начар уйлыйсыз? Бәлки, теге кызларыгыз кебек сокланып карап торамдыр.

Рәхмәтулла. Охшамаган. Сез кергәннән артык житди, Нурзидә Мөбарәковна. Телисезме, мин сезгә Нурзидә дип кенә дәшәм. Сез әле миннән күпкә яшь. Чибәр. Беләсезме, бездә ничә хатын-кыз эшли, арада иң чибәре сез. Нигә елмаясыз? Телисезме, мин сезгә бер мәзәк сөйлим. Ишеттем дә бүген көлә-көлә үлә яздым. Көтүдән бер сыер кайтып килә икән. Капка төбендә бер песи баласы утыра ди. «Кит юлдан»,—дигән сыер,—үзең бәләкәй генә, үзең мыек үстергән булгансың»,—дия икән. «Үзеңне бел,—дигән песи баласы,—тубал хәтле ими үстереп лифчиксыз йөрисен». *(Көлгәненә куанып).* Шәп бит, әйеме?

Нурзидә *(көлүдән туктап).* Ә бит сезнең тормышыгыз мәзәк сөйләп йөри торган түгел, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Сезнең туганыгыз белән без бер йортта торабыз. Сез унбиш ел буена паралич суккан хатыныгызны тәрбиялисез.

Рәхмәтулла. Алдаша ул.

Нурзидә. Алдашмый. Сез аны берәүгә дә әйтмисез.

Рәхмәтулла. Нигә сез аны миңа әйтәсез? Ул бит аны сер итеп

сөйләгәндер. *(Югалып калган).* Кемдә кемнен ни эше бар. Әллә сезнен тормыш тоташ бәхеттән торамы? Бер үтенечем сезгә. Моны мина сөйләп бер ахмаклык эшләдегез, бүтәннәргә сөйләмәгез. Кемдә кемнен ни эше бар. Кешеләр кайгы түгел, шатлык уртаклашырга тиешләр.

Нурзидә. Гафу итегез. *(Ишектә Гөлчирә башын күреп).* Керегез, Гөлчирә Нәҗиповна.

Гөлчирә *(кереп).* Әллә кермәмме?

Нурзидә. Сау булыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Гафу итегез. *(Чыгып китә).*

Гөлчирә. Нигә гафу үтенә ул?

Рәхмәтулла. Мине синнән аерганга.

Гөлчирә. Ха!.. Аерып карасын. Ишекне бикләп куйса, тәрәзәдән керәчәкмен. Сина ни булды? Сөмсерен коелган сыман.

Рәхмәтулла. Озак керми тордын бит.

Гөлчирә. Көлмә инде, чыкканым да юк. Нинага ни әйттен, очынып йөри. Яратам диденме?

Рәхмәтулла. Үлеп яратам дидем.

Гөлчирә. Оятсыз! Кочаклап үтерәм бит үзенне. *(Рәхмәтулланы кочаклый).* Жылыйсым килсә дә, жыламыйм әле. Жылый белмим бит. Нигә алай икән, Рәхмәтулла абый? Ә син мине бер тапкыр жылаттын. Хәтерлисенме, Яна ел каршылаганда. Коллектив белән. Кал безнен янда дидем, калмадын. Ялындым—калмадын. Хурлыгымнан жыладым. Нишләтәсен, үземнеке түгел шул. Кеше кешесе. Уйныйсын дисен мине. Уйнамыйм—бик нык яратканымны сиздермәс өчен уйнаган булып кыланам. Һәр кешегә Ходай ярату хисе салган. Миндә әле анын яртысы да сарыф ителмәгән. Син дә мине яратасын бит, әйеме?

Рәхмәтулла. «Яратмаска сине мөмкин түгел...»

Гөлчирә. Кирәкми, икенче юлын әйтмә. Сон түгел әле, сон түгел. Мин әле сине йөз яшькә хәтле яшәтәм. *(Шаулашып Фаягөл, Нина, Рузалия, Хәдичә керәләр).*

Нина. Все, Рахматулла Хурматуллович, вы—наш. Сез—безнеке.

Фаягөл. Нурзидә Мөбарәковна рөхсәт бирде.

Рузалия. Кучерегез диде.

Гөлчирә. Кучерергә ул бит сезгә шкаф түгел.

Нина. Все, Гуля! Монополия уничтожена—Рахматулла абый общий.

Гөлчирә. Общий булмый торсын.

Нина. Рахматулла аби всенародное достояние. Дөрес әйтәмме, девочки?

Рузалия. Дөрес!

Фаягөл. Дөрес!

Рәхмәтулла. Нәрсә, миннән сорап та тормыйсызмыни?

Хәдичә. Кайтыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Нина. Башла, Фаягул. Һай, Хилляу, Хилляу...

Фаягөл. *(Жыр башлый, ана башкалар кушылалар).*

Алма сатучылар килгән,
Үлчәүләре бар микән;
Әҗәлгә дару бар диләр,
Мәхәббәткә бар микән.
Һай, һилләү, һилләү, һилләү,
Алты кызга бер кияү.
Һай, һилләү, һилләү, һилләү.
Һай, һилләү, һилләү лә.

*Пәрдә*

*1985—2005*



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# ТАНСЫК ЯЗЛАР, ТАНСЫК НАЗЛАР

СИГЕЗЬЮЛЛЫКЛАР

***

**Искесен тапшырып тарихка
Өр-яңа гасырны башладык—
Монысы афәтсез булсын, дип
Теләкләр теләдек баштан ук.**

**Акланыр микән соң өметләр—
Үзебез һаман да иске шул,
Догалар яңа да яңасын,
Дисбесе—чуалган дисбе шул…**

***

**Кемдер җырлый кара төнне ярып,
Җанны биләп ала моңлы җыру,
Җыр сәләте миңа бирелмәгән—
Рәхәт миңа аны тыңлап тору.**

**Сабый чакта әнкәй тибрәткәндәй
Тирбәләм мин шул җыр кочагында,
Кабына да сүнә, кабына да сүнә
Хатирәләр хәтер учагында.**

***

**Ак кәгазьне чарлап барган чакта
Туктап калса кинәт каләмем,
Өзелеп калган җырым ирешер сезгә,
Булып минем соңгы сәламем.**

**Ишетелер ул җыр барып сезгә,
Булып минем соңгы теләгем:
—Әй кешеләр, мин һәрвакыт сезгә
Кояшлы көн генә теләдем!**

***

**Кабат язлар җирдә, Тукай кайткан,
Җаннарның сафланган көннәре—
Тукайны тудырган язлар бу,
Шигырьгә бирегез мөнбәрне!**

**Бушатып иң түрен түрләрнең
Сәкегә салыгыз мендәрне,
Чакырып иң түргә Тукайны,
Юыйк бер күңелдән керләрне!**

***

**Сәер тынлык. Бөтен җиһан
Калган туктап сискәнеп,
Ак күбәләк канатыннан
Тоеп ак җил искәнен.**

**Зәңгәр тынлык. Ак күбәләк.
Аңның серле мизгеле—
Искә алды ахры дөнья
Бер илаһи Изгене…**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941)—*шагыйрь, публицист; «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Гомерлек язым» һ.б. китаплар авторы. Балтачта яши.*

***

Кемгә дә кирәк ул дөньяда
Кемнеңдер йөрәге җылысы—
Шул җылы җитмәсә, күңелнең
Килә гел үксисе. Елыйсы.

Арыгач мәшәкать-борчудан
Сискәнә бу җаным көн дә бер—
Минем дә йөрәгем җылысы
Кирәктер кайдадыр, кемгәдер.

***

Бездәге ашкыну—
Далада җил кебек,
Яшибез ашкынып,
Яшибез җилкенеп.

Кайчакта китәбез
Әйләнеп давылга...
Тик тына беркөнне
Җилләр дә, давыл да.

***

Мин һаман да уртасында
Үткән белән киләчәкнең—
Киләчәктән нидер көтеп,
Үткәннәрдән көләчәкмен.

Көләчәкмен үткәндәге
Бер гөнаһсыз гөнаһлардан,
Тик сез генә көлмәгезче
Минем кебек гөнаһкярдан!

***

Көзләрдә дә, кышларда да
Мин яз көтәм,
Яз җитүен көтә-көтә
Арып бетәм.

Нигә язлар миңа шулай
Тансык икән—
Бер килсен дә, язлар мәңге
Калсын икән!

***

Җәйге йөкләр әкеренләп
Төшеп бара иңнәрдән—
Урасылары урылган,
Җилгәрәсе җилгәргән.

Инде шактый талчыкканбыз,
Инде шактый арганбыз,
Җәйне эскертләргә салып
Көзгә кереп барабыз...

***

Әле генә шаулап таңнар ата,
Әле җитә моңсу кичәләр,
Мин ышанам, җирдә кеше гомере
Шаулап үткән бер көн дисәләр.

Шул бер көнгә сыйган барысы да—
Ярсып яшәү, яну-көюләр...
Көн кояшым инде сүнеп бара,
Туелмаган ләкин сөюдән.

***

Араларда хатлар йөрми инде,
Чоры үтте бүген хатларның,
Еракта́гы яшьлек хатирәсе—
Синең хатларыңны актардым.

Әллә нәрсә булды йөрәгемә—
Шул хатлардан күңел нечкәргән,
Еллар үткән, хатлар суынмаган
Яшьлектәге кайнар хисләрдән...

***

Яңгыр ява. Шул яңгырга
Сузып куйдым учымны—
Уч төбемдә ике тамчы
Йөгереп килеп кушылды.

Кушылды да, җем-җем итеп
Күмелделәр ак нурга...
Әй мәхәббәт, син булганда
Яшәү рәхәт, матур ла!

***

Эзләп-эзләп кенә табып
Булмый мәхәббәтне,
Үзе эзләп бер килә ул,
Сөю—мәрхәмәтле.

Бик теләсәң әгәр аның
Сиңа кичекмәвен,
Ачык булсын һәр мизгелдә
Күңел ишекләрең!

***

Сүзләр күп ул, төрлесе бар,
Мин эзлим ин җылысын,
Туң бәгырьлеләрнен дә бер
Бәгырьләре җылынсын.

Сүзләр күп ул, табалмыйм тик
Сиңа гына дигәнен…
Сизмичә дә пышылдадым:
—Син бердәнбер сөйгәнем!

***

Син минем өзмәгән алмам,
Чәчәк атмаган гөлем,
Алсу алмам, ал гөлем, дип
Мең кат кабатлый телем.

Яумаган лэйсән яңгырым,
Чыгып килгән кояшым,
Кояшлы яңгырда килә
Йөрәгемне юасым.

***

Мәхәббәтне табыш була,
Аны югалтып була,
Табылыр яңасы, диеп
Җанны юатып була.

Сөеп була яңаларны
Җанда ялкын барында—
Тик гомерләр бер генә шул,
Ярлары тар аның да…

***

Таныдыңмы, дип сорама,
Ник танымыйм, таныдым:
Шул сандугач—ботагында
Чишмә буе талының.

Шул ук җырны өздерә ул—
Әллә соң безгә инде!
…Дөньяда бары да шул ук,
Без генә үзгә инде.

***

Йолдыз яуган төн иде ул,
Күкләр җиргә ауган төн,
Безне бәхет үз иттереп
Кочагына алган төн.

Күкнең җиргә иңгән төне,
Безнең күккә менгән төн…
Гомер буе онытылмый—
Әллә төш ул, әллә өн.

Мәдинә Маликова

# ТЫЛСЫМ

РОМАН

• • •

Ә шулай да Мидхәтнең Ленизадан яшерен сере бар иде: командировкага барганда ул Казанга сугылып чыгу җаен тапты. Барыбер кайда да булса бер очкычтан икенчесенә күчеп утырырга кирәк: әйтик, Самара аша да барып була, яисә Казанда тукталыш ясарга туры килә. Самарада ана ни калган?! Ә Казанда... укыган институтына, кафедрага кереп чыгар...

Әмма асылда аны кафедра әһелләре түгел, башка кешеләр тарта иде.

...Әлифәләрнең ишеге ачылуга, борынга татлы хуш ис бәрелде. Бәлеш исе, бөтнек, җиләк исе иде бу. Мидхәтне туган йортка кайткач кына була торган бер иркенәю, рәхәтлек хисе биләп алды.

Аны күргәч, куанычыннан нишләргә белмәгән Әлифәнең йөзен күрде, сүзләрен ишетте, аңлап җиткермәде. Теле мондый очракта әйтелә торган сүзләрне әйтте, сәлам бирде, куллары апакайның иненнән кочып, аркасыннан каккалады, күкрәге аның кочагында иркәләнде. Ә күзләре апаның баш өстеннән бүлмә эченә, алсу халатлы кызга төбәлгән иде. Ул, Әлифә яныннан эчкәрәк атлап, Әнисәнең нәфис кулларын учына алды.

—Ә син үсеп куйгансың,—диде.

—Юк, үсмәдем,—диде кыенсынгандай карашын читкә алып Әнисә.—Уңдүрт яшьтә йөз алтмыш биш сантиметр идем, хәзер дә шулай.

—Үсте, үсте, тәмам җитеште,—дип такылдады һәм гадәтенчә кеткелдәп көлеп куйды Әлифә.—Үлән чәе эчереп үстерәм бит мин аны...

—Җиләк кайнатмасы беләндер әле...

—Анысы да җитәрлек. Быел да авылга кайттык, күп итеп җыйдык. Сине юксындык!

—Яшен астында калмадыгызмы соң?

—Юк инде, акылга утырдым хәзер. Үземнән бер адым да калдырмыйм. Бергә барабыз, бергә кайтабыз.

—Туктаусыз «син кайда, син кайда» дип кычкыра ул,—диде Әнисә үртәгән сыман итеп.

—Без сине монда гел искә алабыз, сагынып беттек инде,—дип такылдавында булды апа.—Киттең дә югалдың. Адресыңны да белмибез. Өйләнгәнсең, кызыгыз туган икән. Соң ишеттек, сез киткәч кенә. Югыйсә, котлаган булыр идек. Үсеп беткәндер инде. Туктале, нишләп торабыз без монда? Сал өс-ләреңне! Әнисә, чәй куеп җибәр!

Табын нәкъ туган өйдәгечә иде. Бөтнекле чәй бик тә тансык, алма бәлеше

*Ахыры. Башы 8 санда.*

ашап туйгысыз, ә инде җир җиләге кайнатмасын әйтеп тә торасы юк.

Мидхәт Әлифәнең сорауларына уйлап-нитеп тормыйча җавап бирә, командировкага баруы, монда юлны бераз гына авыштырып кына керүе турында сөйли, дикъкате исә Әнисәдә, аның чыннан да җитлегеп-җитдиләнеп киткән йөзендә, иягендәге уем эченә куелган сихри тамгада иде. Кыз мәктәпне тәмамлап, медицина училищесына укырга кергән икән.

—Курыкмыйсыңмы?—дип сорады Мидхәт.

—Нидән курыксын ул?—диде Әлифә.

—Бәндә хатадан хали түгел, диләр. Ялгышмыйча булмый. Ә медицинада хаталану—фаҗига дигән сүз...

—Безнеке сирәк ялгышыр, иншалла,—диде Әлифә.—Дәвалау эшенә кулы бик ята. Җәен дачада балалар бакчасында санитарка булып эшләде менә. Тәҗрибә туплый.

Табынны җыеп алгач, Әлифә:

—Яныңда кызыңның карточкасы бармы? Күрсәт әле!—диде.

Мидхәт Рамиләнең фотосурәтен һәрвакыт пинҗәгенең түш кесәсендә йөртә.

—Күз карашы олыларныкы кебек икән,—диде Әлифә, ул биргән катыргыны җентекләп карагач.—Моңлы балага охшаган. Артык уйчан. Карточкага төшергәндә фотоаппаратыннан чыпчык очырмадыңмыни? Менә очып чыга, менә оча, дисәң, елмайган булыр иде...

—Әйдәгез әле, сезнең фотоларны карыйк!—диде Мидхәт.—Альбомнарыгыз бардыр бит?

Әнисә узган җәйне балалар бакчасында эшләгән чагында төшерелгән фоторәсемнәрне күрсәтте. Берсендә ул мандолина тотып утырган иде.

—Син музыкант тамыни әле?—дип гаҗәпләнеп сорады Мидхәт.

—Азрак кына уйныйм...

—Яле, уйнап күрсәт әле абыеңа! Мин синең абыең бит инде, шулай түгелмени?

—Уйна, уйна!—дип кыстады Әлифә дә.

Әнисә шкафның аскы зур тартмасыннан мандолина алып, кылларын чыңлатып көйләргә кереште. Аннары медиаторы белән бөтен кылларга берьюлы бәреп, көмеш тамчылар сипкәндәй яңгыратып куйды. Һәм башын иеп, чак ишетелерлек итеп, Әлфия Авзалованыкына охшаганрак күкрәк тавышы белән, җырлап җибәрде:

«Как-то утром, на рассвете заглянул в соседний сад,
Там смуглянка-молдаванка собирает виноград»...

Җыр бик таныш иде, Мидхәт эченнән генә аңа кушылды.

«Встанем на рассвете зорьки ранние встречать...» Шунда ук күңелендә сүзләрнең чак кына башка төрлерәкләре яралды:

«Чаганнарның яфраклары челтәрле,
Ал таңнарны бергә каршылыйк әле...
Күзләремә бер тутырып карарсың,
Сине өзелеп сөюемне аңларсың»...

Менә җыр тәмамланды, ә Мидхәткә җитмәде, җитмәде! Ул авызын ерып, Әнисәнең янасын башлаганын көтеп утыра иде.

—Татарча да җырлап күрсәт инде,—диде Әлифә.—Балаларга җырлаганнарның берәрсен...

Әнисә ал тасма белән бәйләнгән башын янә иеп, кылларны чиртте...

«Әйт әле, күбәләк, сөйләшик бергәләп»...

—Их, нигә мин шул бакчадагы балаларның берсе булмадым икән!—дип үзе дә сизмәстән әйтеп куйды Мидхәт җыр тәмамлангач.

Әлифә рәхәтләнеп, куанып көлеп җибәрде.

—Анда синнән, миннән башка да җитәрлек! Ата-аналар балаларын Әнисә

эшләгән группага кертү өчен талашып беттеләр!

Һәм кызга сөеп карады.

Шулай итеп, вакытның узганын сизми дә калганнар икән. Мидхәт Әлифәнең:

—Сина урынны диванга җәярбез инде,—дигәненә сискәнеп башын күтәргәндә, дивардагы түгәрәк сәгать унны күрсәтә иде.

—Миннән оялып тормассың,—диде Әлифә.—Барыбыз да авыл балалары, бер сәкедә тәгәрәп үскән. Без икебез бүлмәдә ятарбыз, шәһәр кызы кухняда йоклар. Кеше килсә, аның урыны шунда була.

—Кунакханәгә урнаштым мин,—диде Мидхәт һәм кузгалып, хушлаша башлады.

Әмма инде чыгып китәм дигәндә генә, үтереп эчәсе килгәнен тойды.

—Кайнаган су калдымы әле анда?—дип сорады ул.

—Кунакны су белән сыйламабыз инде,—диде Әлифә.—Әнисә, куй чәйнекне. Тик мин сезнең белән утыра алмыйм. Үпкәләмәгез. Иртәгә иртүк больниска барасым бар. Миннән дә сату иткән өчен медсправка сорыйлар бит. Поликлиникада иртәнге биштән барып чират торырга кирәк.

Шулай итеп, аш бүлмәсенең кызыл роза рәсеме ясалган клеенкалы өстәле янында алар икәү генә калдылар. Мидхәт үзенең ахмак кешедәй елмайганын тоя, әллә ничек кыенсына иде. Ул сүзне шаярудан башларга тырышты.

—Әллә нәрсә башым авыртып тора,—диде кайчандыр Әлифәнең әйткәннәрен исенә төшереп.

—Аспирин биримме?

—Сине кул белән дәвалый белә, дигәннәр иде бит?

Әнисә кызарынып башын иде.

—Ул бит болай гына... Карчыкларда самовнушение көчле.

—Миндә дә көчле ул самовнушение! Башны сыйпап куйсаң, шифасы тими калмас, мөгаен.

Әнисә куе керфекләре астыннан кистереп карады да:

—Сезнең баш авыртмый,—диде.—Сезнең башка җирдә авыру...

—Кайсы җирдә?!

—Психологически...

Бу сүзләрдән Мидхәт сискәнеп китте. Әллә чыннан да күрәзәче сәләте бармы бу кызыкайда? Кешенең иң яшерен кичерешләрен беләме әллә ул? Ә бәлки, ул Мидхәтнең хатыны янынnan очынып диярлек чыгып киткәнен сизәдер?

Кыз, кыенсынгандай, карашын җиләк кайнатмасы тулы бәллүр савытка төшерде.

—Минем беләсем килә...—диде ул кыюсыз гына.—Сорасам, сөйлисезме?

—Нәрсәне?!

Мидхәтнең тавышы ирексездән калтыранып куйды. Теге чакта Әлифә әйткән иде бит Ленизa хакында бу кызыкайның ниләр сөйләгәнен... Ул көнне табын янында Әнисә белән Ленизаның бер-берсен яратышмаганнары бик нык сизелгән иде, шуңа үч итеп әйтүе генә булганмы, әллә чыннан да берәр нәрсә сиземләгәнме?!

Тик кызның уенда башка икән.

—Мәсәлән, эшегез турында,—диде ул.—Сез заводта ниләр ясыйсыз?..

Мидхәт җиңел сулап куйды.

—Завод эше кайда да бердер инде ул. Синең өчен кызык булмас.

—Миңа кызык,—диде Әнисә керфекләрен күтәреп. Аның карашында чын-чынлап кызыксыну, хәтта үтенү ярылып ята иде.

—Шартлаткычлар буенча белгеч бит мин. Цех начальнигының урынбасары булып эшлим.

—Миналар ясыйсызмы? Әллә бомбалармы?

Кызның күзләрендә генә түгел, ярым ачылган иреннәрендә, бөтен йөзендә чалынган шомлану галәмәтләре күреп, Мидхәт көлеп җибәрде.

—Сез... сугышка дип эшлисезмени?..—дип сорады ничектер куркынып Әнисә.

Кара син аны! Күрәзәче дигән булалар тагын. Беркатлы сабый бит бу!

—Шартлаткыч—ул әле бомба яки мина дигән сүз түгел,—дип аңлата башлады Мидхәт.—Шартлау—ул, гомумән, тереклекнең башлангычы, нигезе.

Әнисәнең күзләре гаҗәпләнүдән зур булып ачылды. Я Алла, нинди беркатлы бу бала!

—Һәр тереклек иясенең яшәеше нәрсәдән башлана?

Әнисә сүзсез аңа текәлгән иде. «Шартлаудан түгелдер бит инде!»—ди иде аның карашы.

—Нәкъ менә шартлаудан,—дип көлеп җавап бирде аның сүзсез соравына Мидхәт.—Шартлау нәрсә ул? Кинәт үзгәрү, дигән сүз. Күзәнәк белән күзәнәк кушыла да, кинәт үзгәреш башлана. Күзәнәкләрнең тышчасы шартлап ярыла да, алар үрчи башлый. Әллә шулай түгелме?

Әнисә телсез иде.

—Моны бик борынгыдан аңлаганнар,—дип дәвам итте Мидхәт.—Шартлау элек-электән куаныч, бәхет, тантана билгесе булган. Фейерверклар, бенгаль утлары, салютлар шуннан килеп чыккан. Хәзерге вакытта алга киткән илләрнең иң кәттә шәһәрләрендә кирәксез биналарны шартлатып җимерүне зур бер бәйрәм рәвешендә үткәрәләр. Фейерверклар белән. Әйтик , Лас-Вегаста. Ишеткәнең бармы? Менә күрерсең: мин, Казанга кайтып, Кабан күле буендагы берәр хәрабәне җир белән тигезләрмен һәм моны бөтен шәһәр өчен бәйрәм итеп башкарырмын! Күктән йолдыз коелыр, шәһәр нурга күмелер, җир тибрәнер, халык җырлар, биер. Күрерләр шунда шартлауның нинди могҗиза икәнен!

Кызның нык кызыксынганын күреп, Мидхәт отыры илһамланды.

—Әгәр беләсең килсә, шартлаткычлар сугыш өчен уйлап чыгарылмаган,—дип дәвам итте ул.—Сугыш чукмарлары башкалар өчен уйлап чыгарганны үзләштергәннәр, шул гына. Гайрәтле, шул ук вакытта кеше ихтыярына буйсына торган шартлаткычларны барыннан да бигрәк төзүчеләр, казылма байлык чыгаручылар кирәксенә. Дөньяда иң авыр эш—җир эше. Адәм баласына исә җирне бик нык актарырга туры килә. Тауларны ерып юллар салганда да, елгаларны буганда да. Менә шул эшләрне шартлаткычлар бик күпкә җиңеләйтә. Гасыр башында галим Альфред Нобель кеше ихтыярына буйсына торган шартлаткыч булдыру өчен бик тырышып эшләгән....

Мидхәт мавыгып китеп, Нобельнең башыннан кичкәннәр турында сөйләргә керешә. Тәҗрибәләр үткәргәндә шартлаудан шактый кешеләрнең һәлак булганын, биналар җимерелгәнен... Галимнең дә могҗиза белән генә исән калганын... Нәтиҗәдә аны шәһәрдән куып җибәрүләрен... Шуннан соң Нобельнең тәҗрибә өчен корылманы елга уртасындагы салда төзүен...

—Ахыр чиктә динамит уйлап чыгарган ул. Бу нәрсә шулкадәр күп кирәк булган ки, Нобель берничә завод төзегән, череп баеган. Бик күп миллион акча туплаган. Гомеренең соңында ул, үзеннән соң калган акчага ел саен килеп торган процентларны дөньяда иң зур ачышлар ясаган галимнәргә премия итеп бирергә, дип васыять әйтеп калдырган. Шулай итеп, Нобель премиясенең башлангычы да шартлаткычларга барып тоташа.

Гаҗәпләнүдән, Әнисәнең авызы ачылып, энҗе тешләре күренде. Сабый да сабый, ул да сабый иде...

—Ләкин барыбер шартлаткычларның мең сере ачылмаган әле,—дип сөйләде Мидхәт.—Күп очракларда аларны махсус ясау таләп ителә. Әйтик, җир

токымы йомшакмы, әллә тоташ ташмы? Ә бәлки, мәрмәрдер? Аны нинди тирәнлектә куптарырга? Актарылган токымны кайсы тарафка, нинди ераклыкка күчерергә? Йортны җимерергә кирәк булганда, анын диварларын кайсы якка аударырга? Тирәсендәге корылмаларны зыяннан ничек сакларга? Шартлаткыч—кыргый җәнлек, арыслан кебек. Аны кулга ияләштерә белергә кирәк.

—Сез дрессировщик, димәк? Ләкин шартлаткыч...

Әнисә кашларын күтәреп сүз эзләде, шома мангаенда сөйкемле сыр хасил булды.

—...исән түгел!—дип тәмамлады ул җөмләсен.

Мидхәт тагын көлеп җибәрде.

—Тере, дияргә кирәк, тере!—диде ул.—Син русча «живой» дигәнне тәрҗемә итеп әйттең. Ә ул сүз татарчадагы ике мәгънәне анлата: «исән» яисә «тере».

—Шартлаткыч—тереме?

—Бик тере! Бик! Әгәр эченә җан кертә алсаң.

—Ә ничек ана җан кертергә?

Кызнын йөзе балкып киткәнне күреп, Мидхәт отыры рухланды.

—Бөтен хикмәт шунда шул. Химиклар өчен күнел сизгерлеге, хисләр бик мөһим. Чөнки матдәнең иң кечкенә кисәкчекләре синең хисләреңне аңлый. Аларны яратырга, алар белән мавыгырга кирәк. Салкын акыл белән генә булмый.

—Димәк, мәхәббәт кирәк ...—диде Әнисә уйланып.

—Әйе, саташыр дәрәҗәдә ярату кирәк. Дөньяңны онытып шушы шөгыльгә баштанаяк бирелү! Яңа ачышларны саташмыйча гына ясау мөмкин түгел. Ә син беләсеңме, бик күп ачышлар төштә күргәннән соң ясалган?

—Сез дә шулай яратасызмы?.. Шартлаткычларны... саташырлык булып...—диде күзләрен зур ачып Әнисә.

—Аларны яратучы бер мин генә түгел. Көндәшләр дөнья тулы! Күз алдына китер: әллә ничәшәр катлы биналар. Эче тулы зур белемле, унган, елгыр галимнәр. Һәркайсынын дөньяны шаккатырырлык ачышлар ясап таныласы, макталасы, байыйсы килә. Чит илләрдә андыйларга яхшы түлиләр, бөтен кирәкне табып биреп торалар. Менә шулар белән ярышып кара син!

—Ә сезне... тәэмин итәләрме соң? Галимнәргә аз түлиләр, диләр бит...

—Алар белән чагыштырганда, хезмәтебез бик арзан бәяләнә, анысы хак. Әмма безнен башларга да чүбек тутырылмаган.

—Ә сез бу юлы нәрсә шартлатырга барасыз?

Бу сорау Мидхәтне очып барган җиреннән тартып түбән төшергәндәй итте. Анын башы иелде. Йөзендәге елмаю галәмәтенә монсулык кушылды.

—Әнә, Норвегиядә шартлаткычнын яңа төрен уйлап чыгарганнар,—диде ул сорауга туры җавап бирмичә.—Аларнын шартлаткычы капсулаларда, җир токымына зур булмаган тишекләр ясап тыгып кына куясы. Әгәр берәрсе кирәк чакта шартламый калса да, шул килеш тора, ул инде бульдозер китереп басса да кыймшанмый. Чөнки махсус сигналга гына буйсына. Мондый шартлаткыч эшне дә күпкә ансатлаштыра, куркынычсызрак та. Безнен кайбер шахта-рудникларнын җитәкчеләре үзләренә кирәкне Норвегиядән ала хәзер. Ә анда валюта белән күп меңнәр түлисе! Без менә аларныкыннан яхшыракны эшләргә уйлыйбыз.

—Сез әйттегез, аларда шундый шартлар...

—Безнең ният аларга барып ирешкән инде. Хәзерге вакытта хәбәр тиз йөри бит. Авыз ерып көләләр. Юкка азапланасыз, диләр... Без була торып, без дә бу эшкә ун ел гомеребезне салдык, диләр. Безнен илдә фәнни эш өчен шартлар югын алар да белә.

Әнисәнең карашы читкәрәк авышты, тирәнәеп китте, йөзе җитдиләнде,

серләнде. Гүяки ул диварлар аша ерактагыны күрә иде кебек. Мидхәт сынын турайтып аңа текәлгән, тик кыз моны тоймый иде кебек. Шулай... мизгелләр үтте.

—Сез моны эшләячәксез,—диде Әнисә, ниһаять, карашын егетнең йөзенә күчереп.—Җинел булмас. Ләкин максатка ирешәчәксез.

Саубуллашканда исә аның күзләрендә бөтенләй башка чалымнар барлыкка килде. Аларда соклану да, бик тә якын, үз итү дә бар иде. Җылы карашка сусаган йөрәк татлы җилпенеп куйды.

Баскыч мәйданчыгына чыккач, Мидхәт аякларын бетон идәннән куптара алмый бераз басып торды. Куллары үзләреннән үзләре кызга таба сузылды. Аның да тәне тартылганы сизелә, ул менә-менә кочакка керәчәк кебек иде.

Мидхәт күз кабакларын авырттырып кысты. Ярамый... Хакы юк...

Әнисәнең күз төпләрендә ялкын телләре бөргәләнде, аннары шундук тоныкланып киткәндәй булды: гүяки учакка яңгыр тамчылары сибелде. «Төтен»нең зәһәре күзләрне ачыттырды.

—Иртәгә киләсеңме?—дип сорады ул.

—Юк шул. Иртәгә институтта эшем күп. Андагы яңалыклар белән танышырга кирәк. Төшләреңә берәр нәрсә кермәде микән...

—Ә син буялган төшләр күрәсең, шулай бит?

—Ничек? Нәрсәгә буялган?

—Ну, художникларның картиналары кебек...

—Төсле диген... Төшкә бит ул уяу чакта күргән нәрсәләр керә. Агачлар яшел, күк зәңгәр, җиләк кызыл...

—Җиләк тә керәме?

—Керә. Ашап кына булмый. Авызыма алыйм гына дим, уянып китәм...

Мидхәт артыграгын әйтеп ташлаганын тоеп, баскычка таба борылды:

—Сау бул.

Әнисә аны җиңеннән тотып туктатты.

—Ә самолет кайчан?

—Кич белән,—диде Мидхәт.—Сәгать сигездә.

...Бу сорауга ул әлләни әһәмият бирмәгән, озатырга килерләр, дигән уй башына да килмәгән иде. Аэропортта ак яулыклы Әлифә белән алсу берет кигән, муенына озын алсу шарф салган Әнисәне күргәч, беренче мәлдә үз күзләренә үзе ышанмый торды.

—Әнисәнең сине озатып каласы килде бит,—диде Әлифә.—Үзен генә җибәрергә курыктым.

—Рәхмәт инде,—диде күңеле нечкәргән Мидхәт.—Болай кадерләп, аздырып җибәрмәгез тагын. Мин бит андыйга күнекмәгән...

—Хатының озата барадыр бит?—диде Әлифә.

Мидхәт ялгыш сүз ычкындырганын сизеп, башын читкә борды, сумкасының бавын инбашында шудыргалады. Аңа ярдәмгә килгәндәй, иркен бинаны яңгыратып, хатын-кыз тавышы ул очачы рейска теркәү тәмамланып килгәнен игълан итте. Мидхәт ике кулын Әлифәгә сузды, Әнисәнең инбашыннан каккалады.

—Сау булыгыз,—диде.—Ә сез барыгыз, китегез. Безне әле тагын берәр сәгать бикләп тотачаклар. Вакытны бушка уздырмагыз.

Әнисәнең керфекләре тетрәнә, аларны дым сарган кебек иде.

—Ә син нигә болай моңаясың, Әнисәкәй?

—Жалко-о... Кызганыч...

—Вакыт аз булуы кызганыч шул... Эш бит...

—Мин аны әйтмим,—диде кыз карашын идәнгә төбәгән килеш.—Мин башканы...

—Ә нәрсә...

—Сак булырга кирәк сезгә. Зинһар, сак булыгыз...

—Самолет жиргә мәтәлер, дип куркасынмы әллә?

Әлифә Мидхәтне сумкасыннан тотып, читкәрәк тартты.

—Әнисә төн буе йокламады, борсаланып чыкты,—дип пышылдады анын колагына.—Кызын сакласын, ди.

Мидхәтнен күнеленә ниндидер шом бәргәндәй булды. Ул Әнисәгә таба атлады.

—Син бүген бик ямансу әле,—диде.

Кыз үрелеп сак кына хәрәкәт белән анын күкрәгенә кулын куйды.

—Менә монда авырта, әйеме?

Анын йомшак, шул ук вакытта нык учыннан куртка аша агылып кергән жылы Мидхәтнен бөтен жегәрен алгандай итте.

—Йөрәк чире таптынмы әллә абыеннан?—дип сорады борчылып Әлифә.—Аны инде бу минутта әйтергә кирәкмәстер.

—Ә мин аны кайчан күрәм?—дип кинәт өзгәләнеп сорады Әнисә.—Кайчан килә ул?

Мидхәт ни әйтергә белми анын күзләренә текәлгән иде. Кайчан? Ул кызнын кулын күкрәк турыннан алып, учына кысты.

—Озак тормам... Монда кызыклы идеялар күп икән...—дип, буталып, ниләрдер сөйләнде.

—Ә сез безгә хат язарсызмы?

Мидхәт сәерсенеп китте. Бу кешеләр белән хат алышу башына килмәгән иде әле. Гомернен мондый чорында хатлар атаң-анаңа да сирәк языла.

Әмма кыз ана шулкадәр мөлдерәп карады ки, ул:

—Әлбәттә язачакмын,—диде.—Әлбәттә...

Кызнын бит очлары янып чыккан, тулышкан ирен читләрендә нәни уймаклар пәйда булды. Ул кулларын сак кына шудырып Мидхәтнең учыннан алды.

Регистратура өстәле янында беркем юк, кәрәсе кеше кереп беткән, зәңгәр форма кигән хатын сонгы пассажирнын кәгазьләрен алырга кулын сузган иде.

—Тизрәк булыгыз,—диде ул.—Хәзер ишекләрне ябабыз.

Мидхәт ялтырап торган тимер тоткага ябышып, эчкә узды. Ул борылып, елмаеп башын игәндә, алсу башлыклы кыз, ана таба талпынгандай авышып, шул ук вакытта якын килергә кыймыйча басып тора иде. Күнелдә кинәт, тимер аратаны кире бәреп чыгып, Әнисәне кочаклап бер үбәргәме әллә, дигән тиле бер омтылыш туды. Бит очыннан гына булса да. Ләкин... ярамый иде.

—Хатларны главпочтага «до востребованья» яз!—диде ул тавышын күтәреп.—Карточканны жибәрергә онытма!

Әнисә анлаганын белгертеп башын игәләде, елмаеп кулын болгады. Мидхәт бөтен ихтыярын жыеп, аякларын эчкә таба атларга мәжбүр итте.

Дөрес әйткән икән, аларны «накопитель»дә, ягъни юлчыларны туплый торган иркен, шыксыз бүлмәдә шактый озак тоттылар. Тик Әлифә белән Әнисә ул әйткәнне тынламаганнар икән. Бинадан чыгып, каршыга килеп туктаган автобуснын ачык ишегенә таба барганда, Мидхәт нидер сизеп, борылып карады. Арырак биек багана башындагы лампа тимер рәшәткәне, ана ябышкан алсу башлыклы кызны яктырта иде. Китмәгән... Мидхәтнен һавага, биеккә күтәрелгәнен күрәсе, очар кошларны озаткандай, күздән югалганчы карап каласы килә...

Менә ул рәшәткә аша сузылып, кулындагы алсу шарфын болгады. Мидхәт аннан күзен ала алмыйча тукталып калды. Янәшә басып торган форма кигән хатын, анын иненә орынды:

—Автобуска керегез! Тоткарлыйсыз...

* * *

Ул дөрес чамалаган икән: карьердагылар белән бәхәсләшү, тартышу ун көнгә сузылды. Фәнни-тикшеренү институтыннан белгечләр чакыртырга туры килде. Ахыр чиктә барыбер Мидхәт морадына иреште—комиссия, бәхетсезлеккә китергән шартлауда карьер эшчеләре гаепле, дигән нәтиҗә чыгарды. Кире кайтканда җан тыныч, күңел күтәренке иде.

Әмма өйнең бусагасын атлап керүгә кәеф кырылды—Лениза анын сәламен алмады. Әле ул гынамы! Әнкәсенең чуар халат итәгенә ябышкан Рамилә: «Әти какай!»—дип кычкырып җибәрде. Яңа сүз өйрәнеп куйган...

Ул көнне дә, аннан соң да Лениза аны әтисенә якын китермәскә тырышты, үзе исә авызына су капкандай йөрүендә булды. Мондый өйдә күзгә ямь, җанга ял табам димә шул инде.

Нинди гадәтләр ул—үпкәләшкән саен атналар буе кара коелып, сораганга җавап бирмичә, үзең дә эндәшмичә, телсез-чукракка сабышып йөрү. Чит-ят кебек, хәтта дошман кебек. Моңа ничек чыдап бетмәк кирәк? Мидхәт үскән йортта да савыт-саба шалтырамый тормый, әтисе белән әнисенең кызып-кызып бәхәсләшкән, әрепләшкән чаклары булгалый. Әмма минутында әйтәләр дә, бераздан суынгач, оныталар, мөнәсәбәтләр гадәти эзгә кайтып төшә. Дәшми йөрү дигәнне гомумән белмиләр.

Бәлки, шундый мохиттә үскәнгәдер, Мидхәт бүгенге көндә өендәге хәлне аерата авыр кичерә иде.

Кичләрнең берендә, смена тәмамланганнан соң урамга чыккач, ул, юл читендә тукталып, кире борылып карады. Завод капкасыннан халык агыла. Күпчелеге ирләр. Багана башындагы лампочкадан төшкән яктылыкта талчыккан, караңгы чырайлар чагылып-чагылып китә. Хәер, әнә, берсенең авызы ерык. Кара мыегы астыннан елмаеп, туп-туры Мидхәткә таба килә. Күрше йортта яшәүче Рәмис бу. Кул бирешеп исәнләшүгә, кесәсеннән бөгәрләнгән сигарет пачкасы чыгарып, Мидхәткә сузды.

—Кабызып җибәр берне.

Мидхәт берне тартып алды да, ул сузган зажигалкадан ут элдерде. Эченә суырмыйча гына авызыннан төтен өрде.

—Нәрсә син болай, көзге чебеш кебек шәбәрдең?—диде Рәмис.—Эшегез бара, заказларыгыз җитәрлек. Командировкадан да җиңеп кайткансын дип ишеттем. Синең дә борын салынкы булгач, башкаларга ни кала? Әнә, күрше цехлар атнага күп булса өч көн эшлиләр. Заказлар юк!

Бөтенесен белә Рәмис, чөнки завод идарәсендә тәэминатчы булып эшли.

—Тормыш эш белән генә чикләнми бит әле...

Бу сүзләр Мидхәт авызыннан зарлануга уралып чыкты.

—Аңлашыла-а-а...—диде Рәмис.—Әйдәле, кореш, бераз тамак чылатып чыгыйк.

Каршы якта кечкенә базар бар, андагы ларекларда төрле вак-төяк саталар. Аларның берсендәге сыраханә төн уртасына кадәр эшли һәм бер дә буш тормый. Биек, түгәрәк өстәлләр янында басып торыр өчен кайчакта урын җитми.

Тәмәке төтененә сасыган, өстәлләре күксел-соры таплар белән чуарланып беткән, колакны тондыргыч шау-шулы бу шыксыз урынны Мидхәт яратмый, сырага да хирәслеге юк. Әмма бу юлы ул кесәсендәге акчаны капшады да Рәмискә иярде.

Аларның өстәле янына тагын икәү килеп басты. Якыннан ук таныш булмасалар да, күзгә чалынган кешеләр. Кружкаларның беренчесен чөмергәндә, эш азлыктан, акча юклыктан зарланышып алдылар, икенчесенең күбеген

өргәләгәндә, йөзләр ачыла төште, тагын да берничә йотым кабып куйгач, сүзләр дөнья гаменнән аерылып, йөрәк тирәләренә күчте, ягъни хатын-кызга килеп ялганды. Алар турында гәпләшү—аракыга да, сырага да ин шәп кабымлык бит ул!

Ир-ат сыра йотып, тәмәкесен кабызса, сүз жебенә хәләл һәм хәләл булмаган жефетләр килеп чуалмый калмый. Хатын-кызларнын күбесе үзләре турында ирләрнен ниләр сөйләгәнен күз алдына да китермидер. Тик гаепләргә ашыкмагыз, гүзәл ханымнар. Ирләрне табигать сезгә караганда дәртлерәк итеп яраткан, шунлыктан, бу мәсьәлә аларны күпкә ныграк гамьләндерә. Мөселманнарга дүртәр хатын белән яшәргә рөхсәт ителә икән, бу юкка гына түгелдер. Дәрте ташып торсын да, шул хәтле тамакны туйдырырлык чамасы гына булсын—бер ир заты дүрт хатынны бәхетле итә ала. Һәм үзе дә алар белән бәхетле була ала.

Таплы түгәрәк өстәлләргә терсәкләрен терәп басып торган ирләрнен чырайларында уйнак елмаю пәйда булды, һәркайсынын хыялында ямьле өй, чибәр, мут хатын гәүдәләнде. Сонгысы, бәлки, берәү генә дә түгелдер. Чын тормыш һәм өйдә көтеп торган хәләл жефетләр ерагайды, күздән югалды. Монысы үзенә бер рәхәт иде. Уйлап карасан, өзелеп сөюгә лаекмы сон алар? Көндезләрен нужа арбасын өстерәп, кичкә хәлдән таеп, урынга барып ятуга оеп китә торган жан ияләре... Ирләрен ничек бәхетле итә алсын алар?

Чынбарлык күнелсез, хыяллар—тормышка ашмаслык. Ачы ризасызлык сыраханә әһелләренен эчендә сыра күбеге булып күперә һәм авыздан бөселеп чыга. Ниләр генә ишетмисен кайчакларда!

Хатыннарнын хиссезлеге, тупаслыгы, ир рәхәтен айга ике тапкыр кулга кергән акчанын мөмкин кадәр күбрәк булуында һәм тынгы белми эшләп торган кулларында гына дип белүләре турында... Эштә чамадан тыш унган, иренә дә тик торырга ирек бирми торган, әмма түшәккә яту белән изрәп китеп, күкрәгенә кул салуга кәжәләнә башлый торган хатыннар турында... Ир затына нишләргә? Ургылып торган дәрт-назны кая куярга? Сатлык кызлар янына барыргамы? Ләкин кая бездә андый ышанычлы урыны да, кая анын чистарак, рәтлерәгенә түләрлек акчасы?

Андый зарларны тынлаганда, Мидхәтнен чыраенда тиенкы елмаю гына кабына иде.

—Ә синен ничек сон? Ник бер дә дәшмисен?

—Зарланырлык түгел...

—Әллә ярап бетә аласынмы?

—Сон, тырышам инде.

—Тырышып нишлисен?

—Өйдә ярдәм итешәм... Ул өлгермәгәндә бала керләрен юам...

Моны ишеткәч, ирләр бераз сүз таба алмый аптырашып тордылар. Бер мәлдән берәүсе үзалдына мыгырдагандай:

—Бала керен иреннән юдырткан хатынны мин аны...—дип куйды. Икенчесе түшәмгә төтен өреп:

—Алай димәгез,—диде.—Керен юарга да риза булырсын, иләнен дә! Сонрак теге мәсьәләдә генә татлы булсын. Төн аралаш дигәндәй үз хатынынны тотып көчләргә туры килсәме? Андыйдан яманы юк!

—Без бит үз хатыннарыбызга сатлык хатыннарга караганда чагыштыргысыз күбрәк түлибез, ник өйләнеп маташабыз икән?—дип уфтанып куя шунда берәрсе.

Мидхәт башын иеп, кружкасына текәлгән иде. Эче тулы зар булса да, тәмәке сасысына туенган бу ямьсез бинала, кыршылган, таплы өстәл янында, тупас ирләрнен йонлы колагына түгә торган түгел иде. Күнел ярасына тәмсез телләрдән затсыз сүзләр сибелүен теләми иде ул. Чыраена бәреп әйткәннәре

юк, әмма аның артыннан, хатынының итәк астына кереп беткән, шуннан көн күрә, дип сөйләп йөргәннәре сизелә иде. Андый ирләрне ил мактамый шул инде. Әгәр йортта хатын баш икән, аны кешегә белгертергә һич ярамый.

—Ул инде, корешлар, хатыннарның явызлыгы борынгыдан килә,—диде гадәтенчә шук елмаеп Рәмис.—Юлий Цезарь әйткән, ди, әнә, ил каршында нинди генә бөек шәхес булып саналсаң да, өенә кайткач аңгыра, надан булып каласың, чөнки мең гаебең табыла, дигән ди.

Рәмис китап укырга ярата, шунлыктан башкалар янында белемле, мәгълүматлы булып санала. Һәммәсе дә, кружкаларын куеп, аңа текәлделәр.

—Әле менә гәзиттә бер гыйбрәтле мәкалә укыдым. Исеме дөньяга танылган галим-академикның өенә бер рәссам килгән икән. Портретын ясарга. Каршысына җайлап утырткан тегене, үзе мольберт артына баскан. Художниклар бит алар эш арасында сүз куертырга ярата. Кешенең эчендә ни ятканын беләсе килә. Соңгы вакытта фән кешеләре политикага кысылуны мода итеп алдылар бит. Бу галим дә зур политик буларак танылды. Рәссам ул инде фәнне тирән аңламый, политиканы исә барыбыз да беләбез. Боларның да сүзе думага, партияләргә авышкан. Шунда теге карт: «Мин политика белән кызыксынмыйм»,—дип әйтеп ташламасынмы! Шул тирәдә тыңланып йөргән карчыгы килгән дә учы белән шалт тегенең пеләшенә! «Ничек кызыксынмыйсың? Без демократия өчен көрәшергә тиеш! Бөтен көчебезне биреп!»—ди икән. Художник телсез калган! Шулай булмый ни! Бөтен Рәсәй халкы Алла урынына санап йөргән кешенең башын хатыны дөмбәсләсен әле! Ярый, бусы ялгыш кына булгандыр, дип уйлап, берничә минуттан тагын сүз башлый бу. Менә бездә Американы мактыйлар, үзебез кылганнарны салып таптыйлар, ди икән. Галим ык-мык килгән, хатыны янә моның пеләшенә чәпегән. Әңгәмә шул рәвешле бара, рәссам сүз арасында мольбертына сызгалый икән. Бераздан теге чәүчәләк хатын ул сызгалаганга күз салса, ни күрсен! Анда моның чырае акаеп карап тора икән. Убырлы карчык кыяфәтендә. «Бу ни?»—дип акырган ул. «Мин монда ил агасының портретын ясарга килгән идем, идән чүпрәген түгел»,—дигән художник.

—Шуннан? Оят булмаганмы ул хатынга?

—Хатыннар азса, оятны беләмени!

—Андыйлар турында минем әби: «оят дигәннең о хәрефен дә белми»,—ди торган иде. Ул шулайрак сөйләшә иде мәрхүмә.

—Ә соң академик нишләгән?

—Бернишләмәгән. Андый хәлгә төшсәң, нишли аласың...—дип мыек астыннан елмаеп куйды Рәмис.—Хатын теге художникны пырылдатып куып чыгарган. Шул.

Аннары Мидхәткә борылды да, мәгънәле итеп:

—Укы әле син аны!—диде.—Бездә булырга тиеш ул. Хатын чүпкә чыгарып атмаса...

Сыра янына бер йөз граммны да кушып җибәргәнгә күрә, ул шактый кызды. Коңгырт күзләре майланды, кара мыегы тырпайды. Шаян сүз арасында Мидхәтнең колагына пышылдап алды:

—Синең заначкада тагын бераз калмадымы анда?

Бер башлагач, тыела алмый торган гадәте бар иде шул бу җор телле, ачык чырайлы егетнең.

Мидхәт аны җайлап-көйләп алып чыгып китү ягын карады. Калдырып булмый: үз кеше, гаилә дусты дияргә була. Бер заводта эшлиләр, күрше булып диярлек яшиләр. Рәмисләрнең җиде айлык уллары бар, шунлыктан, хатыннар да якыннан аралаша.

Ул исә өенә ашыкмый иде, ишек төпләренә кайтып җиткәч тә Мидхәтнең җиңеннән тотып, җибәрмичә шактый сөйләнеп торды.

—Сон инде,—диде Мидхәт.

—Ә нәрсә вакыт санап яшәргә безгә? Күз ачуга сәгатькә кара, заводта минутлар сана... Эштән сон да санаргамы әллә? Ир-егет хөр булырга тиеш!—дип бармагын ишек өстен ышыклап торган шыксыз бетон плитәгә төбәде ул.

—Әнә, хатыннар санасын! Вакытын да, акчасын да, башкасын да. Алар янына ашыгып кайтырга ярамый, кореш! Сагынып каршы алсыннар! Көтә-көтә зарыгып, елап бетсеннәр. Хатын-кызнын йөрәк хисләре ачы күз яшьләре белән юылса, янарып, ялтырап китә! Ул бәргәләнсен-өзгәләнсен, ә син нык бул! Хатынга башны да, йөрәкне дә бирергә ярамый!—Бу урында Рәмис шап итеп мангаена сугып куйды, аннары каты итеп кукрәгенә бәргәләде.—Монысына да, монысына да үзен хуҗа булырга кирәк. Җебеп төшсән, аяк асларында чүпрәк булсан, калерен калмый. Янып көл булсан да, ах, бәгырем, харап була күрмә, димәячәк, төтенен күзгә керә, дип тиргәячәк. Алар белән беркатлы булырга ярамый. Бер кулыннан чыбыркынны төшермә, икечесендә прәннек тот. Вакытын белеп, ярсан, аннары бераздан прәннек каптырып, кочагына алсан, менә шунда була анын өчен оҗмах. Анысы, вак-төяк өчен бәхәсләшергә дә кирәкми. Елга яна, ди икән, ие шул, бәгырькәем, мин дә күрәм янганын, диярге кирәк. Күнеле булсын! Ә зурларын әйтергә ярамый. Ю-ук, ярамый, кореш!

Мидхәт, подъезд ишеген ачып, Рәмисне эчкә сөйрәде дә, биленнән кочаклап, өченче катка алып менде, ун ишек янагындагы кыңгырау төймәсенә төртте. Бераз көткәч, бармакны төймәгә басып озаграк тотты, эчтән сузынкы зангылдау ишетелде, әмма хәрәкәт сизелмәде. Бу гаҗәп тоелды. Рәмис сүзенә ышансаң, хатыны аны көтә-көтә көтек булып беткән, күз яшьләрен түккән булырга, кыңгырау тавыш бирүгә, ишекне кин ачып, хәләл җефетен кочагына алырга тиеш иде бит югыйсә. Ә монда...

Ниһаять ишек ачылды, вак чәчәкле зәңгәр халат кигән хатынның сыны бусагага аркылы басты, куе чәче астыннан күзлек пыялалары хәтәр ялтырады. Ул, Мидхәтнең сәламен дә алып тормыйча:

—Ник китердең син моны?—дип Рәмискә таба йомры ияге белән ымлады. Мондыйны һич көтмәгән Мидхәт югалып калды.

—Син нәрсә, Рәйсә... Бу хәлендә урамда калдырыйммыни? Айныткычка алып китсеннәрме әллә?

—Кайда эчкән булса, шунда айнысын иде,—диде Рәйсә.

Рәмис нидер мыгырдый калды, Мидхәт, борылып, баскычтан аска йөгерде.

• • •

Заводта, Рәмисне тәэминат бүлегендә туган көне белән зурлап котлаганнар икән, дигән сүз колакка чалынды. Эштән кайтканда Мидхәт, Рәмисне очратып:

—Дус булып йөргән буласын, туган көненә кунакка да дәшмисен,—дип үпкә белдереп куйды.

—Нишләп дәшмәсен! Шимбә көнгә ниятләп куйган идек. Әйтергә генә өлгермәдем, авызымнан тартып алдын! Икегезне генә чакырабыз, саф татарча сөйләшеп, җырлашып утырырбыз рәхәтләнеп!

Табында чыннан да алар ике генә пар иделәр. Дуслык өчен бер-икене күтәреп, Рәйсә пешергән токмачлы аш, гөбәдия белән нык кына сыйланып алгач, өстәл яныннан кузгалдылар. Лениза белән Мидхәт иркен кәнәфиләргә күчеп урнаштылар, Рәйсә диванда ике баланы—Рамилә белән җиде айлык Илдусны уенчыклар белән юатырга керештe. Рәмис бакыр бакалы кечкенә гармунын кулына алды да:

—Мондыйлар юк хәзер, миндә генә,—диде.—Фатих Кәрим язган

кыңгыраулы яшел гармун бу, кореш. Безнең татар җырлары өчен шуннан иплесе юк инде. Күтәреп йөрергә дә җиңел.

Һәм кычкырып җырлап җибәрде:

«Хәтердә ул тыныч, айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы...»

Аңа хатынының күңелгә ятышлы, йомшак тавышы кушылды. Парлашып еш җырлыйлар, күрәсең, тавышлары бик тә яраша, икесе бердәй хисләнгәннәр. Рәйсәнең Рәмискә таба авышкан гәүдәсендә, алланып чыккан түгәрәк бит очларында, хәтта күзлек пыялаларының елтыравында да башын гармунга иеп утырган ире белән соклану, бәхете белән мактану, хәтта бераз масаю ярылып ята иде. «Карагыз, күрегез, менә без нинди матур пар!»—ди иде аның бөтен кыяфәте.

Менә җыр тәмамланды, Рәмис башын күтәреп, гармун күреген нык итеп кысып куйды.

—Хәзер дә җырларның бик шәпләре ишетелә радиодан,—диде.—Кайсылары еш яңгырый, күңелгә кереп кала. Ишеткәнегез бармы?

Һәм ул гармунын тезендә биетеп, башлап җибәрде:

«Күл буенда ялгыз аккош, каерылган канатлары...»

Гади генә сүзләр... Җиңел генә көй... Ләкин ник соң күңел кылларын болай сызландырып тибрәтә?

«Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре,
Канатларны каера ул аерылу сәгатьләре...»

Ачылды күңел бакчасының капкалары, сайрады гөлләргә кунып сандугачлары... Лениза, керфекләрен кыса төшеп, хисләрен бүлешергә теләп, Мидхәткә борылып карады. Һәм...өстенә салкын су коелгандай бөрешеп китте.

Мидхәт авызын ерып, бөтен гәүдәсе белән алгарак авышып, Рәйсәгә текәлгән иде. Йөзендә шундый соклану, шундый хозурлану! Ә Рәйсә... ике кулы белән баш очына улын күтәргән дә, елмаеп ана текәлгән.

Нәрсәсе бар? Нигә селәгәе аккан бу Мидхәтнең? Аның беркайчан да үз хатынына болай итеп онытылып караганы юк бит! Һәрхәлдә Ленизаның моны сизгәне юк!

Бу уй, көнләшү хисе бәгырьгә пычак белән сызгандай итте. Ә бәлки, алар арасында нәрсәдер бардыр? Лениза белән Рәмис кенә сизми йөриләрдер?

Ләкин Рәмис берни күрми, башын гармун күрегенә терәп, шыңгырдатып ниндидер көйне исенә төшерергә азаплана иде. «Ахмак!—дип, нәфрәт белән карады аңа Лениза.—Борын төбеңдә хатынына кармак салганнар, ә син!..»

Рәйсә кинәт нидер сизгәндәй, баланы тезенә бастырды, башын иеп, башта Мидхәткә, аннары Ленизага карады. Кызганыч, калын пыялалар аша күзләрен күреп булмады...

Лениза көчәнеп чыраена елмаю галәмәте чыгарды. Кунакта чакта ирен белән әйткәләшеп булмый бит инде... Мәҗлес үз тәртибе белән барды: тагын берничә җыр җырладылар, туган якларны сагынып искә алдылар, чәй эчтеләр.

Әмма өйгә кайтып, арган-талган баланы йоклаткач, өске утларны сүндереп, кызыл торшерны кабызгач, өстен алыштырганда, Лениза эченә җыелган ачуын чыгарды.

—Күрше хатыннарына күз сала торган гадәтең барын монарчы белми идем

әле,—диде ысылдап.

Мидхәт анын сүз төбен анлады, кызарынып чыкты. Шунын белән хатынынын шиген раслады да куйды. Ә үзе:

—Мин ана түгел бит...—дип мыгырданды.

—Ничек инде ана булмасын... Тасыраеп утыра идең бит дөньяңны онытып! Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә, диләр...

—Мин бит ана түгел... Дөресрәге, үзенә түгел...

—Ә кемнен үзенә?!

—Анда ракурс шундый иде... Фактура... Яктылык... Сәнгать әсәрендәге кебек...

—Шулаймыни-и?! Ракурсы удачный булдымыни? Монарчы андый фактураны күргәнен юк идемени?

—Кайсыдыр рәссамның портретын хәтерләтте ул миңа... Мадонналарны шулай ясыйлар. Юкка үпкәләмә... Картиналарга сокланып караган кешене тиргәп булмый бит инде. Музейга барырга да рөхсәт итмәс идеңме әллә?

—Сина музейдагылар гына житмәс шул... Сина тереләре кирәк!..

Китте-китте, ишелде жәнжал ташкыны... Хатын кычкырынды, ир телен аркылы тешләде, бала уянып, еларга тотынды...

Ниhаять, хәлдән таеп, тынып калгач, утлар сүндерелгәч, Мидхәт аш бүлмәсенен идәнендә, инде күнегелгән юка сырмада уйланып ята иде. Ул янадан Рәйсәне күз алдына китерде. Сокландыргыч иде шул! Атаклы рәссамнарнын картиналарындагы кебек. Баш очында кети-кети көлеп тибрәлгән йомры ак тәнле сабый мәхәббәт алласы төсле иде. Мидхәтнен карашы аскарак, ананын чиксез сөю белән балкыган йөзенә, йомшак муенына, сөттән тулышып торган күкрәкләренә күчте. Һәм, гөнаh шомлыгына каршы, анын бөтен тәнен күз алдына китерде. Атаклы рәссам Рембрандтның «Даная» картинасындагы төследер ул. Кичләрен, утлар сүнеп, ятарга әзерләнгәч, сөю-назга сусаган тәнен Даная кебек калкыта микән? Бәлки, ана шул минутларда тәрәзә аша ай нуры сузыладыр? Анын бу омтылышында, зарыгып көтүендә якты, кайнар хис бар, әмма чамасыз нәфес, комсызлык дигән нәрсә юк. Фәкать иң тыйнак назнын да кадерен белү, башыннан сыйпаудан гына да олы ләззәт алырга әзерлек бар...

...Ә бит Рәйсәне искитәрлек чибәр дип булмый иде. Шәhәр урамнарында йөргән хатыннарның яртысы шундый. Холкы-табигате белән дә чәчрәп күзгә керми, күктән йолдыз чүпли торганнардан түгел. Ул фәкать бар булганнын кадерен-тәмен белеп яшәп торган хатын.

Мидхәтнен гаиләсенә нәкъ менә шул житми иде. Менә нилектән сокланып, кызыгып карады ул Рәйсәгә! Һич тә өзелеп гашыйк булганнан түгел!

...Кемнәрдер әйтер: көнләшүгә сәбәп бирмәскә кирәк, дияр. Әгәр дә синен бер карашын, ихтыярсыздан йөзенә бәреп чыккан елмаю галәмәте көнләшү дигән күсене котыртырга сәбәп була икән, моннан котылу чарасы бармыни? Күнелгә бер кереп ояласа, син инде ул ерткычны ансат кына куып чыгарам димә. Вакыт-вакыт тынып-посып торса да, жай туры килгән саен уяна да, эчтән кимерә башлый, адәм баласын үрле-кырлы сикертә ул. Хәнжәрдәй тешләрен авыр сүзләр рәвешендә авыздан чыгарып, ин якын кешеннен бәгыренә кадый.

• • •

Мондый хәлгә юлыккан парларнын күбесе күрше белән аралашуны туктата. Ленизанын да башына килгән беренче уй шул булды.

Ләкин, төрле ягын уйлап карагач, ул бу фикереннән ваз кичте. Чөнки бер нәрсәне анлады: хикмәт Рәйсәдә түгел, Мидхәттә. Әгәр дә ир кеше читтән юаныч эзли башлаган икән, барыбер үзенекен итәр: берсе белән

очрашырга мөмкинлеге булмаса, икенчесен табар. Ни генә дисән дә, бусы күз алдында әле. Әгәр син белмәгән берәрсе белән бәйләнсә? Мәңге эзенә төшә алмассың! Шуны яхшы аңлаганга күрә, Лениза өйдәгене тышка чыгармады, күршесенә йөзен бозмады, араларны өзмәде.

Көннәрнең берендә, Рәйсә, аларга кереп:

—Әнисенең үлгәненә биш ел тула, ирләр эштә чакта хатыннарны гына җыеп, Коръән ашы үткәрәм әле,—диде. Аннары бик тә мәгънәле итеп:—Фирдания үзе килә!—дип өстәде.—Сәгать өчкә кер, яме!

...Затлы нигъмәт тулы озын өстәл тирәли тыгызланып утырган унбишләп хатын-кызның күбесе карчыклар иде. Башларында ука белән чигелгән ак яулык, сулган йөзләрендә тыйнаклык, сабырлык. Күбесе үзара таныш булса кирәк, шыпырт кына хәл-әхвәл белешәләр, туган-тумачаларын сорашалар. Сүзләр күңелне төшерә торган: кемдер үлгән, кемдер эштән куылган... Аерылышкан... чирләгән...

Яшь кеше буларак, Лениза ишек төбендәрәк утырды. Аңа сүз кушучы булмады, үзенең дә ятлар белән сөйләшәсе килмәде. Шома чәченнән әледән-әле шуып төшкән күксел ефәк шарфын төзәткәләп, табындагы әфлисун-алма, җимеш тулы савытларга күз йөгерткәләп хәрәкәтсез утырганга, вакыт бик әкрен узды, зарыктырды. Ә дога укуны һаман башламыйлар да башламыйлар. Ниһаять, Рәйсә, аш бүлмәсе ягыннан кереп:

—Нишләптер, Фирдания соңарды бит әле,—диде.—Сәгать уникегә ашка барасым бар, шуннан туры монда киләм, дигән иде. Һаман күренми. Берәрегез укый торасызмы әллә?

—Юк инде, көтик. Фирданиядән узып булмый...

—Аның кебек булдыра алмабыз шул,—диештеләр карчыклар.

—Адресны буташтырмады микән? Чыгып каршы аласызмы әллә?—диде берсе.

...Кинәт кемдер ярым пышылдап:

—Килде...—диде.

Сүзләр өзелде, сыннар турайды, карашлар ишек тарафына төбәлде. Лениза да башын борды. Ким дигәндә сиксән яшьлек бөкерәйгән кортканы күрермен, дип уйлаган иде ул. Ә анда...

Анда озын буйлы, төз гәүдәле, урта яшьләрдәге хатын кереп баскан иде. Чибәр идеме ул? Һич юк. Эре сөякле, зур башлы. Озынча йөзен тукмак борыны бозып тора... Ләкин бер күргәч онытыла торган да түгел үзе. Озын итәкле һәм җиңле, ябык якалы, ачык яшел костюмы бик тә заманча тегелгән, андыйны мөслимәләр генә түгел, европа кызлары да кия ала. Яшел яулыгы башына шундый пөхтә итеп уралган, сәхнәдә яңа киемнәрне күрсәтүче кызларга—манекенщицаларга да килешер иде... Алай да хикмәт аның киемендә түгел, кыяфәтендә, басып торышында иде. Затлылык, үз кадерен белү, шул ук вакытта башкаларга сак игътибар бөркелә иде аннан.

—Әссәламәгайләйкүм, кардәшләр!—диде ул бераз калынрак, әмма йомшак җылы тавыш белән.—Кичерегез, бераз көттердем.

Һәммәсе шаулашып торып бастылар һәм:

—Сине алай гына көтәбез инде... Килүеңә рәхмәт...—диешеп, түргә уздырдылар.

Ленизаның икеме-өчме тапкыр гына Коръән ашында булганы бар һәм алар аның күңелендә шактый монсу тәэсир калдырган иде. Абыстайлар гадәттә догага керешер алдыннан озын итеп вәгазь укый, бер тотынгач, туктый алмый. Сүзләре һаман бер үк нәрсәләр: ата-ананы хөрмәт итү, фәкыйрьләргә сәдака бирү, чисталыкны саклау зарурлыгы, бишвакыт намазның фарызлыгы турында... Аларның озынга сузылган нотыгы Ленизаның эчен пошыра иде.

Бу да шулай күп сөйләп, тәмам гарык итәр микән?

Фирдания урынына урнашып, кыска гына дога кылды да, табынны елмаеп күздән кичерде.

—Ягез әле, борчуларны, кайгы-хәсрәтләрне онытып торыйк,—диде.—Өстән безгә Рәйсәнең анасы Хәтирәттәйнең рухы карап тора. Аның тирәсендә барыбызның да газизләренең рухлары. Алар һәммәсе дә шат. Чөнки без аларны искә алырга жыелдык. Якты, тыныч күңел белән башлыйк. Әгузе билләһи мина шайтан ирражим, бисмилләһи...

Фирдания Коръән сүрәләрен дә бик тә җайлы итеп, көйгә салып укый, сүзләре аңлашылмаса да, бер дә ялыктырмый икән...

Сүрәләр укылып, догалар кылынып, табындагы нигъмәтләр белән сыйлана башлагач, дөнья хәлләре турында сүз китте. Фирдания бу шәһәрдәге татар җәмгыятенең оештыручысы да икән әле. Казан белән элемтә тота, мөмкинлеген табып, аннан төрле вәкилләр, артистлар чакыруны оештыра.

—Артистлар килгәндә гафил булып кала күрмәгез, безнең белән элемтәне өзмәгез,—диде ул.

Мәҗлес тәмамланып, дога кылгач, һәммәсе дәррәү урыныннан кубып, алгы бүлмәгә чыккан Фирданияне уратып алдылар. Кайсы ашка чакыра, кайсы догалыклар сорый, кайсы мәчеттә дәресләрнең кайчан буласын белешә. Ике кулыннан, чабуыннан тотып алганнар, жибәрмиләр генә. Менә нилектән бирегә дә соңга калып килгән икән ул!.. Барган жиреннән жибәрми интектерәләр икән аны!

Бу галәмәтне читтәнрәк күзәтеп торган Ленизa кызыгып куйды. Аның үзен беркайчан да бу кадәр кирәксенгәннәре юк иде шул...

Ниһаять, соңгы кунак артыннан ишек ябылгач, ул Рәйсәгә табын жыештырышырга каласы итте.

—Бу Фирданиягә бал сыланган диярсең, һәммәсе ябышырга гына тора,—дип башлады ул сүзен.

—Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар, дигәннәре дөрес шул,—диде Рәйсә тәлинкәләрне сулы табакта чайкаган арада. Ярый әле күтәрелеп карамады, күршесенең йөзе тартышып куйганын күрмәде. Лениза тамагына килгән ачыны йотып:

—Абыстайга бер дә охшамаган үзе,—диде.—Урамда очратсам, артист икән бу, дияр идем. Коръәнне каян өйрәнгән соң ул?

—Әбисеннән, аннары әнисеннән. Әбисе патша заманында абыстайлардан укыган аның. Анасы, паралич сугып, бик озак урын өстендә яткан, үлгәненә ике генә ел икән әле... Ул Фирданиянең күргәннәрен дошманына да язмасын. Лениза аптырап китте.

—Кыяфәтенә карасаң, бик бәхетле кебек бит үзе!

—Үзен бәхетсезгә санамый ул! Анасын берара апасы алып киткән булган икән дә, тиешенчә тәрбияле алмаганнар. Үзләре эштә чакта, карчык караваттан егылып, исән кулын да имгәткән. Хастаны бит аны бик белеп карарга кирәк. Уң ягы бөтенләй йөрмәгән, сул кулы белән алырга җайлы булсын өчен, ана кирәкне Фирдания караватт янындагы урындыкка билгеле бер тәртип белән тезеп куя торган булган. Ә тегеләр җаен белмәгәннәр. Әби су алырга дип үрелгән дә, әйләнеп килеп төшкән. Ник элегрәк барып алып кайтмадым икән, дип үкенеп туймый Фирдания.

—Кияүгә чыкканмы соң ул?

—Берәү белән никахланышкан булган. Тик анасын ташлап чыгып китә алмаган. Ә иреңең хаста карчык белән бер фатирда яшисе килмәгән. Шуның аркасында Фирдания беренче баласын төшергән, дигән сүзләр йөри.

—Шулаймы-ыни!..

—Шуннан соң бала таба алмый булып калган, диләр.

—Ире белән торалар микән соң?

—Юк инде! Тегесе каядыр китеп барган.

Ленизаның күз аллары томаланып китте. Әле генә ялктырып балкыган ай тотылгандай булды...

—Хәзер ялгыз яшиме?—дип сорады Лениза.

—Анасы үлгәч, бер ир белән никахланышкан. Тегесенең хатыны үлгән, өч баласы бар.

—Кеше балаларын тәрбияләргә калган икән алайса.

—Ул аны авырга алмый. Киресенчә, Ходайның рәхмәте дип кабул итә.

Юеш тәлинкәләрне коры тастымал белән сөртеп торган Лениза, эшеннән туктап, Рәйсәгә текәлде:

—Анасы үлсә дә, авырга алмый, ире ташлап чыгып китсә дә, баласыз калса да... Ул ничек була инде?

Рәйсә дә эшеннән туктады, башын күтәреп, күзлекләре аша көлемсерәп ана текәлде:

—Хак тәгаләгә чын күңелдән ышанганга шулай,—диде.—Син белмисеңмени: иманлы кешеләргә яшәү җиңелрәк бит.

—Кая җиңел? Чир-чор, кайгы-хәсрәт дигәнең дин тоткан кешеләрне дә әйләнеп үтми. Аларның да башына төрлесе килә.

—Дога кылып кына бәла-казадан котыла торган булса, ул инде Алланың рәхмәтен сатып алу булыр иде. Чын күңелдән ышанган кешенең рухы нык була, шуңа күрә кайгыларны ул җиңелрәк кичерә. Чөнки үзен беркайчан да ялгыз хис итми. Ходай миңа юлдаш, ди. Хәер, Фирданиянең ялгыз булганы юк та. Абруе бик зур бит. Мәчет салганда да хезмәте күп кергән. Дин сабакларын да күбрәк ул укыта. Мулла итеп куярлар иде—итәге комачаулый... Күптән түгел яхшы гына йорт салып бирделәр үзенә. Байлар әйтә, шундый мөхтәрәм кешене тыгынлыкта яшәтү гөнаһ, диләр.

—Шөгыле доходлы икән үзе,—дип чәнчеп алды Лениза.

—Бу шәһәр өчен ул үзе зур табыш! Мәчеткә барып егылмаган кеше сирәк. Ахыр чиктә берәүнең дә йомышы төшми калмый.

—Син үзең дә абыстай кебек сөйлисең,—дип куйды Лениза.

Рәйсә көлеп җибәрде:

—Укытучы ич мин, элеккечә әйткәндә, шул ук абыстай... Алай да Фирданиягә җитеп булмый. Кая-а-а! Мәчеткә дә ике-өч кенә тапкыр кергәнем бар. Әмма иманым калбемдә!—Рәйсә юеш кулын күкрәгенә куйды.—Әгәр Ходайга ышанмасам, газиз әнкәемне бүген ничек искә алыр идем?.. Имансыз яшәп булмый! Мин болай уйлыйм: атам-анам миңа кан, җан биргән, исем, тел биргән. Алар миңа иманын мирас итеп калдырган. Канны үзгәртү мөмкин түгел. Исемне дә, туган телне дә алыштырып булмый. Дин дә шулай уктыр, дип уйлыйм. Аллага ышану—ул мәхәббәт кебек бит. Яраткан кешеңнең бу ягы яхшы, бу ягы җитешми, дип уйламыйсың. Фәкать яратасың гына. Чын күңелдән ышанган кешенең Ходайга мөнәсәбәте мәхәббәт белән охшаш. Аерма шунда: кешегә булган мәхәббәтнең ялкыны вакыт узу белән сүрелә. Иман әһеленең раббысына булган хисе—сүнми-сүрелми, ул гомерлек. Фәкать уңга-сулга карамыйча, икеләнмичә-шикләнмичә ышанырга гына кирәк.

...Бу табын, аннан соңгы сөйләшү Ленизаның бәгыренә шырпы кадагандай итте. Бу шырпы—шул ук көнләшү иде. Фирданиядән көнләшү иде бу. Кара син аны: әбисеннән-әнисеннән өйрәнгән догаларның рәхәтен ничек күрә, ә! Югары белеме дә юктыр әле, мөгаен. Анысын сорарга башка килмәгән. Төскә-биткә дә Ленизадан артык түгел бит үзе. Нишләп ул шулай кеше арасында кайнап, шул ук вакытта җан тынычлыгы белән яши, ә Лениза үзенә тынгы таба алмый, эчен туктаусыз яндырган сагыштан башын кая куярга белми?..

Ленизаны балачактан догалар укырга өйрәтүче булмады, бар белгәне «бисмилла» белән «аллаһе әкбәр»дән артмады. Анысын да күрше-күлән әбисәбидән генә отып алды. Чөнки үз әбисе партия члены, алар яшәгән кечкенә шәһәрнең активисты булган, халыкка атеистик тәрбия бирүдә катнашкан, ягъни дингә каршы көрәшкән.

Дөрес, коммунистлар хакимияте җимерелгәч, дин тоту, мәчеткә йөрү мактаулы гамәл булып санала башлады. Элеккеге коммунистларның шактые койрыкны бик тиз борып салды да, хатын-кыз женесеннән булганнары башына яулык урап, ир-ат кәләпүш киеп, мәчет тирәсенә сырышты. Иң өлгерләре хажга барып, дөнья күреп тә кайттылар. Бер ишенә мондый бәхет бөтенләй бушка тәтегән, аларның сәяхәтенә акчаны гарәпләр биргән, диләр. Элеккеге кызыл авыз коммунистлар хаҗи-хаҗия булып йөри хәзер.

Соңгы елларда Ленизаның әбисе дә бисмилласыз ашарга утырмый, дога кылмыйча табыннан кузгалмый. Догаларны ана ата-анасы өйрәткән. Балачакта хәтергә сеңеп калган нәрсә онытылмый, онытылса да, кирәк чакта бик тиз искә төшә шул. Хаҗга барырга да җай тапкан булыр иде әбекәй, чире җибәрми...

Ничек болай үзгәрде соң әле ул?.. Нәрсә диде әле бүген Рәйсә? Аллага ышанган кеше ялгыз булмый, дидеме? Ялгызлыктан котылу чарасын тапкан әбекәй...

Ә менә Ленизага ялгызлыктан ничек котылырга? Ире янында булса да, асылда ул да ялгыз бит... Өстәвенә башкалардан түбән кеше, ким кеше... Төшеп калган, дияргә була...

...Шул көннәрдә Ленизага янә бер эш тәкъдим иттеләр—заводның бер лаборанты бала тапкан икән дә, шуның урынында эшләп торырга. Инженер да түгел, технолог та, нәкъ менә лаборант булып. Үзен кебек югары белемле кешеләрнең йомышын үтәргә... Ул да вакытлыча...

Кызыгырлык түгел иде бу. Өйдә бер килешеп, бер тешләшеп яшәп яткан чаклары иде, кичен Лениза бу эшкә дә күңеле тартмаганын әйткәч, Мидхәт читкә карап:

—Яхшырагы юк бит әле,—диде.—Эшләп кара. Ошамаса, чыгып китәрсең...—Аннары, үзалдына уйлангандай:—Өйдә тик яткан хатыннарның башында таракан үрчи, диләр,—дип куйды.

Лениза пырлый башлагач, каршы әйтмәде үзе. Химия буенча яңа чыккан журналлар алып кайткан икән, баш-аягы белән шуларга чумды. Күзенә аккара күренми, һаман шул Норвегия галимнәре белән узышуында иде ул.

...Кышкы аяз бер көнне Лениза Рамиләне чанага утыртып, һава суларга алып чыккан иде. Мидхәт, шимбә булуга карамастан, эшенә китте, ә хатын иренең бу рәвешле чамадан тыш эшем кешесе булып кылануын өйдән чыгып качарга бер сылтау гына дип уйлый иде. Тротуарда әрле-бирле арба тартып йөргәндә, аның күзенә кояшта ялтырап яткан кар да, ак бәс сарган агачлар да күренмәде, чөнки эче поша иде.

Менә күрше подъезд каршына куе зәңгәр төстәге «Рено» килеп туктады. Аның алгы ишегеннән саллы гәүдәле, пөхтә киенгән урта яшьләрдәге ир кеше төште дә, арткы ишекне ачып эчкә кулын сузды. Ә аннан.. Аннан... Иң кәттә кызлар гына кия торган яшел төстәге кайры тун кигән, ак шәл бәйләгән... Фирдания килеп чыкмасынмы! Нинди ханбикә диярсең!

Корьән ашыннан соң Ленизаның бәгыренә калалып калган шырпы кузгалып, түзә алмаслык сызландырып чәнчи башлады... Нишләп бу хатын шулхәтле абруйлы да, нишләп Лениза болай түбән? Мәчет шулай күтәрәме әллә кешене?

Ул арбаны дыңгырдатып, трамвай тукталышына китте.

...Карагай бүрәнәләрдән төзелгән ике катлы мәчет шәһәрнең читендә,

борынгыдан калган агач йортлар арасындагы бушлыкта әллә каян күренеп тора иде. Трамвайдан төшкәч, күз күреме киңәеп, сулыш иркенәеп китте. Кар белән ышкып агарткандай, күк гөмбәзенең бер ягында кечерәеп-тыйнакланып калган кояш тәлинкәсе эленеп тора, аны киң генә нурлы бождра уратып алган. Аңа үрелгәндәй, мәчетнең нечкә манарасы очында урактай ай елкылдый.

Эче илаһидыр бу бинаның, юшкын баскан күңелләрне тазартырлык, тынгы белмәгән җаннарга ял бирерлек тылсымлы көч бардыр анда. Бер кулына Рамиләне күтәреп, икенче кулы белән арбасын тартып, киң баскычтан кызгылт-сары такта ишеккә таба менгәндә, Лениза нык дулкынланган иде. Тирән сулыш алып, авыр ишекне ачты... Шыгырдаган тавышны ишетеп булса кирәк, эчке өч ишекнең берсеннән, сул ягтагысыннан, башына чәчәкле шәл бәйләгән, бөрешкән чырайлы, кечкенә буйлы карчык килеп чыкты. «Исәнмесез» дигәнгә «вәгаләйкем әссәлам» дип җавап биргәч:

—Ни йомыш?—дип сорады.

Кулына бала күтәргән Лениза аптырабрак калды: ничек дип әйтергә?

—Сәдака бирәсе итсәң, менә монда сал,—дип, карчык диварга беркетелгән тар авызлы калай савытка күрсәтте.—Әрвахларыныңың исемнәрен язып алып килдеңме? Юкмыни? Хәзрәт Коръән чыкканда язганнарның һәммәсен телгә ала, берсен дә калдырмый. Монда язсаң да була, кәгазь-каләм бирермен.

Нинди әрвахлар?! Ленизаның йомышы бөтенләй башка лабаса.

—Мин... Карап чыгарга мөмкинме?

—Аяк киеменне алыштыр.

Карчык кырыйда тезелеп киткән эреле-ваклы башмакларга ишарәләде һәм уртадагы ишекне киң итеп ачып куйды.

Лениза Рамиләне идәнгә бастырып, итеген салды, башмак киде дә, кызын җитәкләп, бусагадан эчкә атлады.

Бинаның эче өч ягтагы зур тәрәзәләрдән төшкән яктылык белән тулган. Диварларында гарәп хәрефләре белән сырланган такталар эленеп тора. Идәненә тоташ келәм җәелгән иркен зал буп-буш, фәкать каршыда ике ягына култыкса ясалган кечерәк кенә күтәренке урын бар.

Арттарак торган карчык Ленизаның нindiлеген чамалаган иде инде. Гомерендә беренче тапкыр мәчет бусагасын атлаган бер ул гына түгел... Әбекәй аңлатма бирүне кирәк тапты:

—Анысы мөнбәр, җомгада, гает көннәрендә мулла абзый шунда басып вәгазь укый,—диде.—Кәгъбә шул ягта.

Лениза аптыраушта иде. Фәкать шушы гынамы? Ә кая тылсымлы көч?.. Лениза бередә үзен эчтән ныгып киткәндәй итеп сизми, киресенчә, югалып калгандай тоя иде. Чит-ят иде аңа бу мохит...

Ул кире өйалдына чыгып, итекләрен киеп азапланганда, тышкы ишектән салкын буга уралып, каракүл тун, шундый ук каракүл түгәрәк бүрек кигән, кечерәк кенә буйлы, түгәрәк битле, кыска сакал-мыеклы, утыз бишләр тирәсендәге кеше килеп керде.

—Әссәламәгаләйкем!—диде көр тавыш белән.—Ходаөүенә килдеңмә? Хоп, хоп, мәйле!

Ленизаның колакчынлы күксел кеш бүреге эченнән бүселеп чыккан чәчләренә, түшенә озын булып салынып төшкән зур ак шарфына елтыр күзләренең карашын бер генә сирпеде дә, уң ягтагы ишектән кереп китте.

—Хәзрәтебез шушы инде безнең,—диде карчык.

—Ни диде ул?

—Мәчеткә килеп дөрес иткәнсең, дип әйтте...

—Нинди телдә сөйли соң ул?

—Үзбәк ул безнең. Үзбәк ни дә, татар ни. Хак тәгалә барыбыз өчен дә

бер... Догалар өйрәнәсен килсә, бездә китапларның төрлесе бар. Гарәпчәләре дә, урыс хәрефләре белән язылганнары да. Татарча аңлатмасы да бирелгән. Казаннан да кайтартабыз, үзебез дә үрчетәбез. Догалар өйрәнергә ниятләсәң, исемеңне теркәп куям. Күбесенең Фирданиядән укыйсы килә. Теләсәң, ана язармын...

Лениза, ашыгып, кесәсеннән акча янчыгын чыгарды да, кулына эләккән илле сумлыкны калтыранган бармаклары белән дивардагы тартманың тар авызына кертә алмыйча азапланды. Аннары көйсезләнә башлаган Рамиләне күтәреп, чыгу ягына борылды.

—Кая киттең? Әрвахларыңның исемнәрен язмадың бит әле?—дип кычкырып калды карчык аның артыннан.

• • •

Хәлбуки, рухына терәк эзләп бәргәләнүче бер Лениза гына түгел иде. Шундый берәү завод лабораториясендә үк бар икән. Зәңгәр халатлы җыештыручы хатынга кайсы Сәгъдәнә, кайсы Серафима дип эндәшә, бу бик тә сәер иде.

Ленизаның моңа гаҗәпсенүен күреп:

—Үзебез дә буталып беттек инде без аның белән,—диделәр.—Паспортында Сәгъдәнә дип язылган, фамилиясе Исламова. Үзе әйтә, чукындырганда атакай миңа Серафима дип исем кушты, ди.

—Чиркәүгә барып чукынганмыни?—дип сорады хәйран калып Лениза.

—Ул анда гел барып йөри, бер дә эзен суытмый. Чиркәү активисты булган! Анасы оятыннан кая керер тишек тапмый, диләр. Борынгы ишаннар нәселеннән икән бит үзләре. Исемнең дә матурын кушкан булганнар: Сәгъдәнә—«бәхет йолдызы» дигәнне аңлата икән. Муллалар белми кушмас. Тик моңа ярамаган, Серафима килешлерәктер.

—Ире урысмы әллә?

—Ире юк аның. Аерылышканнар. Улын берүзе үстерә.

Үзенә кырын караганнарын сизгәнгә булса кирәк, чандыр гәүдәле, җирәнсу чәчле, илле яшьләр тирәсендәге Серафиманың чырае караңгы, кыланмышлары шактый тупас иде.

Кызык, нәрсә тапты икән соң ул чиркәүдә? Анасының каргышыннан курыкмыйча, ни дип анда барып егылды икән?!.

Үзләренең каршысында биегәеп утырган чиркәүгә күзе төшкән саен, Лениза Сәгъдәнәне уйлап куя торган булды. Ишан нәселеннән икән бит үзе. Мәчеткә дә баргалагандыр. Тик менә бит, күңеле ятмаган. Рухына таянычны, җанына юанычны чиркәүгә барып тапкан. Күрәсең, анда бөтенләй бүтәнчәдер. Кереп карарга иде: ничегрәк икән?

Әмма тора салып барып керү ничектер унайсыз кебек иде. Бусаганы атлауга чукыну тиеш бугай әле. Киноларда шулай күрсәтәләр. Анысын ук булдырып булмас щул...

...Андый чакта бер җае чыкмый калмый, монда да шулай булды. Иртә яз иде, кар эри генә башлаган чак. Ленизаның теше сызлый иде, эшеннән сорап китеп, врачка барды. Кайтканда чиркәү турыннан узып бара иде, тротуар кырыена автобус килеп туктады. Аннан дистәдән артык кеше төште. Күбесе өлкән яшьтәге хатыннар. Чалбар, куртка кигәннәр, муеннарына фотоаппаратлар асканнар.

—Безнең шәһәрнең соборын унтугызынчы гасыр башында ук салганнар,—дип төркемгә борылып сөйләргә кереште яшь кенә бер хатын. Экскурсовод иде бу, төркем исә, мөгаен, читтән килгән туристлардыр.

—Әйдәгез, эчкә узыйк,—диде экскурсовод.—Чиркәү үзенең борынгы иконостасы белән данлыклы.

Болар—карарга килүчеләр генә, туристларга чиркәүгә керүгә чукыну мәҗбүри түгел. Ленизa бер-ике адым ара калдырып, төркемгә иярде.

Бик иркен бинаның эче ян-якларда күләгәгә уралган, уртасына биек гөмбәздән яктылык төшкән иде. Каршыда алтынга манылган иконостас, аның алдындагы өстәлдә бихисап шәм яна... Экскурсовод хатын диварлардагы сыннарга, иконаларга күрсәтеп, аңлатмалар биргәннән соң:

—Әгәр теләсәгез, мин руханиларның берәрсен чакыра алам,—диде.—Бәлки, сорауларыгыз булыр.

Руханины көткән арада, тыенкы тавыш белән үзара сөйләшүләр колагына керeп, Ленизa бу төркемнең шәһәр янындагы санаторийдан икәнлеген аңлады. Анда күп яклардан килгән халык ял итә. Арада төрле дин әһелләре бар иде.

Түр кырыйдагы күләгәдә шәйләнгән ишектән озын кара җилән кигән, шома кара чәчле, юка кара сакаллы, ак чырайлы, егерме бишләр тирәсендәге ыспай егет чыкты. Якын танышларын очраткан кебек, ачык йөз белән, шул ук вакытта вәкарь саклап:

—Исәнмесез,—диде.—Хуш килдегез безнең храмга. Ул сезгә ошагандыр, дип өметләнәм, әгәр сорауларыгыз булса, үзем белгән кадәр җавап бирергә әзермен.

Сораулар башта бинаның үзе хакында булды: кайсы архитектор төзегән, кемнәр хисабына, ничек ул коммунистлар заманында җимерелми калган. Биредә күп еллар китапханә булган икән. Өч ел элек кенә китапларны башка урынга күчергәннәр, бинаны өр-яңадан төзекләндереп, бизәгәннәр. Иконостасы моңарчы музейның чоланнарында сакланган булган икән, хәзер менә кире кайтарып урынына куйганнар.

Егет бик гади сөйли, ара-тирә генә «слава господу» дигән сүзне кыстырып куя иде. Тавышы ягымлы, карашы җылы, бик игътибарлы.

—Сез кайда укыдыгыз?

Егет Мәскәүдә дини академия тәмамлаган икән.

—Бу заманда бик күпләр дингә ышанмый бит инде. Чөнки балаларга дини тәрбия бирелми. Хәзерге яшьләрнең ата-аналары динсез үстерелде. Күпчелек чиркәүгә йөрми... Алла каршында гөнаһлары зурдыр.... Теге дөньяда андыйларның һәммәсе тәмуг кисәве булыр микәнни?—дип сорады берәү.

—Бог һәммәсен күреп-белеп тора. Ул адәм баласына акыл биргән һәм сайлау мөмкинлеге биргән. Әгәр дә кеше көн саен шушы чиркәү яныннан узып йөрсә дә, аны күрмәгәндәй узып китә икән, биредә кереп бер генә тапкыр да дога кылмый икән, ул инде үз юлын үзе сайлаган, дигән сүз. Ул юл бог кушкан тарафка илтә торган булмас. Әгәр дә кеше дин турында беркайчан да, берни дә ишетмәгән булса, анысы икенче мәсьәлә. Ләкин бар микән ул андый кеше? Хәзерге вакытта биредә безнең чиркәвебез күтәрелеп балкып тора. Шәһәрнең икенче ягында мәчет. Шулай итеп, кеше үзенә бирелгән сайлау мөмкинлегеннән файдалана ала.

—Хәзер халык күп нәрсә укый, күпне белә,—диде берсе.—Алла күктә диләр, ләкин менә күпме космонавтлар очып йөри, айга да менеп төштеләр, беркемне дә күрмәгәннәр бит...

—Ходай безгә әйткән кадәресен әйткән,—диде рухани.—Әйткәнен әйткән,—дип кабатлады ул.

Егет бу сорауга җавапны шуннан уздырмады. Дәвамы Ленизаның күнелендә үзеннән-үзе туды: «Ә әйтми калдырганы күпме?!» Ләкин ник әйтми калдырган? Адәм баласының аңлап җиткерерлек сәләте булмагангамы? Ләкин безгә сәләтне ул биргән бит!..

—Теләсәгез, мин сезгә бер брошюра бирәм,—диде рухани.—Анда дөньяда иң киң таралган диннәр—христиан, буддизм, ислам, иудаизм турында кыскача гына мәгълүмат тупланган.

Ул, эчке яктан алып чыгып, китапчыклар өләште.

Егет белән хушлашып, чыгып барганда, арадан берничә кеше ишек янындагы тартмага акча салып, нәрсәдер пышылдадылар, башларын иеп, ашыгып чукындылар.

Урамга чыккач, үзара әкрен генә сөйләшеп, автобуска таба киттеләр. Арттанрак барган ике хатын татар икән, үзара пышылдашып алдылар.

—Боларның батюшкалары көчле... Буыннары арасында өзеклек булмады шул... Христиан академияләре беркайчан ябылмады. Ә безнекеләрнен берничә буынын өзеп ташладылар... Тамырдан аердылар... Рухиниларыбызнын күбесенә белем житешми...

«Ходай адәм баласына акыл биргән һәм сайлау хокукы биргән». Нәрсәгә инанырга, ничек яшәргә, нинди гамәлләр кылырга—монысы аның үз ихтыярында.

Ләкин менә Ленизага нишләргә? Әллә сон ялгызын гына шушы рухани янына кереп кинәш сорарга микән? Ярый, бардын ди, чакырып чыгардын, ди. Шуннан? Ни дип сүз башларсын? «Ирем мине яратмый. Анын мәхәббәтен ничек кайтарыйм?»—дияргәме? Ходай язмаганны...

Юк, туктале, аның берәр тәртибе булырга тиеш. Ленизанын күп киноларда күргәне бар: авыр кайгылардан арыныр әмәл тапмагач, якты дөнья кара төн булып күренгәндә, иманлы кешеләр гыйбадәт йортларына барып Аллага сыгыналар. Әлбәттә, ул киноларның геройлары христианнар. Күпчелеге фажигагә дучар булган яшь, чибәр хатыннар... Ә чиркәүләр затлы, бизәкле. Зур, биек бинанын түрендә изге ана—Мариянен сурәте. Менә анын каршына ак яулык бөркәнгән гүзәл хатын килеп баса, догалар пышылдап тезләнә, күз яшьләрен түгеп, мон-зарларын сөйли. Шуннан үзенә юаныч, жинеллек таба.

Христианнарда «исповедоваться» дигән йола бар. Аны шулай ук киноларда бик матур итеп күрсәтәләр. Кеше кичкенә генә куышка кереп утыра һәм бар булган әрнүләрен сөйли, жанын ачып бирә. Бу инде кайдадыр жиде кат күк өстендәге Ходага ялвару түгел. Ул ера-ак... Ә монда, куышта, диварнын икенче ягында, сине ишетеп торучы бар. Зарларын, гозерләрен ниндидер сәбәпләр аркасында, күкләргә күтәрелеп, Ходага барып ирешмәсә—ә бәлки, сүзенне анлаешлы итеп әйтеп бирә алмасан—ул сине төзәтер, үтенечение кабул итүен сорап, Ходага үзе дә мөрәжәгать итәр.

Бу бик анлаешлы гамәл булып тоелды. Алай да орды-бәрде эшләнә торган эш түгел... Лениза янә Сәгъдәнә-Серафиманы исенә төшерде.

...Жыештыручы хатын читтән караганда гына кырыс күренгән икән. Сүз кушсан, тиз ачыла, сөйләшергә ярата икән үзе. «Сезнен белән кинәшәсе килә иде»,—дигәч, тәмам яктырып китте.

Шкафлар, өстәлләр белән бүлгәләнгән иркен лабораториянең бер почмагында аулак урын бар—зур чүлмәктә үскән кин яфраклы пальма артында ул. Төшке аш вакытында алар, шунда ышыкланып, урындыкларга каршы-каршы утырдылар. Сәгъдәнә-Серафима сүзнен четерекле булачагын анлап алган иде инде. Кызыксынудан соры күзләре яна, какча яаклары алланып чыккан.

Иң яхшысы—үгезне мөгезеннән тоту иде. Лениза әйләнеп-тулганып тормады, туп-туры:

—Сезнен исповедоваться иткәнегез бармы?—дип сорады.

Серафима елмаеп жибәрде. Алгы теше төшкән икән. «Куйдырырга, мөгаен, акчасы юктыр инде»,—дигән уй узды Ленизанын башыннан.

—Чиркәүдәме? Нишләп булмасын!—диде Серафима.—Исповедоваться итү—бик кирәкле, изге гамәл бит ул.

—Ничек-ничек эшләнә сон ул?

—Әллә сез дә бармакчымы?

Хатынның йөзеннән, күзләреннән хәйләкәрлек катыш сөенеч бөркелде.

—Болай гына... Беләсем килә...—диде Лениза карашын пальма яфрагына төбәп.—Киноларда күп күргән бар... Дөрес күрсәтәләр микән, дим...

—Кино нәрсә ул! Үзең кылганда бөтенләй икенче! Иң элек өч көн пост тотарга кирәк. Хайваннардан алынган азыкларны—ит, сөт, йомырка, балык ишене ашарга ярамый. Тәнеңне сафландырырга, тазартырга кирәк. Юынырга, мунча керергә. Һич булмаса, ванна. Иң мөһиме—җаның чиста, саф булырга тиеш. Гел яхшыны гына уйларга, матур гамәлләр генә кылырга. Шуннан соң атакай янына барасың. Тезләнәсең. Ул синең башыңа кара тукыма ябындыра. Тукыма үзе кара, ә эче нур белән тулы... Чөнки ул синең үзеңнән, изге ниятләреңнән бөркелә. Атакай синнән, вөҗданың нидән тынгы тапмый, дип сорый. Чын дөресен сөйлисең. Берни дә яшермичә. Аннан сер чыкмаячак. Ул синең гөнаһларыңның Алла тарафыннан ярлыкалганын әйтә, догалар укый, моннан бүтән начар гамәлләр кылмаска куша. Монда иң әһәмиятлесе—ихластан ышану...

—Юк, мин гөнаһлар турында түгел...

—Бер гөнаһсыз адәм булмый инде. Исповедоваться итәргә теләк туган икән, димәк, нәрсәдер бар. Сөйләп бирерсең.

—Минем башка... Мин киңәш сорамакчы идем.

—Нәрсә турында?

—Ирем хакында... Безнең мөнәсәбәтләр...

—Алланың кодрәте чиксез... Син иреңне дә алып кил атакай янына! Икегез берьюлы исповедоваться итсәгез, гел дә әйбәт булачак. Бер-берегезне рәнҗеткән булсагыз, атакай кичерер. Килештерер. Күңелләрегезгә нур тулыр...

Лениза ачы елмаюын яшерә алмады: Мидхәтне чиркәүгә алып барыргамы?!.

—Якшәмбе көнне службага кил әле син,—диде Серафима анының икеләнгәнен сизеп.—Шунда һәммәсен аңлатырлар. Анда без бик изге эшләр башкарабыз. Гарипләргә, ятимнәргә, мескеннәргә ярдәм итәбез. Хәйрия җәмгыяте оештырдык. Киелгән киемнәрне җыябыз да, тәртипкә китереп, бик арзан хакка, аяк ялы бәрабәренә дигәндәй, мохтаҗларга бирәбез. Акчалата ярдәм җыябыз. Анысы тагын да әйбәтрәк. Әгәр мөмкинлегең булса, хәзер үк бирә аласың. Саваплы булырсың...

Лениза, сумкасын актарып, кулына эләккән йөзлекне анның учына тоттырды да, уйлап карарга вәгъдә итеп, урыныннан кузгалды. Ул көнне Серафима тарафына бүтән карамаска тырышты.

«Йә инде, нәрсәгә дип ана шул хәтле акчамны бирдем?»—дип тә үкенде.

...Кара сакаллы яшь кенә егет каршына тезләнеп, башына кара япма бөркәнеп, «иремнең күңеле сүрелде, нишлим?» дип зарлануны ул берничек тә күз алдына китерә алмады. Ярый, зарланды да, ди. Аннан гына ни үзгәрер соң?..

Серафима сөйләгән йола бөтенләй дә ул күз алдына китергәнчә булып чыкмады.

* * *

... Мидхәт гадәтенчә эштән соңарыбрак кайтып керде. Зал ягында битен марля белән ураган хатынны күреп, башта танымады.

—Кунак бармыни әле бездә?

Хатын башын аска ия төшеп:

—Чакырылмаган кунак әле бу,—диде. Аның битен ике яклап төргән марля өстеннән күзлек ырмавының саплары сузылган иде. Пыялалар аша атылган күз карашыннан, аннан да бигрәк тавышыннан Мидхәт Рәйсәне танып алды.

—Ни булды?

Аш бүлмәсе ягыннан Лениза чыкты да, шактый ук кычкырып:

—Өйләрендә савыт-саба шалтыраган. Тәлинкә тиеп киткән,—диде.

Аның тавышында һич тә урынсыз шаяру чагылып узгандай булды. Мидхәт исә тәмам аптыраашта иде.

—Рәмис кыйнадымы әллә?!

—Шул инде, кем булсын...

—Үзе кая соң әле?

—Милициядә.

—Син тапшырдыңмы әллә?

—Ә нишләргә тиеш идем мин? Йөгереп барган идем, ияреп килделәр дә, алып та киттеләр.

—Кайчан булды инде бу хәлләр?

—Кичә кич... Бүген милициягә шалтыраткан идем, иртүк чыгарып җибәрдек, диделәр. Берәр атна булса да ябып тотмаганнар шунда!

—Элекке кебек унбиш суткыга утыртмыйлар бугай шул хәзер,—диде Лениза.

Рәйсә Мидхәткә рәнҗешле караш төбәп:

—Ирләр бер-берсен яклый шул ул! Син дә гел аны яклыйсың бит,—диде.

Мидхәт алгы бүлмәдәге элгечкә курткасын озаклап урнаштырган булып азапланды. Рәмиснең завод каршындагы базарда сату итүче, Роза исемле яшь кенә ирсез хатын белән бәйләнгәнен белә иде инде ул. Акылына кил, гаиләң әйбәт, хатының менә дигән, дип үгетләде дә. Җирән чәчле, акаеп торган соры күзле Розаны балга манып бирсәләр дә ымсынмас идем, дип тә карады.

—Нигә ямьсезләнеп йөрисең?—диде.

Рәмиснең тулы иреннәре җәелә, майлы күзләре кысыла, алардан бал саркыгандай була:

—Ә без ямьсезләнмибез... Матур гына итеп, матур гына...—ди һәм кулллары белән мәгънәле хәрәкәтләр ясап куя.

Кичләрен еш кына Рәйсә Мидхәтләргә телефоннан шалтырата, Рәмисне күрмәдеңме, дип сорый. Мидхәт, билгеле инде, әшнәсен коткару ягын карый:

—Бер цехта авария булды. Рәмис шунда калды, соңрак кайтыр... Ә бәлки, иртәнге сменага хәтле цехтан чыга алмас...—кебек тозсыз сүзләр сөйли.

Боларны күреп-ишетеп торган Лениза аңа чәнчеп-чәнчеп карап ала.

—Бу кадәр дә ата ялганчы икәненне белми идем әле,—ди.—Кеше хатынына шулкадәр ялганлагач, үз хатыныңны ничек кенә алдамыйсың икән?..

...Менә хәзер Рәйсә мөлдерәп карап торганда, Мидхәт үзен бик уңайсыз хис итте.

—Теге көнне син миңа, заводта авария булды, дигән идең,—диде Рәйсә Мидхәтнең күзенә туры карамый гына.—Ә мин бардым анда. Авария заводта түгел, башка җирдә булган... Күптән күңелем сизеп йөри иде инде.

—Әллә берәрсе белән тоттыңмы?—диде Лениза күзләрен зур ачып.

—Тоттым... диярга була. Бик озак ишекне ачмый тордылар. Аннары, мин өсләренә диярлек барып кергәч, җыен юк-барны сөйли башладылар. Имеш, йомыш белән кергән. Ялгыз хатында ир кешенең нинди йомышы булуы билгеле инде. Шкаф ишеген рәтләргә кергән, имеш... Үз өендәгене рәтләмәгәнне...

—Шунда талашып сугыштыгызмы әллә?

—Нишләп сугышыйм... Алар өчен оялдым... Борылдым да йөгереп кайтып киттем. Ул кайткач, кертмәдем. Ул ишек биген тибеп очырды да, миңа китереп бәрде...

—Бер бәрүдә шулай иттеме?

—Күзлеккә эләкте... Ырмавы басып, борын сөяген сындырган...

Рәйсәнең күзлек пыяласы астыннан яшь тамчысы тәгәрәде. Рәмиснең

күнелендә аның башыннан сыйпап юату теләге уянган иде. Әмма аш бүлмәсенең ишеге төбендә сынап карап торган хатынына күз салгач, дәшмәде. Юыну бүлмәсенә кереп китте.

Лениза бәрәнге, колбаса, сыр ише ризыклар куеп, табын әзерләде. Чәй янында Рәйсә ничектер йомшап киткәндәй булды.

—Беренче тапкыр ул кайтмаган төнне бик каты елаган идем,—диде.—Бер-бер хәл булгандыр, дип уйладым. Радиодан, телевидениедән көннен-көнендә юкка чыккан кешеләр турында сөйләп торалар бит. Мин дә милициягә бардым. Астыртын гына елмаештылар да, өч көннән килергә куштылар. Тәртибе шундый икән. Югалганны өч көн үткәч кенә эзли башлыйлар. Ә ул ике көннән әйләнеп кайтты. Мин елыйм, ул авызын ерып көлеп тора. Яратуың хак икән, инде ышандым, ди.

Кыскасы, ямьле күренгән йортта бик тә ямьсез хәлләр барлыгы ачыкланды. Хәер, гел яктыдан гына торган гаиләләр бар микән ул? Кояш ничаклы якты балкыса, күләгәләр дә шулкадәр куе була. Болыт каплаган җирдә генә дөнья һаман бертөрле.

Мидхәтнең нечкә бер тамыры сулкылдап куйды. Йа Раббым, мондый хатынга орган ирнең кулы корыр!..

—Һәммәсенә чыдар идем, кимсетүенә түзеп булмый,—диде Рәйсә әрнеп.—Кешелегемне бетерә. Әллә ничек үземне үзем санга сукмый башладым Тормышыңны дуңгыз белән бәйләсәң, аның белән бергә урам канавында аунарга туры килә икән. Мин шуны аңладым. Житте! Аерылам!—диде Рәйсә сынын турайтып, катгый итеп.—Үземне кызганмасам, баланы кызганырга кирәк. Минем дә кешелегем бетсә, ул ничек үсәр?

—Ирсез яши торган кеше түгел син, берәрсенә чыгарсың әле,—дип куйды Лениза.

—Безнең базар үткән инде...

—Берәрсенең ирен тартып алырсың. Хатыннарын яратмаган ирләр җитәрлек.

Мидхәт аларны читтән генә күзәтеп утырды. Үз сүзләренең хаклыгына нык ышанган Лениза кунагына астыртын бер көлемсерәү белән карап-карап ала, тавышында да ниндидер бер үчекләү бар. Әмма Рәйсә моны сизми, үз хәле хәл, гамьнәре зур иде...

—Бакча сараенын ишеген ничек кирәк алай әмәлләштереп куйган идем инде,—диде ул.—Биген ясый алмыйм. Көрәк-сәнәкне куяр урын юк..

—Ял көнне барырбыз да, куеп кайтырбыз. Нәрсәсе бар анын,—диде Мидхәт.

...Бакчадагы күрше-күлән арасында Мидхәт иң уңганнардан санала иде. Жирне алган көзне үк, һәммәсеннән алда, акча тотмый гына бер сарай әмәлләп куйды. Бакчачылык җәмгыятенең биләмәсен койма белән әйләндереп алганда, бик күп такта башларын кисеп ташладылар. Мидхәт шуларны сорап алды да, стеналар корыштырды, эчтән катыргы белән ышыклады. Ишек куйды, тәрәзә уйды. Түбәсен калдык-постык толь кисәкләре белән япты. Эченә ятак, өстәл ясады.

Рәйсәләрнең җире ширкәтнең икенче башында, шунлыктан сирәк очрашалар иде. Бер узып барганда, ул, Мидхәтнең сараен күреп:

—Рәмис шушындыйны булдырса, башканы сорамас та идем,—дип күрсенеп куйган иде.

Рәмиснең исә күнеле башкада—яр буенда балык тотуда, дуслар белән шашлык кыздырып ашауда, әргән тартып җыр җырлауда...

...Буш кул белән барасы килмәде, Мидхәт андый очракта бүләкнең иң кыйммәтлесен—бер капчык күгәрчен ашламасы күтәреп барды. Мондый хәзинәне ул үзләренең йорт чормасыннан җыеп ала... Мидхәт ишек төбендә аркасына биштәр асып азапланганда, Лениза сиздерми генә янәшә торган

капчыкны кыймшатып карады. «Аркасында биштәр, жилкәсендә шушы капчык... Ничек өстерәп барыр икән?—дип уйлады.—Рәйсә дигәндә көчен кызганмый!» Үзләренә шундыйны алып барганда ирен кызгану Ленизаның башына килмәгән иде, әлбәттә...

Ләкин урынга барып, ачык һавада чирәмгә урнашкач һәм эшкә керешкәч кенә Мидхәт үзенең ялгышканын аңлады: капчык белән ашлама түгел, келәшчә, чүкеч, калак, стамеска алып килергә кирәк булган. Корал эшли, ир мактана, дигәннәр, коры кул белән әллә ни эш майтарып булмый. Ара шактый ерак булса да, үзләренең сараена барып, кирәк-яракны алып килергә туры килде.

Хатыннар чирәмлектә учак ягып ашарга пешерәләр. Битен марля белән ураган Рәйсә ит турый, Лениза бәрәңге әрчи. Чөкердәшәләр, көлешәләр, борчаклары бик тә пешкән кебек күренә. Шунда ук бала арбалары, Илдус белән Рамилә уйныйлар. Көн аяз, жилсез, жылы, түтәлләрдә уткойрыклар чүпләнә, бакча башындагы агачлыктан кошлар сайраганы ишетелә. Дөнья матур, һәммәсенең күнеле хуш кебек иде.

Алар караңгы төшкәндә генә кайтып керделәр. Лениза чәй куярга ашыкты. Мидхәт Рамиләнең курткасын, ботинкаларын салдырып, уенчыкларын тоттырды.

—Уйна, кызым!—диде дә, ванна бүлмәсенә юынырга кереп китте.

Гөнаһ шомлыгына каршы, чәйнекне газга куеп бүлмәгә чыккан Лениза аның диванда яткан костюмын шкафка элеп куясы итте. Кулы күнегелгән хәрәкәт белән чалбар кесәсен капшады. Мидхәтнең кесәләрен еш тенти иде ул, тик монарчы гаеп-кыек табылмаганга, гөнаһлы гамәле сизелми килде. Ә бу юлы кесәдән конверт почмагы күренде. Хат иде бу. Лениза аны тартып алды да, адресына текәлде. Хат почтага «до востребованья» жибәрелгән. Язучысы—Гомәрова. Казаннан... Кем ул Гомәрова? Әгәр институттан булса, ник турыдан-туры өйгә язмаган?

Ленизаның калтыранган бармаклары конверттан вак кына зәңгәр хәрефләр белән шыплап тутырылган бер бит кәгазь һәм... төсле фоторәсем тартып чыгарды. Хатынның битен ялкын теле ялмап алгандай булды: рәсемнән ана күзләрен зур ачып, уемлы ияге белән үртәп Әнисә текәлеп карап тора иде. Лениза, корт чаккандай, фотоны идәнгә ташлады да шытырдатып хат битен ачты.

«Кадерле Мидхәт абый!—дип язылган иде анда.—Синең бу хатың безгә зур шатлык булды...»

«Бу хатың»... Димәк «тегеләре»—элеккеләре дә булган? Мидхәтнең бу хакта теш агартып бер сүз дә әйткәне юк иде! Әйтерлек булса, килгән хатларны почтага барып алыр идемени ул?

Ленизаның күзләре ашкынып кәгазь битендәге юллардан йөгереп узды. «Соңгы сынауларыгызның уңышлы узуына бик-бик сөендек. Димәк, Норвегия белгечләренең үкчәсенә басасыз? Мин сезгә жиңү телим, Мидхәт абый! Үземнең көчемне, кодрәтемне жибәреп торам!»

Менә кем сихерләп ята икән Мидхәтне! Менә кем кергән арага! Аның карточкасы да сихерлидер, мөгаен! Югыйсә, күзләре бу кадәр томырылып, бәгырьгә үтеп карар идемени? Лениза ул күзләрне күрмәс өчен башмагы белән басып, ышкыды. Бозган бу Мидхәтне, бозган!

«Тагын кайчан кайтырсың икән, Мидхәт абый? Синең белән сөйләшәсе сүзләр шулкадәр күп!»

Димәк, алар күрешкәләп торалар?.. Мидхәтнең Норвегия белгечләре белән узышканын да белә, эшенең ничек барганын да... Монысы инде Ленизаның башына сыймаслык иде...

Мидхәт, трикосын киеп, чәчен сөлге белән ышкыштырып юыну

бүлмәсеннән чыкканда, Лениза идән уртасында таш сын булып басып тора иде.

—Бу нәрсә?—дип, хатны иренең битенә китереп терәде ул.

Мидхәт бер кулы белән башындагы сөлгене артка шудырып, икенчесе белән кәгазьне читкәрәк этте. Алланган йөзендә аптырау чагылды, ул эшнең нәрсәдә икәнен аңламыйрак торды.

—Каян алдың син моны?—дип сорады аннары.

—Кесәңнән килеп төште! Кайчаннан бирле хат язышасыз сез аның белән?

Мидхәт каушап китте, гаепле елмайды.

—Беренче хат кына... Язышса ни? Нәрсәсе бар аның?—диде.—Чит кеше түгел бит... Авылдашлар...

—Нинди авылдаш булсын ул сиңа! Сихерче чегәннең авылы буламыни?

—Нинди сихер?

—Әнә, портретына кара!—дип идәндәге карточкага башмак очы белән төртте Лениза.

Мидхәт иелеп, карточканы кулына алды.

—Юкка кызасың,—диде.—Яшь кыз бала турында...

—Ул кызның самый кызган чагы, если хочешь знать! Апасының ниләр сөйләгәнен хәтерлисеңме?

—Нәрсә турында?

—Анасы белән яшерен хат алышканын... исеңә төштеме? Алар икәүләшеп... кем әле?

—Әлифә апаны әйтәсеңме?

—Менә шуны сихерләгәннәр. Шулай булмаса, ул чит кеше баласына шулкадәр хезмәт итәр идемени? Хәзер синдә осталыгын сынарга булгандыр. Сине аздырып, башка хатыннар белән буташтырып...

—Нинди хатыннар?!.

—Ниндие туры килсә, шундый... Бозым кергән иргә теләсә кем ярый. Менә бүген дә ниләр генә кыланмадың, теге дүрткүзгә ничек кенә ярарга тырышмадың! Миңа кирәк артыннан алай галопом чапмас идең әле! Ирләре ташлап киткән хатыннар кирәк сиңа. Мин генә житмим! Аларның әллә нәрсәсе бар дип беләсеңдер!

Мондый нахак сүзләрне һич көтмәгән Мидхәтнең күз алдын кызыл томан каплагандай итте, ярсуы ташып чыкты, ул үз-үзен белештермичә:

—Әйе, синдә юк нәрсәләр бар анда!—дип кычкырганын сизми дә калды.

Ялгыш ычкынды, дөрес әйтелмәде. «Нәрсәләр» түгел, «сыйфатлар» дияргә кирәк иде. Ләкин сүз чыпчык түгел, авызыннан бер чыгып очкач, тотып алып булмый.

Нәкъ менә шул кызулык белән ычкынган бер сүз Лениза өчен иренең хыянәтен раслый торган бик зур дәлил булып тоелды да инде. Хатынның чырае чалшаеп, бурлаттай кызарып чыкты. Тыны кысылды, әйтер сүзләре бугазына килеп төйнәлде.

—Ах, шулаймыни? Каян белдең әле син аның андый нәрсәләрен? Күптән күрсәттеме?!

Ул кизәнеп, нык селтәнеп Мидхәтнең яңагына сугып жибәрде.

Авыртуны сизмәде Мидхәт, әмма тынсыз калды. Хатынының кулы аның тиресенә, сөякләренә орынмыйча, турыдан-туры эчкә, бәгырьгә китереп органдай итте. Һәм ул Ленизаның кулын тотып алды да, бөтен көченә артка таба каерды:

—Гафу үтен хәзер үк! Гафу үте-ен!

—Үтерәсе- е-н!..

Бу тамашаны монарчы почмактан өзгәләнеп карап торган Рамилә әнисенең итәгенә килеп ябышкан, елый, әтисенә әйтеп бетерә алмаслык рәнжеш белән

текәлгән иде. Ул әнисен яклый, әнисен кызгана! Кем әйтә, балалар һәрчак хаклы, гадел дип?

Мидхәт Ленизаны караватка илтеп салды да, кулын ычкындырды. Хатын ун кулын сулы белән ышкыштырып, сулышына буылып сикереп торды да:

—Подлец! Негодяй! Бар ычкын фахишән янына!—дип кычкырды.—Чыгып кит хәзер үк! Эзен булмасын монда!

Һәм сикереп торды да, шкафның ачык киштәсеннән кулына кергән беренче әйберне алып идәнгә томырды. Ә кул астына аларның туена бер ел тулган көнне заводтагылар бүләк иткән чынаяклар эләкте. Алар артыннан бизәкле зур чәйнек идәнгә очты.

—Кит! Кит!

Нишләгәнен белмәгән Лениза ары-бире бәргаләнгән арада, өзгәләнеп елаган Рамиләне тезе белән төртеп екканын сизми калды.

—Нишлисең?! Үтерәсең бит баланы!

Мидхәт кызчыкны күтәреп алды да, ишекне ачты.

—Калдыр баланы! Калдыр!—дип чатлап килепябышты ана Лениза. Алар шулай бер-бер артлы чабышып урамга чыктылар. Ишек төбендәге эскәмиядә һава сулап утырган карчыклар, машиналары янында әвәрә килгән ирләр барысы берьюлы алар тарафына борылды.

—Бир диләр сиңа баланы! Хәзер милиция чакыртам! Халисә апа! Күрмисезмени?! Милициягә шалтырат әле!—диде үзенә көч-куәт өстәлгәнен сизгән Лениза.

—Бүтән тиясе булма! Кара аны!—дип, Мидхәт мышык-мышык килгән Рамиләне җиргә бастырырга мәҗбүр булды.

Һәм, абына-сөртенә йөгереп, йортның икенче ягына китеп барды. Карчыклар аның артыннан:

—Карале, бу да эчүгә сабышкан икән... Рәтле генә күренә иде...—дип сөйләнеп калдылар.

Тирә-якта ял көнендә кичләрен була торган җан тынычлыгы хөкем сөрә, кемнәрдер сонарып бакчадан, яисә кунактан кайтып килә, кемнәрдер сабыйларын һава суларга алып чыккан. Бәхетле балалар, бәхетле аталар! Бер Мидхәт кенә адаштырылган эт хәлендә...

Хәер, аның хәлендәмени хикмәт! Рамилә—бәгырь кисәге нишли икән анда? Үз-үзен белештермәс хәлгә килгән хатын иренең үчен баладан алмый микән?

Йорт янындагы яшь агачлар арасына фонарь яктысы килеп ирешми иде. Мидхәт бераз вакыт караңгыда, аулакта ялгызы әрле-бирле йөренде. Аннары аяклары үзеннән-үзе кире өйгә таба атлады. Тәрәзәләрнең бер ягы чебен кермәсен өчен марля белән генә капланган. Өйдәге тавышлар тышка аермачык ишетелә. Кемнендер телевизоры сөйли, кемдер музыка уйната, кайдадыр телефон зыңгылдый. Бала елаган тавыш юк. Аллага шөкер...

Төнне ул заводның кунакханәсендә үткәрде. Вакыт соң, дежур трамвайны озак көтәргә туры килде, барып җиткәнче ярты төн узды. Ярый, завод идарәсе бинасында командировкага килгән кешеләрне урнаштыра торган берничә бүлмә бар. Ярый, директор урынбасары ирләрнең хәлен аңлый торган, тәҗрибәле кеше. Төн уртасында телефоннан шалтыраткан өчен ачуланмады, кунакханәдә кизү торучы хатынга инженер Халиковны буш бүлмәгә урнаштырырга рөхсәт бирде.

Тар караватка сузылып ятканда ул шактый тынычланган иде инде. Аек акыл белән бер сорауга җавап табасы килде: кем гаепле?! Гаепне ул ин элек үзеннән эзләде. Ир кеше гаиләне иҗле тотарга, хатынына хуҗа ук булып бетә алмаса да, үз җаена салырга тиеш түгелмени? Ничек әле ул хатын-кызга кул күтәрү дәрәҗәсенә барып җитте?!

Ләкин, гауга купкан минутны күз алдына китергәч, йөрәктә көчле ризасызлык кубып, уйларның юнәлеше үзгәрде. Чөнки ана беркайчан да мондый мәсхәрәле рәвештә китереп органнары юк иде. Малай чагында да ул битенә суктырганын хәтерләми. Кизәнсәләр, йодрыгын каршы куя белде, берничә кеше килеп ябышса, егылганда башын томалады. Иң якын кешеннең мондый кыланмышын ул хурлау, кимсетү, аяк астына салып таптау дип кабул итте.

Бер академик турында ни сөйләгән иде әле Рәмис? Пеләшен хатыны дөмбәсли дипме? Шуны күргәч, рәссам аның портретын ясаудан баш тартканмы? Аны кешегә санаудан туктаганмы?

Юк инде, Мидхәт андый көнгә төшмәс, хатыныннан кыйнатып тормас!

Ә Лениза? Ул ничек иренә кул күтәрә? Яши белмәвенең үчен аннан алуымы әллә бу?!

Һаман ярату-яратмау турында сөйләнү, һаман ятак кайгысы шул анда... Ләкин яшәүнең сөешүдән башка да бик күп төрле мәшәкатьләре, гамьнәре, куанычлары бар. Эше-хезмәте, жыры-моңы, сагышлары, күңел ачулары... Дөрес, гыйшык дигәндә һәммәсе онытыла, диләр. Мәхәббәт бөек хис, диләр. Әмма үз башыңа төшсә, Алла сакласын икән андый утлы хисләрдән! Мәхәббәт ул башка берәүне үзенә кол итәргә тырышудан гыйбарәт икән. Хәер, колларның да, мөгаен, уйларына, хис-тойгыларына, кайчакта кемгәдер сокланып күз атуына хуҗа булып бетә алмыйлардыр. Аларның иң нечкә тойгылары, хыяллары, күңел кылларының чынлавы иректә каладыр. Әмма сине сөям дигән берәү, синең белән гомерен загс чылбырлары белән бәйләгән кеше күңеленә хуҗа булырга теләсә, нишләргә?

Монысына риза булган ирләр тоташ ялган эчендә яшәргә дучар булалардыр. Һәм мондый тормыш аларны изә, кешелеген бетерә, шәхесен җимерәдер.

Суда тәнкәләр уйнаган кебек, җил исеп узган кебек, кояшлы янгыр явып үткән кебек, вакытлыча күңелнең уйнап алуын ниндидер бер фаҗигага әверелдерергә кирәк микән?

Ахмак та түгел кебек югыйсә, нишләп Лениза шушы гап-гади нәрсәләрне аңламый икән? Сөюе чынмы соң аның?

Шунда кинәт Мидхәтнең күз алдында тылсымлы лампа кабынып, үткәннәрне яктыртып күрсәткәндәй булды. Беренче тапкыр кавышу күз алдына килде. Өзелеп сөйгәнгә күрә бирелдеме ана Лениза?! Әгәр ул кичне, тулай торакка кайтыр алдыннан, кунакта булмасалар, ул Мидхәтне үзенә шулай якын җибәрер идеме икән?! Һич юк! Әнисәдән көнләгән ул аны, югалтудан курыккан. Шуңа шулай сыланган да. Мәхәббәт түгел, көнчелек кавыштырган аларны!

* * *

Шуннан соң атна буе Мидхәт өйгә кайтмады. Ул эшли торган цех заводның читендә, лабораториядән ерак. Анда барып, ирен күзәтеп йөрергә Ленизаның горурлыгы ирек бирмәде. Ясле-бакчадагы тәрбияче әйтүенчә, сәгать җиделәр узгач кына анда кереп, Рамиләнең хәлен сораша икән үзе. Аннары кая китәдер, кайда төн үткәрәдер, билгесез. Лениза кебек ялгызы сагыш утына уралып аунап ятмыйдыр, үзенә бер җылы кочак тапкандыр әле!..

Ленизаның бәгырен көнчелекнең бер генә түгел, йөз күсесе кимерә кебек иде. Мең мәртәбә ул Мидхәтне башка бер хатынның кочагында күз алдына китерде. Менә кайчан аңлады ул ирләрен, йә хатыннарын үтергән кешеләрнең халәтен!

Бу газаплар өчен җавап бирергә тиеш ул. Шундый итеп үч алырга кирәк, ул да чыдап булмаслык өзгәләнсен. Ленизага боз күз белән караганы өчен,

аны ташлап чыгып киткәне өчен мең үкенсен! Аяк астында тәгәрәп гафу сорасын!

Ләкин ничек итеп аны шундый хәлгә житкерергә?!

Эчендәге уттан көеп, карангыда ялгызы яткан хатынның башына һич көтелмәгән уйлар килә. Әгәр Лениза юк булса, бу газапларга түзә алмыйча үлеп китсә, нишләр иде икән ул?! Гомеренең ахырына кадәр вөжданы тынгы белмәс иде! Димәк... үләргә... Язу калдырырга кирәк булыр...

Завод лабораториясендә контроль көчле, теләсә нәрсә болгата алмыйсың. Аңа вакыт та юк: Ленизаның жаны түзми, ниятен бүген үк тормышка ашырасы килә иде. Дөньядан китүнең унайлы чарасын эзләү ярсып типкән йөрәкне бераз тынычландырып жибәрде. Көн яктырып, беренче трамвайның дөбердәвеннән карават жинелчә генә тибрәлгәндә, баш бераз суынган иде инде... Үләргә үк ярамас, әлбәттә. Куркытырга гына кирәк булыр, үлгән булып кыланырга. Коты алынсын... Тәүбәгә килсен... Ә аннары, шактый вакыт узгач кына, күзне ачып, аны чиксез куандырырга...

Ныклы карарга килү көч бирде. Ул Рамиләне дуылдатып торгызды да, ашыгып киендерә башлады. Кыз сызланып елап жибәрде: әнисе кабалануыннан баланың оеклы штанын ипләп кигезмәгән, аяк бармагының йомшак тырнагына жеп эләгеп, каерган икән.

—Тукта хәзер үк!—дип бармагын аның борын төбендә селкеде Лениза.—Тынынны чыгарасы булма! Атаң күзләре белән акаеп карама мина!

Кызчыкның елавы сулкылдауга әверелде. Лениза аны жилтерәтеп бакчага алып китте. Лабораториягә телефоннан шалтыратып, чирлим, температурам утыз сигезгә күтәрелде, дип бер көнгә отгул алды.

Көнне ул шәһәр буйлап аптекаларда йөреп уздырды. Хәйләләп, ялынып, йокы даруы жыйды.

Вакыты да бик жайлы туры килде: радиодан кат-кат суыклар килүе турында хәбәр итеп тордылар. Төнлә каты кырау төшәчәк икән. Бу якларның сәер бер үзенчәлеге бар шул: август урталарында нык кына суытып ала, бакчадагы помидор-кыяр түтәлләрен капламасаң, бетерә. Атна-ун көннән тагын жылыта үзе, исән калган кыяр үсә, помидор сабагында кызара һәм шулай тагын ай буе диярлек дәвам итә.

Бакчасына күпмедер күңел биргән хужалар моны яхшы белә, кырау килгән көннәрдә түтәлләрен полиэтилен пленкалар белән каплый. Мидхәт, әлбәттә, унган хужа, кагыйдәләрне төгәл үтәргә күнеккән. Бүген ул бакчага бармый калмаячак. Өйгә, бәлки, кайтмас та, ә анда булыр! Шунда ук кунып йөрми микән әле!

Ничек кенә булмасын, ниятләгән чараны анда гамәлгә ашыру дөрес булыр.

Кичкә таба автобуста барганда, Ленизага һәммә нәрсә күңел кайтаргыч булып тоелды. Халык ямьсез киенгән, чөнки күпчелеге чыннан да бакчага бара, телләрендә гел шул помидор да кыяр.

Автобустан төшкәч кенә, бакча күршесе Аня белән очраштылар.

—Чирләмисендер бит? Төсең качкан,—диде Аня сәлам алышкач.—Больничныйдамы әллә?

—Кәефем юк, баш авыртып тора. Эштән сорап киткән идем. Кырау була, диләр бит, шуңа килдем.

—Кәефсез килеш ник интегеп йөрисең? Мидхәтен эштән соң килер иде әле.

—Син дә килгәнсең бит менә.

—Минем Николай отпускыда бит. Таннан торып балыкка киткән иде. Дөньясын оныткандыр, кырау төшәсен дә ишетмәгәндер. Баланы әбисенә калдырып, өч кенә сәгатькә дип килүем.

Кырыктан узган Аня ике ай элек кенә кыз бала тапкан иде.

—Ә минеке... полигонда...—диде Ленизa.

—Мондый көнне сонарып булса да килә инде ул!

Аня, җавап көтеп, бераз тынып торды. Саллы гына гәүдәле, алпан-тилпән атлап йөрүче, чал кергән чәчен шома итеп тарап куйган бу хатын бик игътибарлы, ярдәмчел, шул ук вакытта артыгын төпченми, гайбәт сөйли торган гадәте дә юк иде.

—Синең Мидхәтең хуҗалыкчан шул,—диде ул.—Минем Николайга кая инде! Балык тотудан башканы белми... Синекеннән үрнәк алсын иде ичмасам...

«Тәүбә диген... Минекеннән үрнәк алып, әллә кайда йөрсә, ник шунда яр башында балык тотып кына утырмый икән, дип мең уфтанырсың...»

Ләкин юк, монысын әйтмәде Ленизa, тел очында тотып калды.

Аның бакчага байтактан килгәне юк иде. Мидхәт һәммәсен тәртиптә тота: чүп үлән заты юк, түтәлләрне ябарга пленкалар әзерләп куелган. Әллә чыннан монда кунып йөри микән? Ә бәлки, ялгызы гына килмидер?!.

Башка вакытта Ленизa Мидхәтнең уңганлыгы белән мактана иде. Хәзер исә ачуы кабарды: юри шушылай кылана, күршеләр алдында үзе генә эшләгәнен, Ленизаның ялкаулыгын күрсәтү өчен тырмаша! Аның шундый гадәте бар! Баш күтәрми эшли, эшли, эшли! Әрәмәлеккә барасы, су буйларын гизәсе урында, туфракта чокынудан, тузан йотудан арынмый. Аның аркасында Ленизa да беркая бара алмый, берни күрми. Рәтле кешеләр бакча җиренә тоташ үлән чәчәләр дә, су буенда кызынып яталар!...

Карлыган куагыдай биек, куе георгиннарның эре-эре ак, сары, кызыл чәчәкләре, күңелне хушландырасы урында, эчтәге ачу белән сөю катыш җәһәннәм утын тагын да ныграк көйрәтеп җибәргәндәй итте.

Ленизa өйгә керде дә, сумкасын ачып, эчендәге бар нәрсәне өстәл өстенә селкеде. Кульяулык, көзге, ирен буявы ишеләр арасыннан дару капларын аерып алды, шытыр-шытыр ачып, вак төймәләрне учына җыйды. Чиләктән чынаяк белән су чумырды.

Һәм тирән итеп сулыш алып, кулындагы төймәләрне авызына китерде. Шулчак:

—Ленизa!Ленизa!—дигән тавыштан сискәнеп, туктап калды.

Аня кычкыра иде.

—Ленизa! Син өйдәме соң?

Җавап бирми калып булмый иде.

—Өйдә...

—Чәй куеп эчмәкче идем, шырпым беткән... Ни булды?!. Әллә йөрәгең тоттымы?

Күрше хатынның тавышында чагылган борчылу, кызгану, ярдәм итәргә омтылыш шулкадәр көчле иде ки, Ленизаның кинәт хәле китте. Ул урындыкка утырды да, елап җибәрде. Аня аны иңеннән кочып алды, өстәлдәге кәгазь капларга, Ленизаның кулыннан чәчелгән дару төймәләренә күзе төшеп, сискәнеп китте.

—Бу ни бу? Нәрсәгә ул хәтле дару? Кая, мин сиңа бөтнек кайнатып бирим. Эчәрсең дә, бераз ятып торырсың...

—Их, Аня, минем йөрәк ярасын бөтнек белән генә төзәтеп булырлыкмыни? Яшисем килми минем... Ул монда килер дә, минем үле гәүдәмне күрер дә...

—Син нәрсә... Болай кыланырга... Үпкәләшмәгән ир белән хатын дөньяда юк...

—Ул мине күралмый... Әгәр мин юкка чыксам, башка хатын алып кайтыр иде дә, гел бәхетле булыр иде... Ник яшәргә миңа? Ничек яшәргә?

Аня аның башын сыйпады.

—Артыгын ярсыгансың син, һәммәсен эчеңә җыеп, күперткәнсең. Ярамый алай. Эчеңне бушатып, киңәш-табыш итәрдәй беркемең дә юкмыни соң?!

Ленизa башын чайкады.

—Минем дә кая барып, кемгә сыенырга белмәгән чакларым аз булмады,— диде Аня Ленизаның башын йомшак күкрәгенә кысып.—Рухи таяныч кирәк шул адәм баласына, өмет кирәк. Рухи таянычы, алда өмете булмаган кеше тамыры киселгән гөлгә тиң. Аз гына җил бәрсә дә, кубарыла. Үземнән беләм.

—Әллә синең Николай да?...

—Юк. Минем башка яктан... Озак еллар балабыз булмады бит безнең. Кырыктан узгач кына буйга уздым. Шундый куанган идек. Ә ул гарип булып туды, күп тә тормый үлеп китте. Шулай итеп, бала хәсрәте килде миңа. Ә аннан ачысы юк диләр... Минем дә яшисе килмәгән көннәрем булды. Җитмәсә тагын врачлар, бер ел үтми торып балага узасы булма, югыйсә, икенчесе дә гарип туачак, дип кисәттеләр. Минем яшьтә андый сүз ишетүнең ни икәнен белмисең шул әле син...

—Балаң бар бит синең... кызың Алевтина...

—Ул кызга ирешкәнче шактый авыр хәлләр кичерергә туры килде. Мин дә төрле якка бәргәләндем. Чиркәүгә дә бардым. Сабыр ит, диделәр, табибларның сүзенә колак салырга киңәш иттеләр. Башымны кая куярга белми йөргәндә танышларга ияреп клубка барып кердем. Анда Укытучы белән очраштым.

«Встретилась с Учителем»,—диде Аня.

—Нинди фәннән укытучы?—дип сорады Лениза.

—Мәктәп укытучысы түгел. Аны зурлап шулай атыйлар. Башта бер дә исем китми генә тыңлаган идем. Аннары сизәм: җаным тынычлана, күңелем яктырганнан-яктыра.

—Нәрсә сөйләде соң ул?

—Мин аны кабатлый белмим. Үзен тыңларга кирәк... Соңыннан аның янына сәхнәгә мендем. Ул минем хәлемне ике сүздән аңлап алды. Күземә тутырып карады да, синең өчен йолдызларның торышы август аенда кулай, балаң шушы айда яралса, сау-сәламәт туачак, диде. Узган елны август аенда булды бу.

—Сүзе расланды дамы?

—Алечкам томрап тора!

Беразга тынып калдылар.

Лениза Аняның нindидер җәмгыятьме, оешмамы белән элемтәсе барлыгын кемнәндер ишеткән, тик моңа илтифат бирмәгән иде. Хәзер шул искә төште дә, күңелдә шик туды, чөнки соңгы вакытта әллә нинди хикмәтле секта-мәзһәпләр хакында төрле сүзләр йөри иде. Телевизордан аларның яшерен урыннарда очрашканнарын, сәер, шомлы кыланмышларын күрсәтәләр. Арада зур җинаять кылганнары да бар икән. Мәсәлән, Япониядәге шундый бер мәзһәп Токио метросында агулы газ таратып, йөзләрчә кешеләрне зарарлаган. Бу хакта шау-шу бик озакка сузылды.

Лениза шуларны уйлап утырган арада, Аня өстәл тартмасыннан шырпы табып алды.

—Боларны эчәргә беркайчан да соң түгел,—дип, өстәлдә таралып яткан кәгазьләргә ымлады.—Әйдә, чәй эчеп алыйк әле без. Бөтнек чәенең йөрәккә шифасы бик зур.

Алар Аняга кереп чәй кайнатып эчтеләр, аннары бергәләшеп аның түтәлләрен томаладылар. Өстәл янында да, түтәл тирәсендә әвәрә килгәндә дә сүз туктап тормады. Аня йомшак, уйчан тавыш белән Укытучының бик галим кеше икәнлеге, төрле илләрдәге зур философлар белән бәйләнешта торуы, үзенең дә гыйльми хезмәтләр язуы турында сөйләде. Китаплары бик күп шәһәрләрдә тарала, тарафдарлары да меңнәр белән санала икән. Тузга

язмаган хорафатларга ышана торган наданнар түгел, зыялы, укымышлы кешеләр тартыла икән аңа, арада инженерлар, галимнәр, врачлар, укытучылар күп икән... Һәркайсының үз гаме, үз борчулары бар, берсенең дә капчыгы буш түгел. Әмма бергә җыелгач, күзләр ачыла, борчулар тарала. Кеше арасында рәхәт инде ул! Бигрәк тә үз ишләрең белән булганда.

—Ничек алай бер иш була соң алар?

—Фикердәшләр генә җыела бит. Укытучы алып килгән тәгълиматны кабул итә алмаганнар бер килеп тыңлап карый да, китеп бара. Ихлас ышанганнар гына кала.

—Нинди тәгълимат соң ул?

—Укытучының үзен тыңлап карасаң иде син... Ул хәзер монда.

Ленизаның икеләнгәнен күреп:

—Ошамаса, борылырсың да чыгып китәрсең,—дип дәвам итте Аня.—Анда берәүне дә көчләп тотмыйлар.

—Кайда... очрашасыз соң сез?

—Клубта очрашу киләсе атнада була. Иртәгә китапханәдә җыелып сөйләшәчәкбез.—Аня район китапханәсендә эшли иде.—Кеше күп булмый, актив йөрүчеләр генә.

Лениза ярыйсы гына тынычланып киткән иде инде. Ни дисәң дә, китапханә йөрәккә якын урын, институтта укыган кеше өчен бигрәк тә. Ә нигә кереп чыкмаска? Андый җирдә начар гамәл кылынмас.

...Киткәндә, ул үз бакчасына бүтән кереп тормады. Мидхәт килер дә, һәммәсен җайлар, дип уйлады.

Ул кайтканда, күптән караңгы төшкән, тәрәзәләрдә ут юк иде. Ә Рамилә кайда? Әтисе үзе белән бакчага алып киткәндер, мөгаен. Эштән чыккач, балалар бакчасына сугылмый калганы юк бит аның...

Берәр сәгатьтән ишек кыңгыравы зыңгылдады. Бусагада бер кулына кечкенә арба, икенче кулына Рамиләне күтәреп Рәйсә басып тора иде.

—Уф, ярый әле кайткансың,—диде ул.—Икенче керүем инде, бая ишек ачучы булмады. Кайда йөрдең соң син? Нигә Рамиләне барып алмадың?

—Мидхәт барырга тиеш иде бит!—диде Лениза кызын аннан алып.

—Мидхәтең командировкага киткән бит, белмисеңмени?

—Кайчан киткән?

—Көндез үк инде. Кайсыдыр шахтага җибәргән шартлаткычлары тиешле җиргә куйгач шартламаган, ди. Кире ала алмыйлар, орыныргa куркалар икән. Көне-сәгате белән килегез дә, үзегез казып алыгыз, дип телеграмма сукканнар. Хәлләр харап ди анда. Шахтада эш бөтенләй туктаган.

—Миңа берни әйтмәде бит ул!

—Син бүген эштә идеңме соң?

—Поликлиникага барган идем...

—Сине тапмаган инде алайса... Тәрбиячеләргә әйтеп калдырган, бүген килә алмыйм дигән. Алар безгә шалтыратты да, барып алдым менә. Иртәгә санитария көне икән, кунарга калдырмаганнар. Мин аны Илдус белән бергә әйбәтләп ашатып куйдым инде.

—Уз әйдә, нишләп бусагада торасың?

—Рәмис, озак йөрмә, дип артымнан кычкырып калды анда,—диде Рәйсә шаян елмаеп.—Ятар алдыннан тәмләп чәй эчә торган гадәте бар аның.

—Бәби түгел лә, чәйне имезлектән эчермисеңдер!

Авызыннан төртмәле сүз ычкынганын Лениза үзе дә сизми калды. Тик Рәйсә моны аңламады, әллә аңлап та илтифат бирмәде.

—Анысы да булгалый, бер-беребезгә кашыклап каптырабыз!—диде шаяруга борып.—Чәйнең иң татлы балы—парлашып-чөкердәшеп эчүдә, ди ул.

Рәйсә бәхетен уртаклашканны көтеп, елмаеп карап тора иде. Йөзе-күзе

күптән төзәлгән, күзлек пыялалары астыннан ике бит алмасы алланып тора.

—Сулга йөрүдән туктадымыни?—дип сорады లениза.

—Тынды, Аллага шөкер. Тиз туктады. Югыйсә, ирләр алар бер тайпылса, ике елсыз игә килми.

—Нишләп ике ел?

—Аларның срогы шундый. Хатын-кызга кузгалган гыйшык дәрте ике елга гына чыдый. Шуннан соң сүрелә.

—Үз хатынына дамы?

—Гыйшык бит ул күнел эше, загс язуына карамый! Ә аларның күңеле шулай яратылган.

—Ике елдан соң ничек яшиләр?

—Ир-хатын ике елда бер-берсенә күнегә, җайлаша. Уртак милек, фатир... Бала!.. Балага булган мәхәббәт сүнми. Ә сөяркә нәрсә... Аягың тартмаса, бармыйсың гына...

—Ул шулай икешәр ел әллә кем кочагында аунап кайтсын, ә син шуны...

Лениза сүз табалмый торды.

—Пычрак өстерәлчекне кочак җәеп каршы аласыңмы?—дип дәвам итте аннары.—Ул башканы синнән артык күреп, синнән көлеп йөргән. Син шуны гафу иттенме?

—Ә ул миннән гафу сорамады.

—Кичер мине дип тә әйтмәдемени?

—Бер сүз дә әйтмәде.

—Нәрсә диде соң ул?

—Кайчан?

—Ну, теге хатын яныннан кайтып кергәч?

—Эштән кайтты ул. Ни дигәне истә калмаган. «Карчык, ашарга әзерме», диде бугай...

—Әзер идеме?

—Хәтерләмим инде. Әзер булмаса, бераз көткәндер. Баланы карагандыр. Шунысын беләм: ул кайткач, өйгә ямь керә, кот инә.

—Гомер буе шулай яшәрсезме?

—Бүтәннәр аннан яхшыракмы әллә?—дип сорауга сорау белән җавап бирде Рәйсә.—Унга карыйсың, сулга карыйсың... Берсенең дә ире фәрештә түгел, һәркайсының кимчелеге бар... Син дә Мидхәтнең житмәгән ягын табасыңдыр...

—Бар , нигә булмасын. Сина гына идеал булып күренә ул, синең генә күзне кыздыра...—диде Лениза үзе дә сизмәстән.

Рәйсәнең ияге салынып төште, калын пыяла астындагы күзләре зур ачылды.

—Авызыңнан жил алсын! Син нәрсә! Минем хакта начар уйласаң уйла, иренә нахак бәла ягып гөнаһлы була күрмә! Булмаганны эзлиләр димени! Булганына күз йомарга өйрәнергә кирәк!.. Ай, нишләп торам соң әле мин дөньямны онытып? Сүз бозау имезә... Үпкәләп утырмасын тагын!

Ул борылып, таш баскычтан аска томырылды, үкчәләре тыпырдаганы гына яңгырап калды.

Ул төнне Лениза бик озак йокыга китә алмады.«Алар, мөгаен, ятакта бер-берсенә бик тә ярашалардыр,—дип уйлады ул Рәйсә белән Рәмис турында.—Сөяркәсен сөйгән ир үз хатынын да сөя, диләр бит». Ләкин Мидхәт ятакта суынды! Ул Рәмис түгел, бөтенләй башка! Икене берьюлы йөрәгенә сыйдырмас. Лениза да иренең йөрәк түрендәге урынын башкалар белән бүлешә торганнардан түгел. Ә ул урынны кемдер билэгән. Рәйсә түгел, бүтән... Ә бәлки, ул «бүтән» Казандадыр? Командировкада йөргәндә анда кереп чыгу ягын тагын табар, бәлки?..

Ул төн Лениза өчен бик озын тоелды.

Ул төнне каты кырау төшеп, капланмаган түтәлләрдәге кыяр-помидорларны, ак, сары, кызыл чәчкәле гөлләрне—һәммәсен кара күмер итте.

* * *

Китапханәнең кечерәк кенә уку залында, алгы рәттәге өстәлләр артында унлап кына кеше утыра иде. Мондый җиргә гадәттә студентлар, өлкән класс укучылары йөри, китап укыйлар, конспект язалар. Биредәгеләр исә утыз белән илле арасында булып, күпчелеге хатын-кыз иде. Өстәлләре буш, үзара шыпырт кына сөйләшәләр. Аня белән Ленизаны күргәч, сүзләрен өзеп, тынып калдылар.

—Таныш булыгыз, минем күрше бу, исеме Лениза, һөнәре инженер-химик,—диде Аня.

—Исәнмесез,—диде Лениза.

—Саумысез... Хуш киләсез безнең арабызга...—дип урыныннан кузгала төшеп, кулын сузды алгы өстәл артыннан кара костюмлы, башына ак шарф ураган, чандыр гәүдәле, иллеләр тирәсендәге апа.

Барысы белән дә кул кысышып, исәнләшеп чыгарга туры килде. Һәммәсе үзенең исемен һәм һөнәрен әйтте. Чыннан да укымышлы халык җыелган икән: инженерлар, табиблар, музыкантлар, фән әһелләре. Киемнәре пөхтә, кыяфәтләре затлы. Йөзләрендә җитдилек тә, нindидер зур вакыйга көткәндә була торган дулкынлану да чагыла. Лениза бу кешеләрдә тагын бер уртаклык барын күреп алды: хатын-кызлар һәммәсе бер үк төрле медальон таккан иде—нечкә чылбырга тагылган ырмау эчендә бишпочмаклы йолдыз. Алтын булса кирәк, ялтырап тора...Ирләрнең пинжәк-куртка якаларында да шундый ук значок бар, тик сары түгел, ак металлдан ясалган.

Лениза, арткарак узып, аерым бер өстәл артына утырды. Китап белән шыплап тутырылган киштәләр, тезелеп киткән урындык-өстәлләр—студент чактан күнегелгән бу мохит аның күңеленә бик тә ятышлы иде. Шул ук вакытта нindидер бер серлелек бар иде монда һәм бу серлелек шомландыра торган түгел, ә бәлки якты иде, гүяки нindидер бик тә кызыклы яисә шатлыклы вакыйга булачак иде.

Һәм менә.... Ишек ачылды, бусагада Ул күренде. Һәммәсе урындыкларын шудырып торып бастылар.

—Исәнмесез! Нур һәм сафлык!—диде ул күңелгә сары май булып ятышлы куе тавыш белән һәм уң кулын учы белән башкаларга каратып, күкрәк турында сулга-уңга селкеп куйды.

—Нур һәм сафлык, Укытучы (Учитель)!—дип җавап бирделәр бүлмәдәгеләр бертавыштан. Алар да кулларын түш турына күтәреп, салмак кына болгап алдылар. Лениза үзе дә сизмәстән алар артыннан: «Нур һәм сафлык...»—диде, кулы ихтыярсыздан башкалар ясаган хәрәкәтне кабатлады.

Зур ачылган күзләре исә, карточкага төшереп алгандай, каршыда басып торган затның бөтен кыяфәтен күңелендә уйды да куйды. Аның затлы бүрек кебек күпереп торган кыска кара чәчле йомры башын, шома итеп кырылган булуына карамастан каралып торган киң яңаклы түгәрәк йөзен, сул кашын кыйгачлап узган яра эзен, киң, шакмаклы ияген, бүлтәеп торган муен төенен... Аның буйлы кара костюм кигән озын-таза, мөгаен бик көчле буй-сынын, күзләрне чагылдырырлык дәрәҗәдә ялтырап торган бик тә кыйбатлы очлы башлы шиблетларын... Чибәр дип булмый, әмма гайрәтле ир-егет, алай гына да түгел, чын мәгънәсендә җинүче иде бу.

Ә шулай да өнсез иткәне бу кешенең тышкы кыяфәте түгел иде. Мәһабәт буй-сын, килешле йөз-бит күпләрдә бар ул! Үз-үзен кадерләгән-караганнары, шәп киенгәннәре, чыраена акыллы кыяфәт чыгарганнары да күп. Хикмәт шунда ки: алда санап үтелгән барлык сыйфатлар бу затның кысасы гына иде.

Асылташлар өчен саф алтыннан, бик зәвыклы бизәкләр үреп, шундый кысалар ясыйлар. Ләкин ул нихәтле генә затлы булса да, әйбернең чын кыйммәте анда түгел, ә бәлки аның уртасында балкып торган җәүһәрдә. Кысалар үз эчендәге ташның матурлыгын, һиммәтен ялтыратып күрсәтү өчен эшләнә.

Бу кешенең дә киеме, кыяфәте, үз-үзен тотышы—барысы да күзләренең серле нурын, тирәнлеген күрсәтү өчен кирәк иде кебек. Ни текәлеп карасаң да, аларның төсен ачык кына әйтеп булмый иде: әллә коңгырт, әллә сорырак микән... Ул сина туры гына төбәлмәгән дә кебек, бәбәкләре куе-зәңгәр томан белән өртелгән шикелле. Әллә бүлмәдәге һәммә кешене күрә, әллә үзенең серле уйларына бирелгән... Ләкин аннан карашны алып булмый. Ихтыярсыздан син, минем тарафка бер генә тапкыр кыска, куе керфекләрен сирпеп, күз салсын иде, дип эчтән ялварасың...

Менә ул алдагы өстәл янына килеп, бүлмәгә йөзе белән басты, кулындагы портфелен куйды.

—Әйдәгез, утырышыйк,—диде.

Беренче карашка, мондагы мохит чыннан да мәктәп классын хәтерләтә иде. Алдагы өстәл артында укытучы утыра, башкалар зур дикъкать белән аңа текәлгән. Ләкин ул шундый ачык чырай белән, йомшак итеп сөйләшә, һәркайсын шундый зур дикъкать белән тыңлый—бер сүз белән әйткәндә, үзенең башкалардан өстенлеген берни белән дә сиздерми иде. Биредә син үзеңне һич кенә дә гади укучы итеп сизмисең. Бу—сагынып-зарыгып күрешкән дусларның, фикердәшләрнең очрашуы иде. Ә каршыда, Лениза алдан уйлаганча укытучы түгел—Остаз утыра. «Учитель»нең татарчада мондый мәгънәсе дә бар бит. Аралашу гади кебек тоелса да, эчке бер киеренкелек, нык дулкынлану сизелә: йөзләр алланган, күзләр елтырый, тавышларда үзенә бер куанычлы тынгысызлык, хәрәкәткә омтылыш ишетелә.

Лениза тыңлап кына утырды. Алай да Остаз ара-тирә аңа карап ала, еш кына, ул аңласын өчен, башкаларга мәгълүм булган нәрсәләрне дә кабатлый иде булса кирәк. Аның һәр сүзе Ленизаның күңеленә күптән кипшенгән туфракка яуган талгын, җылы яңгыр кебек сеңеп кенә барды.

Бирәдәгеләр—безнең чорның үсешенә тәңгәл килгән, шушы заман кешеләренең рухына яраклы яңа тәгълиматның тарафдарлары, алдынгы карашларны алга сөрүчеләр икән.

—Без бер динне дә инкар итмибез,—диде Остаз. Бу урында берничә кеше аның сүзләрен ияк кагып хуплады һәм борылып, Ленизага мәгънәле караш салып алды.—Безнең «Нур һәм сафлык» тәгълиматын кабул итүчеләр арасында христианнар да, мөселманнар да, яһүдләр, буддистлар да, атеистлар да бар. Чөнки без кешелекнең алга баруын, вакыт узган саен күбрәк мәгълүматка ия булуын беләбез, шуны исәпкә алабыз. Галәм өзлексез хәрәкәттә, кешелек аның серләрен өйрәнә, яңадан-яңа мәгълүмат туплый. Шуны исәпкә алып, Илаһи Зат җиргә һәр яңа чорда яңа пәйгамбәрләрен җибәреп торган. Ләкин менә берничә гасыр инде кешеләр ул җибәргән пәйгамбәрләрнең берсен дә аңлап, тиешенчә зурлап кабул итә алмадылар.. Кемнәрдер Будда сөйләгәннән башканы белми, кемнәрдер Иисус вәгазеннән ары узмый, кемнәрдер Мөхәммәт пәйгамбәр әйткәннәргә инана. Тик алардан соң яшәеш бик нык үзгәрде, кешеләрнең аңы да бөтенләй икенче бит инде...

Ленизаның хәтеренә келт итеп чиркәүдә атакай әйткән сүзләр килеп төште: «Ходa безгә әйткәнен әйткән...» Әйе, шул чор кешеләренең аңына барып җитәрлекне әйткән... Ләкин без чыннан да Иисус заманындагы кешеләр кебек түгел, бөтенләй башка!

«Нур һәм сафлык» тәгълиматы җиһанны, бар тереклек ияләрен, адәмнәрне бар иткән Илаһи Затның, Бөек Кодрәт Иясенең барлыгын таный. Ул югарыда, биектә, ләкин искергән диннәр раслаганча, җиде кат күк өстендә түгел, ә

бәлки галәм кинлегендә хәрәкәт итә. Барча җисемнәр хәрәкәтләнгән кебек, ул да урынын алыштыра. Хәзерге вакытта ул Сириус йолдызында.

Адәм баласының һәркайсы күкләр белән, галәм белән аерылгысыз тыгыз бәйләнгән. Галәмнән килгән нурланыш безнең һәркайсыбызга килеп ирешә, бездән сибелгән дулкыннар да галәмгә тарала. Тик менә адәм балаларының бик сирәге генә Бөек Кодрәт Иясеннән килгән нурланышны тоеп, мәгънәсен аңлап, аны башкаларга җиткерү сыйфатына ия була ала. Моңа ирешү өчен тәнеңне дә, җаныңны да камилләштерергә кирәк. Остаз нәкъ менә шундый—галәмнән килгән нурланыш-хәбәрләрне кабул итә белүче, аңлаучы—эзотерик—икән.

«Ул нурланыш миңа да килеп ирешә бит инде, мин дә аларны аңлый алыр идем...»—дигән татлы хыял Ленизаның башын әйләндереп җибәрде.

Югарыдан килгән хәбәрләргә караганда, хәзерге вакытта җир йөзенең төрле урыннарында ахырзаман хәлләре бара. Моңа кешеләр үзләре гаепле. Кызганычка каршы, бүгенге чорда адәм балаларыннан галәмгә тискәре тәэсир итә торган дулкыннар күп китә. Соңгы елларда кешеләрнең бихисап явызлыклар кылуы, пычрак уйлар, шөгыльләр белән мавыгуы күз алдында бит. Болар һәммәсе галәмнең камиллеген боза, анда төрле гайре табигый үзгәрешләр туүга китерә. Шуннан соң һәртөрле фаҗигаләрнең көчәюенә, сугышлар башлануга гаҗәпләнергә дә кирәкми. Әгәр шулай дәвам итсә, кешелекнең киләчәге бик тә аяныч булачак.

Моны булдырмас өчен, бар көчебезне куеп, адәм балаларыннан космоска, галәмгә китә торган начар дулкыннарны киметергә тиешбез. Иң элек кешеләрнең үзләрен үзләре сафландыруы зарур. Тәннәре дә, күңелләре дә чиста булырга тиеш аларның.

...Бик тә аңлаешлы һәм йөрәккә якын иде эзотерик Остазның сүзләре!

—Мин сезгә үземнең яңа китабымны алып килдем,—дип портфелен ачты ул. Китап калын гына, ялтыравык тышына йолдызлар, планеталар һәм аларга кулларын сузган кыз белән егетнең сурәте ясалган иде.

—Таратырбыз, таратырбыз,—диешеп, һәммәсе кулларын суздылар.

—Сез дә укып карарсыз, бәлки?—дип томанлы да, үткен дә карашын Ленизага төбәде ул.—Эзотерикларның берәр китабын укыганыгыз бармы? Юкмыни? Аларны аңлар өчен күпмедер күләмдә әзерлек кирәк, билгеле. Сез югары белемледер бит?

—Аңлатырбыз, ярдәм итәрбез,—диде ак шарфлы хатын.

—Аңлату җитми шул, җитми,—дип аның сүзен хуплады Остаз.—Шунлыктан, халыкның күпчелеге томана хәлендә яши бирә. Сез биредә күпме листовка, күпме журналлар тарата алдыгыз?

Шулай итеп, сүз үзеннән-үзе халык белән эшләүнең кыенлыкларына барып терәлде. Күп кенә шәһәрләрдә «Нур һәм сафлык»ның листовкаларын, игъланнарын бастыру, җыелышып сөйләшү-киңәшү, килгән кешеләрне кабул итү өчен аерым бүлмәләре, хәтта биналары да бар икән. Ә менә «Н» шәһәрендә бу мәсьәләдә кыенлык килеп чыккан. Бер кечкенә куышың да булмагач, халык белән ничек эшләмәк кирәк?

—Дәрәҗәле, бай кешеләрне җәлеп итәргә кирәк,—диде Остаз.

—Алар шул һәркайсы үзенең нәселе тоткан дингә тартыла. Урыс булса, чиркәү сала, татар булса, мәчет торгыза,—дип зарланып алды ак шарфлы хатын.

—Чын йөрәктән түгел, халык каршында гына яхшатланалар,—дип нәтиҗә ясап куйды Остаз.—Чын хакыйкатьне аңларга теләмиләр. Алар өчен Алла—акча! Долларга табыналар!

Ә Ленизa калтыранган бармаклары белән китапны сыйпый иде. «Герман Светлый. Нурлы юлдан сафлыкка» дип язылган иде аның тышына. Исеме Герман, димәк...

Бер атнадан шәһәрнең зур гына мәдәният сараенда халык белән очрашу

булачак икән. Шуны ничек оештыру хакында сөйләштеләр. Һәм, ниһаять Остаз урыныннан кузгалды. Лениза анын сонгы тапкыр үзенә генә елмаеп каравын, бирәр ым кагуын, һич булмаса керфек сирпүен көткән иде. Бик теләгән, өметләнгән иде. Ләкин Остаз бушап калган портфеленен ялтырап торган биген шартлатып япты да, башын күтәрми генә хушлашып, жинел. нык адымнар белән чыгып та китте.

—Бездә бик әйбәт журналлар да бар,—диде Аня.—Теләсән, берничәсен ал.

Лениза анын түшендәге медальонга текәлгән иде. Остазнын рухын чагылдырган тамга...

—Ә мондыйны каян алып була?—дип сорады ул Аянын түшенә ишарәләп.

—Бездә сатыла ул. Төрлесе бар: алтыны кыйбатрак, акча тимереннән ясалганы арзан гына. Әнә, Рәсимә сата,—диде ак шарфлы хатынга ымлап Аня.—Күбрәк ал син аны, эшегездә күрсәтерсен. Матур бит.

Герман Светлыйнын китабын чыннан да бер төн эчендә укып чыгу мөмкин түгел иде, чөнки ул шактый катлаулы фәнни телдә язылган икән. Астрономия, космогония, физика, психиатрия, медицина—күп фәннәрдән мәгълүмат тупланган иде монда. Шунын өстенә астрология, теология тәгълиматлары да бирелгән иде. Әйе, мондый хезмәтне зур галим генә яза ала!

Анын урынына Аня биргән журналлар су кебек эчелә икән. Сонгы битләреннән шул да мәгълүм булды: алар бик күп итеп, берничә телгә, хәтта татарчага да тәржемә ителеп басылып чыккан.

Менә берсе: тышында шарлавыклы-инешле гөлбакча сурәтләнгән. Гөлләр арасында нигъмәт тулы өстәлләр; алар тирәсендә елмаешып утырган кешеләр. Олысы-кечесе, ак тәнлесе, кара тәнлесе—һәммәсе бергә, бертигез. Бер читтәрәк кечкенә кыз бала аккошнын муенын кочаклаган, икенче якта бер малай бүренен сыртын сыйпый.

Ожмах манзарасы иде бу. Баксан, ул күкләрдә түгел, жир йөзендә булачак икән, һәм дөньянын жәннәткә әверелүен көтәргә озак та калмаган инде. Тик монын өчен ашыгыч рәвештә жирне тазартырга кирәк. Барыннан да бигрәк адәм баласынын күнелен сафландырырга, шакшыдан арындырып, изгелек белән тутырырга...

...Икенче көнне Рамиләне бакчадан алып кайтканда, Лениза тагын китапханәгә сугылды. Кичәге хатыннарнын берничәсе анда Остазнын яна китабы хакында сөйләшеп утыралар иде.

—Әгәр халык боларны белсә, безнен тормыш бөтенләй башкача булыр иде шул!—дип уфтаныштылар алар.—Укымый шул халык! Надан!

Сүз Остаз куйган бурычка—китап-журналларны күбрәк таратуга килеп терәлде. Ә монын өчен бүлмә кирәк иде, бүлмә...

—Ксерокс алырга акча тапкан идек инде, шуны көйләп эшкә жибәрергә генә урын булса да ярап торыр иде...—диде Рәсимә.

—Шундый зурмыни сон ул?

—Зурлыкта түгел хикмәт. Эшләтергә кирәк бит аны. Кәгазьләрне каядыр куярга, аннары таратырга. Бераү гел шунда булырга тиеш, килгән-киткәнне кабул итәргә. Үземдә генә жайлап жибәрер идем, улларым рөхсәт итми...—Ул авыр сулап куйды.—Кришнаитлар шул алар...

—Балаларыгыз кришнаит, үзегез мондамы?—дип сорады Лениза гажәпләнеп.

—Ни анлый сон әле алар? Ялгыш юлдан киттеләр,—дип башын аска иде Рәсимә.—Барып каптылар... Белмиләр шул, анламыйлар!—дип өзгәләнеп әйтеп куйды аннары.—Анлатып житкерә алмыйбыз... Остаз белән очрашуга чакыру кәгазьләрен күбрәк таратасы иде бит! Кайда гына басарга сон?

—Ә монда булмыймыни?—дип уку залын күздән кичерде Лениза.

—Ю-ук, рөхсәт итмиләр. Хөкүмәт учреждениесе бит бу. Очрашуларны да

яшереп кенә үткәрәбез.

Ленизаның да бу изге эшкә үз өлешен кертәсе килә иде. Чакыру билетларын басарга гына булса да... Мидхәт командировкада. Әле кайчан кайтыр... Анда тагын комиссия төзегәннәрдер, мөгаен...

—Минем квартир зур түгел түгелен,—диде ул.—Бәлки, ике-өч көн бездә эшләп алырсыз?

—Нишләп ике-өч көн генә?

—Ирем командировкада чакта, дигән идем. Берәр атнадан кайтыр ул.

—Атна эчендә башка берәр куыш табар идек әле!—диде Рәсимә тәвәккәл тавыш белән.—Хәзер үк барып карарга буламы?

Ул шулхәтле җитез атлый иде, аның артыннан трамвай тукталышына барып җиткәнче, кечкенә арба белән бала тарткан Ленизаның сулышы капты. Фатирны күздән кичергәч, Рәсимә иреннәрен кысып:

—Нишлисең, шуннан да әйбәте юк бит,—диде.—Алай да, Остаз үзе килеп караса, яхшырак булыр иде. Мин аңа әйтермен.

Аның бу сүзләреннән Ленизаның йөрәге кысып куйды. Ул Рәсимәнең түшендәге медальонга ишарәләде:

—Боларны син сатасың дигәннәр иде.

—Сатам. Акчасын тулысынча үзебезнең кассага тапшырам.

—Кыйбатмы?

—Алтыны мең ике йөз. Көмеше алтмыш тәңкә. Тимере егерме биш сум. Күбрәк алган кешегә арзангарак та бирәбез. Чылбыры да кирәкме?

—Чылбыры үземдә дә бар. Аня әйткән иде, бурычка да алып була, дигән иде.

—Сиңа бирәбез. Акчаң булгач, түләрсең.

—Әгәр мөмкин булса, кызыма да алыр идем.

—Яследә андыйны тактырырлар микән?—дип икеләнә калды Рәсимә.

—Тәрбиячеләр күрмәслек итәрмен.

Рәсимә сумкасыннан медальоннарның сарыларын, акларын чыгарып өстәлгә сипте.

—Бишне алсам ярыймы?—диде Лениза.

—Сиңа ярый. Алган кадәресенә язу бирерсең, шул гына. Остаз монда килергә кайчан вакыт таба алыр икән инде,—дип борчылып куйды Рәсимә.—Телефонның бардыр бит? Номерын бир әле. Аның белән сөйләшүгә, шалтыратырмын.

...Остаз шул ук кичне килде. Сәгать тугыздан соң Рәсимә шалтыратып, бу хакта әйткәч, Ленизаның тез буыннары йомшап китте.

—Үзе генәме?—дип сорады ул телен чак әйләндереп.

—Белмим шул. Бәлки, берәрсе белән булыр. Анысын тикшерү минем эш түгел.

Рамилә инде йоклаган, бүлмәдә кызыл торшер гына янып тора иде. Лениза, ашыгып, кием шкафын ачты. Чалбар кияргә ярамас... Әллә кайчан алынып та, монарчы рәтләп киелмәгән плиссе юбкасы бар иде. Өйдә килешергә тиеш. Ак кофта... Башка ак шарф урарга... Рәсимә юкка гына бәйләмидер, шулай тиештер... Ул алгы бүлмәгә чыгып, диварга беркетелгән көзге каршына басты, кыяфәтен күздән кичерде дә, канәгать калды. Иренен чак кына кызартып, каш-керфекләрен төзәтеп куйды. Алай да һаман нидер җитми иде кебек. Кире бүлмәгә кереп, тартмадан «Нур-сафлык» медальонын алып такты. Янә алгы бүлмәгә чыгып, көзгегә карады. Нечкә бөҗра эчендәге бишпочмаклы йолдыз аңа килешә, шул ук вакытта күнелне һәртөрле шикшөбһәдән, гөнаһлы теләкләрдән арындыра, хәтта башкаларның нәфесле карашыннан да саклар кебек иде.

Кыңгырау тавышына ул дерт итеп куйды.

—Кем бар анда?

—Минем киләсемне сезгә әйтеп куймадылармыни?—диде таныш тавыш.

Ишек ачылганда, ул шундый ягымлы, үз итеп елмаеп басып тора иде, Ләниза да ирексездән елмаеп җавап бирде.

—Нур һәм сафлык! Хәерле кичләр!

—Нур һәм сафлык! Исәнмесез, хөрмәтле Остаз! Узыгыз!—диде Ләниза әкрен тавыш белән.—Гафу итегез, бала йоклый иде.

—Ә ник аның өчен гафу үтенергә? Баланың вакытында йоклавы яхшы.

Ул кызыл ут белән яктыртылган бүлмәгә башын сузып карады да:

—Кая?—дип сорады.

—Нәрсә... Кая?..

—Ксерокс, кәгазьләр.

—Китермәделәр бит әле. Рәсимә бүлмәне бүген генә карап китте.

—Бер рәтле эшләре юк! Монда минем бүген үк үрчетәсе кәгазьләр бар иде!

Шулай дип, Остаз кулындагы портфельгә шапылдатып сугып куйды. Ләниза гаепле кешедәй башын иде.

—Гафу итегез,—диде.—Белмәдем...

Кунак аның каршында биегәеп, бүлмә ишеген каплап тора иде. Менә ул каты бармаклары белән Ләнизаны иягеннән тотып алды да, баласытып башын күтәртте:

—Ә ник гафу үтенәсең? Синең гаебең юк бит монда.

Ләниза ни дип җавап бирергә белмичә һәм аның карашына түзә алмыйча, керфекләрен аска төшерде.

Остаз аның ияген ычкындырды да, үз итеп шаяргандай:

—Кунакларны шушылай бусагадан борып җибәрәләрме әллә сездә?—диде.—Бу якларда якты чырай, такта чәй, дигән әйтем бар, дип ишеткән идем. Кайда якты чырай? Кайда такта чәй?

Ләниза аш бүлмәсенең ишеген ачты:

—Әлбәттә, әлбәттә,—диде.—Хәзер була... Узыгыз... Утырыгыз...

Күпмедер вакыттан соң алар кара-каршы чәй эчеп утыралар иде инде.

—Менә чия кайнатмасы, монысы җиләкнеке...—дип ана таба савытларны этте Ләниза.—Сез, Остаз, кайсын яратасыз?

—Мин чәйне шикәр белән генә эчәм. Ә нигә «Остаз» дип дәшәсең мина? Исемемне белмисеңмени әле?

—Беләм, китап тышлыгында язылган бит. Ләкин ничек дәшәргә? Остаз Герман, дипме, әллә Герман Остазмы?

—Якын кешегә алай чачаклап-чуклап дәшмиләр ләбаса!

Һәм ул Ләнизаның аңа гаҗәпләнеп текәлгәнен күреп, җинелчә көлеп җибәрде.

—Чит-ятны өйгә чакырмыйлар, шулай бит? Бәлки, сезнең монда башкачадыр?

—Сез бит... Эш белән... Рәсимә әйтүе буенча...—дип мыгырданды Ләниза.

Герман өстәл почмагы аша кулын сузып, аның беләгеннән тотып алды.

—Ташла,—диде.—Сүзләрдәмени хикмәт.

—Ә нәрсәдә?

—Бөтен хикмәт күзләрдә, мышонок! Син минем болай дигәнемә үткәләмә. Коты алынган тычкан баласы кебек дер калтырап утырасың. Китапханәдә очрашуны онытгыңмыни? Миңа ничек караганыңны күрмәде, дип беләсеңме әллә? Карашың белән чакырдың син мине. Үтенеп, өзелеп чакырдың. Димәк, мин сиңа чит түгел. Шулай булгач, Герман дип кенә дәш. Ә менә син үз исемеңне әйтмәдең бит әле. Әйдә, танышыйк!

Аның мәгънәле елмаюы җанны өтте, беләгеннән саркыган кайнарлык тамырлар буйлап йөгерде.

—Лениза исемле мин...

Шулай диде ул, карашын кунагының ак күлмәк җиңеннән сузылып чыккан куе кара төкле беләгенә текәп. Шул төкләреннән үк бу ирдән үзенә бер гайрәт, кыргый бер көч саркый иде шикелле.

—Лениза, кадерле кунакларны чәй белән генә сыйлыйлармыни соң сездә?

—Гафу итегез... Тәмле әйбер пешерергә өлгермәдем...

—Мин башканы әйтәм... Запасыгыз юкмыни?

Лениза шунда гына аңлады. Урыныннан торып, бүлмәгә керде, шкафның ябык киштәсен ачты. Анда алай-болай кирәк булса дип Мидхәт әзерләп куйган өч шешә тора иде: шампан шәрабе, «Алиготе» һәм гап-гади аракы. Хуҗабикә күтәреп кергән шешәләрне күргәч, Герман:

—Йөзәр грамм булса, шул җитә,—диде.—Без сәрхүшләр түгел, шулай бит?

«Йөз грамм» ул аракы иде, билгеле. Лениза үзенә «Алиготе» ны да салмакчы иде, кунак:

—Анысы белән авыз пычратып тормыйк инде без,—диде.—Нәрсәдән ясалганы да билгесез.

Лениза кечерәк рюмкалар алып кергән иде, Герман зурракларын сорады:

—Йөз грамм сыярлык булсын инде.

Бәллүр бокалларны мөлдерәмә тутыргач:

—Әйдә, соңгы тапкыр бер татып кал,—диде.—Моннан ары тиз генә тәтемәс.

Һәм Ленизаның йөзендә сорау галәмәте күреп, аның түшендәге медальонга ишарәләде:

—Син чынлап торып безнең сафларга басарга карар кылгансың, шулай бит?

—Әйе, чынлап...

—Алай да безнең тәртипләрне белеп бетермисеңдер әле. «Нур-сафлык» тарафдарларына эчү каттый тыела. Бездә—сухой закон!

«Ә соң син үзең?..»

Болай дип турыдан-туры сорарга Ленизаның кыюлыгы җитмәде, әмма Остаз аңлады. Сөйкемле балага карагандай яратып, сокланып күз сирпеде дә:

—Бу инде югарыдан шулай кушылганга түгел, ничарадан бичара, дигәндәй, аптыраганнан куелган кагыйдә. Безнең халык эчә башласа, чаманы белми, ямьсезләнә, тәртипсезләнә. Шуңа күрә генә сафлануның бер шарты итеп хәмердән тыелуны таләп итәбез. Ә без үзебез чаманы югалтмыйбыз, шулай бит? Аннары син безнең сафка кереп тә җитмәгән бит әле.

Шуннан соң Ленизаның зиһенен ураган томан тәмам куерып киткәндәй булды. Герман аңа җан турында, тән турында сөйләде. Адәм баласының җаны мәңгелек икән, тик ул бер тәннән икенчесенә күчеп кенә йөри. Остаз үзе моннан ике гасыр элек Һиндстанда далай-лама булган, йөз ел элек—Африкада кабилә башлыгы...

—Сез гади кеше булмагансыз инде, әлбәттә,—дип хуплады аның сүзләрен су урынына эчеп утырган Лениза.

—Җан беркайчан да юкка чыкмый, ә менә тән—фани. Ул кешегә газапланыр өчен дә, ләззәт алыр өчен дә бирелгән. Газапларны киметеп, ләззәтләрнең тәмен татырга өйрәнү адәм баласының үзеннән тора.

Лениза монысы белән бәхәсләшергә омтылыш ясады:

—Газапларны сорап алмыйлар бит. Чир көтмәгәндә килә. Йә машина бәреп китә. Яисә... сөйгән ярың сиңа суына, башкага гашыйк була...

—Тәне җәрәхәтләнмәгән, һич булмаса сыдырылмаган кеше дөньяда юктыр. Менә шул җәрәхәтләрне төрле кеше төрлечә кичерә. Берәүләр җинел генә ярадан да аһын җуя, икенчеләр үз тәненә үзе хәнҗәр белән сызып җибәрә—эһ тә итми. Бар шундый кабиләләр, андагы кешеләр тәннәренә юан-юан энәләр кадыйлар, үз-үзләрен кан чәчрәп чыкканчы камчы белән яралар... Түзәләр бит,

авыртудан егылып, бәргәләнеп ятмыйлар... Киресенчә, сызлануларны җиңү аларга үзенә бер рәхәтлек, ләззәт бирә... Адәм баласына газапларны кичерү бик кирәк. Ул аларга мохтаҗ! Ипинең чын тәмен ачлык күргән кеше генә белә, дөньяның ямен дә кайгы-хәсрәт кичергән, газапланган адәм баласы гына тоя.

Тагын ниләр сөйләнгәндер, соныннан аларын Лениза хәтеренә төшерә алмады. Кайсыдыр мизгелдә Герман зәнгәрсу рәшә өртелгән күзләрен ана төбәгән хәлдә урыныннан кузгалды, аның артына килеп басты да, зур, йомшак, кайнар, шул ук вакытта авыр кулларын иңбашларына куйды. Аннары... кинәт... өермә китереп бәргәндәй булды. Ул, пинжәген салып, линолеум җәелгән идәнгә ташлады. Шунда ук Ленизаның плиссе итәге күпереп килеп төште. Германның авыр, кайнар гәүдәсе Ленизаны идәнгә кысып беркетте, гайрәтле куллары тәнен урап алды. Иреннәре битенә ялкын бөркегәндәй итте, сулышны буды, өнне алды.

Ул гүяки Ленизаны тәмам эретеп бетереп, ахырынача үзенеке итте. Тәмтомга хирыс малай туңдырманы шулай суыра торгандыр. Юк, алай гына да түгел, чүлдә адашып, чамасыз сусаган кеше ниһаять кулына килеп эләккән тире капчык — турсыктан суны шулай чөмерәдер. Ул һичнәрсә белән исәпләшмичә, ерткыч җанварларча табигате кушканны гына үтәде. Ленизаны бөтенләе белән «алды»,үз тәненең бер өлешенә әверелдерде.

Табигать бу кешегә башкаларның җанын үзенә буйсындыру талантын гына түгел, аларның тәненә хуҗа булу сәләтен дә мул биргән иде.

Аш бүлмәсенең идәне мондый кыланмышлар өчен кысан иде, Ленизаның боты газ плитәсенең аскы киртенә кат-кат бәрелде. Тик ул үзе моны сизмәде, сизәрлек хәлдә түгел иде.

Герман аннан аерылып, чалкан ятканда, Ленизаның аңын да, санын да җыярлык хәле калмаган иде....

—Төн буе монда аунарга уйламыйсыңдыр бит?

Германның бу соравы аның башына бераздан гына барып ирешге.

—Бүлмәдә җәелмәле диван бар анда...

—Соң нишләп монда аунап ятабыз? Әйдә, шунда керик!

Шундук бүлмәгә кереп, диванны җәйде, җәелеп ятты да:

—Мыс-мыс итеп алсак, зыян итмәс бит, ә?—диде.—Йолдызлар моны хуплар, мөгаен...

—Моңарчы минем иремнән башка беркемне дә якын китергәнем юк иде,—диде Лениза.

—Син сизәсеңме өстән ингән нурны?—дип аның башын сыйпады Герман.—Ул безне хуплый! Без бергә булырга тиеш идек. Бу безгә күкләрдән ингән әмер иде.

Һәм озак та үтми гырлый да башлады. Ленизаның исә күзенә йокы кермәде. Уйлар буталган, ә бәгырь сызлый иде. Нәрсә булды бу? Нишләп Мидхәт белән болай булганы юк?

Болай тәвәккәл, каты кылана алмый шул ул. Артык нәзакәтле, артык сизгер күңелле. Иң хисле мизгелләрдә дә бөтенләй онытылып китеп, үз хаҗәтен генә үти алмый, һаман парын кайгырта: ана рәхәт булсын, ул да ләззәтләнсен дип тырыша. «Күкәй баш»ны меңдәргә салсаң да йомрыланмый, һаман үзенчә булып кала. Ә мондый чакта башның эшләве тәннең кайнарлыгын сүрелдерми калмый шул инде. Китаплардан укыган киңәшләрне кулланырга тырышу да мондый минутларда файда итү урынына зыян гына сала икән, бу бер дә гаҗәп түгел.

Мидхәт хатынын үзендә эретеп бетерә алмады, чын ир була белмәде. Димәк, арада өченче кешенең пәйда булуына башлыча ул гаепле!

Герман иртә уянды. Сикереп торды да, киенә башлады.

—Бәлки, чәй куяргадыр?

—Нинди чәй? Дворниклар кузгалганчы чыгып китәргә кирәк.

Шунда Лениза анының нинди зур кеше икәнен исенә төшерде. Андыйлар качып-посып йөрми...

—Мин сине ялгызың килерсең дип уйламаган идем,—диде ул. Фикерен әйтеп бетермәде, Герман гадәттәгечә анын сүз төбен шундук аңлап алды.

—Ә-ә, син тән сакчыларын әйтәсеңме? Аларга бөтенесен белү кирәкмени? Әллә син шаһитлар булуын телисеңме?

Ул чыгып киткәч, Лениза ванна бүлмәсенә кереп, душ астына басты. Андагы көзгегә карагач, йөрәге тагын сулкылдап куйды: ирен читләре кызарып җилсенгән, муенында, колак астында кара таплар күзгә ташлана. Ул аларны үз күзләреннән яшерергә тырышкандай, юеш чәчләрен тарткалады. Сөртенгәндә, күзе ботларына төште: анда да таплар ярылып ята иде.

* * *

Мидхәт командировкадан көндез кайтып төште. Озын юллар үтеп, чит җирдә шактый болганганга һәм ят кешеләр белән күп аралашканга күрә, күңел шактый үзгәргән, үпкә-сапкалар кимегән иде. Ул завод кунакханәсенә кайтып төшү турында уйламады да. Туры эшенә барып, кәгазьләрен тапшырды. Лабораториягә шалтыраткан иде, аннан, Лениза төштән соң сорап китте, диделәр. «Рамилә авырмагандыр бит?»—«Юк-юк, борчылмагыз. Кызыгыз бакчада. Бу арада Ленизаның бик ашыгыч эшләре булды әле».

Мидхәт йөгерә-атлый бакчага китте. Көн салкынча, янгыр сибәләп тора иде, ә ул ашыгудан һәм борчылудан эсселәп, тирләп чыкты.

Агачлык эчендәге ике катлы бина тып-тын, ишек төбендә дә, коридорда да һичкем очрамады. Көндезге йокы сәгате иде бу. Мидхәт сабыйларның рәт-рәт булып тезелеп торган нәни ботинкалары янына юеш сумкасын куйды, кроссовкаларын салып, оекбаштан тын гына атлап, өске катка күтәрелде. Бар җир чип-чиста, диварларга шаян аю, куян, керпе кебек җанвар сурәтләре ясалган. Аларны күргән саен Мидхәтнең күңеле нечкәреп, иреннәренә ихтыярсыздан елмаю бәреп чыга. Биредәге балалар, әлбәттә, бик бәхетле булырга тиеш. Әмма нигә соң ак ишек артыннан ниндидер сызланган аваз килә? Кайсыдыр сабый елый түгелме? Әйе шул, елый. Тик, иркә балаларга хас булганча акырып-бакырып, таләпчән тавыш белән кычкырмый, ишетелер-ишетелмәс кенә сулкылдап сыкрана. Мидхәт Рамиләнең тавышын таныды. Сакланып кына ишекне ачты да, кечкенә караватында күзләрен уып утырган нәни кызчыкка кулларын сузды:

—Кызым, сабыем! Мин килдем, балакаем!

Ул Рамиләнен йомшак тәнен кочагына кысты, бала анын муенына җылы битен терәп сулкылдады. Мидхәт алгы бүлмәдәге кечкенә элгечләрдән анын бишмәтен табып алды, аска төшеп, ботинкаларын кигезде. Шунда гына каяндыр ак халат кигән тәрбияче хатын килеп чыкты:

—Сез нишләп уяттыгыз аны?

Мидхәт, иелгән килеш, аңа астан өскә гаепле кешедәй елмаеп карады.

—Исәнмесез. Гафу итегез. Әле генә командировкадан кайттым. Бик сагынган идем.

—Сагынырсыз да шул,—диде тәрбияче.—Атналар буе күрешми торасыз бит.

Иңендә сумка, кулында бала булганга, Мидхәт фатир ишеген ача алмый азапланды. Ахырда ишек үзе ачылып, каршыда Лениза урынына башына ак шарф ураган ят бер хатын пәйда булды.

—Кунак бармыни әле бездә?—диде бераз аптыраштa калган Мидхәт.

—Ә сез кем буласыз соң?—дип шактый кырыс итеп, сорауга сорау белән җавап кайтарды хатын.

—Без бу квартирның хуҗалары булабыз,—диде Мидхәт һәм аны читкә этәреп, эчкә атлады.

Һәм өен танымады. Галәттә уртада тора торган өстәл кырыйга шудырылган, аның өстенә ксерокс куелган. Диван җәелгән хәлендә булып, ана пөхтә итеп кәгазь өемнәре тезелгән иде. Өстәгесеннән Мидхәткә чәче кыска итеп алынган йомры башлы, шакмак иякле, сәер карашлы адәм чекерәеп карап тора иде.

—Бу ни бу?—дип сорады соң дәрәҗәдә гаҗәпләнгән Мидхәт.

—Чакыру билетлары. Берсекөнгә Мәдәният сараенда Остаз белән очрашу булачак,—диде хатын.

—Кемнең остазы белән?

—Барыбызның да!

Хатынның арык чырае төксе, яшькелт күзләренең карашы чәнечкеле, тавышы шактый ачы иде. Хуҗаның көтмәгәндә кайтып кереп, эшне бүлдергәнен яратмады, күрәсең.

—Кемнәр ул—«барыгыз да»? Сез үзегез безгә кем буласыз соң әле?

—Мин... Ленизаның чакыруы буенча...

Мидхәт кәгазь кисәген алды. «Нур һәм сафлык» дигән зур баш астында сәер карашлы адәмнең сурәте һәм вәграк хәрефләр белән: «Әгәр дә сез югарыдан иңгән изге нурны йөрәгегез белән кабул итәргә теләсәгез, дөньяның саф-чиста булуына ирешәсегез килсә, Остаз белән очрашуга килегез!»—дип язылган иде.

—Менә нәрсә, апакай,—диде Мидхәт.—Сез боларны хәзер үк җыештырып алыгыз әле!

Һәм тәвәккәл хәрәкәт белән кәгазьләрне бер якка сыдырып, урын бушатып, Рамиләне утыртты.

—Кая куйыйм мин бу хәтле әйберне?!

—Сумкагызга тутырасызмы, капчык табасызмы—анысы сезнең эш. Тик озакка сузмагыз. Бушатыгыз өйне. Ксероксыгызны да алырга онытмагыз. Мин юлдан кайткан кеше. Ашыйсы-эчәсе, юынасы, ял итәсе бар. Сезгә монда урын тәкъдим итә алмыйм.

—Нишләп мин алып китим аларны? Минеке генәме әллә? Хатының белән сөйләшерсең!

Апа алгы бүлмәдәге чөйдән аксыл плащын алды да, пырлап чыгып китте.

Иң беренче эш итеп Мидхәт ксероксны электрдан өзеп алып ишек төбенә куйды, кәгазьләрне диван япмасына урап, аның өстенә ташлады. Һәм аш бүлмәсенә чыгып, балага ботка пешерергә кереште.

Кайнар су килми иде, плитәгә ике чәйнек куярга кирәк булды. Мидхәт Рамиләнең зәңгәр бизәкле фланель күлмәген сабынлап ышкыганда, түшендәге җөй учын тырнады. Нәрсә бу?! Әнисе булавка калап, шул ачылганмы әллә? Юк, әнә очы күренми... Мидхәт дивар көзгесе астындагы киштәдән лезвие алып, юеш җөйне сүтәргә кереште. Аннан ак тимер кисәге килеп чыкты. Челтәрле ырмау эчендә бишпочмаклы йолдыз. Уртасына нәрсәдер язылган. «Нур һәм сафлык»,—дип укыды Мидхәт. Башта инглизчә, аннары русча. Ник тегеп куйган моны Ленизa баланың күлмәгенә?! Сихерме әллә? Шул гына җитмәгән иде!

Мидхәт кабаланып тагын өч күлмәкнең изүен капшады. Һәммәсеннән шул ук нәрсәне тартып чыгарды...

Тышкы ишек ачылганы ишетелде. Ул борылып карады. Һәм беренче мизгелдә хатынын танымады.

Башына, ияк астыннан ук урап, кин ак шарф бәйләгән бу хатын—Ленизамы соң?

—Син кайттың дамыни?—диде ул пошамангa төшкәндәй.—Мин сине көтми идем әле...

—Көтмәгәнсең шул, күренеп тора,—диде Мидхәт.—Ни булды сиңа?

Ленизa гомергә башына яулык-шарф бәйләмәде, килешми, ди иде. Чыннан да килешми икән... Йөзен бозып, үз яшеннән өлкәнрәк итеп күрсәтә. Ә бәлки бу—көз карашында чагылган, чыраена бәреп чыккан каушау-курку галәмәтеннән шулайдыр?

—Минамы? Берни булмады,—дигән була үзе.

—Кил әле монда!

Мидхәт Ленизаның курткасын салып элгәнне дә көтмичә, жилтерәтеп бүлмәгә тартып кертте һәм идәндәге өемгә аяк очы белән типте.

—Нәрсә бу? Кем иде ул бездә?

—Рәсимәне әйтәсеңме? Чакыру билетлары баса иде... Ул әзерләп куя, без таратабыз...

—Син шуларны таратып йөрдеңмени әле?

—Анда без күп...

Мидхәт мие түнгәнне басар өчен, ике учы белән чигәләренә тотынган иде, уң йодрыгындагы сәер тимер кисәге исенә төште.

—Ә бусы ни? Ник тектең аны Рамиләнең күлмәкләренә?!

Лениза, ниһаять, үзен кулга алды булса кирәк, алгы бүлмәгә борылып плащын салып элде, шарфын исә, муеным ачылмадымы икән, дип тикшергәндәй, сыйпаштырып кына куйды.

—Хәзер барысын да сөйлим... Әйдә, утырыйк әле.

Әти-әнисенең әйткәләшүенә күптән күнегеп беткән Рамилә «ту-ту-ту» дип уенчык машинасын тәгәрәтеп юана иде. Мидхәт урындыкка утырып, аны тез арасына кыстырды. Лениза диванның бер башына утырып, сынын турайтты.

—Әйе, син югында кайбер...—Лениза сүз эзләп торды да,—вакыйгалар булды...—дип җөмләсен тәмамлады һәм тынып калды. Мидхәт исә сорау бирмәде, аны ашыктырмады.

—Аня мине бик яхшы кешеләр белән таныштырды,—диде ниһаять Лениза.

—Кайсы Аня? Нинди яхшы кешеләр?

—Бакча күршесе. Без аның белән китапханәгә очрашуга бардык. Анда бик кызыклы кешеләр килгән иде. Һәммәсе югары белемле, бик мәгълүматлы... Кызганыч, син булмадың... Без монда үз кабыгыбызга бикләнеп яшибез, дөньяда ни барын белмибез...

—Ә нәрсә бар дөньяда?

—Мин кыскача гына аңлата алмам. Менә мондагы журналларда, китапта язылган...

Лениза урыныннан кузгалып шкаф киштәсеннән китап-журналлар алды.

Мидхәт таркау гына хәрәкәт белән ялтыравык тышлы китапны ачып, химикатлардан тиресе юкарган ак бармаклары белән актаргалады.

—Әллә берәр яңа секта оешканмы?—дип сорады гаҗәпләнеп.

—Нинди секта? Алар зур галимнәр! Эзотериклар! Бөтен галәмне юктан бар иткән Илаһи Кодрәт белән элемтәгә керәләр.

—Хат алышалармы, әллә интернет аша эш итәләрме?—дип талчыккан тавыш белән сорады Мидхәт.

—Син көләргә ашыкма, укып кара. Без монда, наданлыгыбыз аркасында, бөтенләй артта калганбыз. Син дә шартлаткычтан башканы белмисең...

—Әйдәле, кызым, бергәләп карыйк әле, күр нинди матур кәртинкәләр ясалган монда,—дип журнал тышына бармагы белән төртте Мидхәт.—Карале, нинди матур кыз аккошны кочаклап алган... Синең шулай итәсең килмиме?.. Күр, ул кызның әтисе белән әнисе нинди матур итеп өстәл янында, кунаклары белән бергәләшеп чөкердәшеп чәй эчеп утыралар...

Мидхәтнең болай сөйләнүләре Рамиләдән бигрәк Ленизаның күңелен нечкәртеп җибәрде.

—Беләсеңме, минем күз алларым яктырып киткәндәй булды. Сиңа Остаз белән, әлбәттә , очрашырга кирәк. Ул монда чакта...

—Килгән кешемени?...

—Ул бирегә изге миссия белән килгән.

—Каян?

—Мин аның адресын сорамадым.

—Ә сорарга кирәк иде. Кайда яши икән?

—Син һәрнәрсәне җиргә бастырасың. Ә монда илаһилык турында сүз бара.

—Илаһимы, түгелме, һәркемнең адресы бар. Хәтта Ходай Тәгаләнең дә. Җиде кат күк өстендә, ди, әнә, безнең әни.

—Илаһи Зат хәзерге вакытта Сириус йолдызында икән. Эзотериклар сигналларны шуннан алалар.

Мидхәт күзләрен зур ачып аңа текәлде.

—Шулаймы-ыни? Офисы шунда, димәк, ә? Ә эзотерик дигәнең, остаз дисеңме әле?

Лениза аның сүзен раслаганын белдереп, ияген какты.

—Ул адәм психиатрда учетта тормый микән? Тагын очратсаң, сора әле син аннан!

Ленизаның чырае кызарып чыкты:

—Син бернәрсәгә дә, беркемгә дә ышанмыйсың!—диде ул тавышын күтәреп.—Синең өчен бөтенесе әшәке! Шул гадәтең аркасында шушы көнгә төштек инде...

Әмма Мидхәтнең тавышны зурга җибәрәсе килми иде.

—Тукта, кызма,—диде ул.—Мин бит начарлык белән түгел, шаярып кына әйттем. Ялгыш ычкынды, гафу ит.

—Син юри кыланасың, конечно! Минем белән санашмыйсың! Әйткән сүземә төкереп тә бирмисең! Болай яшәргә невозможно!

Шулай дип кычкырды Лениза һәм шушы сүзләрдән соң кинәт үзенә көч кергәнен тойды. Әйе-әйе, моннан соң ул Мидхәт белән яшәмәячәк. Шуның белән һәммәсе хәл ителә дә куя. Шарфны чишеп, муендагы тапларны, чалбарны салып—ботлардагысын күрсәтәсе дә булмый! Моны кочаклап, башканы күз алдына китереп ятасы булмаячак.

—Бар әле, кызым, машинаң белән уйна,—дип Рамиләне янә идәнгә җибәрде Мидхәт.

—Бүгеннән мин синең хатының түгел!—дип үз-үзен ярсытып кычкырынуында булды Лениза.—Кстати, син әллә кайчаннан минеке түгел инде. Бар, әнә, миннән яхшыраклар янына кит!

Мидхәт бөтен сабырлыгын җыеп, тыныч булырга тырышып:

—Туктале, Лениза, иплән кенә сөйләшик әле,—диде.—Ул хәтле ярсырга сәбәп юк лабаса. Ну, китапханәгә баргансың, кемнәр беләндер сөйләшкәнсең. Анда сиңа ирең белән аерылышырга кушмаганнардыр бит?

—Китапханәнең ни катышы бар монда? Мин әллә кайчан синнән аерылырга карар кылдым инде. Әйтми генә йөрдем!

Мидхәтнең болай да кояшта янган йөзе кызарудан карасуланып китте, борын канатлары киерелеп, алар тирәсендә тир тамчылары бәреп чыкты, куллары салынып төште.

—Димәк, бу синең күптәннән уйланган ныклы карарың?—дип сорады ул күзләрен зур ачып.

—Окончательный карарым.

—Обжалованию не подлежит, дисең инде алайса...

—Юк! Кискән икмәк кире ябышмый!

Бу соңгы сүзләр Мидхәтнең башына сизмәстән килеп төшкән кирпеч кебек тәэсир итте: аның сизгерләнгән зиһене аларда куркыныч мәгънә барын тоеп алды.

—Ах, шула-аймыни?—диде Мидхәт өмете сүнгән тавыш белән.—Син мине үзеңнән кисеп ташладыңмыни инде?

—Думай как хочешь! Теләсә ничек аңла!

Колакларны чыңлатырлык киеренке тынлык урнашты. Мидхәтнең карашы машинасын «тү-тү» итеп идәндә үрмәләп йөргән кызчыкка төбәлгән иде.

—Аерылышканда да сөйләшми генә булмый,—диде ул мөмкин кадәр тынычлыгын сакларга тырышып.—Минем белән яшисең килми икән, мәҗбүр итә алмыйм. Тик менә уртак милекне ничек бүлешербез икән соң?

—Нәрсәне бүлешергә? Әз генә горурлыгы булган ир мондый очракта чыгып кына китә.

—Мин риза,—диде Мидхәт аның йөзенә туры карап.—Квартиры да, башкасы да сиңа булсын... Тик син...

—Нәрсә?

—Рамиләне миңа бир. Без чыгып китәбез... Ә син теләгән чагында аның белән очрашырсың... Курыкма, начар яшәтмәм, син мине беләсең...

—Да ты что?! Нинди ана баласын үзеннән читкә биреп җибәрсен? Кем кулына? Синең сөяркәләреңәме? Аннары минем хакта, әшәке хатын ул, баласын ташлады, дип дөнья сасытып сөйләп йөрсеннәрме әллә?

Мидхәт башын иеп тынлады, чөнки ни дә булса әйтүдән файда юклыгын аңлый иде.

—Әгәр балаңа тыныч булсын, дисәң, үзең чыгып кит! Менә шул чакта булырсың кеше! Балакаем, газизем! Ата була белмәде сиңа бу кеше, безне бәхетсез итәргә генә йөри ул!—дип, Рамиләне күтәреп алды Лениза.

Мидхәт командировкадан кайткач бушатып өлгермәгән сумкасын алды да, кабаланып кроссовкаларын киде, элгечтән курткасын йолкып, ишектән чыгып китте.

Нишләргә инде хәзер? Башыңны ташка бәреп ватар идең дә, бала кала бит! Мидхәтнең иң зур бәхете, тормышының кояшы булган Рамилә кала!

Ут капкан өйдән чыгып котылып буладыр, әмма явыз хатын ургыткан уттан котылу юк икән. Чөнки аннан ургылган ялкын телләре эченә үрләп, бәгыренне ялмый. Су сибеп кенә сүндерә торган түгел!

Ул автобуска утырып, бакчага китте. Анда аны кара көйгән, салкын яңгыр астында шәбәргән түтәлләр, сулган гөлләр яшь түгеп каршы алдылар.

* * *

Лениза баш-аягы белән Остазның кичәсен үткәрү эшенә чумды. Төннәрен ксерокста листовкалар баса, эштән соң баланы арбага утыртып, урамнар буйлап йөри: мөмкин булган һәр җиргә листовкалар ябыштыра, очраганнарга журналлар өләшә, тыңлаганнарга «Нур һәм сафлык» турында, Остазның илаһи сәләте турында сөйли иде.

Аның күңел түрендә Сириус йолдызындагы нур тәхетендә утырган Илаһи Зат нәкъ менә Герман төсле булып җанлана, нәкъ аның кебек өздереп тә, баласытып та, чак кына үчекләгәндәй итеп тә карый, абыйларча йомшак та, нык та итеп эндәшә иде. Һәм кинәт һуштан яздырып, ут өермәсендә бөтереп ала да, ташлы тауга китереп органдай итә. ...Ул кичне искә төшергән саен, Ленизаның бөтен тәне калтыранып куя, андый минутларда ул үз-үзләрен кан чыкканчы кыйнаудан ләззәт алган, безгә кыргый тоелган дин әһелләрен аңлаган кебек була.

Бу Илаһи Зат белән аны күзгә күренми, әмма өзеп тә булмый торган җепләр бәйли иде шикелле. Табигый ки, Ленизаның ана лаек буласы, кылган эшләре белән мактанасы килә иде.

Мондый изге эшләр арасында бала мәшәкатьләре артык борчу булып тоела иде. Шулай бер кичне, Рамиләне бакчадан алып кайткач, өйдә рәтле

ризык юклыгы беленде. Берничә урынга барып, игъланнар эләсе бар, шунда кибеткә керергә булыр иде булуын. Әмма баланы хәзер ашатырга кирәк. Лениза кабаланып бәрәнге пешереп изде, куе итеп кесәл ясады. Кызын ашыгып ашатты. Аннары чыгып китәм дигәндә генә, кызчыкның бите, бөтен тәне бурлаттай кызарып чыкканын күреп, туктап калды. Гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул минутта ишек кыңгыравы зыңгылдады. Лениза ишекнең чылбырын эләктереп, чак кына ачты. Аның каршысында Мидхәт басып тора иде.

—Мин сиңа, килеп йөрмә, дип әйтмәдеммени әле?—диде Лениза. Ни могҗиза беләндер, Мидхәт эчтәрәк басып торган кызын күреп алды:

—Ни булды Рамиләгә?

—Юк, болай гына, шаярган иде...

—Шаярганнан бала шулай була димени?! Ач ишекне! Баламны күрергә минем закон буенча хакым бар!

Лениза, болай да ачуы ташыган Мидхәтне тагын да ярсыту хәерле булмасын аңлап, чылбырны ычкындырды. Мидхәт ачынып елаган кызчыкны күтәреп алды да, тышка ташланды, аның артыннан Лениза чабып чыкты. Алар шулай йөгерешеп поликлиникага барып керделәр.

Дежур табиб, өлкән яшьтәге таза гәүдәле хатын, бер генә күз салды да:

—Нәрсә ашаттыгыз?—дип сорады.

Аннары, башын чайкап, Ленизага шелтә белән карады:

—Күпме өйрәтәбез без сезне, күпме талкыйбыз, балаларның ризыгына игътибарлы булыгыз, дип. Тоташ углеводлар белән голкындыргансыз бит сабыйны. Сөт эчерегез, тәмле боткалар ашатыгыз! Яшелчә, җиләк-җимеш белән күбрәк сыйлагыз.

—Доктор, ә хәзер нишләтергә? Берәр дару...

Табибә, Рамиләнең алтынсу ефәк төсле чәчен сыйпап, бармакларын чигәсендә озаграк тотып алды:

—Температурасы юк, кәефе әйбәт, нәрсәгә аңа дару... Әйтәм бит, сөт эчсен. Әгәр мондый хәл кабатлана торган булса, үзегезнең участок табибына барырсыз.

Аннары үткен күзләрен өлкәннәргә төбәде дә:

—Әти кеше дә битараф булмасын,—диде.—Баланы сау-сәламәт үстерү җиңел түгел, икәүләшеп тырышсаң да бик таманга килә.

Алар өйгә кадәр дәшми-тын гына кайттылар. Тышкы ишек төбендә Лениза Мидхәт кулыннан баланы тартып алды да:

—Сау бул,—диде.

—Нишләп... алай?

Соңгы көннәрдә Ленизаның башыннан үткән хәлләрнең иң мөһимен белмәгәнгә күрә, Мидхәт югалып калган, ул хатынның аңлаудан гаҗиз иде.

—Слушай, әйттем ич инде мин сиңа! Ничә кат кабатларга тагын!

Бу сүзләрне Лениза шундый ныклык, ышаныч белән әйтте ки, Мидхәтнең соңгы өметен дә балта белән чапкандай өзде дә куйды.

...Иртәгесен кич кызын алырга килгән Ленизаны тәрбияче гаҗәпләнеп каршы алды:

—Рамиләне әтисе килеп алып китте бит!

—Кайчан?

—Көндез үк инде. Поликлиникага барасыбыз бар, дип әйтте.

Өйдә кеше юк иде. Лениза заводның кунакханәсенә китте. Анда кизү торучы хатын:

—Халиковмы? Командировкага китте бит ул,—диде.

—Ә бала?

—Нинди бала?

—Кызыбызны бакчадан алган бит ул.

—Анысын әйтә алмыйм. Көндез үк чыгып китте, кулында сумка гына иде.

Кая киткән? Ник? Әмма завод идарәсендә эш сәгате беткән, беркемнән бернәрсә белеп булмый иде.

Шунда кинәт Ленизаның исенә төште: теге көнне, кичен баланың әтиәнисе килмәгәч, тәрбияче Рәйсәләргә шалтыраткан, Рамиләне ул барып алган иде бит!

Ә аларның ишеге артыннан гармун тавышы, аңа кушылып җыр ишетелде: «Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре...»

Парлашып сузалар, кинәнеп, ләззәтләнеп! Гомергә бер дә үпкәләшмәгәннәр, диярсең!

Төймәгә икенче тапкыр баскач кына кыңгырауны ишеттеләр, җыр туктады. Ишекне спорт костюмы кигән Рәмис ачты.

—Син белмисеңме? Мидхәт кая китте икән?—дип сорады Лениза сәлам бирергә дә онытып.

—Исәнме, Лениза! Киткәнмени? Мин ишетмәгән идем.

—Командировкага киткән бит ул. Баланы сездә калдырмады микән, дигән идем...

—Бакчада юкмыни?

—Юк шул, алып китте, диләр.

—Командировкага киттем, дип юри генә әйткәндер, бәлки? Монда берәр танышларындадыр?

«Баланы чыннан да сәяркәсенә алып киткәнме әллә?!»—дигән уй Ленизаның миен яшен кебек көйдереп узды. Ул, хәле китеп, ишек яңагына сөялде. Эчтән үрелеп карап торган Рәйсә иренең сүзенә каршы төшеп:

—Алай димә әле син, яхшым,—диде.—Туганнарында дисәң, бер хәл иде.

—Монда туганнарыбыз юк бит безнең,—диде Лениза.

—Әйтми-нитми нишләп алай итеп йөри соң ул? Үпкәләткән идеңме әллә?

—Без аерылышырга булдык. Баланы үзенә аласы килә аның...

—Шуңа ук барып җиттегезмени инде?—диде Ленизаны гаепләгән сыман итеп Рәмис.

—Эшне алай зурга җибәрмәскә кирәк иде,—дип аның сүзен җөпләде хатыны.—Кер әле син, чәй эчик. Атасы кулындагы бала өчен ул хәтле бәргәләнергә кирәкмәс.

Ләкин Ленизаның бәхетле пар янында бәхетсез булып утырасы килми иде.

—Юк, эчәсем килми,—диде. Аннары үзалдына сөйләнгәндәй:—Аерылган ирләр балаларын менә шулай урлыйлар икән,—дип куйды да, чыгарга дип ишекне ачты.

—Туктале, андый зур гаеп ташларга ашыкма әле син!—диде Рәмис.

—Ирләр алар әйләнә-тулгана да, барыбер үз йортына кайта,—дип янә иренең сүзен куәтләде Рәйсә.

Тик Лениза аларны тыңламый иде инде. Көн кебек ачык: Мидхәт Рамиләне урлап качкан... Әгәр еракка китеп, бөтенләй кайтмаса?!.

Ул өй ишеген ачканда, телефон зыңгылдый башлады. Мидхәт! Лениза сулышына кабып, трубканы алды.

—Хәерле кичләр! Син кайларда йөрисең, мышонок?—диде Остазның гамьсез, шаян тавышы.

—Хәерле... кич... Чыккан гына идем...

—Бүтән чыгасың юкмы? Югыйсә, минем үрчетеп аласы кәгазьләр бар иде. Әгәр син каршы килмәсәң... Өйдә үзең генә бит син...

«Каян беләсең?» Ләкин моны сорап торуның кирәге юк иде. Ире өйдә

булган хатын сөяркәсе белән башкача сөйләшә. Ә бәлки бөтенләй сөйләшеп тормый...

Мидхәт тавышын ишетергә өметләнгән Лениза башта нык каушаган иде, берничә мизгелдән җинеләеп киткәндәй булды. Бу шалтырату шулхәтле вакытлы иде! Әллә соң Герман ерактан ук Ленизаның хәлен тоеп тора микән? Ул килер, юатыр, акыллы киңәшен бирер. Ә бәлки әле Мидхәт белән баланың кайда икәнлеген дә беләдер?!

Плиссе итәген киеп, башына ак шарф ураганда, бу юлы инде зур бүлмәнең уртасында ашыгып табын әзерләгәндә, Ленизаның халәте бөтенләй үзгәргән иде.

...Ксероксны кузгатып тормадылар, Остазның кәгазь үрчетәм дию сылтау гына булган, билгеле. Табынга кайнар кибет пилмәне, казылык, сыйр куелды, узган юлы яртылаш эчелми калган аракы шешәсе менеп кунаклады. Бераз йотып куюга, Лениза сабырсызланып бәгырендәге сызлавыкны тишге:

—Ирем командировкага киткән, кызыбызны үзе белән алып киткән,—диде.

Кайнар пилмәнне авызында әвәләгән Германның яралы сул кашы күтәрелеп куйды.

—Беренче ишетәм,—диде ул бераз көттереп.

—Нәрсәне?

—Бала күтәреп командировкага йөргән ирне. Ник син аны алай интектерәсең?

—Минме?!.—Лениза җавап табудан гаҗиз калган иде.—Ул үзе... Кызыбызны урлап киткән ул!

—Урлаган? Үз баласынмы?

—Әйе шул, урлаган. Миннән урлаган...

—Ничә яшьтә соң ул бала?

—Өченче белән бара.

—Урлаган, дисең. Кулдан төшмәгән сабыйны... Тапкан икән... Тоже мне киднайпер! Селәгәй... Андый ир белән нинди хатын торсын?.. Аерылганыгызга күптәнме инде?

Лениза аның йөзенә текәлде.

—Син... килгәч...—диде.

Герман көлеп, башын чайкап куйды.

—Ну ты даешь!—диде.—Миңа хәтле син ир күрмичә күпме яшәгән идең инде, ә?

—Анысы бит аның болай гына... Без үпкәләшкән генә идек...

—Ә нигә соң син миңа шулай зарыгып, чакырып карадың?

—Ул бит... Ул бит...—Лениза кулын йөрәк турына куйды.—Йөрәкнең януына түзә алмаганнан... . Башымны кая куярга белмәгән чак иде.

—Ирең кем әле синең?

—Улмы? Инженер-химик. Бик талантлы уйлап табучы.

—Күкәй башлы, димәк. Ни чыкса, шулардан чыга шул.

Остазның тавышында, болай да юка иреннәрен кысып куюында, «күкәй башлы»ларга, ягъни галимнәргә, уйлап табучыларга кимсетүле мөнәсәбәт чагылды.

—Ул Норвегия галимнәре белән ярышырлык ачышлар ясады!—диде Лениза.

—Андыйлар үзара ярышырга оста, бер-берсен уздырмас өчен җан тырмашалар,—диде Остаз мәгънәле көлемсерәп.—Ә менә тормышны алып бару мәсьәләләрендә ифрат беркатлы шул алар. Күр инде, үз баласын үзе урлап йөри мескен. Монда ничек котылырга белмисең, ә аның нужасы көчәйгән.

—Ничек син алай дисең? Үзең дә шундый бит—күкәй башлы!—диде

Лениза.—Миңа биргән китабыңны гына укысаң да, нинди зур галим икәнлегең ярылып ята.

—Аны мин үзем язган дип уйладыңмы әллә син?

—Герман Светлый—син түгелмени?

—Ә син институтта укыганда рефератларыңны, курс эшләрен үзең яздыңмыни? Диплом эше өстендә дә ми черетеп утырдыңмы?

Әйе, бу юлы Лениза Остазның зәңгәр пәрдә белән капланган күзләрендәге мәгънәне бик ачык күрде—аларда мыскыллау чагыла иде. Бу заманда курс эшләрен, дипломын үз кулы белән язган кешеләргә карата мәсхәрәләү ярылып ята иде аларда!

—Урамнарда багана саен, игълан тактасы саен, «курс эше, диплом эше, теләсә нинди диссертация язып бирәбез», дигән язуларны укыганың юкмы әллә? Кемнәр ябыштырган аны? Синең ирен төсле күкәй башлар. Йомры башларга ялланырга атлыгып торалар, аларның учыннан җим чүплиләр! Сезгә анда, үзегезнең институтта, иҗтимагый фәннәрне, кешелекнең тарихын укытканнардыр бит? Кем башлаган икенче бөтендөнья сугышын? Гитлер. Ефрейтор. Генераллар, күкәй башлы галимнәр аның каршында тетрәп торган. Кем белән сугышкан ул? Яшь чагында семинариядән куып чыгарылган Сталин белән. Ә ул Сталин җир шарының алтыдан берен йодрыгында тоткан!

Герман кулын йодрыклады, ак җиңеннән беләге сузылып чыкты. Аның тыгыз тәнендә беләзеге турысыннан ук куе кара төкләр тырпайган иде. Ерткыч җәнлекнеке кебек.

—Җир шары кояш тирәли әйләнеп торганда, күкәй башлы бәндәләр менә шушындый куллардан туеначак!—диде ул нindидер бер тантана белән.—Әллә син мине, шундыйлардан бер китап яздырып алырлык та хәле юк, дип уйлыйсыңмы? Ул чакта минем хакта бик түбән фикердә булып чыгасың түгелме?

—Киресенчә!—диде Лениза.—Шундый зур хезмәт язган дип сокланган идем.

—Син теологиядән бераз хәбәрдардыр бит? Диннәрнең тарихын аз-маз булса да беләсеңдер?

Лениза башын иде:

—Аны бит мәктәптә дә, институтта да укытмыйлар...

—Пәйгамбәрләр китапларны үз куллары белән язмыйлар, мышонок! Алар югарыдан килеп ирешкәннәрне адәми затларга телдән сөйләп бирә. Аларның сөйләгәннәрен тарафдарлары кәгазьгә төшереп куя. Без дә шулай иттек. Мин ниләр язарга кирәклеген бик яхшылап аңлаттым, алар шуларны фәнни яктан нигезләп, компьютерга төшереп бирделәр.

Аның йөзе кырысланып китте:

—Рәхмәт әйтсеннәр!—диде.

—Изге сүзләрне теркәүне ышанып тапшырган өченме?

—Мин аларны бомба ясау, агулы матдәләр эшләп чыгару, иң камил технологияләрне файдаланып, кешеләр артыннан шымчылык итү кебек начар, пычрак гамәлләр кылу өчен ялламадым. Изгелеккә, сафлыкка хезмәт иттердем!

Остазның сөйләгәннәре нигезле, ышандырырлык булып тоелды. Ленизаның күңеле тынычланып китте. Чыннан да нинди көчле, бөек кеше утыра бит аның каршында!

—Ә мин менә нишләргә белми аптырыйм. Баланы ничек үземә кайтарып алыйм икән?

—Ә нәрсәгә? Бушап торырсың бераз.

Ленизаның тәмам коелып төшкәнен күреп, Герман шундук сүзен төзәтергә ашыкты:

—Алай бик борчыласың икән, милиция аша эзләт.

—Ничек?

—Үзен уйлап кара, кая илтә ул баланы?

Герман бераз көтеп торды. Җавап булмагач, үзе әйтте:

—Әбисе белән бабасына, билгеле. Адресларын беләсеңдер бит? Милициягә бар да әйт. Шуннан барып алып кайтсыннар.

Чыннан да, бик гади, бик тә аңлаешлы иде бит бу! Монарчы ничек Ленизаның үз башына килмәгән. Ул, җиңеләеп, елмаеп җибәрде.

—Менә син шундый чакта сөйкемле, мышонок,—диде дә Герман, аның иягеннән тотып башын күтәрде, каты иреннәре белән авызына беректе. Һәм мендәр урынына диванга ташлады да өстенә капланды. Лениза сыкранды, ыңгырашты. Әллә сызланудан, әллә ләззәттән—үзе дә аңламады...

* * *

Кинәт өйдә бөтен утлар сүнде. Бик каты күк күкрәп, йорт селкенеп куйгандай булды. Ишегалдындагы машиналарның каракланудан саклау өчен куелган сиреналары, колакны ярып, төрле тавышларга чинарга кереште. Кайдадыр этләр өрде.

—Алла, Ходаем, бу ни хәл бу?—диде Әлифә.—Сентябрь бит инде, бу нинди күк күкрәү тагын? Электрны өзде бит! Бездә генә микән?

Ул пәрдәне шудырды да, тәрәзәне ачып, караңгы урамга карады. Көчле җилдән бөгелеп бәргәләнгән биек каен-тирәкләрнең шавы күңелне шомландырды, эре тамчылар биткә бәрде. Каршы йортларда да, ишегалдында да утлар сүнгән иде.

—Бөтен районны электрсыз калдырган бу,—диде Әлифә һәм ашыгып тәрәзәне япты.—Шәмнәрне кабызмый булмас... Әнисә, шәмнәр кая икән безнең? Табып бир әле.

—Белмим...—диде битараф, хәлсез тавыш.

—Ни булды соң сиңа бүген? Иртәдән бирле үзеңә урын тапмыйсың. Әллә яшеннән куркасыңмы?

—Аннан түгел... Эчем поша.

—Яшь кешенең эче поша димени?! Әйдә, шәмнәрне кабызыйк та, ашап алыйк. Аш әзердер анда.

Әлифә кармаланып шкафның аскы киштәсеннән шәмнәрне табып алды да, кечкенә банкаларга утыртып, өчне берьюлы кабызып җибәрде.

—Әйдә, кил әле,—диде.—Ашагач, кәеф яхшыра ул. Хәзер бүләм.

Әнисә өстәл янына килеп утырды, әмма кашыгын кулына алмады. Шәмнең тотрыксыз саран яктысында аның күзләре җемелди, карашы ишек тарафына юнәлгән, гүяки ул кемнедер көтә иде.

—Аша инде, нишләп утырасың?

Нәкъ шул минутта шакыган тавыш ишетелде. Ишеккә килгән кеше гадәттә кыңгырауны зыңгылдата, шуңа күнеккәнгә, Әлифә башта шакуның каян икәнен аңламады. Әнисә исә сикереп торды да, барып ишекне ачып җибәрде.

—Кыңгыравыгыз шалтырамый,—диде таныш ир-ат тавышы. Аңа кушылып яшь баланың сыкраныпмы, сызланыпмы нәрсәдер лепелдәгәне ишетелде. Әлифә, үз колакларына үзе ышанмыйча, шәмнәрне күтәреп аш бүлмәсеннән чыкты.

Ишек катында Мидхәт басып тора иде. Костюмнан гына, тәмам шәбәреп беткән, чөнки курткасын салып, кулындагы баланы төргән. Иңендә юл сумкасы.

—Исәнмесез! Көтмәгән идегезме?

—Исәнме-саумы! Хуш киләсез!

Ул арада Әнисә баланы алып, идәнгә бастырган, бишмәтен, башлыгын салдырып, юеш чәчен, битен сөрткәли иде инде. Исәнләштеме-юкмы, анысын Әлифә ишетми калды, кунакларның бу рәвешле һич көтмәгәндә килеп керүе

кызны бөтенләй гаҗәпләндермәде дә шикелле. Әлифә исә әле һаман аның жыя алмый, шәмне күтәреп, ишектән тагын кемнең дә булса кергәнен көтә иде.

—Нишләп хәбәр итмәдегез? Әнисе кая?—дип сорады ул.

—Әни кеше өйдә калды.

—Әллә икәү генә килдегез?

—Икәү генә шул.

Ул арада гөлт итеп утлар кабынды, яктыда Мидхәтнең бик кыенсынып, хәтта оялып басып торганы күренде. Аның бөтен кыяфәтендә ялвару ярылып ята иде.

Әнисә исә баланы диванга утыртып, аяк киемнәрен салдырды да, чәйнекне утка куйды, шабырдатып ваннага су җибәрде.

—Коры киемнәре бармы?—дип сорады.

—Запас кием алмаган идек шул,—диде Мидхәт.—Кирәк-яракны иртәгә кибеттән алырбыз инде, әйе бит, кызым.

Кызчык дәшмәде, ул ятсыныпмы, куркыныпмы, хәрәкәтсез утыра иде.

—Хәзер ашап алырбыз да, юындырырмын,—диде Әнисә.—Сөлгегә төренеп ятып торыр. Ул арада киемнәрен юып үтүкләп бирермен.

—Үзем эшлим мин анысын. Бала юындыруның рәтен белмисеңдер әле син,—диде Мидхәт.

—Белә, белмәгән кая! Каникул вакытында детсад дачасында санитарка булып эшләде бит ул,—диде Әлифә горурлангандай.

Ни гаҗәпләнгән булса да, ул кызның кинәт үзгәргәнен, ачылып, дәртләнеп киткәнен күрми калмаган иде.

Бит-кулларны юып, аш янына утыргач, Мидхәт бу гаҗәп хәлне аңлатырга тиеш булды, билгеле. Әлифә иң беренче итеп:

—Нигә соңгы вакытта бер хат та язмадың?—дип сорады.—Әнисә әйтә, язам, ди, ә синнән хәбәр юк. Хатының авырып киттеме әллә?

—Юк, сау-сәламәт.

—Аллага шөкер,—диде җиңеләеп киткәндәй Әлифә.—Бу сабыйны кая алып барасың соң? Әниләрегезгәме?

—Юк... Аларга кайтырга ярамас... Аннан безне тиз табарлар, шулай бит, кызым?

Һәм хуҗаларның мондый хикмәтне аңламаудан гаҗиз булганнарын күреп:

—Без аерылыштык,—диде.

Бу сүзләрне әйткәндә, Әнисәнең күзләрендә сөенеч чалымнары кабынырга тиеш кебек иде, әмма ул, киресенчә, җитдиләнеп, ямансуланып киткәндәй булды.

Әлифәнең дә ияге салынып төште.

—Эчүгә сабыштымы әллә? Азып-тузып йөриме? Бүтән кеше белән бәйләндеме?

—Юк, эчми дә, азмый да, йөрми дә... Просто характерларыбыз килешмәде.

—Тәртипле анадан мондый бәләкәй баланы тартып алалар димени!—дип, тавышын күтәрә төшеп, әрнеп әйтте Әлифә.—Бигрәк тә кыз баланы. Күр дә тор, синнән алып, анасына бирәчәкләр аны. Юкка болай интегеп йөрисен. Аның дәгъвасе, шау-шуы... Телевизордан күрсәткәлиләр бит инде андый хәлләрне. Мәңге очына чыга алмаячаксың, нервыларың гына бетәчәк. Сабыйга да анасы була торып ятим яшәү...

—Нишләп ятим булсын! Минем белән бит ул!

—Уйла әле син... Кызган баштан гына кылануың бу... Юлда суынгансыңдыр, яңгыр астына да эләккәнсез. Әнә, Әнисә баланы юындырсын да, аннары син коенып чыгарсын. Диванда бала белән бергә йокларсыз. Мин үземә идәнгә җәярмен. Әнисә кухня диванында да бик әйбәт йоклый...

—Идәндә без йокларбыз,—диде Мидхәт нык итеп.—Иркенрәк тә, егылмаска да җайлы булыр..

Шул рәвешле Әлифә өй мәшәкатьләренә чумган булып кыланды, Мидхәтнең башына төшкән хәлләрнең хикмәтен җентекләп сорашырга, нинди дә булса кинәш бирергә теләк белдермәде.

Аннары шактый вакыт юыну, җыештыру, әйберләрне тәртипкә китерү белән узды.

Арган-талчыккан баланы йоклатып, Әлифә дә яткач, Мидхәт белән Әнисә аш бүлмәсенең өстәле янына чәй эчәргә утырдылар. Икесе өчен дә бик истәлекле бер кичтәге кебек...

Ләкин бүгенге сөйләшү башкачарак иде. Чөнки Әнисә бик моңсу, ниндидер зур гаме бар кебек иде. Ничек укуы турындагы сорауларга таркау гына җавап биргәләде. Һәм кинәт башын күтәреп, Мидхәткә өздереп карады да:

—Нишләргә инде хәзер?—дип сызланып сорады.

—Син... Нәрсә турында?..

—Ничек «нәрсә»? Рамиләне кая куярга?

Баксаң, ул чын йөрәктән бала өчен хәсрәтләнә икән лә!

Мидхәткә кинәт җинел булып китте. Ул ялгызы түгел икән бит! Бүлешкән кайгы кечерәйми калмый ул.

—Берәр чарасы табылыр әле,—диде ул кызны юаткандай елмаеп.—Менә шушы авыр бер чорны гына ничек тә булса үткәреп җибәрәсе иде. Берәр айга гына түзәсе.

—Ә аннан ни була?

—Мин сина яна төр шартлаткычлар хакында сөйләгән идем бит әле? Менә шуларга патент алу артыннан йөри идек. Шунын очына чыгып бетерсәк, күчеп китеп булыр иде. Башка шәһәргә. Бүтән заводка эшкә урнашырга.

—Шушы... аерылышу аркасындамы?

—Бала язмышы һәммәсеннән мөһимрәк, Әнисә! Рамилә кайда, минем өем шунда. Ә ана әнисеннән ераграк булу хәерле.

—Мин дә шулай дип уйлыйм,—диде һич көтмәгәндә Әнисә.—Җәй көне эшләгән балалар бакчасында танышларым бар минем. Бәлки, шунда урнаштырып торырга мөмкин булыр иде.

—Ә кем илтеп, алып кайтып йөрер икән соң аны?—дип шикләнә калды Әлифәнең сүзләрен исенә төшереп Мидхәт.

—Мин үзем... Үзем карар идем.

Мидхәт икеләнеп башын чайкады.

—Бала карауның ни икәнен белмисең шул әле син.

—Минме? Мин белмимме? Ике энемне менә шушы кулларда үстердем!

Әнисә моны шундый ныклы ышаныч белән әйтте ки, Мидхәтнең җилкәсеннән тау төшкән кебек булды.

—Атналык группа бармы соң ул бакчада?—дип сорады ул.

—Бар, андые да бар! Шундый матур бакча. Парк эчендә утыра!

Мәсьәләне шулай әйбәт кенә хәл кылып булуына алар икесе дә чын күңелдән ышанганнар иде.

Әмма иртәнге болытлы көн яктысында хәлләр бөтенләй икенче төрле булып күренде. Чәй эчеп утырганда, Әнисә тезендә утырган кызчыкның алтынсу чәчләрен сыйпаштырып:

—Апа, Рамиләне үзебез генә алып калыйк әле,—диде.

«Ботка пешеримме?»—дип сорагандай гади итеп, сүз арасында җинелчә генә әйтеп куйды. Әлифәнең исә капкан чәе ялгыш юлдан китте. Ул чәчәде, сулыш ала алмый интекте, кызарынып-бүртенеп йөткерде. Әнисә бер кулы белән баланы тоткан хәлдә, икенчесе белән аның аркасыннан каккалады.

—Озакка түгел бит, Мидхәт абый эшен тәмамлаганчы гына. Берәр айдан эшеннән чыгып, үзе монда кайтачак.

—Кешеләрнең берсен тегендә, икенчесен монда әвеш-тәвеш китерергә без кем әле ул хәтле?—диде, ниһаять, Әлифә күз яшьләрен сөртеп.—Баланы уенчык дип белдеңме әллә? Үзе исән чакта анадан сабыен тартып алырга бернинди закон да, шәригать тә рөхсәт итми! Андый эшләргә тыкшыну олы гөнаһ!

Аннары чәен кабып куйды да:

—Үзеннекеләр азмыни?—дип сорады.—Әнә, Радуны чит-ятлар уллыкка алырга йөриләр икән анда. Әтиең хастаханәдә ята. Минем бүген шунда чыгып китәсемне әйтмәдеңмени әле абыеңа?

Чыннан да, үзенекеләр турында Әнисә Мидхәткә берни дә сөйләмәгән иде.

—Кичке поезд белән Мәскәүгә китәм мин бүген,—диде Әлифә Мидхәткә карап.—Аннан Кишиневка. Синең хәлең безнекеләр белән чагыштырганда бер дә баш китәрлек түгел әле. Саташып кына йөрисез.

—Апа! Рамиләне кире җибәрергә ярамый!—дип кинәт өзгәләнеп, кычкырып куйды Әнисә.—Алып калыйк, апа! Үзем карармын!

—Укуыңны ташлап, декретка чыкмакчы булдыңмы әллә?!

Тынлык урнашты.

—Кызмыйк әле,—диде аннары Әлифә һәм сүзне җиңеләйтергә теләгәндәй кеткелдәп көлеп куйды.—Баш ярылып күз чыкмаган. Тормыш үзе барын да җайга сала ул. Мидхәт синең белән минем кулга карап тора торган түгел. Ир кеше ул! Үзе хәл итәр!

Менә шуның белән өзде дә куйды. Һәм йомшарып:

—Бүген кичкә хәтле карап тора алам баланны,—диде.—Күрәсе кешеләрең булса, барып килерсең.

—Командировка кәгазенә кул куйдырып кайтасы бар иде шул,—диде Мидхәт.

—Ә син, Әнисә, дәресеңә соңга кала күрмә!

Һәм баланы аның кулыннан алып, тезенә утыртты да, үчтекили башлады.

* * *

—Зинһар, килми кала күрмә инде,—дип ялынды Лениза Германга.—Синнән башка бер киңәшер кешем дә юк бит.

Чыннан да, кемгә генә сүз кушса да, Мидхәтнең кайтканын көтәргә, сабыр итәргә кушалар иде. Рәйсә белән Рәмис тә тыныч бул диләр. «Сабыр иткән—морадына ирешкән»,—ди Аня. Милициядә исә астыртын көлемсерәделәр генә: «Атасына кунакка киткән һәр кеше артыннан чапмасак, безгә эш беткәнме әллә?—диделәр.—Бик борчыласыз икән, барыгыз үзегез. Берочтан кайнанагызны да күреп кайтырсыз!» Ленизага шул гына җитмәгән иде! Анда барып, бер Мидхәт урынына бер өй кеше белән талашырга! Өелешеп тукмап җибәрмәсләрме тагын!

Вакытны сузу исә аерата куркыныч булып тоела иде. Мидхәт аның Герман белән бәйләнгәнен сизгәндер. Шулай булмаса, мондый дуамаллыкка барыр идемени? Ә бәлки, мона дәлилләр туплый, шаһитлар җыя торгандыр инде. Судта аерылышканда, хатыным хыянәт итте, дип исбатласа, баланы үзендә калдыру чарасын, һичшиксез, табачак. Аннары Рамилә аның кулында бит инде, аерылышкач, тартып алып кара!

Шуңа күрә кул кушырып утырмаска, чарасына үзе керешергә булды ул.

—Пропискадан төшереп куй син аны,—диде Герман.

—Ул үзе дә фатирны миңа калдырам дигән иде диюен...

—Алай булгач, ни авырлыгы бар аның!

—Баланы миңа калдырсаң, дигән шарты бар шул.

—Соң, баланы алып киткән бит инде!

—Юк, баланы бирмим!

Герман ана мәгънәле итеп карады да:

—Тап жаен,—диде.—Квартирны да үзеңдә калдыр, баланы да бирмә! Шунлык та үткенлегең юкмыни? Нишләп шулхәтле жебеп торасың? Хатын-кыз бит син!

Лениза үзен кечерәеп, ямьсезләнеп киткәндәй хис итте. Жебегәнлек, унмаганлык бирәүне дә бизәми... Ә аның Герман каршында чибәр дә, унган да булып күренәсе килә иде.

Һәм ул тәвәккәлләде: эшеннән өч көнгә түләүсез ял алып, шәһәр буйлап чапты. Судка тиешле кәгазьләрне тапшырды, йортлар идарәсенә кереп, пропискадан төшерүнең тәртибен белеште.

Мидхәт көндез кайтып төшкән икән, суд юлыннан кайтып кергән Лениза һич көтмәгәндә аның белән йөзгә-йөз калды.

—Исәнме, Лениза...

—Минем исәнлегем сиңа ник кирәк? Үлеп куйган булсам, синең өчен яхшырак булыр иде, так ведь? Нишләтеп йөрттең баланы әллә кайларда? Кызым, исән-саумы син? Чирләмәденме?

Лениза бүлмәгә кереп, Рамиләне күтәреп алды да:

—Моннан ары балага якын киләсе булма!—диде.—Белеп тор: милиция учетына бастырдым мин сине! Икенчесендә утыртып куячаклар!

Мидхәт нишләргә, ни әйтергә белми ишек төбендә таптанды.

—Ненавижу! Күралмыйм! Вон отсюда! Чыгып кит хәзер үк! Эзең булмасын монда!—дип ничектер эченнән суырып, кызарынып ысылдады Лениза.—Мин разводка бирдем инде. Бу квартирда урын юк сиңа!

Бала күтәреп ерак юллар узганда күп уйланган иде Мидхәт, үз хәленең никадәр аяныч икәнен бик яхшы төшенде. Инде эш аерылышуга барып житкән икән, ир кешенең хәленә кереп, аның ягына басучы табылыр, дип өметләнмә. Шушындый гаилә дәгъвалары аркасында күпме ирләр куышсыз калып, сукбайлык сукмакларында бәргәләнеп-кыйналып йөри!

Хәер, ул үзе, эшсез дә, куышсыз да калырмын, дип һич тә борчылмый иде. Норвегиягә дә чакырып торалар, әнә. Риза да булыр иде, бәлки, ләкин Рамиләне ничек калдырып китәсең? Аны үзең белән алып бару хакында исә сүз дә булырга мөмкин түгел иде.

—Нәрсә син, квартир да квартир дип такылдыйсың? Ни дип белдең син аны? Бетон стена бит ул! Таш!—диде ул.

—Нәрсәсе бар, дисеңме? Таш дисеңме? Ә ник син ана чатлап ябышып ятасың алай булгач? Ник балага тыныч кына яшәргә ирек бирмисең?

—Квартир өчен түгел!

—Шулаймы? Алай булгач, төш пропискадан! Югыйсә мин сиңа Рамиләнең чыраен да күрсәтмәячәкмен!

—Соң мин сиңа әллә кайчан әйткән идем бит инде, квартир сиңа калсын, ә Рамилә минем янда яшәсен, дип.

—Әйткәнсең икән, эшлә.

—Ә син... бу шартны үтәрсеңме соң?—дип, гаҗизлек аралаш өмет тулы, яшь белән өртелгән күзләрен хатынының йөзенә текәде Мидхәт.

Бу караш Лениза күнеленең нечкә бер кылына чиртеп куйгандай итте.

—Арагызга киртә куймам, обещаю,—диде ул сорауга туры гына җавап бирмичә.—Күпме телисез, шулкадәр аралашырсыз...

Мидхәт керфеген дә какмый һаман ана карап тора иде әле.

—Аңла,—диде ул.—Рамилә кайда булса, минем өем шунда.

—Ә син мине аңлыйсыңмы? Мин синең белән яшәргә теләмим!

—Мин сине борчымам... Кичләрен Рамиләне яследән барып алырга рөхсәт итәрсең бит? Ял көннәрен үзем белән йөртергә...

Мидхәтнең тавышы калтырана, ул кулларын кая куярга белми угалый иде. Әллә кайларга барып, җиде ятлардан үз хокукыңны дәгъвалап йөрсәң, тапталып кына калачаксың, теләгеңә ирешә алмаячаксың. Ыгы-зыгы, ызгыш-талаш арасында балаганиләр кичерергә туры килмәс тагын! Ә болай ул күз алдында булачак. Көн саен. Мидхәт бата башлаганын белә иде, аннан да бигрәк Рамиләне суга төшкән дип хис итә иде. Шунлыктан, ул саламга тотынудан башка чара юклыгын аңлады.

Бу фатирда ул үзе дә яши алмаячак иде инде. Ленизаны ул сафлыгы өчен яраткан иде. Ай нурына уралган беренче кичтәге тойгылары бөтенләй үк онытылмаган, карурмандагы яктырткыч кортларның ымсындыргыч яктысы рәвешендә генә булса да, вакыт-вакыт чагылып ала иде әле.

Ләкин шундук сүнә иде шул алар. Чөнки соңгы вакытта Ленизаның чисталыгы, ихласлыгы кимеде, ә бәлки бөтенләй үк юкка чыккан кебек тоела башлады. Ниндидер шакшы урап алган кебек иде аны. Очкычларда күп сәгатьләр очканда да Мидхәт бу хакта күп уйланды һәм Рәйсәнең теге вакытта йөзе җимерелгәч әйткән сүзләре исенә төште: дуңгызга гашыйк булсаң, аның белән бергә урам күлдәвегендә аунарга туры киләчәк. Менә хәзер Ленизa урам күлдәвегендә аунап чыккан кебек булып тоела иде. Хәер, абынып, яисә ялгышып егылганда пычрану ул кадәр үк куркыныч түгелдер. Тәнне юып була. Тик керләнгән җанны ничек сафландырырга?

Мидхәткә Ленизаның җаны пычранган кебек тоела иде. Һәм ул бу шакшы хатын белән бер ятакта була алмый иде. Абруйлы уйлап табучының дан тоткан куллары-бармаклары гына түгел, күңеле дә ифрат сизгер иде шул!

—Ярый, мин пропискадан төшәрмен. Тик син вәгъдәңне онытмассың бит?

—Әйттем ич, очрашырсыз дип. Бар хәзер үк йортлар идарәсенә! Паспортистка бүген сигезгә хәтле эшли.

Әмма Мидхәт ишеккә борылмады, бүлмәгә таба атлады. Аның йөзен чалыш елмаю бозган иде. Әллә сүзләре шаяру гына булганмы, әллә хәзер Герман турында, Ленизаның хыянәте хакында йөзенә бәреп әйтеп, сугып җибәрмәкчеме? Төптән уйлап карасаң, бәреп үтерсә дә, хаклы булачак бит ул!

Лениза куркынып артка чигенде. Мидхәт аның калтыранган кулларыннан Рамиләне алды да, битен сабыйның түшенә терәде. Ул гына ишетерлек итеп:

—Балам... синең хакка...—диде.—Үзем өчен болай кыланмас идем... Синең өчен кушсалар, борыным белән җир сөрәчәкмен, газизем...

Аннары Рамиләне диванга утыртты да, курткасын киеп, сумкасын алды да, Ленизага күз дә салмый чыгып китте.

* * *

Мәдәният сараенда очрашу алдыннан Лениза Остазның күңелен күтәрерлек берничә сүз әйтеп, кулын кысмакчы иде. Ләкин аны сәхнә артына кертмәделәр. Шунда ул беренче тапкыр аның тән сакчыларын күрде. Алар өчәү иде: уклау йоткандай төз сынлы, таза гәүдәле, кырыс карашлы ике ир-ат һәм бер хатын-кыз. Утызлар тирәсендәге бу хатынга Лениза сынап карады: ыспай буй-сынына килешле, озын итәкле зәңгәр костюм кигән, чәчен салам төсенә буяп, пөхтә итеп күпертеп куйган. Түшендә нәни генә алтын «Нур-сафлык» медальоны, йөзендә баллы елмаю. Ленизаны күрүгә, аның каршына килеп басты да:

—Хуш килдегез!—диде.—Әйдәгез, мин сезне залга озатып куям. Халык күп, урынсыз кала күрмәгез.

Лениза аны әйләнеп узмакчы иде, теге ике ир-ат ана таба атладылар. Ул, алар аша үрелеп, эчкә карады.

Буш сәхнәдә Герман ялгызы әрле-бирле йөренә иде. Кара костюм, ак күлмәк кигән, янып торган кызыл галстук таккан. Үзалдына нидер сөйләнә, кулларын изәп куя. Карашы гадәттәгедән дә томанлы, шул ук вакытта серле ялтырый. Һичкемне, һичнәрсәне күрми, жаны-тәне белән үз кичерешләренә чумган иде ул. Талантлы артистлар спектакль башланыр алдыннан шундый кыяфәттә була торгандыр.

Сары чәчле хатын Ленизаны култыклап алды да, артка таба тартты.

—Мин бу кичәне оештыручыларның берсе!—диде Лениза үзенең Остаз белән сөйләшергә хокукы барлыгын белдерергә омтылып.

—Ах, шулаймыни? Алайса сез монда бик жаваплы кеше бит әле! Әйдәгез, мин сезне яхшырак урынга утыртам. Остаз чыгыш ясаганда, ана залдан нык таяныч кирәк булачак. Сез мине аңлыйсыздыр бит? Очрашуның ахырында взнослар жыячакбыз, сез бу хакта беләсездер инде?

Лениза анысын ишетмәгән иде, дәшмәде. Хатын моны ризалык билгесе дип аңлады булса кирәк:

—Андый чакта үрнәк күрсәтергә кирәк, шулай бит?—диде.—Сез ничек, акчалата бирмәкче буласызмы?

Лениза акчаны янында кирәк кадәр генә йөртә иде.

—Күпме бирим икән?—дип сорады.

—Юк, сез акча бирмәгез. Иң яхшысы—бирәр әйбер салыгыз.

—Нинди әйбер?

—Сумкагызны ачып караган булыгыз да, күршегезгә ишеттереп, ах, акчам аз икән, диегез. Аннары, әйтик, алкаларыгызны салырсыз. Алтындыр ич алар сезнең?

Ленизаның гажәпләнеп текәлгәнен күреп, хатын аңлатып бирүне кирәк тапты.

—Бу фәкать башкаларны оештыру өчен генә кирәк. Үрнәк күрсәтү өчен. Биргән әйберегезне соңыннан кире алырга була.

Һәм аны култыклап, сәхнәдән алып төшеп тә китте.

Халык чыннан да күп, биш йөз кешелек зал шыгрым тулы иде. Ни радиотелевидениедән, ни гәзитләрдә игъланнар бирелмәгән, кичәне оештыру белән шәһәр-район житәкчеләре шөгыльләнмәгән иде югыйсә. Алар бу чараны күрмәмешкә салыштылар, фәкать шул гына. Калганын «Нур-сафлык»ның үз кешеләре башкарып чыкты. Керү бушлай иде, пенсионерларның, ялгызларның, хасталарның хәлен яхшырту турында житди сүз барачак, дип очраган бер кешегә аңлаттылар, чакыру кәгазьләре өләштеләр. Халыкны талап миллиардлар туплаган комсыз байларның хәрәм малын тартып алып, хөкүмәткә кайтару, аны һәммәбезгә тигезләп бүлү мәсьәләләре кабыргасы белән куелачак, дип сөйләп йөрделәр.

Тырышлыклары бушка китмәгән, шуна күрә алар бик канәгать кыяфәттә төрлесе төрле жирдә чәчелеп утыралар иде. Рәсимә уртада, Аня уң кырыйда, калганнар кайсы кайда.

Сары хатын залдагы тәртипне күзәтеп йөрүче ападан урындык китерттереп, Ленизаны урта рәтнең сул кырыена утыртты.

—Уяу булыгыз!—дип колагына иелеп пышылдады.—Мин әйткәнне онытмагыз.

Остаз сәхнәгә очып диярлек, ашкынып килеп чыкты. Ике кулын канат кебек күтәрде, кызыл галстугы күкрәгендә шәфәкъ утыннан яралган коштай жилпенде.

—Исәнмесез, кадерле туганнар!—диде ул йомшак, гадәттәгечә күңелгә май булып ята торган тавыш белән.—Нур һәм сафлык барыгызга да! Иманым

камил, бу залда караклар да, җан кыючылар да, сугыш чукмарлары да, бездән талап алган акчаны чит ил банкларына озатучылар да юк. Һәммәгезнең намусы чиста, теләкләре изге! Мин сездән бөркелгән җылы хисләрне тоям, алар миңа канат куя, рухымны югарыга, биеккә күтәрә. Һәм мин күкләрдән сирпелгән нурланышта коенгандай булам, аның серен аңлый башлыйм! Без барыбыз да күктән ингән нурларда коенып яшибез. Тик менә алар аша җибәрелгән хәбәрләрне күпләр акылы белән аңлап, теле белән әйтеп бирә белми. Андый сәләткә ия булган кешеләрне борынгыдан пәйгамбәр дип атаганнар...

Остаз беренче сүзләре белән үк, аннан да бигрәк ыспай да, гайрәтле дә, серле дә кыяфәте белән, үткен дә, томанлы да карашы белән, талпынулы хәрәкәтләре белән бөтен залны тынсыз, өнсез итте. Аның һәр сүзе рас, бөтен сөйләгәне нигезле иде бит! Ул моннан күп гасырлар элек яшәгән пәйгамбәрләрнең күкләрдән ингән хәбәрләрне адәмнәр теленә күчерүе турында, тик ул мәгълүматларны кешеләрнең үз чорына хас фикерләве аша аңлавы хакында сөйләде. Шунлыктан, төрле пәйгамбәрләрнең сөйләгәннәре арасында аермалыклар килеп чыккан, нәтиҗәдә, төрле диннәр барлыкка килгән. Һәрнәрсәнең үз вакыты булган кебек, диннәрнең, тәгълиматларның да үз чоры була.

—Уйлап карагыз: без Будда дәверендәге кешеләр кебекме? Яшәешебез Муса, яисә Гайсә пәйгамбәрләр заманнарындагы төслеме? Белемебез, фикерләвебез Мөхәммәт пәйгамбәр чоры дәрәҗәсендәме? Юк бит! Юк! Җитмәсә, әле Иләһи Затның алар аша ирештерелгән сүзләрен төрлечә боза килделәр. Хәтта явыз ният белән файдалана торган булдылар. Кешеләр, нишләттеләр безне? Илләргә таркаттылар, диннәргә тараттылар. Бер-беребезгә каршы өстерәләр, бер-беребез белән сугыштыралар! Без барыбыз да атабыз Адәмнең балалары бит югыйсә! Күк—барыбызга да бер! Җир—бер! Әмма без аларның кадерен белмибез, җирне дә, күкне дә пычратабыз. Әгәр моны туктата алмасак, тиздән ахырзаман киләчәк! Аның башлангычы безнең күз алдыбызда инде! Бер иманны кабул итеп, бер максатка хезмәт итсәк кенә котыла алачакбыз без!

«Шулай бит, чыннан да шулай бит!»—дип пышылдады Ленизаның янәшәсендә утырган кәләпүшле абзый. «Әйе-әйе»,—диеште бөтен зал.

Ленизә татлы да, сызланулы да бер халәттә иде. Ни өчен бу кешегә бер күрүдә гашыйк булганлыгын, ни хакына газаплы, әрнүле кавышуларны түземсезлек белән көтеп алганлыгын ул нәкъ шушы минутларда аңлады..

Биредәге биш йөз кешене, әллә ничә шәһәрләрдәге меңнәрчә башкаларны үзенә җәлеп иткән, алай гына түгел, әсир иткән бу затка бик күпләр тәкатьсез гашыйк иде, билгеле.

Лениза моны да аңлады. Һәм йөрәгенә көнләшү уты капты. Бу инде Мидхәттән көнләшү генә түгел иде! Ул Германны күзләре белән сәхнәдән суырып алып, үзенеке, фәкать үзенеке генә итәргә тели иде. Тик моңа ирешүнең әмәлен белми иде. Остаз биегәя, ерагая бара, аның тавышы чыннан да күкләрдән килеп ирешә кебек иде.

—Оҗмах җиде кат күк өстендә булачак, дип безне алдамасыннар. Җирдә булачак ул. Һәм аны кешеләр үзләре төзергә тиеш. Моның өчен без җирне тазартырга, иң беренче чиратта үзебезнең күңелләрне һәртөрле шакшыдан арындырырга тиешбез. Без бу бөек эшне күптәннән башладык инде. Үзебезнең бистә- поселогыбыз бар, Святонино дип атала. Анда өч мең кеше яши, арада бер генә фәкыйрь дә, эшсезлектән интегүче дә юк. Анда һичкем һичкемне җәберләми. Һәммәбез бертигез, бердәм, бергә. Авыр чакта берәүне дә ташламыйбыз. Мин сезгә аны барып карарга тәкъдим итәм. Кем тели, рәхим итегез! Килегез, кешечә яшәрсез, изге эшкә үз өлешегезне кертерсез! Әгәр

бүген үк кузгалып бара алмыйсыз икән, ул чакта бөек эшкә моннан торып та ярдәм күрсәтеп була.

Кемнәрдер нindидер сораулар бирде, аларның күпчелеге артык беркатлы, хәтта мәгънәсез иде: хасталар сырхауларыннан дәва табуны өмет итә, кемнендер якын кешесе кинәт үлгән, кемнедер житәкчеләр җәберләгән. Остаз һәркайсына юату сүзләре тапты.

Ул арада сары чәчле хатын полиэтилен пакет тотып ярдәм җыярга керешге. Ым белән, киная белән, кайсына исә пышылдап, активистларны да торгызды. Алар да рәтләр буйлап киттеләр. Лениза торып басар алдыннан үтә күренмәле букчага алкаларын салып куйды. Күп тә үтмәде, ярдәм җыючылар тоткан букчалар акчадан бүлтәйгән, акча астында алтын йөзек-алкалар елкылдый иде инде. Сары чәчле хатын җәлт кенә аларны эләктереп алды да, сәхнә артына кереп китте.

Бу эш тәмамлангач та, халык тиз генә таралмады, шактые Рәсимә тирәсендә тукталып, төркем хасил итте: ул анда «Нур һәм сафлык» медальоннары сата иде.

Аня Лениза янына килеп:

—Син алкаларыңны салып бирдең түгелме?—дип сорады.

—Теге сары чәчле хатын әйтте...

—Розананы әйтәсеңме? Оештырып йөрүчене дим?

—Ул әйтте, башкаларга үрнәк күрсәтү өчен генә кирәк, соңыннан бирербез, диде.

—Алайса бар тизрәк, кереп ал. Алар хәзер китәләр.

—Кемнәр?

—Остаз үзе дә, аның белән килгән башкалар да. Аэропортка илтәсе машиналар ишек төбендә тора.

Ленизаның йөрәге убылып төшкәндәй булды. Ул халыкны аралап сәхнә артына ыргылды.

Бу юлы аны берниндн тән сакчылары да туктатырлык түгел иде инде.

—Остаз мине үзе чакырды! Үзе!—дип кычкырынды ул.

Герман сәхнә артындагы кечкенә бүлмәдә ялгызы утыра иде. Иңнәре салынган, галстугы кыйшайган, йөзе сүрелгән. Алдында кәгазь каплы җимеш суы һәм бер стакан кызгылт-сары сыекча тора.

Ул Ленизага тонык күзләре белән карады да, хәлсез елмаеп:

—Ну ничек, мышонок, булдырдыммы?—дип сорады.

—Искиткеч!.. Син китәсең, диләр, дөресме шул?

—Эш бетте бит инде, монда нишләп ятыйк?!

—Минем белән хушлашмыйча да китәр идеңме әллә?

—Ну, хушлашабыз бит менә.

—Ә син кайчан кайтасың?

Герман аның соравын аңламады.

—Кая?

—Кая булсын, монда!

—Белмим шул. Бәлки, бер елдан, бәлки, соңрак...

—Бер елдан? Бер ел?!.

—Ә ник аңа гаҗәпләнәсең? Иллә шәһәрләр күп ләбаса, безне һәркайда көтәләр.

—Алайса, мине дә үзең белән ал!

—Ник?

—Син мине болай гына ташлап китә алмыйсың... Мин синнән калмыйм,—диде дер калтыранып Лениза.

Герман, сәерсенгәндәй, башын чайкап куйды.

—Чемодан түгел бит син, күтәреп йөрергә.

—Ярдәмчеӊ итеп ал!

Германның йөзе җитдиләнеп китте.

—Минем ярдәмчеләрем җитәрлек.

—Теге Розананы әйтәсеңме?

—Менә нәрсә, мышонок, хуш, сау бул, диешеп куллар бирешик тә, аерылышыйк әле без. Күрмисеңмени, ардым мин.

—Мин синсез яши алмыйм!

Шунда Ленизаның хәтеренә келт итеп, Мидхәтнең «очратсаң, адресын сора» дигән киңәше килеп төште.

—Яши торган җиреӊ кайда соң синеӊ?—диде ул ялварып.

—Ну, пропискам Святониноде минем.

—Син анда еш буласыңмы?

—Мондагыдан ешрак, әлбәттә.

—Алайса, мин шунда барам.

—Теләгәнеңне эшлә. Тик шуны бел, безгә анда синең белән бу рәвешле икәүдән-икәү калып очрашу мөмкин булмаячак.

—Нишләп?

—Аңла, мышонок, мин үземне кемгә дә булса бирә алмыйм! Залдагыларның миңа ничек караганын сиздеңме? Мин аларның һәммәсенеке. Гайсә пәйгамбәрнең хатыны булмаган!

«Әһә, димәк, буйдак... »

Бу уй Ленизаны тынычландырып җибәрде. Ярый, өйләнмәсен. Тик аны сирәк кенә булса да күрергә мөмкинлек булсын!

—Мин Святониноға барам,—диде Ленизa ныклы карарга килеп.

...Шуннан соңгы көннәрне ул үзалдына урысның мәгълүм җырын көйләп йөрде:

> «Жанкаем, бәгърем, алып кит мине,
> Ерак җирләрдә ярым диярсең».
> «Жанкаем-бәгърем, бик алыр идем,
> Ерак җирләрдә ярым бар минем». .
> « Сеңлем диярсең»...
> «Сеңлем бар минем»...
> «Чит-ят диярсең»...
> «Жанкаем-бәгърем, бик әйтер идем,
> Ерак җирләрдә чит-ят кирәкми»...

Соңгысы үзәкне өзә иде, Ленизa күз күрмәгән якларга мәгъшугына чит-ят булып бара, әмма күңел күгендә өмет йолдызы кабынган һәм ул торган саен яктырак яна иде: күз алдында булгач, араларны ныгыту чарасы табылыр, ә бәлки аның гомерлек яры булуга ирешергә мөмкинлек тә ачылыр әле... Тик араларны гына ерагайтмаска кирәк!

* * *

Ленизa фатирын «Нур һәм сафлык» оешмасына бер елга арендага биреп, ачкычларны Рәсимәгә тапшырды. Һәм сентябрь ахырында, чемодан өстерәп, бала арбасы тартып, Святониноға барып төште.

Тирә-якта байлыгы белән дә, серлелеге белән дә дан тоткан авыл иде бу. Аның хакында бик күп сөйләп булыр иде, әмма автор үз алдына андый максат куймый. Кешелек яралганнан бирле адәм балаларының иң акыллы һәм булдыклылары бар халыкны мул, рәхәт яшәтү чараларын булдырырга омтылды. Борын-борыннан, Герман әйткән «күкәй баш»лар моны оештыруның ысулларын тәкъдим итеп китаплар яздылар. Кызыксынган кеше Томмазо Кампанелланың унҗиденче гасырда язылган «Кояш шәһәре»н, Маркс, Ленин, Мао Цзэ-дун китапларын алып укый ала. Алар һәммәсе җирдә яшәүче барча

адәм балаларын, шул исәптән, без фәкыйрьләрне дә кайгыртып язылган. Бәгъзеләре моны риясыз, бернинди хак алмыйча, намус кушуы буенча гына башкарып чыкканнар. Кампанелла, мәсәлән, үзенен хыялый хезмәтен зинданда, сакчылардан яшереп иҗат иткән...

Аларның акылына таянып, бу юнәлештә «йомры башлар» кешелек өстендә шактый тәҗрибәләр үткәрде. Тарихта моның мисаллары җитәрлек. Маронитларның үзидарәләрен, СССРның коммуналарын, колхозларын, Камбоджада Пол Пот тудырган системаны, Израильнең кибуцларын мисалга китерергә мөмкин. Алар һәммәсе изге ният белән оештырылган, әлбәттә. Нәтиҗәсе төрлечә булды: коммуналар таралды, колхоз системасы уңышсыз дип табылды, Пол Пот шушы юлда зур тырышлык куеп, үз халкының дүрттән берен юк иткәннән соң, хакимияттән куылды, ватандашларының мәңгелек каһәренә дучар ителеп, үтерелде.

Маронит җәмгыятьләре исә, бик шауламыйча гына, һаман борынгыча яшәп яталар, кибуцларның да уңышлы гына эшләп килүе мәгълүм.

Святонинода элеккеләрнең хаталарын кабатламаска тырышалар, уңышлардан исә үрнәк алалар, һәр эшне фәнни нигездә алып баралар иде. Хуҗалык җитәкчеләр теле белән әйткәндә, аягында нык тора, уңышны мул җыя. Район-өлкә күргәзмәләренә куелган кәбестә-чөгендерләрнең иң эреләре, сыерларның иң сөтлеләре, күркәләрнең иң зурлары шуннан китерелгән була. Аларның фермаларында, басуларында чит илләрдән алынган, ялтырап торган машиналар эшли. Шулай булмый мөмкин дә түгел: хуҗалыкның башында Америка кешесе мистер Джонатан Смит тора иде.

Безнең илдә эшләп баеп булмый, яшәү читен дип әйтәләр әйтүен дә, ни хикмәттер, әле анда, әле монда чит илдән килеп, заводлар корып, авылларда фермалар оештырып, нык кына мантып китүчеләр бар.

Мистер Смит шундыйларның берсе иде. Түшенә «Нур-сафлык» тамгасы тагылган булса да, ул яна тәгълимат турында сүз сөйләп йөрми, баш-аягы белән хуҗалык эшенә чумган иде. Бер сүз белән әйткәндә, «йомры баш» иде ул. Хәер, озын буйлы, сыек сынлы бу адәмнең яртылаш пеләш башы кыяр кебек озынча булып, аскы ирене салынып торган чырае һәрчак бик җитди иде. Яна килгән кешеләрне дә эшкә ул үзе билгели икән. Озак сөйләшеп тормыйча, Ленизаның кулына ике бүлмәле өйнең бер ягына ачкыч тоттырды һәм:

—Химикларга бездә ихтыяҗ юк, әлегә идарәне җыештырырсың, кизү торырсың,—диде.—Эш көне унике сәгать, иртәнге сигездән кичке сигезгәчә.

—Мин бала белән...—дип, Лениза аның сүзен бүлдермәкче иде, Смит аңа әллә күксел, әллә зәңгәрсу, нинди дер төссез күзләре белән акаеп карады да:

—Бездә тәүлеклек ясле-бакча эшли,—диде.—Гомумән, сез монда ник килгәнегезне беләсездер бит?

Һәм Ленизаның ни дип җавап бирергә белми югалып калганын күреп, чырайна нинди дер җирәнү галәмәте чыгарды, аскы иренен тагын да ныграк салындырды да:

—Эшләргә килдегез сез монда!—диде..—Хезмәт белән сафланырга һәм дөньяны тазартырга. Шулай бит? Килгәнсез икән, эшләгез!

Лениза мистер Смитны бер күрүдә яратмады. Аны күрмәс өчен фермага барып тирес көрәргә әзер иде, әмма бирердә эш сайлау дигән нәрсә юк икән. Кем кая куелган, шунда бөтен көчен биреп, көн саен уникешәр сәгать хезмәт итә. Югыйсә, җитештерүчәнлекне Святонинодагы кебек текә күтәреп булыр идемени?

Чын мәгънәсендә ашау байдан, яшәү Ходайдан икән биредә. Ризык ашханәдә пешә, кием-салымны складтан түләүсез алырга була. Балалар башта ясле-бакчада, аннары озайтылган көнле мәктәптә үсә.

Дөрес, кыр эшләреннән бушагач, кышның иң салкын чакларында, эш көнен кыскарталар икән. Ул айларда клуб та, спорт залы да гөрләп эшләп тора, һәртөрле ярышларда катнашу хуп күрелә.

Ләкин боларның берсе дә Ленизага кирәкми иде. Аның гайрәтен чигергән тагын бер нәрсә бар иде: ул да булса, һәр иртәне парк янындагы зур буага төшеп чумып чыгу. Бу гамәл авыл халкының һәммәсе өчен мәҗбүри санала, чөнки тәнне сәламәтләндерә, рухны ныгыта, шулай итеп, адәм баласын һәртөрле кердән арындыруга ярдәм итә, дип исәпләнә иде. Бу хакта да бик белдекле кешеләрнең китаплары җитәрлек, кызыксынган һәркем табып укый ала. Әмма Лениза һәр иртәне нык сыкранып кузгала һәм, Рамиләне бакчага илтеп тапшыргач, кайтыр юлда суга чумып чыгуны зур газапка саный иде. Аның белән бер өйдә, күрше бүлмәдә яшәүче карчык Дарья Петровна бу җәзадан котылу чарасын тапкан—табиблардан йөрәк сырхавы хакында белешмә алып кайткан икән. Лениза аңа көнләшеп карый, тик үзен хаста дип игълан итә алмый иде бит инде! Үзе бер хәл, ул балалар бакчасындагы сабыйларны да һәр иртәне салкын суга чумдырганнарын белә, кызын кызгана иде. Ләкин бернишли алмыйсың, бер Рамиләне генә башка балалардан аерып куеп булмый шул.

Шулай итеп, зиһенне ураган томан эчендә, аңгы-мингe хәлдә бер ай вакыт узып китте.

* * *

Әле кичә генә каеннар, чаганнар яшел, сары, коңгырт буяуларга манылган ябалдашлары белән мактанышып утыралар иде. Әле кичә генә юл кырыйларындагы чирәм күперенке яшел келәм кебек иде. Ә менә бу иртәне тышка чыгуга салкын һава тынны куырды. Агачлар шәрәләнеп калган, аларның коелган яфрак өемнәрен, сукмак тирәләрендәге чирәмне ак бәс сарган.

Бу көнне Лениза буаның бозланган ярында аеруча авырлык белән чишенде һәм бөтен көчен җыеп, күзен чытырдатып йомып, суга сикерде. Тик юкка курыккан икән: тәнне салкын куырасы урында, ялкын теле ялмап алгандай итте.

Кире чыгып киенгәндә, янәшәдә ыгы-зыгы килгән хатыннарның:

—Остаз кайткан бит, Остаз кайткан!—дигән сүзләре колагына килеп ирește. Бу хәбәр җанга бозлы судай бәреп керде дә, ут белән өткәндәй итте. Ул кайткан! Лениза аны күрәчәк!

Дөрес, күзгә-күз очрашу рөхсәт ителми, дигән иде диюен. Ләкин Лениза аның өчен мондагы меңнәрдән берәү генә түгел бит, ә сөйгән кешесе! Эчендә җаны булса, бөтенләй онытып, исенә төшерми йөрмәгәндер! Ленизаның йөрәгендә ургыган кыргый учакның бер чаткысы гына булса да, аның күңеленә төшми калмас!

Эчендә ни булгандыр, әмма Герман һични сиздермәде. Мистер Смит белән бергә идарәгә килеп, алгы бүлмә аша узганда, өстәл артыннан сикереп торган Ленизага карамыйча гына:

—Исәнмесез... Нур һәм сафлык...—дип мыгырданып узып да китте.

Бөтенләй чит кеше кебек, танымаган да шикелле...

Берәр сәгатьтән соң кире чыгып барганда, янә күз салмады. Буш өстәл яныннан узып киттемени! Аңа якын килмәскә сүз биргән, ерактан гына бер күрүгә дә риза булыр идем, дип уйлаган Лениза йөрәге сыкранудан нишләргә белмәде.

Көндез түзми хәлең юк, идарәдә кеше өзелми, сораганга җавап бирәсе, телефоннан килгән хәбәрләрне язып барасы, почтаны актарасы...

Җан газапларының иң ачылары төнлә килде. Рамиләне йоклатып, караватка яткач, чыдар әмәле калмаганын аңлады ул. Бу минутларда Герман ни уйлый,

ниләр кичерә икән? Ленизаны бөтенләй исенә дә төшерми микәнни? Шулхәтле кайнар тәнле, дәртле кеше мондый төннәрне ялгызы изрәп йоклап ята аламы? Ә бәлки бу минутларда аның янында башка берәү бардыр? Розана түгел микән?

Тарсылдаган йөрәк менә-менә күкрәк куышыннан сикереп чыгар кебек иде.

Ленизa урыныннан кузгалды да, төнге күлмәге өстеннән плащ киеп, аягына чүәк элеп, урамга чыкты.

Ә төн суык, аяз, айсыз иде. Карасу-зәңгәр күк капусы түбәнәйгән, аның аркылы үтә күренмәле киң тукыма булып киек каз юлы сузылган. Аксыл, саргылт, зәңгәрсу, яшькелт йолдызлар аерата чекерәеп текәлгәннәр кебек. Лениза балачактан таныш Җидегән йолдызга карады, аннан чамалап Сириусны эзләп тапты. Башкалардан яктырак янган бу йолдыз хәзерге минутларда җиргә нинди хәбәр җибәрә икән? Янган йөрәктән ургылган хисләр дулкыны анда барып җитәдер бит, җитми мөмкин түгел! Ни җавап бирә аның мең соравына Илаһи Зат? Йолдыз җемелдәп ана текәлгән, ләкин ни әйткәнен аңлап булмый иде. Хәер, нигә аңламаска! Бар, ди ул, чыккан юлыңнан тукталып калма!

Остазның биек болдырлы, юан-юан карагай бүрәнәләрдән салынган зур йорты идарә белән янәшә, ана шактый ерак барасы иде. Лениза караңгы урам буйлап абына-сөртенә йөгерде, кайбер капка артларыннан этләр өреп калды.

Йортның тәрәзәләрендә ут юк, болдыр өстендә генә лампочка яна иде. Бирегә килгән һәркем еракта күренсен өчен махсус асып куйганнармыни. Ә бәлки шулайдыр да... Ләкин кире борылып китәргә көч калмаган иде инде. Ул болдырга менде дә, таза-калын такталардан ясалган ишекне башта бармаклары белән тырнаштырды, аннары каккалады. Ниһаять, аңына килеп, сузылып, тәрәзә янагына суккалады. Эчтә ишек ачылганы ишетелде, карлыккан тавыш ризасызлык белән:

—Кем ул анда?—дип сорады.

—Мин бу, Герман. Мин, Лениза.

Ишек ачылды. Көчле куллар Ленизаның плащ түшеннән эләктереп алып, эчкә тартты.

—Нишләп йөрисең монда? Якын киләсе булма, дип әйтмәдеммени мин сиңа!

—Мин тырыштым,—диде еламсырап Лениза.—Тик түзүнең дә чиге бар бит!

Герман караңгыда ян ишекне ачты да, Ленизаны күтәреп, киң ятакка томырды, плащын, төнге күлмәген йолкып алып идәнгә ыргытты. Лениза авыртуны тоймый, тупаслыкны аңламый иде. Сагынылган тәннең исеннән исереп, тилереп, аның ихтыярына бирелде, сызланулы ләззәттән ыңгырашып җибәрде. Герман киң учы белән каты итеп аның авызын томалады:

—Тынынны чыгарасы булма! Берәрсе ишетсен дисеңме әллә?

Лениза авырттырып иреннәрен тешләде.

...Хәл җыеп та өлгермәделәр кебек иде әле, Герман бармагы белән аның иңенә төртеп:

—Тор! Нәрсә ятасың,—диде.—Кеше-кара кузгалганчы үз өенә кайтып ят.

Лениза көч-хәл белән күтәрелде дә:

—Яратмыйсың син мине,—дип, үксеп елап җибәрде.

—Әле генә мин сиңа ничек яратуымны исбат итмәдеммени?

—Аны шулай итәләрмени? Шулай?

—Ә ничек тагын? Ирен белән башкача була идемени?

Ир турындагы сүз Ленизаның бәгыренә өстәмә яра ясады.

—Мин болай яши алмыйм! Яши алмыйм!—диде ул.

—Ну, анысын үзең карыйсың инде. Монда сиңа нянька юк. Миңа меңләгән кеше карап тора. Иртәгә тагын китәбез.

—Кая?

—«С» шәһәрендә очрашу планлаштырылган. Көтәләр.

—Ал мине үзең белән. Ал!

Ләниза идәнгә тезләнде дә, Германның каты, йонлач балтырларын кысып кочаклады.

—Әгәр син мине монда калдырсаң... Әгәр үзең белән алмасаң... Мин сине көтеп ала алмаячакмын! Шуны бел!

—Кем дип алыйм мин сине?

—Озатып йөрүчеләрең бар бит синең! Әнә, Розана!

—Алар алышынып тора. Бу юлы Розана бармаячак.

Бу сүзләрдән Ләнизаның эченә җылы йөгерде.

—Шулай булгач, мине алсаң да буладыр бит!—диде ул сөенгәндәй.

—Ярый. Бер генә юлга! Тик белеп тор: андый җирдә күзәтү аеруча көчле. Без аулакта кала алмаячакбыз.

—Булсын... Мин читтәрәк йөрермен... Якын килмәм...

—Вәгъдәңдә тора белмисең шул син.

—Кичер мине бүгенгесе өчен... Ачуланма... Мин башка алай итмәм.

—Әгәр эһ кенә дисәң дә...

—Димәм, димәм...—диде шатлыгыннан нишләргә белмәгән Ләниза.

* * *

Ул Рамиләне атналык бакчада калдырып китте. Бала ике-өч көн инде ютәлләштереп тора, тәрбияче алып калырга авырсынган да иде, әни кешенең Остаз кушуы буенча тиз генә барып киләсе җире барын белгәч, аяк терәп каршы тора алмады.

Ике көн узгач, төн уртасында анын ишеген каты шакылдаттылар. Фатир буш иде, чыгучы булмады. Күрше ишекне дыңгырдатырга керештеләр. Ниһаять, Дарья Петровна урынынан кузгалды.

Атналык бакчаның төнге тәрбиячесе килгән икән. Рамиләнең тамагы шешеп, сулышы буыла башлаган.

Дарья Петровна тиз генә киенде дә, ашыгып шәфкать туташының өенә китте, тәрбияче кире бакчага йөгерде.

Шәфкать туташын уятып алып килгәнче, ул районга шалтыратып, «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакырганчы, аның шоферы йокысыннан айнып, күзләрен тырнап ачканчы, аннары төнге юлдан кырык чакрым араны узып, Святонинога килгәнче һәм, бала белән озатучысын алып, кире районга кайтып җиткәнче күп сәгатьләр үтте. Бу төнге мажараларны нечкәләп сөйләп бирергә, барыннан да бигрәк Дарья Петровнаның тезендә яткан сабыйның газапларын тасвирларга минем каләмемнең көче җитми.

Баланың тынсыз гәүдәсен кабул итеп алган табиб урта яшьләрдәге ир кеше иде. Ул Рамиләнең тамагын тишеп көпшә куйды, укол кадады, шактый озак ясалма сулыш ясатырга тырышты. Ахырда тирләп-пешеп бетте... Ниһаять, өмет юклыгын аңлагач, операция бүлмәсеннән чыгып, битлеген умырып алды да, коридорда басып торган Дарья Петровнага:

—Ник болай соң китердегез?—дип кычкырды.—Авыруы беренче көн генә булмаган бит инде бу баланың! Ни карадыгыз? Күзегез чәчрәп чыккан идемени? Әчегездә җаныгыз юкмы әллә?

Һәм җавап көтмичә, кулын селтәп китеп барды. Карчык күз яшьләрен сөртеп басып калды.

...Өч көннән, мәрхүмәне җирләп кайткач, хәсрәткә баткан Ләниза, аз

булса да юаныч эзләп, күршесенә кереп утырды. Дарья Петровна күлмәк изүен ачып, эчтән алтын тәре тартып чыгарды. Святонинода алтын-көмеш тагып йөрү гаеп санала, килгән бер кеше андый әйберсен бухгалтериягә кертеп тапшыра. Ә менә бу кортка бирмәгән, яшергән икән. Ул тәресен үпте дә, түр почмакта матурлык өчен эленгәндәй асылынып торган чигүле сөлгене алып куйды: астан икона килеп чыкты.

—Господи Иисусе Христе! Пресвятая мать богородица!—дип баш иеп чукынды ул.—Прими душу безвинно убиенного младенца, рабы твоей Рамили. Прости нам грехи великие...

—Нишләп алай «гаепсез үтерелгән» дисез, Дарья Петровна! Үз чире белән үлгән баланы...—диде әрнеп Лениза.

—Ә син нишләп газиз баланның рухына багышлап дога кылмыйсың?

—Мин белмим шул...

—Атаң-анаң, әби-бабаң бер нәрсә дә өйрәтмәделәрмени?

—Бисмилла әйтә беләм, шул гына...

—Һич югы шуны укы...

—Бисмиллаһи-иррахман-иррахим...—дип пышылдады Лениза.

—Мәчеткә барырга кирәк иде, анда өйрәткән булырлар иде...

—Бер кергән идем. Ничектер ятсындым. Буш тоелды.

—Бөтенләй буш идемени?

—Әйе. Иркен бина. Стеналарында Коръән сүзләре. Мин аңламый торган. Тәрәзәләре күп. Бик якты.

—Ә сиңа ул якты гына җитмәгән инде алайса. Караңгыга чыгып, күктән йолдыз чүпләргә кирәк булган... Баланың атасы юкмыни? Җеназада күренмәде.

—Бар.... Тик мин аңа хәбәр итмәдем әле.

Дарья Петровна бер мәлгә телсез калды. Ниһаять, аңын җыеп:

—Ничек алай?—диде.—Андыйны кан дошманына да хәбәр итәләр. Чит - ят түгел, баласын йөрәк астыңда йөрткәнсең... Ярата идеңме соң син аны?

—Ярата идем... Үлеп көнләшә идем...

—Яратмагансың син аны! Чын сөюне көнләшү сүндерә алмый. Минем Федорым, царствие ему небесное...—бу урында Дарья Петровна тагын чукынып куйды,—безне ташлап чыгып китте, яшьрәккә өйләнде. Ә минем мәхәббәтем сүрелмәде. Аны еракта гына күреп калсам да, дөньям яктыра иде. Улыма әтисен мактап-яклап тордым. Ах, ул чакларда бик бәхетле булганмын икән лә... Господь аларның икесен дә үз янына алды шул.

—Ничек? Сезнең дә балагыз...

—Әйе, алар икесе берьюлы авариягә юлыгып үлделәр. Менә кайчан килде миңа кара төн. Менә шунда әвәрә итеп бирегә китерделәр дә инде. Пенсионер карчык идем, ялгызым калган идем шул... Чиркәүгә барып юаныч табарга өйрәнмәгән идем... Мондагыларның күбесе, минем кебек, олы хәсрәттән миләре түнгән чакта килеп капкан да инде.

—Кире кайтыгыз соң,—диде Лениза.—Теләсәң китәргә була, диләр бит.

—Кая кайтыйм? Фатирымны аларга яздырдым шул мин... Син дә шулай иттеңме әллә?

—Мин арендага гына бирдем. Бер елга...

—Слава богу! Кире алып була икән. Кызганыч, баланның кабере монда кала. Бик еш килә алмассың инде... Ә әтисенә бүген үк хәбәр ит! Хәзер үк! Каберенә барып, рухына дога кылсын. Чардуган куйсын! Таш кую ягын кайгыртсын! Якты дөньяда ятимә хәлендә иде бичара бала, рухын ятимә итмәгез! О господи, татулыкны саклый алган булсагыз, сабыегыз бүгенге көндә, мөгаен, исән-сау булыр иде!

—Ник алай дисең син, Дарья Петровна!—дип сыгылып төште Лениза.—

Инде син дә шулай дигәч, баламның атасы мине кичермәячәк, беркайчан да гафу итмәячәк...

* * *

—Ул кайтты,—диде Әнисә.

—Кая? Юк ич беркем дә,—диде Әлифә.

—Шалтыратырга хәле юк аның,—диде Әнисә. Һәм барып ишекне ачты. Баскыч мәйданчыгындагы лампочкаларны гел борып алып торалар, шунлыктан караңгы иде. Әнисә диварга сөялеп торган шәүләне сулышыннан таныды.

—Исәнме, Мидхәт абый. Кер әйдә. Без монда сине көтә-көтә көтек булдык инде.

Әлифә Мидхәтнең күгәренгән чыраен, нурсыз күзләрен күреп куркып китте:

—Син каян болай?

—Зираттан... Аның кабереннән...

—Әйтәм аны, Әнисә ничә көн инде үзенә үзе урын табалмый... Димәк, дөрес?

—Яшен сукты мине, Әнисә...—диде Мидхәт хәсрәтле елмаеп.—Йортымны яндырды, бәгыремне көйдерде... Синең каршыңда коры кабык кына басып тора...

—Бала хәсрәтеннән ачысы юк, диләр, алай да, Мидхәт, бу хәтле бетеренмә әле,—диде Әлифә.—Яшь бит әле син, тәнеңдә бу дөньяга киләсе яңа җаннарның яралгысы бар. Алар хакына үзеңне сакларга кирәк.

—Әйдәле, Мидхәт абый, сал өсләреңне,—диде Әнисә.—Менә шулай. Кил әле, утыр менә бу урындыкка. Заманында син мине үлемнән коткарып калган идең... Ул көнне мин җыйган җиләкнең тәмен онытмадыңмы әле?

—Әле дә телемдә, Әнисә...

—Мин аның сиңа буласын белгән идем... Шуңа иң эреләрен, татлыларын гына өзгән идем...

—Син мине ул чакта белми идең бит әле!

—Иң якын кешем белән очрашасымны күңелем сизгән иде...

Мидхәт башын күтәреп аның тылсымлы тамга салынган, уйчан да, чак кына елмаюлы да йөзенә, якты, серле күзләренә төбәлде. Әнисә үзе сөйләнә, үзе аның башы тирәли кулларын йөртә иде.

Бераздан ул Мидхәтнең йөзенә нур инеп, күзләре яктырып киткәнен күрде дә, җинел сулап:

—Әлхәмделиллаһи раббил галәмин,—дип куйды. Мидхәт гаҗәпләнеп:

—Син андый сүзләр дә беләсеңмени әле?—дип сорады.

—Апа өйрәтә.

—Һәм ышанасың дамы?

—Ышанам.

—Һич икеләнмичәме?

—Апа әйтә, иман безгә тән кебек, җан кебек, исем кебек үк ата-бабалар тарафыннан бирелгән, ди. Аны ихластан кабул итеп, инану тиеш, ди. Ходайга ышану ул мәхәббәт кебек бит. Чынлап сөйсәң, яраткан кешеңнең гаебен эзләмисең, ничек бар шулай кабул итәсең, диләр. Бернигә карамый инанырга кирәк...

Гади генә сүзләр Мидхәтнең күнелендәге авыр ташны кузгатып, җинеләйтеп җибәргәндәй итте. Әйе, чыннан да, яратырга кирәк. Инанырга кирәк. Икеләнмичә-шикләнмичә яратырга, инанырга. Яратмыйча, инанмыйча яшәү—яшәүмени ул?!



# Әхмәт Гадел

## Ватаным

Бу газиз түбәләр, ак юллар, зәңгәр күк...—
Гел бала чагымда—гел үткән елларда күргән күк...
Бу үлән, чәчәкләр, бу кылган, куаклык...—
Балачак сәламе, җаныма зур шатлык!

Тезләнәм, баш иям туган ил алдында,
Сәҗдәгә китәм мин Ватаным алдында.
Сулары канымда, җилләре аңымда,
Һәр сулыш-бураны саклана җанымда.

И, Ватан, и газиз-мөкатдәс илкәем,
Юллардан кайтканда каршылар—энкәем,
Бабамнар кабере... исәннәр—кадерле,
Җан-җанаш, сөйгәнем, хуш исле гөлкәем!

...Син мине тудырдың, назладың, үстердең.
Син мине пакьләдең, сафладың—үз күрдең.
Син генә, син генә вөҗданны сакларсың,
Ялгышсам—хакларсың, керләнсәм акларсың.

Мин—тирән тамырлы мең яшьлек нык тирәк,
Тамырым тотсынга, туфрагым, син кирәк!
Назлаучы таң җилем, аклаучы ал таңым...
И минем җан илем—Идел-йорт, Ватаным!

## Шәһәр урамында ялгыз гармун моңы...

Шәһәр урамында ялгыз гармун моңы
Төн пәрдәсен ера, алсу таңнар ата...
Гармун моңы минем күңелемә тулды,
Хатирәләр булып ул йөрәкне уята.

---

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) — *шагыйрь, прозаик; «Чам», «Яшьлек урамы», «Дәрт» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шәһәр урамында ялгыз гармун моңы,
Айкап урман-кырны, кайта, таба мине...
Берүк сүз әйтмәгез, туктатмагыз шуны,
Шәһәр урамында шул адашкан көйне.

Шәһәр урамында ялгыз гармун моңы,
Дулкынлана, кайный, таш диварга кага...
Шәһәр урамында, әйдәп урман-суны,
Миңа таба таша—бәгыремә ага.

Шәһәр урамында ялгыз гармун йөри,
Зур каланы гизә, күңелләрне били.
Шәһәр урамында үлмәс яшьлек гөрли,
Авыл хәбәрләрен өйгә кереп сөйли.

Әллә минем җаным, әллә синең җаның,
Әллә инде килгән—хыялларның өне...
Шәһәр урамында өзелеп чакыра таңны
Ерак бабамнардан мирас—татар көе...

***

Күңелем тын гына аланда, аулакта
Уйланып ятуны ярата.
Тик нигә болытлар биектә, яулыктай,
Хушлашу моңнарын тарата?!

Тез чүгеп иелсәм, тиерсәм иренем,
Ямь-яшел, хәтфәдәй үләнгә,
Шатланып мин дә бер фикергә килермен:
Гомерлек—Ватаным, дигәнгә.

Йә, нигә агачлар иделәр башларын,
Теләпме җырчыны күрергә?
Эчәсе суларым, ашыйсы ашларым
Күпме әле—җиремдә йөрергә?!

Зәп-зәңгәр күкләрдәй моңланды күзләрем,
Ятсам да, торсам да, уем бер:
Мәңгелек—илемдә саклармы эзләрем,
Илемдә кочармы беркөн—гүр?!

***

Бу тормыш—мәйдан, әмма
Белмидер күпләребез:
Аяк астында ята
Гүяки—күкләребез...
Табан астында җырлар—
Күңел сандугачлары
Кайчан туар бездә көч—
Күк күтәрелер ары?!
Күкне күтәрүче—без,
Әмма безне таш баскан.
Көч туплыйк, торыйк, чыгыйк,
Хәтерләрдәме дастан?!

**Дөрес, йөрәк ашалган,**
**Дөрес, йөрәк туралган.**
**Яралы йөрәк кулга**
**Сөлге булып уралган.**
**Шуңа да без куәтле,**
**Иләһи көчкә ия!**
**Кайсыгыз каршы чыга,**
**Кем безне «чөям!» дия?!**

**Җиңел булмас көрәш тә,**
**Таш—зур. Әмма без—тимер!**
**Башаркан кыен булса,**
**Ян аша ташлап җиң бер!**
**Кемдә курку шаукымы,**
**Мәйданнан шүрли күңел?!**
**Без Алып нәсле, безне**
**Чөюләр җиңел түгел!**
**Булсын ашалган йөрәк,**
**Таушалган йөрәк булсын!**
**Тик Аллаһ хөкемендә,**
**Милләткә тугры булсын!**

**Кулыбызда ак сөлге,**
**Терәлгән аяк җиргә.**
**Хак ныклык бирсен билгә,**
**Дан казаныйрбыз Илгә!**
**Әйе, тормыш—киң мәйдан.**
**Аек акыл, көч кирәк.**
**Ил, халык дип яшәсәк,**
**Җиңелү белмәс йөрәк!**

---

*Алхәбәр*

Нурихан Фәттах

## АКЛАН

ХЫЯЛЫЙ РОМАН

Аклан... Аклан иле... Атлантида... Безнең борынгы тарихыбыз Атлантида иленә барып тоташа, имеш. Бу—олуг язучыбызның үзе исән чакта нәшер ителмичә калган соңгы романы. Хыялый әсәр булса да, аның һәр вакыйгасын чып-чын итеп тоеп, мавыгып-йотылып укыйсың. Язучының тормыш иптәше Руфия Фәттахованың кереш сүзе белән ачыла.

*Роман журналыбызның киләсе саныннан басыла башлый.*



Асия
Юнысова

# КОЕ КҮЗЛӘРЕННӘН СУ АЛДЫМ...

## Афәт

**—Исемең ят, ни урысча түгел,
Ни хохолча түгел,— дидем мин
Поезддагы яңа танышыма,
Бу ханымның белгәч исемен.**

**—Үзем дә мин шушы ят туфракка
Төшеп калган Кырым йөземе...
Әнекәем, исән калсын диеп,
Ят кулларга биргән үземне.**

**Исемемне минем сораганнар,
Бер генә сүз әйтә белгәнмен.
Колагыма сеңеп калган ул сүз:
«Афәт, афәт, афәт!»— дигәнмен.**

**Хәзер генә белдем: афәт—бәла икән,
Шул исемне йөрттем мин-бала.
Әткәм-әнкәм телен мин җуйганмын,
Хәтер исән әле! Йә, Алла!**

**Күзәнәктә калган хәтер исән—
Рәнҗетелгән халык канында.
Рәнҗеткәннең генә хәтер кыска—
Яңа кысу бара Кырымда...**

**—Кырымтатар дигән ул явызлар
Гел бозалар, имеш, канунны.
Бабалары дәүләт тоткан җирдә
Уйлый болар яшәп калуны!—**

**Тарих белмәгәннең сабагы юк—
Типкәлиләр ханнар оныгын.
Япан кырда—гел заманча өйләр!
Булдыксызның килә кытыгы:**

—Эшләр болай барса, Кырым тагын
Төшмәгәе татар кулына!

(«Архипелаг» диеп «елау»ларның
Әҗере юк Кырым улына!)

Әрем кисә һаман афәт җиле,
Җелекләргә төшә бинахак...
Берияләр күләгәсе һаман
Кырым егетләрен кыйнаса?

## Нигез сакчысы

Универмаг тора анда хәзер.
Биек шундый, әллә ун катлы.
Түр бакчалы, челтәр кашагалы
Агач өйләр иде ул чакны.

Агач өйле шәһәр бар иде шул.
Кемдер шуны үлеп сагына.
Мин авылдан. Анда кычыткannar
Гаскәр кеби нигез сагында.

Түр бакчалы өйләр каршысына
Таш гасыры баскач өрәктәй,
Нәфис гөлләр ничек чыдасын ла,
Әрекмәннәр хәтта өреккән.

Күчеп киткән моннан хуҗалары.
Качып калган сыңар гөл-орлык.
Шытып чыгар әмәл тапкан ласа!
Матур үзе—карап торырлык.

Сабагыннан кыскан тимер-бетон,
Җиләс җилгә сузган ал башын.
Шундый тансык аңа иркен бер тын,
Шундый кирәк аңа яшәну!

Кульяулыктан күчкән бизәк кебек
Таш астыннан чыккан ал чәчәк,
Япа-ялгыз калып, нигез саклый!
...Иң соңыннан өмет үләчәк.

* * *

Кушучыңнан су эчердең,
Көмеш тә, көмеш инде.
Суың салкын—теш камаша,
Камашу тиеш инде.

Кушучыңнан суың эчтем,
Иелеп чак-чак кына.
Көмеш суда сагаюлы
Уйнады балдак кына.

Кушучыңнан су эчердең—
Көмеш тә көмеш инде.
Яшем тамды балдагыңа,
Хушлашу тиеш инде.

## Гитара

Зур гитара кочаклаган яшь кыз,
Тартып, чиртеп нечкә кылларын,
Үзе тойган хисләр дәрьясында
Йөздермәкче уен коралын.

Чегән, испан көе чалымнарын
Берәмтекли җитез куллары.
Җиде кылга җәеп салу, имеш,
Кыен аңар татар җырларын...

Арпеджио, тагын глиссандалар—
Җиде кылда нечкә нюанслар.
Озын көйле татар җырларыннан
Үзгә түгел, юкса, романслар.

Дәртле кыллар елап ямансылый!
Әй, баламдыр! Кызы кызымның...
Бер җырларсың, белəм, сагышланып,
Татар җырын—озын-озынын.

## Су кызы

Су кызы мин...
Ике тамчы судан яралганмын
Туйлардан соң—хәләл уеннан.
Юк белән бар бусагасын узып,
Дөньялыкка йөзеп чыгылган.

Су кызы мин...
Терек суы белән коендырып,
Кабул итеп алган бу дөнья.
Шул көннән соң елмаюлы йөзне,
Һәм күз яшен көмеш су юа.

Су кызы мин...
Тәпи басмас борын йөзеп киттем,
Чәчләремне юдым Ыгымда.
Дулкыннарга каршы йөзә-йөзә,
Ныгыгандыр холкым агымда.

Су кызы мин...
Чыңлы чылбырларны уйнаклатып,
Кое күзләреннән су алдым:
Изге чишмә суын кушучымда
Сөйгән ярга: «Эч!»— дип соналдым...

Су кызы мин. Күзем йомганда да:
«Су яратты»,— диеп сөйләрсез.
Соң тамчыны тел очыма салып,
Терек суын янә сибәрсез.
Су кызы мин—агып китәр кыз!

## Балтачы

Татар турысында сүзләр төрле,
Яхшысыннан күбрәк яманы.
Минем бабам балта белән йөрде,
Өйләр салды—корды яңаны...

Балта тотып барды урысына,
Мукшысына барды һәм арга.
Бура бурап, өйләр салган оста—
Ашлы табын булды татарга.

Җәяү генә чыгып китәр иде,
Иңбашына элеп балтасын.
Киндер капчыгында—эш коралы,
Кирәкми дә аңа башкасы.

Ил буенча киткән татарларның
Берсе иде бабам—балтачы.
БМО илчесе дә түгел иде,
Тик нияте аның ап-ачык.

Бабам салган өйләр урам-урам,
Авыл-авыл торып калгандыр.
Татар салган өйдә гомер итеп,
Аны хурлау үзе ямандыр.

Балта астыннан очты йомычкалар,
Туракланган яман гайбәттәй...
Урыс, чуаш, мукшы, арлар илен
Төзеп бирде Кара Түбәтәй.

## Читән

Ык талларын бөгелдереп,
Толымлап үргән читән—
Егетнең йортка бүләге,
Китеп барышы читкә.

«Тизгә генә китәм, диеп,—
Саклама миңа үпкә»,—
Назлысын үпкәненә дә
Инде ни гомер үткән?!

Китте егет, кайталмады
Тизгә дип киткән җирдән...
Читән ышыгын яратты—
Үрчеде яшел чирәм.

Читән буе чирәмендә
Бәбкәләр саклый Назлы.
Азга гына киткәннәрне
Мәңге көткәннәр азмы?

Толымлап үргән читәннәр
Ишелде инде күптән...
Яңа читән ышыгында
Үз ярын үбә бүтән.

## Төнге поезд

Төнге поездларның хикмәте бар.
Һәр юлдашың анда—табышмак.
Үткәнең юк анда, яңа баштан
Башланырга мөмкин танышлык.

Үз-үзеңә кызык түгел чакта
Кызыксынып, берәү сүз ката.
Ачыласың яңа китап кебек,
Сөйләшәсең юлда төн ката.

Укыласы килә... Серләрең күп,
Тәрәз артындагы төн кебек.
Бөтенләйгә аннан югаласың,
Юлда күргән сәер төш кебек.

***

Ялгышлардан сабак алыр өчен
Бу бер гомер миңа аз булды.
Уй-хисләрем минем, яшәлмичә,
Шигырь итеп кенә язылды.

Януларым гел ихластан иде.
И түктем лә шуны кәгазьгә!
Каләм очындагы ут-яктыдан
Кара төннәр шашты беразга.

Кәгазь өсләренә юллар салды
Гамәлемә шаһит каләмем...
Беләм хәзер гомер сабакларын
Әҗер савап итү әмәлен.

**Редакциядән:**

***Бу айда шагыйрә һәм публицист Асия Юнысованың түгәрәк юбилее. Аңа яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез!***

*Хикәяләр конкурсына*



Марат Әмирханов

# УБЫР УТЫ

Мәрьямнең хәлсез гәүдәсе тагын күпер әрәтәсенә килеп сыланды. Әйләнчек бәрән шикелле ирексез баштан һаман шушы тирәдә әвәләнә. Җә, Ходай, зиһене тәмам чуалды. Кисәк кенә күнеле сынып китте, гүя шом-шөбһә дингезенә чумдырып алдылар. Хәзер, әнә, аяк буыннары да тубырланып катты…

Кыз муенын киереп, ал тарафка күз атты. Ләкин карашы кул сузымыннан ук төн пәрдәсенә килеп төртелде.

Бирән аждаһадай һәр нәрсәне йотарга әзер торган куркыныч кара төн. Кыш димәссең, кар яктысы да шәйләнми хәтта. Ерак юлга йөргәндә күп тапкырлар кыр уртасында япа-ялгыз төн үткәргәне булды Мәрьямнең, әмма мондый сихерле манзарага беренче мәртәбә юлыгуы иде.

Гәүдәсен кыенлык белән генә әрәтәдән аерып, янә атламакчы итте. Кая ул. Аякларына гүя зәнбил ташы такканнар, һич кузгатырмын димә. Ә кузгалырга кирәк, аны өйдә көтәләр. Бригадир да аркадан сыйпамас, кичкә урап кайтасың дип кенә җибәргән иде…

Шулвакыт әлеге сәер төн пәрдәсен ертып, җырга охшаш авазлар чәчелеп киткәндәй булды. Мәрьямнең колаклары үрә торды. Бәхетенә, әллә бер-бер юлаучы киләме?

Авазлар ачыграк ишетелә башлады. Тик алар, җыр дисәң хәтерең калыр, исерек адәмнәрнең акыру-бакыруларына тартым иде. Уф, тагын саташам ахры, дип сызланды кыз, бу аулак җирдә нинди юлаучы йөрсен?

***

Өченче сыйныфка күчкән елы иде. Ул моны бик яхшы хәтерли. Чөнки соңгы кыңгырау бәйрәмендә укытучылары Җәмилә апа аны бөтен кеше алдында мактаган иде бит.

—Мортазина соңгы чиректә бик тырышты, алдынгылар сафына басты, ударница булды,—дип, Мәрьямнең аркасыннан сөеп торды,—җырдан гына тартыласы бар. Монысы инде кыен булмас, җырчы Мәгъфур кызы лабаса ул.

Укытучы ярыш күрсәткечләре тактасындагы Мәрьямнең исем-фамилиясе язылган кәгазьне ташбакадан алып, ат сурәте өстенә калады. Гөрләтеп кул чаптылар.

И, сөенгәннәре! Аэропланда «очучы» отличниклар да болай сөенмәгәндер, мөгаен.

Ул жыр дигән фәнне дә һичшиксез иярләячәк, кулында аргамак төзгене аның хәзер!

Әлеге изге ниятенә кыз кичекмәстән тотынды да, кичке якта мунчада бик тырыша-тырыша тавышын көйләү белән шөгыльләнде. Әтисе килеп кереп кенә эшне бозды. Аның кайчан шаяртуын, кайчан җитди сөйләшкәнен дә белмәссең. Авызына каратып кына тора. Тик бу юлы Мәрьям әтисенә бик нык үпкәләде. Үпкәләмичә соң?

—Кем кәҗә койрыгын кыса икән дисәм, син икәнсең, кызым,—дип мыскыллады ич.

Мәрьям гарьлегеннән ялангa чыгып йөгерде. Җыр-моң хакында элек тә сүз чыккалап тора иде анысы. «Анаң ягына тарттың син, кызым, алар нәселләре белән саңгырау, барысының да колакларына аю баскан»,—дип чын күңелдән борчыла иде әтисе. Үзе ул авылда бер җырчы.

Ялан тулы кыз-кыркын, малай-шалай. Чыр-чу киләләр. Тиздән көтү кайтасы, мал-туарларын каршыларга төшкәннәр. Ул да шуларга кушылды. Үпкәсе дә онытылды. Дөньяда җырдан башка да күңелле шөгыльләр җитәрлек ләбаса! Кызыл карагат пешкән ди әнә. Беркөнне әтисе дус кызы Нәгыймә белән аларны Байгыҗат атавына илтеп куйды. Әбәт вакытында килеп алырмын, диде.

Карагат Ачы әрәмәсендә дә бар. Бу әрәмә авылга авам дип кенә тора. Тик андагысын пешәр-пешмәс сыдырып бетерәләр.

Кызыл карагатны җыюы бик ансат. Ешлыкка кереп чүгәлисең дә, күзәтәсең. Җимеш унган елны алар күзгә тәгәрәп кереп торалар.

—Кара әле, Нәгыймә, кара, ут чыккан кебек бит, куак аслары кып-кызыл,—диде Мәрьям куанычыннан нишләргә белмичә.

—Мыж,—дип, Нәгыймә дә хак бәясен чыгарды.

Җимеш ботакларга тәлгәш-тәлгәш булып эленгән иде. Эредер үзләре, берсе-берсе бер уч, чыпчык башы кадәр. Тырыслары бик тиз тулды. Аннан авызларына җыярга тотындылар. Бераз гына әчкелтем, әмма искиткеч татлы иде карагат. Сусыл, кабуга эреп китә. Шартлар чиккә җиттеләр, ә күзләре һаман комсызлана...

—Житте, кыз, юньлелеккә түгел бу,—дип, иң беренче Нәгыймә туктады.

—Әткәй дә килеп җитәр инде,—диде Мәрьям.

—Әйдә соң, чыга торыйк,—диде Нәгыймә.

Ләкин кайсы якка барырга белмичә аптырап калдылар. Кызып китеп, шактый эчкә кергәннәр икән.

—Адаштык бугай без, Мәрьям,—диде Нәгыймә як-якка карангалап.

—Курыкма, әткәй таба безне,—дип юатты Мәрьям дустын. Әмма үзенен дә тез буыннары калтырана иде.

Бәргәләнү-суккалануларның бер фәтвәсе дә булмады, нииндидер күл тирәсендә әйләнделәр дә тулгандылар. Кычкыра-кычкыра тамаклары карлыгып бетте.

Бер арада Мәрьямнең колагына яфрак лепердәве кебек кенә нәзек моң кагылып киткәндәй булды. Кыз сагаеп калды. Тик канәчкеч кигәвеннәр безелдәвеннән гайре тавыш ишетелмәде.

Өмет өзелгәндә генә моң янә кабынып алды. Тагын сүнде, тагын кабынды. Ниһаять, аермачык ишетелә башлады.

Шәм шәриф дигән ай шәһәрдә
Ахшам бетми капка ябылмас;

Үткән дә генә гомер, калган хәтер
Сатып алам дисәң дә табылмас.

Кызлар абына-сөртенә җырга каршы йөгерделәр.

—Сез бит, чибәркәйләр, башкорт ягына ук чыгып киткәнсез, насила таптым,—дип акланды Мәгъфур.

—Алай да җырлый беләсен әле, әткәй,—дип, Мәрьям әтисенә елышты.

***

Юлда ниндидер бәндәләр төркеме пәйда булды. Менә кемнәр икән ул гауралы җыр ияләре! Ләкин кыз шатланмады. Чөнки бик шөбһәле төркем иде бу. Кайсы авыз тутырып акыра, кайсы маймылдай сикергәләп бии, кайсы шырык-шырык көлә. Әйтерсең лә, тиләләр йортыннан качкан адәмнәр. Ә иң алдан чәчен-башын туздырып Сәгыйдә килә…

Аны күргәч, Мәрьям коелды да төште, җаны калтыранган бармак очларында гына эленеп калды. Ни дип җавап бирер ул? Картларның юравы рас килә түгелме?

Шөкер, җавап тотарга туры килмәде. Чөнки бу сагым иде. Мәрьям, үзе дә сизмәстән, борынгыдан калган ташландык каберлек хәрабәләрендә хакимлек итүче өрәкләр биләмәсенә килеп кергән иде.

Моны кыз үзе дә абайлап алды. Ләкин ни файда, алар аны барыбер тозакларыннан ычкындырырга ашыкмадылар. Теге чакта, карагат җыйганда, әтисенең җыры коткару алып килгән булса, боларның кычкырышу-бакырышулары әсирлек богавы гына кидерде.

***

Ул көнне төштән соң коеп яңгыр яуды. Ишелеп кенә төште. Меңнәр тавы артыннан шабыртап-дөбертәп кара болыт килеп чыкты да, күк йөзен каплап та алды. Мизгел эчендә печән пакусларын, күбәләр, чүмәләләрне су йотты. Җир бу мул суны сеңдерә алмыйча тончыгып калды.

Печәнчеләр кибәнне сырып алды. Тик монда да дулап-дулап яуган яңгырдан ышыкланыр чама юк иде. Берөзлексез күк күкри, яшен яшьни. Ахыр заман диярсең.

Ярты сәгатьләп шулай талкыды-талкыды да, болыт Агыйдел арьягына кереп югалды. Яңгыр туктады. Ләкин кешелекне калдырмады.

—Җәмәгать, Аллаһы Тәгалә гамәлләренә каршы килеп булмый,—диде бригадир Әкрәметдин бабай,—бүгенгә таралышырбыз, үземнең әтбитстбиннескә алам, кайсыдыр ки, мунча ягып керегез, юеш киемнәрегезне киптерегез, яманыгыз, иртәгә ыштубы кәк нәят.

Хатыннар торналар кебек тезелешеп, кайту юлына чыктылар. Аяк асты лычтыр-лычтыр килә, атлаулары мең бәла. Яшьрәкләр аяк киемнәреннән арындылар.

—Җинеләеп киттем, син дә чабатанны сал, Сәгыйдәттәй,—диде Мәрьям күршесенә.—Интекмә.

Сәгыйдә эре сөякле көчле хатын. Сузгә килешкәндә, җенләнеп китеп, чалгысын тауга каршы селтәргә дә күп сорамый. Әмма йомшак күңелле, бик тиз кайтып төшә. Ярдәмчел. Мәрьям аны шушы миһербанлыгы өчен ихтирам итә дә инде.

—Бу хатын тилебәрән орлыгы ашаган ахры дип көләрләр иде бугай,—диде Сәгыйдә көлемсерәп.—Ике бала әнкәсе бит мин, синең сыман яшь туташ түгел…

Әллә ялгыш басты, әллә таеп китте, сүзен дә тәгәлләргә өлгермәде, Сәгыйдә мәтәлеп сазга барып төште.

Хатыннарга бу бик кызык булып тоелды, күрәсең, бот чабып көлешергә, шукланырга тотындылар.

—Авылга ничә чакрым калган, кодача?

—Болай да күренә ләбаса, җиргә ятып карамасаң соң...

—Кичә генә Хөббәтеннән хат алган ие бит, шуңа тез буыннары калтырый аның, түземлеге төкәнгән... ха-ха-ха...

—Тычканга үлем, мәчегә көлке, әллә ни әйттерерсез,—дип, Сәгыйдә Мәрьям ярдәмендә торып басты.

—Әйттем мин сиңа, чабатаңны салып кулыңа тот дидем. Барыбер салырга туры килде,—дип, Мәрьям дә төрттергәндәй итте.

—Утын алып керсәң, мунчаны уртакка ягарбыз,—диде Сәгыйдә. Аннан сукранып алды: «Бу калхузны әйтер идем, яшь балалы хатынны җәһәннәм артына эшкә йөртә бит, бүген Рәҗибә нарасыемны имезергә дә алып килә алмады, елый-елый ярсып беткәндер инде, бәбкәчәем».

—Рәҗибә үзе дә терсәк буе гына ич әле,—диде Мәрьям.

—Яклашма, элек, әнә, сигез-тугыз яшьтә кызларны кияүгә ярәшкәннәр...

—Сөйлисең тагын, булмаганны.

Рәҗилә дөрестән дә имине бик сагынган иде. Кулга алуга, нәни бармаклары белән, түземсезләнеп, ярсый-ярсый әнисенең изүен тарткаларга кереште.

Ул арада Мәрьям белән Рәҗибә мунчага су ташыдылар. Мичен Сәгыйдә тергезеп җибәрде.

Рәҗибә курчакларын күтәреп, Мәрьям янына керде. Ул күрше кызын бик ярата, еш кына кунарга да кала.

—Матур апа, менә бу курчагымны әле бүген генә ясадым, тач син инде, иеме?—дип, кыз кәгазь кисәген бөтереп укмаштырган кечкенә төргәк-курчакны Мәрьямгә күрсәтте.—Күзләре синеке шикелле йомры, чәчләре чем кара. Күр, каен күмере бу, сагыз белән ябыштырып куйдым, ошаганмы? Ирене калын, авызы олы. Кызылга буярга каләмем генә булмады.

—Син инде бигрәк, Рәҗибә, авызым олы дигәч тә, алай капчык кадәр үк түгел бит инде...

—Олы булса ни, ул бит матур олы...

—Әйдә, ярар, синеңчә булсын.

—Күлмәге генә иске,—диде кыз йөзенә сагышлы кыяфәт чыгарып,—синең бирәр ситсы кисәгең юкмы?

—Ә-ә, хәйләкәр төлке, менә нигә миңа охшатып ясагансың икән ул курчагыңны. Бер-бер җаен тапмый ярамас инде, матур апаның күлмәге дә матур була ич инде аның.

—Сәдәф тә кирәгие...

—И, кабык ирен, без танау.

Кызлар мунчага да житәкләшеп киттеләр.

—Кайтуыгызга талкан кыздырып, чәй куеп торырмын, иркенләп керегез,—дип озатып калды аларны Сәгыйдә.

Шуннан соң күп тә үтми, уйламаганда-көтмәгәндә, башка атылган таш кебек, җиргә адашкан яшен угы сызылып төште. Сөн буендагы актирәкләр ышыгында посып торган сәләмә генә болыт кисәге әнә шулай дөньяны дер селкетте.

—Матур апа, колагым чыңлый,—диде Рәҗибә,—мин куркам...

Бик якында чәрелдәде, бәла-каза була күрмәсен берүк, дип борчылып куйды

Мәрьям үзе дә. Кызыкайга гына сиздермәде.

—Яңгырдан куркып торырга, син житкән кыз ич инде,—дип көлгән атлы булды. Тик борчуы барыбер басылмады. Ахыры, коенырга чиста су алып керү сылтавы белән, ишек алдына чыкты да, өйгә атылып керде.

...Сәгыйдә чалынган мал кебек мич авызында гына аунап ята иде. Чалкан төшкән. Учакта чатыр-чотыр килеп ут яна, казанда талкан пешә...

Хужабикәнең ачык мангаенда биш тиен зурлыгында кара-көрән тап шәйләнә. Күрәсең, яшен эзедер...

Йөгерешеп күршеләр кереп житте. Сәгыйдәнең йөзен генә ачык калдырып, жиргә күмеп куйдылар. Имеш, жир яшенне суыра. Ләкин файдасы тимәде, суырмады жир яшь хатынның яшенен.

Картлар моны әйбәткә юрамадылар...

***

Өрәкләр янында аты-юлы белән сүгенергә кирәк дигәнне ишеткәне бар иде Мәрьямнең.

—Әй, каткан крисләр, таегыз моннан!—дип, ул да ачу сүзләрен өрәкләргә сипте.

Чыгынчы атларны, үшән сыерларны, ялагай маэмайларны, кирәк-кирәкмәгән жирдә тибенеп йөрүче кош-кортларны «каткан крис» дип орыша Мәрьям. Билгеле, аның орышуын тегеләр колакларына да элмиләр. Өрәкләр дә ишетмәде, ахры. Чөнки башы һаман иләс-миләс, уйларын, акылын һич бер төенгә төйни алмый. Аңа исә түшендә шуышып булса да бу афәтле урыннан чыгу, котылу әмәлен табарга кирәк.

Мәрьям күпер әрәтәсеннән аерылды да, алпан-тилпән бер-ике адым жир атлады. Тик янә туктап калды. Чөнки каршысына ниндидер ут йомарламнары тәгәрәшеп килә иде. Коты качты. Алар шундый зур тизлек белән килäләр ки, менә хәзер таптап-изеп, яндырып-көйдереп, кара күмергә әйләндереп китәрләр төсле. Тышаулы аякларга ышаныч юк, качып котылырмын димә. Кара төндә, өрәкләр биләмәсендә ярдәмгә дә өмет итә алмыйсың. Ә жан калерле.

—Коткарыгыз!

Үзенчә кычкырган сыман тоелса да, бу юлы тавышы чыкмады. Аны шул ук мизгелдә шөкәтсез салкын нур ярып узды, тәнен көзән жыера башлады, гүя берьюлы меңәрләгән энә кададылар. Шунда ул әлеге ут йомарламнарының убыр уты икәнен төшенеп алды.

Күрәселәре бар икән, Ходаем, өрәкләре генә житмәгән, инде убыр уты...

Тәүге тапкыр әбисе авызыннан ишеткән иде ул бу Аллаһ каргаган әрвахларның жаны турында. Бер караңгы көзге кичтә йомыш белән урамга чыкканнар иде. Аяк астын шатырдатып туңдырган, әмма әле кар күренми. Аның урынына, жил котырына. Кое янындагы тупылның ябалдашларын пыран-заран китерә. Карга оялары ничек түзәдер?

—Әбекәй, Сөн аръягында нинди ут йөри ул?—дип сорады Мәрьям. Аның үткен күзләре жем-жем итеп тәгәрәгән ут шарын шәйләп алган иде.

—Бисмилланы әйт, балам, бу убыр уты,—диде карчык шомлы тавыш белән,—каһәрле кабер анда. Шул гөнаһлының жаны үзенә урын таба алмыйча изалана, утка әйләнгән әнә. Тәүбә-тәүбә, әстәгъфирулла, Ходай күрсәтмәсен.

—Жан нәрсә соң ул, әбекәй?—дип төпченде кызчык.

Карчык сорауны ишетмәмешкә салынды, оныгын житәкләп сүзсез генә өйгә ашыкты.

Әбисе, убыр уты бәндәләрне саташтыра, адаштыра, алмаштыра, дип

куркытса да кызчык ни өчендер шөбһәләнмәде. Киресенчә, анын убыр утын якыннанрак күрәсе, кулга ияләштерәсе, хәтта куыша-куыша уйныйсы килеп китте. Нинди икән ул утка әверелгән серле жан?

***

Мәрьям балаларны үзенә алып чыкты. Чөнки башка сыеныр кешеләре юк. Әтиләре Хөббәтнең анасы исән исәнлеккә, ләкин бу ярымсукыр карчыкның үз хәле хәл, кая анда оныклар карау? Бәлки, ныклабрак чарасына керешсән, бер-бер әмәлен табырга да булыр иде. Ә Мәрьям теләми. Ярата ул бу балаларны. Гел бергә укмашып яшәделәр бит. Балалар да Мәрьямне үз итә. Рәжибә анын ерак юлдан кайтуын түземсезлек белән көтә иде. Тыны-көне бетеп каршысына йөгереп чыга, кочаклап ала. Аннан сон:

—Матур апа, куян күчтәнәче алып кайттыңмы?—дип сорый.

Мәрьям үзе шушы гадәткә күндерде бәләкәчне. Бөрмәкәендә һәрвакыт бер кыерчык ипи булыр иде. Шул туңган ипи кисәген әлләнигә күрә иде Рәжибә, кәнфит-прәннекләрен бер якта торсын.

—Тешләрен каната-каната кимерә,—дип көлә иде Сәгыйдә.

Рәжиләсе дә матур апасынын үчтеки-үчтеки итүен көтеп кенә тора. Кулга алуга, күгәрчен кебек гөрелди башлый.

Әнисез калу бу сабый өчен беренче чиратта имисез калу иде. Ул аны бик авыр кичерә. Жылый, көйсезләнә, начар йоклый. Мәрьям аны Тәслимә исемле хатынга алып барды. Тик сөте үз баласына да житми икән, бер тапкыр гына имезде.

Рәжилә һаман ими даулый. Мәрьямнең изүенә һич тынгы бирми, бәгыр, йомшак кулларын эчкә үк шудыра. Имезлеккә генә риза түгел. Берсендә бик өзгәләнеп кымтырыклый башлагач түзмәде Мәрьям, имиен балага каптырды. Әллә нинди сәер халәт иде бу. Әүвәл кытыгы килде, аннан тәне буйлап ләззәтле дулкыннар йөгерешеп узды, ниндидер чит теләк кабынды… Рәжилә ими башын тешләп алгач кына ярсуы басылды. Балага исә сөт кирәк. Ә ул юк. Үзе барыбер имине авызыннан ычкындырмый.

Акрынлап икесе дә яраклашты әлеге хәлгә. Ә бердән-бер көнне күкрәгенә сөт төште. Шатлыгыннан башы күккә тиярдәй булды Мәрьямнең. Рәжилә хәзер «әннә» дип очынып тора, дөньясы түгәрәкләнде.

Сәүит Галимә килеп кергәндә дә шул шөгыльдә иде, оялуыннан йөзе чөгендер сыман кызарып чыкты. Кызын бишеккә салмакчы булып кабалана-кабалана торып та баскан иде. Кая ул, Рәжилә имиенә сагыздай берекkән, рәисен бармы да юкмы аңа.

—Имезәсең ызначитсы,—дип сузды Галимә, исе китмичә генә—ә зерә…

—Нәрсә, әллә ярамыймы?—диде Мәрьям хафаланып,—бик юксынды бит… Аллага шөкер, менә… сөт тә төште…

—Иптәш Мортазина,—дип бүлде аны рәис,—бала урлау зур жинаятькә санала, сәүит хөкүмәте мондый башбаштаклыкка юл куя алмый.

—Галимә апа…

—Галимә апа түгел, иптәш Сафина!—дип төзәтте рәис йорт хужасын.

Анын авылда «иптәш» дигән кушаматы чыккан. Анасына да «Хәлимә иптәш», дип мөрәжәгать итә, имеш. Шундый инде ул, бик рәсми зат. Кеше тентергә бик маһир. Эштән кайтучыларны басу капкасы янында иләк аша уздыргандай уздыра. Ике хатынны төрмәгә утыртты инде.

—Иптәш … Сафина … апа … минем бала урлаганым юк, аларны урамда калдырып булмый ич инде. Хөббәт абзыйнын да рөхсәте бар, хатын да күрсәтә алам…

—Башын яшь әле мине өйрәтергә иптәш Мортазина, ул шәхси хат кына, юридик дукәмит түгел.

—Алайса нишләргә соң, юлын өйрәт ип... ип... тәш Сафина апа, мин ул балаларны карарга ризамын.

—Һы, ризамын, имеш, Хөббәт иптәшне курортта дип беләсенме әллә? Фронтта ул. Сугышта! Ә сугышта атышалар ызначитсы. Әгәр һәлак булса, ызначит тәк. Ул вакытта нишләрсең?

—Белмим...

—Ә мин беләм, Мәрьям иптәш,—дип күзләрен чекрәйтте рәис,—балаларны детдомга бирергә кирәк. Хөкүмәт карамагына. Алар анда менә дигән бәлшивистик тәрбия алачак. Син бирә алмыйсың андый тәрбияне. Птаму шту белемен сай, ызначит тәк.

Мәрьямнең күзләренә яшь бәреп чыкты.

—Син әле яшь кыз, иптәш Мортазина,—дип дәвам итте рәис бераз кайта төшеп,—үз гаиләңне дә корасың бар. Ул вакытта бу балалар нишләр? Кыскасы, метрикәләрен сәүиткә китер.

Галимә артыннан ук диярлек очынып-җилләнеп Рәҗибә кайтып керде.

—Мине бөтенесе кимсетә,—диде иреннәрен мелт-мелт китереп.—Халисә минем белән уйнамый...

—Халисә бөтен кеше түгел бит әле ул,—дип көлемсерәде Мәрьям.

—Ятим итәләр...

Мәрьям кызчыкны күкрәгенә кысып, чәчләреннән сыйпап торды да:

—Әллә нәрсәләр уйлап тапма инде, Рәҗибә,—диде.

—Әнә бит, үзең дә кызым димисең, Рәҗибә дә Рәҗибә...

—Кызым инде, кызым...

—Ә мин сиңа әнкәй дип дәшермен, яме? Шуннан соң Халисә дә минем белән уйнарга кимсенмәс.

Кызчыкның иртәнге чык шикелле ихлас сүзләрен ишетү бик рәхәт иде Мәрьямгә. Әнкәй... Нинди кадерле сүз! Балдай татлы сүз. Ишетеп туймастай сүз. Тик аның дәрәҗәсен дә төшерергә ярамый.

—Синең әнкәең Сәгыйдәттәй, кызым,—диде Мәрьям тыныч кына,—ана кеше бер генә була ул.

—Ә мин сиңа укытучы Җәүһәрия апаның Ләйләсе сыман әни диярмен. Матур апа әни! Сиңа бик килешә, матур апа да, әни дә.

Их, балакаем, сәүит Галимәнең нинди ният белән йөргәнен белмисең шул әле син, дип сызланды Мәрьям. Үтмәс пычак белән бәгъремне тураклап чыгып китте бит, хәерсез. Аның белән сүз көрәштерә алмыйсың, ул урындагы кеше. Ярар димичә ни дисең, ярарның чабатасы тузмый диләр ич. Ләкин Мәрьям дә сүзендә торачак, балаларны барыбер ташламаячак. Яннарына барып йөрер. Шөкер, Такталачык ерак түгел, җәяүләп тә көнендә урап кайтып була. Ял көннәрендә авылга алып кайтыр. Барысы да җайланыр, Аллаһы боерса.

Мәрьям әчке бер дулкынлану һәм борчылу белән сәүиткә чакыруларын көтте. Ә аның гүя барлыгын да оныттылар, рәис күзгә-күз очрашканда да кырын карап кына уза. Ул, әлбәттә, район балалар йорты ябылуыннан, дүртбиш районга бер генә шундый сыену урыны калдыруларыннан хәбәрдар түгел иде. Галимә аңа бу хакта әйтүне кирәк тә тапмады.

Мәрьям дә кул кушырып утырмады анысы, хәлне бәйнә-бәйнә аңлатып, Хөббәткә хат юллады, балаларны ташламаячагын янә бер тапкыр тәкърарлады. Ярдәм сорарга да исәпләгән иде дә, кыймады, фронттагы кешедән нинди ярдәм өмет итмәк кирәк, дип уйлады.

Ә ярдәм килде. Бөтенләй көтелмәгән яктан килде. Бер көнне аны иртән иртүк авыл советына дәшеп алдылар. Тәки сүзен сүз итә, кәтүк, каныкса каныга инде мәгәр, дип юл буе эченнән генә Галимәне орышып барды Мәрьям. Галимә исә, гомер булмаганны, ачык йөз белән каршылады.

—Әйдүк, уз, иптәш Мортазина! Уз,—дип бер алдына, биш артына төште.

Мәрьям шунда гына район түрәсен абайлап алды. Еш күренгәли ул авылда. Йомгактай тыгыз гәүдәле юантык кына кеше.

—Бик миһербанлы кыз икәнсең, сеңлем,—диде ул этиләргә хас ихтирамлылык белән,—ятим балаларны тәрбиягә алганың икән. Маладис.

—Иң алдынгы комсомолкабыз,—дип, Галимә мактау сүзе кыстырырга ашыкты. Хәлбуки, Мәрьям комсомол әгъзасы түгел иде. Шулай да бәхәсләшеп тормады, бу матур сүзләрнең тәмен җибәрәсе итмәде.

—Дәүләтебезнең иң мөхтәрәм җитәкчеләреннән берсе Михаил Иванович Калининның күрсәтмәсе буенча, фронтовик Хөббәт Хәйруллинның ике кыз баласын тәрбияләвең өчен сиңа, иптәш Мортазина, большевикларча рәхмәт җиткерәм һәм бүләк тапшырам,—диде түрә тантаналы рәвештә.

Ул Мәрьямгә бер пар резин галош, балаларга күлмәклек тукыма тоттырды. Кыз каушап төште.

—Болар барысы да миңа… безгә… миңи?—дип сорады тотлыга-тотлыга.

—Сезгә, Мортазина, сезгә,—диде түрә,—манный ярмасына, шикәргә карточка да бирәбез әле, аларын раймагтан үзең төшеп алырсың.

—Эштән җибәрмәсләр шул…

—Борчылма, җибәрербез,—диде рәис.

Мәрьям әле һаман бу ишелеп төшкән бәхетенә ышанып бетми иде. Шуна күрә:

—Рәҗиләне дә, Рәҗибәне дә тартып алмыйсызмы инде?—дип кат-кат белеште.

—Кайгырма, аталары кайтканчы балалар синдә кала,—дип кабатлады түрә.

Соңыннан барысы да ачыкланды. Хөббәт солдат СССР Югары Советы Президиумы рәисе Калининга хат белән мөрәҗәгать иткән булган икән. Фәрештәнең, амин, дигән вакытына туры килгән күрәсең, Михаил Иванович йөзләгән мөрәҗәгать арасыннан нәкъ менә Хөббәтнекенә игътибар иткән.

Хәзер Мәрьям чын яшь аналар кебек балалы хатыннар рәтендә йөри. Эше дә авыл эчендә. Ашлык җилгәрүдә. Көтү куып, йорт кирәк-яракларын барлаганнан соң, Рәҗиләне бәләкәй арбага сала да, ындыр табагына юнәлә. Рәҗибәсен уятмый, ашарына-эчәренә генә хәзерләп куя. Хәер, Рәҗибәгә дә эш җитәрлек. Идән юу, өй җыештыру, су ташу, чүп утау кебек эшләр аның вазифасына керә.

Мәрьямне кулдашлары кыз-хатын дип ирештерә, егет кәмәшләрен өркетеп бетерәсең бит инде, диләр.

—Өркетергә егетләре юк бит әле,—дип көлә Мәрьям.

—Ярар, кешене юкка тинтерәтмәгез, ярата ул бу балаларны,—диде чираттагы бала имезү вакытында Гөлсинә исемле хатын,—күрмисезмени, баласы имиенә сөлектәй ябышкан.

—Анысы хак инде, тапкан да ана, баккан да ана.

—Кенә Елгадагы ар хатыны Нәстүк хәленә калса нишләрбез, исәркәем,—дип күз кысты Маймүнә шаян.

—Ә ул нинди хәлгә калган соң?

—Яратуына тәкать тапмыйча баласын килегә салып төйгән ди бит ул, исәркәем.

—Жә-жә…

—Такмаклый-такмаклый төя ди ишу житмәсә:

Сөйдем, сөйдем, сөйдем маниш,
Килегә салып төйдем маниш,
Аяклары тыпыр маниш,
Күзләре калдиш-коллиш…

***

Менә чын убыр ничек була икән? Теге вакытта, әбисе бик шомлы итеп сөйләгәндә, Сөн аръягында очып йөрүче ут шарыннан бөртек тә курыкмады. Ул аңа нindidер мавыктыргыч, серле, кызык уен кебек булып кына тоелган иде.

Бервакыт дусты Нәгыймә:

—Ишеттеңме, кызый, Гыйндулла корткасының моржасыннан убыр уты чыкканны күргәннәр,—дип күнелен ярсытты.

Кайчандыр ихтирамлы, абруйлы остабикәнең күпләр хәзер исемен дә белми, Гыйндулла корткасы дип кенә йөртәләр. Гыйндулла авылның иң мәртәбәле хәзрәте булган. Инкыйлабтан соң Архангел якларына сөргәннәр. Шунда агач астында калган мескен. Ә остабикәне йорт-җиреннән, мал-туарыннан мәхрүм итеп, авыл читендәге бер мунчага чыгарганнар. Балаларын да сөргәннәр.

Кортка кеше белән аралашмый, ярдәм сорамый, йомышсыз урамга чыкмый, йөзен күрсәтми. Җаен-кышын шәлгә уралган булыр.

—Әйдә, андыйбыз,—диде Мәрьям күзләрен очландырып.

—Ә-ә, убыр урлап алып китәр иде бугай…

Мәрьям бер кушуч кабак төше бәрабәренә дустын барыбер ризалаштырды. Күккә энгер-менгер пәрдәсе эленүгә, кача-поса шунда килделәр. Тавык кетәге кадәрле генә бу шомлы йорт гүя төн катында эреп югалган иде. Салам селкенгән тавыш та ишетелми. Нindidер хәвефле тынлык. Йөрәкләре кабыргаларын сытып чыгардай булып тибә. Менә хәзер убыр очып килер дә эләктереп алып китәр сыман.

Шул вакыт якында гына мәче мияулаган тавыш ишетелде. Кызыкайларның икесе берьюлы үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде: «Үтерәләр!»

…Ә бу кыр уртасында кычкырып та булмый.

***

Хөббәтнең тәкъдиме аяз көннең яшене кебек тәэсир итте Мәрьямгә, күнеле таралып китте. Бу хакта аның уйлап караганы да булмады. Кешеләр дә андый сүз ишеттермәде. Югыйсә, амбар хатыннарының теле тоздан әче, шаярткан атлы булып, астыртын гына төрттерәләр дә, ишарәлиләр дә. Ә бу турыда ник берсе юри булса да сүз кузгатсын? Димәк, ихтимал дип тә санамыйлар. Төптәнрәк уйлап караганда, Хөббәтнең тәкъдиме гадәти дә, табигый да, вакытлы да.

Мәрьям хатны ятлап бетерде инде, жиде төн уртасында йокысыннан уятып сорасалар да сөйләп бирә алыр иде, мөгаен. Менә ул:

«Хат башы, яз каршы. Минем өчен кадерле вә гыйзэтле булган сенлем Мәрьямбикә, сезләргә һавадагы йолдызлар, судагы балыклар санынча күптин-күп, чуктин-чук сәламнәремне житкерүче ошбу хатның иясен боец Хәйруллин Хөббәт дип белерсен.

Сәлам шулай ук яраткан кызларым Рәжибә белән Рәжиләгә. Һәм дә инәкәем Шәмсебәдәр корткага, күрше-күләннәргә, шулай ук минем хәлемне белешкән

барча авылдашларыма. Сәлам соңыннан түбәндәгеләрне белдерәм: шөкер, үзем исән-сау, командирларым разый, әмма дә ләкин сугыш хәлләрен хатка язарга ярамый. Шуңа күрә озынга сузмыйча гына тәкъдимемне җиткерергә ашыгам.

Минем өчен кадерле вә гыйззәтле булган сеңлем Мәрьямбикә! Балаларымны каравына ихлас рәхмәтемне белдерәм. Бу минем иң зур куанычым. Мин сугыштан кайткач та аларны бергәләп кеше итсәк иде, дим. Чык мина кияүгә. Сина мәгълүм, мин төпле кеше. Миңа ышанырга була. Үзебезнен дә балаларыбыз булыр. Каз оясы кебек ишле балалар үстерербез. Сәгыйдәне инде кире кайтарып булмый, догада булыйк.

Кайсыдыр ки, әгәр риза булсаң, Башкорт ягындагы Татыш авылына барып, Гыйльметдин бабайдан никах укыт. Изге гамәлне озакка сузарга ярамый. Без танышлар. Аннан һәр елны бәрән печәне сатып ала торган идем, бәрәннәр бик яратып ашыйлар иде печәнен. Мин кайткач, районга төшеп загска керербез. Сине рәнжеткәнгә күрә ул сабакы сәүит Галимәне женем сөйми. Анарда язылмыйбыз.

Каз канаты кат-кат булыр, алып язар хат булыр. Хәзергә сүзем бетте. Түземсезлек белән җавап көтеп калам.»

Кеше хәлен кеше белми, уклау төште башыма, диярсең. Киңәш-табыш итүчесе дә юк бит анын. Әти-әнисе вафат. Якын туганнары юк. Чит кешегә чыгарасы килми. Барысы да үз башына калды. Ятса шул уй, торса шул уй. Балалар аны болай да әни дип саный. Бәлкем, тәвәккәлләргәдер? Үзе язганча, Хөббәт абзый төпле адәм, булдыклы, хуҗалыкчыл. Җор, уенчак. Дөнья көтәргә, яшәргә менә дигән.

Мәрьям үз-үзенә елмаеп куйды. «Юк килмәгән җирләре», дип җыр сузасы гына кала икән ич. Бер кешегә күбрәк түгелме бу күркәмлекләр? Хәер, яхшыга юрасаң, яхшы була кеше, начарга юрасаң, начар була кеше, дия торган иде атасы. Кимчелексез кеше булмас. Әнә, дүрт аяклы сыер да абына. Чамасына туры килсә, шул җиткән.

Алар ничектер электән үк бер-берсен күз уңында тотып яшәделәр. Мәрьямне, эрерәк сөякле булгангамы, җиденчене бетергәч, атлы эшкә билгеләделәр. Хөббәткә дә ат җене кагылган. Арба-чаналары шуна күрә еш кына бер эздән йөри иде.

Бервакыт юл эшенә җибәрделәр. Ел саен урып-җыюга керешер алдыннан заготзерно юлына «иләк белән су ташу» башлана. «Иләк белән су ташу» дигәне Хөббәт сүзе. Чынлыкта, юлга ком-таш җаяләр. Ләкин Хөббәт тә хаклы. Ник дигәндә, ул юлга ташыган ком-ташны бер урынга өйсәң, Каф тавыннан ким булмас иде, шөт. Сазлы җир ул. Убыр урынына йотып кына бара. «Бер җиннән ике кул чыгарып эшләсәң дә туйдыра алмассың ул бирәнне»,—дип көлә Хөббәт. Ләкин башка чарасы да юк, тирә-якта күлләр җәйрәп ята.

Мәрьямнең аты көчлегә көчле үзе, күпме төясәң дә тарта. Тик чорсыз. Кичә, әнә, пырдымсызланып чигенгән иде, бер як арт тәгәрмәч түмгәккә эләгеп, арба йөз түбән ауды да китте. Хәтта кендеге дә чыгып очты.

—Бабаң утырмага килсен, әбиеңә сәлам әйт, кая китеп барыш болай, балдыз?—дип җорланды Хөббәт.

—Сүз бозаулатканчы атны тотар идең, җизнәкәй, күрмисеңмени, ни-нәмә майтарды, ул җенле торып чабарга да күп сорамас,—диде Мәрьям җиңелчә шаяру белән,—сез ир-атка авыз ерырга гына булсын.

Хөббәт ике атлап, бер сикерүдә җилкенчәк бахбайның каршысына төште дә, йөгәненнән эләктереп алды. Ул арада башкалар да килеп җитте. Тиз-тиз генә арбаны бастырып, кендекләп тә куйдылар.

—Балдызым, калдырмам ялгызын, дип кайчаннан бирле тукып килэм мин

сина,—дип, жорлануында булды Хөббәт.

—Балдыз сөю язык ди бит, жизнәкәй...

—Язык казык башында, балдызым-ялгызым...

Кайчан, ничек шулай килеп чыккандыр, алар шаяртып бер-берсенә «балдыз-жизнәкәй» дип мөрәҗәгать итешәләр. Югыйсә, Хөббәтнен хәләле Сәгыйдә аръяк кызы, Башкорттан. Мәрьям белән ике арада бернинди туганлык җепләре дә сузылмаган. Үпкәләми, Сәгыйдә үзе дә кин күнелле шаян зат. «Уеннан уймак чыгармагыз»,—дип бармак кына яный.

***

Менә хәзер, чыннан да, уеннан уймак чыгарга тора.

Гыйльметдин мулла атлар карый икән. Мәрьям аны шунда барып тапты. Юка гәүдәле кечерәк кенә карт. Ду китереп абзар чистартып йөри иде. Житез күренә. Күзләре дә очлы, ахры, йомышчы кызны шундук абайлап алды. Агач көрәген кулыннан төшерми генә сәлам кайтарды.

—Әссәламегаләйкүм, кыдым, Ходай гамәлләренне ун кылыр, шәт. Вәләкин атка исәп тотма, әнәтрәк. Персидәтел үде дә җәяү җөри, бүген районга да тәпи-тәпи төшеп китте. Атларны жигү бетте, әнәтрәк, ядгы чәчүгә хәтле ял бирергә карар кылдык. Бигайбә.

—Бабай, мин Күзәкәй авылыннан, Хөббәт абзыйның әманәте артыннан йөрүем...

—Ә-ә, шулаймыни, мин теге, якалы сырма кигәчтен, яна килгән укытучы-мөгаллимә икән бу диеп уйлаганием. Татарстаннан икәнсең әле, бик хуш. Хөббәт балакайны әйтәм, гүәрдиндәй тала жегет ие. Бер чүмәлә печәнне бер кадауда элеп алыр ие. Хат-хәбәре килә алайса, исән-сау әйләнеп кайтырга ядсын,—дип сүзләрен сәйләндәй тезде карт.—Әманәт дигәнен дә әйт инде, тынлап караек.

Мәрьям хәлне анлатып бирде.

Карт ияген көрәк сабына терәп, катып калды. Мәрткә киткәндәй озак кына шушы халәтендә басып торды. Керфексез кысык күзләре дә, тун төймәсе кадәре генә тумпак борыны да, юка иреннәре дә, хәтта авызын әйләндереп алган кыска сакал-мыегы да уйга калган кебек иде.

—Бик сәер йомыш белән җөрисен икән, кыдым, әнәтрәк,—диде карт, ниһаять, телгә килеп,—мондай никах хакында беренче ишетүем. Минем генә баш житмәстер, мөгаен, киңәш-табыш итешмәенчә булмас.

Юл унаенда ул Хәбибҗан атлы ап-ак сакаллы бабайны ияртте. Парлап өйлә намазына бастылар. Аннан соң икәүләп бу гадәти булмаган әманәт хакында гәпләштеләр. Мәрьям ишек алдында көтеп торды.

Татышка аның беренче килүе. Жыйнак кына төзек авыл икән. Салам түбәле өйләрне бармак белән генә санарлык. Хәлле яшиләр, күрәсең. Хәер, урман-суга бай як бит бу. Агыйдел буе авылларында болай да болын-әрәмәлекләр мулдан. Ә Татышта аның иге-чиге юк, ди. Печән күп. Алыш-биреш шуна корылган. Язын печән алтын бәһасе тора. Өстәвенә, балык, җиләк-җимеш бихисап...

Мәрьям йомыш-гамәле турында уйламаска тырыша иде. Хәер, уйны йөгәнләп була ди мени? Ул рөхсәт сорап тормый, бар булганыңны биләп ала. Борчылырлык та шул. Кияүсез кияүгә чыга лабаса!

Тик әле бу Алла кулында. Дөресрәге, мулла кулында. Ә ул бик егылып төшмәде, икеләнебрәк калды. Бер караганда, шиккә урын да юк сыман. Мәрьям риза, Хөббәт риза дигәндәй.

Ниһаять, тәрәзә кагып, Мәрьямне өйгә чакырдылар.

—Әнәтрәк, кыдым, бед Хәбибҗан агай белән шундай фекергә килдек кайсыдырки, Коръән-Кәримдә дә, хәдисләрдә дә бу очрак турында телгә алынмай. Рөхсәт тә, тыю да юк. Шулай булгачтын, әлеге гамәлне үтәргә ярай булып чыга, ягъни дә сөннәт бодылмай,—дип шәрехләп китте Гыйльметдин мулла,—әмма дә ләкин никахта ике якның да катнашуы тиеш. Дәхи дә шаһитлар…

—Укымыйсыз мыни инде алайса?—дип сорады кыз.

—Сабыр, кыдым, сабыр, сүләп бетергәнне көт,—диде мулла чыраен сытып,—бүлдермәйчә генә тыңла. Әнәтрәк, бед шулай килештек: кияү җегетен бәдәлче алыштырыр, Хәбибҗан агай бәдәлче булырга рида, әнәтрәк. Бер-бер адәм өчен хаҗ кылу бар бит, шуның күек инде, әнәтрәк…

Картлар керфексез күзләрен челт-челт йомгалап, кызга текәп бактылар. Өйдә тынлык урнашты. Тып-тып итеп тәрәзә төбеннән тамчы тама, казан астында чытыр-чытыр учак яна. Ләкин картларның аларда гаме юк, Мәрьямнең сүзен көтәләр. Чөнки тәгаен генә ни-нәрсә кылырга икәнен үзләре дә белми иде.

—Жу-ук, мулла бабай, жу-ук,—дип сузды Мәрьям еларга житешеп,—үзем өчен дә, Хөббәт абзый өчен дә җавапны үзем тотам… арага чит кеше кертергә теге… никах бит бу!

Картлар бер-берсенә карашып, жилкәләрен сикертеп куйдылар, бигайбә, янәсе. Шуның белән бергә, үтенечне кире кагасылары да килми иде, ахрысы.

—Анабыд Хәуваның, Иблис коткысына бирелеп, богъдай агачының җимешен өдеп алуыннан башлана бәндәнең гөнаһлары,—дип, ерактанрак суктырып сөйләп китте Гыйльметдин карт, әйтерсең лә, бу «гөнаһлы» гамәлне Мәрьям уйлап тапкан иде,—алай да Аллаһының рәхмәте киң, Атабыд Адәм галәйһиссәлам бик ялынып-ялбарып сорагач, Аллаһы Тәгалә Анабыд Хәуваны ярлыкады. Иншаллаһ, сед колларын да мәрхәмәтеннән ташламас. Догада булыгыд. Шуна да күрә, әнәтрәк, сыңар килеш булса да, нихакка тәвәккәлләргә ният иттек. Кардәшебед Хөббәт мелла хакына ният иттек. Ник дигәндә, Һитлер мәлгунь жирдәге Иблис инде ул. Иблискә каршы орышта катнашучы Хөббәт кардәшебеднең әманәтен башкару Ходай каршында үде бер саваптыр…

—Бу яхшылыкларыгызны ничек тә бәхилләтербез, мулла бабай,—диде Мәрьям,—Ходай үзегезгә дә шатлык-куанычлар насыйп итсен…

—Сүдемне бүлдермә, әйткәнне тыңлап бетер әүвәл,—диде мулла төксе генә,—шартыбыд да бар әле беднең, әнәтрәк.

—Нинди шарт?—дип, янә пошаманга төште кыз.

—Ирең кайткачтын бу никахны яңарту фарыд. Аллаһы кушып, исән-имин торсак, иң беренче монда килерсегед. Бед бакыйга күчкән сүрәттә генә башка муллага мөрәҗәгать итәрсегед, әнәтрәк. Инде дә килеп, Хөббәт кардәшебед белән, сугыш хәлен белеп булмай, ул-бу килеп чыга-нитә калса, син барыбер никахлы җәмәгать саналасың, ягъни дә, ир хатыны исәпләнәсең. Уйла, бу иманга тиң бик олы бурыч.

Карт чепи күзләре белән Мәрьямгә текәлде. Ә ул озак көттермәде:

—Мин риза,—диде.

***

Төн пәрдәсенең бер чите аз гына ачылып китте. Шул тонык ачыклык арасыннан беленер-беленмәс кенә яктылык сирпелеп алды. Мәрьям дә җиңеләйде, гүя баядан бирле аны тышауда тоткан богауны кемдер өзеп ыргытты.

Ул шатлана-шатлана элеккечә житезлек белән алга элдертте. Ниһаять, сихерле

күпер дә артта калды. Бераздан куе агачлык башланды. Монда карангы икән. Ләкин әле генә тәмуг базыннан хәвеф-хәтәрсез котылган кеше өчен бу карангылык мич арасына кереп чыгу кебек кенә иде. Кыз ана игътибар да итмәде. Каршында янып торган ике ут ноктасы пәйда булгач та төсе үзгәрмәде, битараф кына: «Әстәгъфирулла, әллә тагын убыр уты инде»,—дип уйлап куйды.

Курку соңрак килде. Тик бу вакытта әлеге котсыз пар ут кисәве ыргылып, аның өстенә оча иде инде. Ул читкә тайпылды. Убыр да өлгер. Һөҗүм арты һөҗүм. Әгәр абынып-сөртенеп китәсең икән, беттең, тора алмаячаксың. Шуңа күрә бөтергеч урынына бөтерелә Мәрьям. Үз-үзенә көч биреп, сөйләнә-сөйләнә бөтерелә:

—Ега алмассың, нибуч, минем ике кызым бар, аларны ятим итәргә хакым юк. Аңлыйсыңмы, каткан крис, хакым юк! Рәҗиләм әле имчәк баласы гына. Рәҗибәмне дә аякка бастырасы бар. Аллаһу боерса, Хөббәтем дә сугышлардан исән-сау әйләнеп кайтыр. Чөкердәшеп гомер итәселәр алда әле безнең. Хөббәт, балаларыбыз ишле каз оясыдай күп булыр, ди. Бирсен Ходай. Тәүгесенә Рәхилә дип кушарбыз. Исеме түтәләренекенә охшаш булсын. Мин ир хатыны, аңлыйсыңмы шуны, каткан крис!

Мәрьям, сөйләнгән арала, ничектер җаен китереп, ике кулы белән убырның ике казнасыннан эләктереп алды. Убыр моны көтмәгән иде, ахры, үзенә бер дуамаллык белән бәргәләнә, типкәләнә, суккалана башлады. Бер арала хәтта ычкынып та китә язды. Сырма җиңе очендәге терсәге белән тегенең авызын томаларга өлгермәсә, тарткалаш, һичшиксез, кызның фаҗигасенә әйләнәчәк иде.

Өлгерде Мәрьям, Аллага шөкер, өлгерде! Нарасыйларының бәхете җиңде. Бар куәтен, бар булган ихтыяр көчен, бар усаллык вә үҗәтлеген бер йодрыкка туплап, үлем ачысы белән имән ботагын аергандай, убырның казнасын аерды...

Җиңел сулап куйды. Чоңки чытырдап сынган сөяк тавышын кул бармакларына кадәр ишетеп торды.

—Үзең гаепле, каткан крис, үзең юлыма каршы төштең,—диде ул сыер картасы шикелле җыерылып төшкән убырны кызгангандай.

Бу минутта Мәрьям убырның сынсыз сагыми сихер икәнлеге турында уйлап та карамады. Ул кайгымы соң, аны авылда Рәҗиләсе көтә, Рәҗибәсе көтә ләбаса! Бәлкем, Хөббәтеннән дә хат килгәндер? Никахлы ире бит хәзер Хөббәт. Әлеге хәбәрне ишеткәч, и, сөенер инде...

Мәрьям, яралы кулларындагы канны кар белән юып төшерде дә, юлын дәвам итте. Өереннән куылган карт бүренең үләксәсе читтә аунап калды.

Офыкка ал төс кунды, убыр вакыты чыкты.

*2007 ел, апрель.*

♣

# КӘРИМ ТИНЧУРИН

Татар халкының күренекле драматургы, артист һәм режиссер Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә элекке Пенза губернасындагы Аккүл (Таракан) авылында дөньяга килгән. Туган ягында мәдрәсә белеме алганнан соң 1900 елда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Анда уку елларында әдәбият һәм сәнгать белән тирәнтен кызыксына. Мәдрәсә белеменнән тыш үзлегеннән дә күп укый. «Мөхәммәдия»дәге укыту-тәрбия тәртипләре белән ризалашмыйча, 1906 елда мәдрәсәне ташлап чыккан 87 шәкерт арасында К.Тинчурин да була. Аннары ул төрле эшләр башкара, мөгаллимлек итә.

Беренче иҗади әсәре—«Мөназарә» исемендәге комедиясен Тинчурин1906 елда мәдрәсәдә укыганда ук яза. 1910 елда ул Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасына актер булып урнаша һәм шул вакыттан алып үзенең бөтен гомерен, сәләтен татар театр сәнгатен һәм драматургиясен үстерүгә багышлый. Үзе сәхнәдә уйнау белән берлектә, К.Тинчурин труппаның репертуарын баетуга да зур көч куя. Шул ук 1910 елдан башлап, ел саен диярлек, берәр-икешәр пьеса яза. Ул «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910-12), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Җилкуарлар» (1916) һ.б. әсәрләре белән үзен драматург итеп таныта. Әсәрләрендә ул үз чорының тискәре якларын тәнкыйтьли. К.Тинчуринның иҗаты татар драматургиясенең үзенчәлекле һәм кыйммәтле сәхифәсен тәшкил итә.

Октябрь инкыйлабыннан соң, Казаннан ак чехлар куылгач, 1918 елның көзендә К.Тинчурин «Сәйяр» труппасының җитәкчесе итеп билгеләнә. Ватандашлар сугышы елларында Кызыл Армиянең сәяси идарәсе карамагындагы Унөченче театр труппасының баш режиссеры һәм җитәкчесе була. 1920 елда хәрби округның сәяси идарәсе тарафыннан Самара шәһәрендә ачылган театр студиясендә укытучы һәм баш режиссер, 1921 елда Оренбург шәһәрендә Г.Кариев исемендәге татар пролетар театр труппасының җитәкчесе вазыйфаларын башкара. 1922 елда Ташкентта Гыйльми Советның театр сәнгате бүлеге мөдире булып эшли. Шул ук елда Казанга кайткач, Татарстан хөкүмәте К.Тинчуринга, күренекле татар артистларын туплап, Дәүләт труппасын оештыру эшен тапшыра һәм үзен булачак труппаның баш режиссеры итеп билгели. Шул рәвештә 1922 елның 8 ноябрендә Казанда махсус бинада К.Тинчурин җитәкчелегендә Татар дәүләт театры (хәзерге Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры) ачыла.

Ул елларда театр сәнгате өлкәсендәге оештыру эшләреннән тыш Кәрим Тинчурин актер, журналист һәм язучы буларак та иҗат активлыгын киңәйтә. Янача җәмгыять төзү елларында ул «Сакла, шартламасын!» (1918), «Зар» (1922), «Казан сөлгесе» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Тутый кош» (1923), «Американ» (1924), «Нәни абый» (1925), «Җилкәнсезләр» (1925) кебек танылган комедия һәм драмаларын иҗат итә.

Егерменче еллар урталарыннан К.Тинчурин иҗатында төп урынны музыкаль драмалар били һәм бу жанрда әдип югары уңышларга ирешә. Ике зур талантның—К.Тинчурин белән Салих Сәйдәшевнең уртак иҗаты нәтиҗәсендә туган «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930), «Сүнгән йолдызлар» әсәрләре һәм алар өчен махсус язылган җырлар—татар сәнгатенең җәүһәрләре.

Утызынчы елларда К.Тинчурин совет чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесалар иҗат итә.

К.Тинчурин татар мәдәнияте тарихында үзенчәлекле режиссер буларак билгеле. Пьесаларын ул үзе сәхнәгә куя, аларда үзе дә уйный, әсәрләренең фикерен тамашачыларга тәэсирле итеп җиткерә белә. К.Тинчурин сәләтле актер булып таныла, матур тавышлы, оста җырчы була.

Ул оста педагог буларак та билгеле. Күп кенә яшь драматургларны театр әдәбиятына тарта, аларның әсәрләрен сәхнәләштерә. Татар артистларының бөтен бер буыны аның җитәкчелегендә иҗат мәктәбе үтә.

К.Тинчурин талантлы прозаик буларак та танылган. Аның юмористик һәм сатирик хикәяләре 1917 елга кадәр үк татар матбугатында еш басылган. 1935-37 елларда ул үз тормышындагы вакыйгаларга нигезләнеп «Мәрҗәннәр» исемле хикәяләр (новеллалар) циклын язган.

Кәрим Тинчуринның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге әдип үзе исән чагында ук югары бәя ала. 1926 елда аңа Татарстанның атказанган артисты дигән исем бирелә. 1936 елның май аенда киң җәмәгатьчелек аның иҗади эшчәнлегенә егерме биш ел тулуны зурлап бәйрәм итә. 1934 елда ул Язучылар берлеге әгъзалыгына кабул ителә.

К.Тинчурин 1937 елның 17 сентябрендә кулга алынып, нахакка гаепләнеп 1938 елның 15 ноябрендә атып үтерелә. 1955 елда әдип тулысынча аклана, китаплары басыла, әсәрләре кат-кат сәхнәләрдә уйнала башлый. К.Тинчуринның әсәрләре 1969—1971 һәм 1986-87 елларда Татарстан китап нәшриятында ике томлык һәм өч томлык тупламнарда чыкты.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәр театр сезонын К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасы белән ачып җибәрә.

Татар дәүләт драма һәм комедия театрына 1988 елда Кәрим Тинчурин исеме бирелде. Шулай итеп мәшһүр татар драматургы Кәрим Тинчуринның данлы исеме һәм бай иҗаты мәдәниятебез тарихында мәртәбәле урынын алды.

*(Бу биобиблиографик язмада Р.Даутов һәм Н.Нуруллинаның «Совет Татарстаны язучылары» (1986) хезмәте файдаланылды).*



*Кәрим Тинчурин (сулда)*
*һәм Габдулла Кариев.*
*1913 ел.*



*Салих Сәйдәшев һәм Кәрим*
*Тинчурин. 30 нчы еллар.*



*Кәрим Тинчурин (икенче рәттә сулдан икенче) чордашлары—сәнгать әһелләре арасында.*
*30 нчы еллар.*



*Заһидә Тинчурина һәм Кәрим Тинчурин. 1919 ел.*



*К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы.*



*Язучыларның I Бөтенсоюз корылтае. Урта рәттә сулдан беренче—К. Тинчурин. Мәскәү, 1934 ел.*



Индус
Таһиров

# ТЕЛ ВӘ МОҢ—МИЛЛИЛЕК ЧЫГАНАКЛАРЫ

## Алар нинди мөнәсәбәттә торалар?

Бу сорауга тарих аларны бер җепкә тезгән дигән җавап биреп булыр иде. Чөнки моңсыз телебез юк, моң да телебездән башка яши алмый. Алар—бертуганнар. Икесе бергә татарны татар иткәннәр, үз эчләренә аның тарихын сеңдергәннәр. Татар җырларына татар яшәгән җирләрнең моң-зары сеңгән.

Татарлар, мөгаен, моңнан яралгандыр, дисәм, ялгышмамдыр. Чөнки борынгы татар җырларын тыңлаганда төркиләр яшәгән Алтайдагы гүзәллекләрнең, татарны татар иткән дала киңлекләренең моңы йөрәккә үтеп керә. «Ишеттем мин кичә берәү җырлый, чын безнеңчә моңлы милли көй» дип язган Тукай. Шушы юлларны укыганда бер татар йөрәгеннән өзелеп чыккан моңлы көй икенче татар йөрәгенә шулай ук өздереп үтеп кергәнлегенә, һәммә татарга хас булган, аның язмышын чагылдырган милли моң гасырлар буе канга сеңә килгәнлегенә инанасың. Милләтебезнең җиңел булмаган язмышын күзаллыйсың. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, шушы «өзелеп-өзелеп» чыккан «зарлы моңлы көй» аша «өч йөз елда тәкъдир безне ничек изгәнен» һәм шул ук вакытта тарихта «бер дә тапсыз көзгебез» икәнлеген тойгандай буласың.

Александр Ключарев язганча, татар җырының үзенә генә хас «музыка теле» бар, аңа «мелизм чәкәннәренең бик бай булуы характерлы». Ул бу яктан башкорт музыкасына якын булса да, аннан бик нык аерылып тора[1]. Заманында татарларның борынгы музыкаль традицияләрне саклап кала алганлыклары хакында Зәки Вәлиди дә язып чыккан иде[2]. Шунлыктандыр инде татар моңы дөньяны таң калдырырдай яңгырашлы. Юкка гына кытайлылар булып кытайлылар төрки музыканы үз итмәгәннәрдер, аны Ерак көнчыгыш халыкларына, шул исәптән Япониягә дә илтеп җиткермәгәннәрдер. Беренче төрки аваз да шул моңнан барлыкка килеп, телебезне тел итүгә өлешен керткәндер.

Тел. Туган тел. Ул да дала моңнарыннан, гомумтөрки тел буларак, төрки моң белән бергә яралган булса кирәк.

Телебез иң бай, матур телләрнең берсе. Бер вакыт Мәскәүнең иң зур залларының берсендә татар мәдәни чарасы бара. Җыр, нәфис сүз бер-берсен алыштырып тора. Шул вакыт кичәне алып баручыларга залда утыручы бер рус кешесе язу җибәрә. Анда «телегез искиткеч матур, аның киләчәге зур. Мин бу телне өйрәнергә сүз бирәм» дигән сүзләр бар иде. Югыйсә, бу кешегә татар теленең кирәге дә шулкадәрле генәдер. Күрәсең, аны телебезнең «моңлылыгы», ягымлы яңгырашы үзенә тарткандыр.

---

[1] А. Ключарев. Татар халкының музыка иҗаты //Казан утлары. – 2006. – №2. – Б. 72.

[2] Валиди Тоган. Воспоминания. Борьба народов Туркестана и других восточных мусульман-тюрков за национальное бытие и сохранение культуры. – Уфа, 1998. – С. 8.

Искә төшерсәк, татар теленең Евразия киңлегендә яшәгән халыкларга бик тә кирәкле шанлы чаклары да булган. Ул берничә гасыр дәвамында үзара аңлашу теле буларак яшәп килгән. Шулай булмаса, атаклы рус сәүдәгәре Афанасий Никитин Һиндстанга сәяхәтен, Йосыф исемен алып, татар кыяфәтендә кылмаган һәм үзенең «Хождение за три моря» әсәрен өлешчә татар телендә язмаган булыр иде. Туган телебезнең тәэсирле көче булмаса, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң да, күп еллар буе Россиянең Шәрык илләре белән аралашу теле рәвешендә яши алмас иде.

1870 елда Сембер шәһәрендә чыккан бер китапта «татарлар Россиядәге иң ныклы халык» дип язылган. Анда «алар үзләренең, азчылык булуларына да карамастан, рус йогынтысына бирелмәделәр, аларга рухи яктан түгел, тик сәяси рәвештә генә буйсындылар» диелгән юллар бар. Телебез дә шулай ук «ассалар да, киссәләр дә» үлмәде.

Киресенчә, коллык чорына кергәч тә, аның башка халыкларга да бик көчле уңай йогынтысы була килде. Чөнки ул аларга үзенең байлыгы, Нәҗар Нәҗми сүзләре белән әйткәндә «ачык йөзлелеге», «уңганлыгы», «акыллылыгы» белән үрнәк булды. Күпләр өчен әдәбият дөньясына керү ачкычына әверелде. Тугандаш халыкларның язучылары, шагыйрьләренең күбесе, иҗат сукмагына шушы тел ярдәмендә бастылар. Күптән түгел Төркиянең бер галиме татар теленең, гомумән, үзбәк әдәби теленең формалашуына татарларның керткән өлешенә багышланган хезмәт язды. Телебезнең удмурт, мари, чуаш телләренә ясаган йогынтысы да бик зур. Моның шулай икәнлеген үз галимнәре дә раслый.

Әгәр дә мин моңыбызга, телебезгә мәдхия җырлау белән генә чикләнсәм, дөрес булмас иде. Чөнки күз алдында моңыбыз да, телебез дә юкка чыга бара. Моның, әлбәттә, объектив сәбәпләре дә бар. Аның беренчесе, мөстәкыйль дәүләтебез булмау. Икенчесе, федераль сәясәтчеләрнең Россиядәге татар мәгарифен һәм мәдәниятен кысрыклаулары. Өченчесе, татар теленең чын-чынлап дәүләт теле була алмавы.

## Телне саклау бурычы гаиләгә тапшырылган

Аллаһы Тәгалә һәрбер кешене телле итеп ярата. Ата-ананың изге бурычы шул телне матур һәм дөрес итеп ачудан гыйбарәт. «Иң әлек шул тел белән әнкәм бишектә көйләгән», дип язган Тукаебыз. Димәк, телебез балага бишектә үк милли моң-җыр белән бергә сеңә, ныгый. Моң җыр сорый, сүз таләп итә. Бишек җыры балага милли хис сала, теле ачылуга юл ача.

Менә шуңа күрә адәм баласының теле милли моңга бәйле. Ата-ана үз баласының телен милли моң, бишек җыры белән ачарга тиеш дибез. Әлбәттә, гаиләнең вазифасы баланың теле ачылу белән генә тәмамланмый. Киресенчә, ул вазифа катлаулана гына төшә. Элек-электән сөйләнеп килгән әкиятләргә Тукай юкка гына шул кадәр урын бирмәгәндер. Әкиятләр баланың телен генә түгел, аның рухи дөньясын да баета, аңарда милли хисләр тәрбияли, аңа халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын сеңдерә. Яхшы белән яманны аерырга өйрәтә.

Аннан соң гаилә телне баета, аны яшәү коралына әверелдерә. Моның шулай булырга тиешлегенең төп шарты—ата-ананың балалары белән тик туган телдә аралашу. Әгәр ата-ана үзара рус яки башка телдә аралаша икән, аларның балалары да шул телгә күнегә. Аларга тумыштан бирелгән тел, ачылмастан, йомыла.

Күп ата-ана балаларының туган телләрен белмәүдә мәктәпне гаепләмәкчеләр. Имештер, мәктәптә татар телен өйрәтмиләр, укыту тик рус телендә генә бара. Бу сүзләрдә дә дөреслек юк түгел. Чыннан да, безнең шәһәрләрдәге, хәтта татар дип аталган мәктәпләребездә дә, күп фәннәр русча укытыла. Балалар үзара русча сөйләшәләр.

Ә патша Россиясендә татар теле дәүләт теле булмаган, хөкүмәт татарлар өчен милли мәктәпләр дә ачмаган. Киресенчә, аларны бик кысрыклаган. Тик татарлар телләреннән бизмәгән. Алар үз көчләре белән дистәләрчә мәктәпләр ачып, миллионлаган тиражлы китаплар, дистәләрчә газета-журналлар чыгарып, Россиянең иң укымышлы халкына әверелгәннәр. Чөнки ана теле беренче урында торган, аның аша дөньяга, аң-белемгә юл ачылган.

Бүген дә Финляндиядә, Америка, Кытай һәм Японияде татар мәктәпләре юк. Ләкин балалар татар телен камил рәвештә беләләр. Чөнки бу илләрдә татар теле—гаилә теле. Тел аларга бишектән үк сеңә. Монда тел милли моң белән уралып бара. Ата-ана үзара да, балалары белән дә тик татарча гына сөйләшә. Бу татарларның җырлары да гасырдан-гасырга күчеп килгән чын татар җырлары. Америкада да, Японияде дә безнең эстраданың бүгенге өч көнлек такмакларын өнәмиләр. Аларга милләт язмышын тасвирлаган, буыннан-буынга килгән пентатоникага корылган җырлар булсын. Иҗатлары белән традицияләрне уңышлы дәвам иткән Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннар, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтов һәм кайбер башка классик композиторларыбыз тудырган үлемсез җырларны да алар яратып җырлыйлар һәм тыңлыйлар. Шушы җырларның сүзләре аларда телебезгә мәхәббәт тәрбияли.

Әйе, җыр сүзләре телебезгә мәхәббәт тәрбияли. Фольклорыбызда сакланган җырлар бер үк вакытта халык педагогиясен өйрәнү чыганагы да булып торалар. Анда гореф-гадәтләребез, төрле йолалар, кешеләрнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре бөтен тулылыгы белән чагылган. Күп шагыйрьләребез дә халык фольклор традицияләрен дәвам итә. Милләтебез алар иҗат иткән җырларның шактыен халык иҗаты рәвешендә кабул итә.

Әлбәттә, бу өлкәдә проблемалар юк түгел. Эстрададан күп вакыт булырбулмас сүзләрдән торган текстларга көйләнгән, милли музыкаль культурабызга бернинди катнашы булмаган «җырлар» яңгырый. Шулар нигезендә дистәләгән такмактан башканы белмәгән җырчылар үсә тора. Кызганыч ки, болар халкыбызны традицияләребездән читләштерәләр генә. Ә безгә, әгәр милләт булып яшәүне дәвам итәсебез килсә, халык җырларын күбрәк пропагандаларга кирәк. Дөрес, аларны башкару зур осталык сорый. Аларны теләсә кем җырлый да алмый. Такмак җырлау күпкә җиңел. Әйтик, кайбер «йолдыз» дип аталган җырчылар «Шөгер», «Минзәлә» һәм башка бик күп җырларны башкару түгел, аларның хәтта барлыгын да белмиләр. Мин «Зиләйлүк», «Асылъяр», «Иске кара урман», «Кара урман», «Уел» һәм башка бик күп халык җәүһәрләре турында әйтеп тә тормыйм. Боларны бүген Мирсәет Сөнгатуллин, Фердинанд Салахов, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров, Идрис Газиев һәм тагын берничә җырчыбыздан башка җырлаучылар аз. Имеш, болар иске, аларны тыңламыйлар. Алай булгач нигә соң инде онытылып беткән «Тазалыкта, байлыкта» җырын үзбәк «Ялла» ансамбле башкарып күрсәткәннән соң, ныклап җырлый башладылар? Әгәр дә җиренә җиткереп, заман төсмере һәм тиешле ритм биреп җырлаучылар булса, бик тә тыңлыйлар. Айдар Фәйзрахмановның «Караоке»сы халык җырларына урын таба бит. Һәм бу тапшыруның рейтингы арткаңнан-арта бара. Аны халык бик яратып карый. Яки Мәскәү җырчысы Наилә Фатехова иске җырларыбызга Бари Алибасов ярдәмендә заман мелизмнарын оста, күңелгә ятышлы итеп үрә, аның җырлары да күңелгә үтеп керә. Роза Хәбибуллинаның Мәскәү балаларын борынгы иске җырларыбызны заманча башкарырга өйрәтүе дә мактауга лаек. Ләкин андыйларны, ни кызганыч, Татарстанда начар беләләр.

Бәлки мондый җырчыларга юл бирмиләрдер? Сәхнәдә монополия хөкем сөрәдер? Ә бәлки аларга тиешле кайгыртучанлык җитмидер? Сәбәп нидән булуына да карамастан, халык җырларына мәйдан күбрәк бирелергә тиеш.

Чын халык традицияләренә нигезләнгән көй үзе үк сүз сорый. Андый көйләрнең сүзләре дә телне начар белгән, ләкин татар моңына мөкиббән кешеләрне татарча сөйләшергә дә өйрәтә, нииндидер сәбәпләр аркасында ачылмый, йомылып калган телләрен ача.

Бервакыт Бишкәк шәһәрендә җирле татарлар оештырган концертта бер җырчының сәхнәгә чыгып, «Әйтмә син авыр сүз» дигән җырны башкаруын тыңладык. Бик тә хисләнеп җырлады егет. Ул сәхнәдән төшкәч янына килдем. Татарча көчкә-көчкә генә сөйләшә егетем. Ә кулында шушы башкарган һәм башка җырларның текстлары. Күрәсең, егетнең күңеленә сеңгән милли моң сүз, татар сүзен сорый. Телебезне ныклап өйрәнү омтылышын тудыра.

Бу очраклы мисал гына түгел. Әйтик, атаклы җырчыбыз, инде мәрхүм булган Гали Ильясов Владивостокта туып, туган тел даирәсендә үсмәгән. Ә күзәнәкләренә сеңгән татар моңы аның татарлыгын уяткан, җыр аша туган

телне үзләштерүгә юл ачкан. Алай гына да түгел, аны Казанга китергән, татар дөньясына керткән. Мондый мисаллар күп. Алар тел белән милли моңның бергә уралган булганлыкларын, моңның телне «уяту» көче бар икәнлегенә дәлил булып торалар. Бишек җырлары гасырлар дәверендә юкка гына җырланмаган. Алар балада миллилек тәрбияләгәннәр. Җырсыз-моңсыз үскән балалар бәхетсез, чөнки алар милли хисләрдән мәхрүм. Алардан туган балаларга ятлар арасына сеңеп югалу өчен юл ачык. Катнаш никахларның күплегенә әнә шул милли хисләр булмау сәбәп булып тора да инде. Телен белмәгән, җырын җырлый алмаганнар өчен милләтнең бернинди әһәмияте дә юк.

Тел һәм моң—милләт сакчылары. Тел бетсә, моң да калмый, милләт бетә. Менә ни өчен без гаиләдә тел мәсьәләсе беренче урынга куелырга тиеш, дибез. Менә ни өчен бабаларыбыздан мирас булып калган милли моңыбыз язмышына битараф була алмыйбыз.

Күп вакыт ата-аналар балам русча белсен, русча укысын, рус теленнән башка яшәү авыр, җәмгыятьтә урын алу кыен, ди. Гадәттә, мондый ата-аналарның күпчелеге үз вакытында рус телен начар белү аркасында интеккән, авырлыклар күргән була. Алар балаларына андый язмыш теләмиләр. Моны аңлап була. Беркем дә үз баласына начарлык теләми. Укысыннар балалалар русча да, инглизчә дә, французча да, немецчә дә. Татар кешесе башкалардан ким түгел. Тик менә шушы телләрнең, гомумән, белем-мәгърифәтнең ачкычы туган телебез икәнлеген онытмасыннар иде алар. Үсеп буйга җиткәч, җәмгыятьтә үз урыннарын алгач, Тукаебызга ияреп «Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы» диярлек булсын киләчәк буын татарлары.

Шул ук вакытта без замананың искиткеч темплар белән үзгәрә барганлыгын истән чыгарырга да тиеш түгелбез. Хәзерге заманда русча белми калу мөмкин түгел. Ул тел, телисеңме, теләмисеңме, инде һәрбер йортның эченә кереп оялаган. Дистәләгән телевидение, радио каналлары барлык тапшыруларын рус телендә алып бара. Бүген русча белмәүчеләр юк дәрәҗәсендә, һәммә мәктәптә рус теле, хәтта татар авылларында да күп фәннәр русча укытыла. Шунлыктан, телебез өчен беренче куркыныч баланы бишектән үк туган телендә тәрбияләмәү булса, аның икенчесе—телевидение һәм радио. Өченчесе—ишек артында рус телендә кайнап торган тормыш.

Тик боларны котылгысыз фаҗига итеп карарга ярамый. Инде, әйткәнемчә, ерак чит ил татарлары күптән шундый шартларда яшиләр. Шулай булуга да карамастан, алар бездән аермалы буларак, ике-өч тел беләләр. Чөнки алар өчен төп тел—туган тел. Өйләрендә алар татарча сөйләшәләр. Ә инде ишекнең теге ягында яшәгән илләренең дәүләт телләрендә сөйләшәләр. Аларга радио да, телевидение дә комачауламый. Киресенчә, тарихи ватаннары белән якынлаштыра. «Татарстан—яңа гасыр» телеканалы хәзер күп җирләргә үтеп керде. Чит илләрдә, мәсәлән АКШ башкаласы Вашингтонда «Татар радиосы»н, «Азатлык»ны тыңлыйлар. Вашингтонда гомер кичерүче мәшһүр милләттәшебез Сәгыйть абый Салахның йортында үземнең шушы каналлардан татар тапшыруларын тыңлап хозурланганым бар. Америкада яшәүче татар гаиләләре тормышында татарча теле-радио тапшырулар зур урын алып тора. Алар Интернеттан күп файдаланалар, СМС һәм ММС аркылы үз телебездә аралашып торалар.

Сәгыйть абый Салах Кореяда Сеул шәһәрендә туып-үскән. Ул шәһәрдә үткән гасырның 50 нче елларында нибары 26 татар гаиләсе яшәгән. Араларындагы бер мәрхәмәтле татар бае Сеулда татар мәктәбе һәм мәчет төзеткән. Мәктәп өчен татар китаплары Японияддә бастырылган. Сугыш башлану сәбәпле, язмыш Сәгыйтьне Америкага китергән. Ул монда бер ел эчендә урта белем алган. Дүрт ел эчендә ике югары белем иясе булган. Фән докторы булып, АКШ хөкүмәтенең атом-төш проблемалары буенча киңәшчесе булып эшләгән. Шушы уңышларның ачкычы—туган татар телем, ди Сәгыйть абый. Ул моның өстәвенә камил рәвештә инглиз, япон, кытай һәм корея телләрен дә белә. Туган тел аны татар итеп саклаган, зур фән юлына чыгарган. Сәрия ханым белән алар ике татар баласы үстереп, аларны зур тормышка чыгара алганнар. Шул ук АКШта, Финляндиядә, Кытайда һәм башка илләрдә моңа охшаш мисаллар күп.

## Бездә нинди хәлләр бар?

Татарстанда да шактый уңай үзгәрешләр бар. Алар 1990 елның 30 августта кабул ителгән суверенлык Декларациясенә, 1992 елның 21 мартында үткәрелгән Референдумга һәм Россия белән 1994 елның 15 февралендә төзелгән ике яклы Шартнамәгә бәйле. Алар безнең милли тойгыларыбыз уянуга сәбәп булдылар, телебезнең яңартуына юл ачтылар. Татар теле дәүләт теле итеп игълан ителде. Инде икенче дистә ел татар телен гаммәлләштерү программасы эшләп килә. Болар нигезендә татарлар, тартынып тормастан, үз телләрендә киңрәк аралаша башладылар. Күп кенә мәктәп һәм гимназияләр, балалар бакчаларында татар төркемнәре булдырылды. Телебезнең алга баруын бигрәк тә трамвай-троллейбус, автобусларда барганда сизәсең. Анда кайвакыт игъланнар ике телдә яңгырый. Татарча сөйләшүгә рус булмаган пассажирларның реакциясе дә элеккегечә түгел. Югыйсә, үзара татарча сөйләшүчеләргә, «говорите по-русски» дип кенә кычкыра торганнар иде. Бүген болар бетте диярлек. Аның кайбер рецедивлары гына калды.

Татар мәктәпләре, гимназияләре күпләп ачылуы үзе бер шатлык. Әлбәттә, монда да проблемалар җитәрлек. Дөресен әйтик, халкыбызда милли горурлык саегып бара. Катнаш никахлар арта, халык саны кими. Ни хикмәт, сугыш утында яшәүче чечен, ингуш һәм башка Кавказ халыкларының саны арта тора. Азәрбәйҗаннарның саны республикаларында 10, ә Иранда хәтта 30 миллионга җитте. Казакъ, үзбәк туганнарыбызның да саннары ныклап арта. Ә без киму юлында. Безнең милләт, Тукай әйтмешли, үлгәнме, әллә йоклый гынамы? Әллә яшәү көчебез кимегәнме?

Юк, без әле исән. Безгә тик милли хисләр, милли горурлык җитми. Ә бу исә, үз чиратында, телебезгә игътибар кимүгә сәбәп. Россия төбәкләрендә, Татарстан шәһәрләрендә гомер кичерүче татарларның күпчелеге русча аралаша. Авылларыбызда да телебез шактый бозылды. Татарларның өчтән дүрте татарча китап, газета-журналлар укудан мәхрүм. Кайчагында бу китаплар, газета-журналлар кем өчен языла икән, дигән сорау да туа. Дөресен генә әйткәндә, җитәкче даирәләр аларны укымый диярлек.

Ата-аналарның балаларын татар мәктәпләренә, гимназияләренә бирүләре кимүгә дә күз йомарга ярамый. Моңа бер сәбәп итеп Татар университеты булмауны күрсәтәләр. Монысы да дөрес. Ләкин, өлешчә генә. Татарча матбугатының аз укылуы, милли университет булмавы күңелне тырнамый түгел, тырный. Ләкин төп сәбәп—телгә ихтыяҗ булмауда. Ихтыяҗ—ул телнең яшәү теле булуында. Дәүләтнең халкы белән үз телендә сөйләшә алуында, чиновникларның телебезне камил белүендә. Бүген исә дәүләт үз халкы белән татарча сөйләшми, чиновниклар татарча белми, указ-приказ һәм төрле инструкцияләр рус телендә генә туалар һәм аңлый алмаслык дәрәҗәдә татарчага тәрҗемә ителәләр. Халык белән хөкүмәтнең аралашуы тик рус телендә генә бара.

Күрәсең, русча аралашу кулайрактыр. Украинаның элеккеге президенты Леонид Кучма үзенең «Украина—не Россия» исемле китабында, чиновниклар, әгәр мәҗбүри чаралар күрмәсәң, тик русча гына эш итәләр» дип язды. Ә бит бу очракта, бәйсез дәүләт булган Украина турында сүз бара. Анда да әлегә кадәр матбугат чараларында рус теле хакимлек итә. Шунлыктан анда украин телен гаммәләштерү өчен мәҗбүри чаралар кулланыла. Әгәр, син чиновник булып каласың килә икән, өйрән украинча, халык белән шушы телдә аралаш! Әгәр моңа риза түгел икәнсең, алдыңнан артың матур! Бер казанга ике тәкә башы сыймый.

Ә менә без бу ике башны тыгызлап булса да бер казанга (Казанга) сыйдырырга тиешбез. Һәм бу өлкәдә шактый тәҗрибәбез дә бар. Билгеле булганча, 1920 нче елларда Татарстан республикасы игълан ителгәч, татар теле рус теле белән тигез дәүләт теле итеп игълан ителә. Урыннарда ике теллелек урнаша башлый. Күп кенә дәүләти документлар ике телдә төзелә. Татарлар күпчелек булган урыннарда дәүләти вазифалар тик татар телендә генә башкарыла. Суд эшләре дә ике телдә бара, гомумән, аның карарлары Татарстан республикасы исеменнән кабул ителә башлый.

1926 елны ВКП(б) Өлкә комитеты дәүләт органнарында эшләүчеләр татар телен белергә тиешлекләре турында карар кабул итә. Шул елның декабрендә Партия Өлкә комитетының XII Өлкә конференциясендә докладчыга «Сез татарча өйрәнергә теләмәгән рус иптәшләр Татарстанны ташлап китәргә тиеш, дидегез. Шунлыктан Республиканы бүген үк ташлап китәргә теләүчеләр күп, моны бүгеннән үк башларга мөмкинме? дигән сорау бирелә. Өлкә комитеты секретаре М. Хатаевич, моңа әнә шул карар барлыгын әйтә. һәм аның нигезендә татарча белү мәҗбүри булган учреждениеләр-

нең исемлеге төзелгәнлеген, анда эшләүчеләр, татар булу-булмауларына да карамастан, татар телен үзләштерергә тиеш икәнлекләрен, ә моны булдыра алмаганнар эшләреннән китәргә тиешләр, дип җавап бирә. Бу гамәлләр нәтиҗәсез калмый. Дәүләт органнарында эшләүчеләр татар телен үзләштерә башлыйлар.

Ләкин, ни кызганыч, бу сәясәт бик кыска гомерле була. Ул бик тиз гамәлдән чыгарыла. Гомумән, 1937 елдан башлап Татарстан автоном хокукларын югалта һәм, нигездә, гади административ берәмлеккә әверелә.

Илдә үзгәртеп кору башлангач, Татарстанның суверенлык декларациясе нигезендә татар теле кабат дәүләт теле итеп игълан ителде. Тик, кайбер тырышлыклар булуга да карамастан, гомумән, татарча белү мәҗбүри булган эш урыннарының исемлеге кабул ителмәде. Суд эшләре дә бер телдә генә алып барыла, суд карарлары да тик Россия Федерациясе исеменнән генә чыгарыла. Кыскасы, дәүләт үз халкы белән, нигездә, бер телдә генә сөйләшә. Татар теле әлегәчә тулы канлы дәүләт теле булып җитмәгән әле. Моның өчен шактый күп эшләр башкарасы бар.

Ни эшләргә? Иң беренчесе, телебезне, милли моңыбызны гаиләгә кайтару таләп ителә. Әгәр дә гаиләдә тел һәм милли моң бергә үрелеп яшәсә, миллилегебезне беркем дә бетерә алмый. Ни кызганыч, иҗтимагый оешмаларыбыз милли гаилә проблемаларына, гомумән, милли тәрбиягә, бик сүлпән карыйлар. Заманында Казанда «Ак калфак» оешмасы, аның җитәкчесе Роза Туфитуллова бу эшне җәелдереп җибәргәннәр иде. Ниндидер сәбәптән әлеге башлангыч дәвамсыз булды. Ә бит аның дәвамы башкалада гына түгел, бүтән шәһәрләрдә дә булырга тиеш иде. Чөнки бүген татарның күпчелеге шәһәрләрдә яши. Шунлыктан шәһәр татарча сөйләшсә, татарча җырласа, халкыбыз милләт булып яшәячәк. Монда бернинди шик булырга тиеш түгел.

Икенчесе, булган мөмкинлекләребезне тулысы белән файдаланырга өйрәнүдән гыйбарәт. Тиешле законнар бар. Аларны тормышка ашыру өчен матди мөмкинлекләр дә юк түгел. Моның өчен яшәешебезне биләп алган битарафлыктан гына арыну кирәк. Хөкүмәтне тәнкыйтьләп кенә эш чыкмый. Кайвакыт аның үзенә дә җәмәгатьчелек ярдәме кирәклеген онытмыйк. Урамдагы килделе-киттеле плакатларны, урам-авыл исемнәренең язылышын Президент, Премьер-министр яки Дәүләт Советы рәисе тикшереп йөрергә тиеш түгел бит! Моны җәмәгатьчелек үзе башкарырга тиеш. Ә дәүләт ике телле белгечләр әзерләргә, чиновникларын татарча эш алып барырга өйрәтергә тиеш. Дәүләт телләре турындагы законны бозучыларга тиешле чараларны вакытында күрү шулай ук аның вазифалары булып тора.

Өченчесе, шактый баеп өлгергән милләттәшләребез бар. Алардан көнләшергә кирәкми. Күбрәк булсыннар иде алар. Алардан тик милли эшләребезгә актив катнашу гына таләп ителә. Бу да мөмкин булмаслык түгел. 1917 елга кадәр татарның мәгариф системасы, мәдәнияте, китап, газета-журналлар чыгару тулысы белән эшкуарларыбыз җилкәсендә булган.

Дүртенчесе. Дин әһелләребезнең тырышлыгын арттырырга кирәклекне ассызыклап үтәсем килә. Бүген исә, аларның эшчәнлеге күпләрне канәгатьләндереп җиткерми. Мәчетләребез күп, ә йөрүчеләр аз. Кайбер яшь муллаларыбыз үзара тик русча гына аралаша. Аларга карап мәчеткә йөрүче яшьләребез дә русча сөйләшәләр. Боларга телебезне камил рәвештә белүне шарт итеп куясы иде бит. Алай гына да түгел, мәчетләребезне татарча аралашу үрнәге итсеннәр иде.

Бу очракта мин, дин әһелләребезнең эшен инкяр итмим. Алар милләт өчен шактый күп гамәлләр кылдылар. Сүз аларның җәмгыятебезгә йогынтысын арттыру турында бара. Дин бит, дәүләттән аерылган булса да, җәмгыятьтән аерылмаган. Безгә диннең милләтебезне саклап калудагы роле бәя биреп бетергесез зур икәнлеген хәтердән чыгармыйча эш итәргә кирәк. Әгәр дә 1552 елдан татарга ярдәмгә Ислам дине килмәгән булса, ел бәлки инде милләт буларак яшәвен туктаткан да булыр иде. Дин—милләтнең, телебезнең, гореф-гадәтләрнең сакчысы булды. Ул бүген дә шундый ук сакчы булсын иде. Муллаларыбыз җәмгыять тормышына тирәнрәк үтәргә өйрәнсеннәр иде.

Әлбәттә, милли яшәеш проблемалары моңа гына кайтып кала алмый. Аның телебездән, динебездән, милли моңыбыздан башка да тармаклары җитәрлек. Тик ничек кенә булмасын, яшәешебезнең асылы булган Тел һәм татар кешесенең эчке халәтен тәшкил иткән Моң беренче урында булырга тиеш.

# БАЙ ТАРИХЛЫ ГАЛИ МӘДРӘСӘ

Татар әдәбияты соңгы елларда тоташ юбилейлар сызыгында тора. Үткән 2006 ел хәтта әдәбият һәм сәнгать елы дип тә игълан ителгән иде. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Җәлил кебек әдип-шагыйрьләребезнең 120, 100 еллык зур юбилейлары, башка язучыларыбызның төрле юбилейлары бәйрәм ителде. Быел бөек әдибебез Г. Ибраһимовның 120 еллык юбилее киң билгеләп үтелде. Җ. Вәлидинең 120 еллыгы да быелга туры килә. Алда—Г. Нигъмәтинең 110, Исхакыйның 130 еллыклары көтелә.



Биредә тагын бер юбилей—атаклы «Галия» мәдрәсәсенең 100 еллыгы һәм шул уңай белән Уфа шәһәрендә үткәрелгән чаралар турында сөйләмәкче булабыз...

«Галия» мәдрәсәсе революциягә чаклы Россиядәге иң алдынгы уку йортларының берсе була. Дини һәм дөньяви белем биргән әлеге мәдрәсә үз заманында югары уку йортына тиңләштерелгән (гали, галия—гарәпчә бөек, югары дигән мәгънәне аңлата). Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнгән галим Мансур ага Хәсәнов билгеләп үткәнчә, ул милли институт дәрәҗәсенә күтәрелгән мәшһүр уку йортларының берсе булган. Чын мәгънәсендә интернациональ, милләтара уку йорты булган ул, башкалардан демократик рухы белән аерылып торган, анда иҗади, әдәби мохит хөкем сөргән (бу уңайдан шунысын дә әйтеп китик, Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәтиләрнең әсәрләрендә һәм хезмәтләрендә төрле халыкларга, тугандаш төрки халыкларның тарихына, әдәбиятына, теленә, мәдәниятенә зур мәхәббәт чагылу «Галия» мәдрәсәсендәге тәрбиядән килә, моның нигезе шунда салынган була).

«Галия» мәдрәсәсе мәгариф, фән, әдәбият, мәдәният тарихында тирән эз калдырган байтак шәхесләрне үстереп чыгарган. Анда төрки милләт вәкилләре (татар, башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз, һ. б.) бик күп укыган. «Галия» мәдрәсәсендә тарихи мәгълүматларга караганда, 1906 елдан алып 1919 елга хәтле, мең ярым чамасы кеше белем алып чыккан. Болар арасында исемнәре алда телгә алынган Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, шулай ук Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Солтан Габәши, Хәсән Туфан, Галә Ходаяров, Сәлах Атнагулов, Шәһит Әхмәдиев, Гыйбад Алпаров, Нигъмәт Хәким, Хөсни Кәрим, Шамун Фидаи, Гата Исхакый, Вәли Хангилдин, Ибраһим Башмаков, Вәсим Солтанов, Бикбулат Салиев, Хәбибулла Зәйни, Кәрим Хәкимов, Хаммат Гомәрев, Фәйзи Вәлиев кебек күренекле язучы, шагыйрь, галим, педагог, мәдәният һәм дәүләт эшлеклеләре бар. Мәгълүм ки, болар Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда, 1920 нче елларда татарның интеллектуаль, әдәби, гыйльми куәтен тәшкил иткән талантлы буын вәкилләре, шул чорда әдәби, мәдәни алгарышыбызны, яңарышыбызны булдыруга үзләреннән бик зур өлеш, күп хезмәт керткән фидакяр затлар. Аларның барысын шул чорның киң мәдәни-иҗтимагый хәрәкәтенә, милли яңарыш хәрәкәтенә тартып керткән, эчтән берләштергән сәбәпләрнең берсе—«Галия» мәдрәсәсендә, бер гаилә балалары булып укып-тәрбияләнгән кешеләр булудан киләдер. «Галия»

мәдрәсәсендә алган белемнәре яна шартларда, яңа заманда әдәби, фәнни, педагоглык, иҗтимагый эшчәнлекләрен унышлы алып баруда ярдәм иткән. Бер генә мисал китерик. Г. Нигъмәти, мәсәлән, «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң укуын 1920 елда Мәскәүдә Дәүләт журналистика институтында дәвам итә, Мәскәүдә Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик университетында (КУТВ) укый, бу уку йортларында А. В. Луначарский, Л. Б. Красин, тарихчы галим М. Н. Покровский, Шәрык белгечләре А. А. Губер, И. М. Рейнер, Б. З. Шумяцкий һ. б. галимнәрдән лекцияләр тыңлый. Аларның тәгълиматын кабул итү өчен билгеле бер әзерлек, җирлек кирәк булган, әлбәттә. «Галия» мәдрәсәсе Г. Нигъмәтидә яңа заман рус-европа гыйлемен, казанышларын үзләштерү югарылыгына күтәрелерлек база булдыра алган, шундый белем потенциалын салып чыгарган. Бу буын кешеләренең үз эшчәнлекләрендә «Галия» мәдрәсәсендә алган белем байлыгыннан, дини һәм дөньяви гыйлемнәр хәзинәсеннән яңа заманда, совет чорында ничек файдалану мәсьәләсен әле безгә чынлап торып тикшерәсе, ачасы, өйрәнәсе бар.

«Галия» мәдрәсәсендә укыган шәхесләр арасында, шулай ук, Бикмөхәммәт Майлин, Мәгъҗан Җомабаев кебек казакъ язучылары, соңыннан Казакъстанның Мәгариф министры булган Ногман Манаев; үзбәк язучылары һәм галимнәреннән— Мирмөхсин Ширмөхәммәтов, Мөэминҗан Мөхәммәтҗанов, Булат Сәмиев; чиркәс Әхмәт Хатков, Ишангали Арабаев һәм башка төрки халык вәкилләре дә булган. «Галия» мәдрәсәсендә төрле елларда укыган зыялылар соңыннан да аралашып яшәгәннәр. Г. Ибраһимовның, мәсәлән, «Галия» мәдрәсәсендә бергә укыган шәрикләре, үзе укыткан укучылары, бергә эшләгән укытучыларының күбесе белән бәйләнештә торганлыгы мәгълүм. Г. Нигъмәти 1920 нче еллар башында Мәскәүдә Үзәк башкарма комитетының милли матбугат инструкторы булып эшләгәндә, шул бүлек карамагындагы Татарстан, Башкортстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Кырым һ. б. республикаларда чыгып килә торган газета-журналларга кураторлык иткән; соңрак, татар әдәбияты, башкорт әдәбияты һәм башка төрки әдәбиятлар турында, аларны үзара бәйләнештә чагыштырып өйрәнеп, вакытлы матбугат битләрендә мәкаләләр язып бастырган. Г. Нигъмәти белән казакъ язучысы һәм галиме (соңыннан академик) Җумалаев, кырымтатар язучысы Кәрим Җаманаклы арасындагы бәйләнешләр турында да беләбез. «Галия» мәдрәсәсендә укыткан мөгаллимнәрдән Г. Ибраһимов тугандаш төрки милләтләрдән булган шәкертләре, төрки кардәшләре турында: телләре төрле булса да, күңелләре бер, дип язган.

«Галия» мәдрәсәсен заманының алдынгы мәшһүр уку йорты итеп танытуда аны нигезләүче, аның җитәкчесе һәм алыштыргысыз мөдире Зыя Камали (Пәрвазетдин Җамалетдин улы Камалетдинов) дигән шәхеснең роле зур була. Аның турында бераз мәгълүмат биреп китик. Дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог-реформатор, күренекле галим һәм ислам белгече Зыя Камали 1873 елда Уфа губернасы Келәш авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне үз авылында алган, аннан укуын Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә дәвам иткән, соңыннан шунда укытучы булып эшләп калган. Уфа мөселман хәйрия җәмгыяте ярдәме белән Истанбулда, аннан соң Каһирәгә «ал-Әзһар» университетына күчеп, фәлсәфә факультетында белем алган. Зыя Камалига Мисырда укыганда Көнчыгышның мәшһүр философы, күренекле дин эшлеклесе һәм мәгърифәтчесе, дин реформаторы Мөхәммәд Габдеһүнең йогынтысы көчле булган. Аның тәэсирендә Камали үзен фәнгә һәм гыйлем таратуга багышлау карарына килә, хәтта үзенең мулла кушкан исемен (Пәрвазетдин) Зыя дип, ягъни белем нуры, дин нуры дигән мәгънәне аңлатучы исемгә алыштыра. Мәгърифәтчелек, исламны яңарту, мөселман халыкларының көнкүрешен европалаштыру тарафдары булып китә. Хәерчелектән, царизм изүеннән, милли тигезсезлектән котылуның бердәнбер чарасы дип ул белем һәм мәгърифәтне санаган. Россиягә, Уфага зур галим булып укып кайткач, ул рус, гарәп, фарсы, төрки телләрдәге газета-журналлар белән таныша башлаган, немец телен өйрәнгән. «Госмания» мәдрәсәсендә укыту эшчәнлеген (фәлсәфә, Коръән укыткан) дәвам иткән,

иҗтимагый тормышта актив катнашкан, вакытлы матбугат битләрендә реформаторлык идеяләрен пропагандалый башлаган, Коръәнне татар теленә тәрҗемә иткән.

1906 елда ул «Галия» мәдрәсәсен оештыру эшенә керешә. 1909 елда Уфаның икенче җамигъ мәчетенең имамы вазифасына билгеләнә һәм «Галия» мәдрәсәсенең рәсми җитәкчесе була. Шулай итеп, әчке Россиядә беренче югары мөселман уку йортын нигезли. Үзенең фәнни, мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән Зыя Камали җәдитчелек хәрәкәтенең лидеры булып таныла. Ул мөселманнарның милли янарышы, илдәге иҗтимагый тормышны, шул исәптән, динне демократияләштерү тарафдары булган. «Әлгаләмел-ислами» газетасында аның күп фикерләре басылып чыга.

Үзенең белеме, абруе белән Зыя Камали «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренә көчле йогынты ясаган. Г. Ибраһимов аның турында «мина ин көчле йогынты ясаган кешеләрнең берсе иде» дип яза. Мәдрәсәдәге иҗади һәм хөр мохитны булдыруда, әлбәттә, иң элек «Галия» мәдрәсәсенең зыялы җитәкчесе Зыя Камалинең роле бик зур була. 1915 елда «Галия» мәдрәсәсе турындагы бер мәкаләсендә Г. Ибраһимов болай дип яза: «Без иске фанатизм бишегендә тудык. Гакылыбыз, фикеребез иске әкиятләр белән томаланып үскән. Адәмнең җанын үтерәчәк бу тунлыклардан котылуда миңа иң беренче тәэсир итүче Шиһаб хәзрәт булса, икенчесе Зыя Камалидыр. Бу ике затка мин гакылымны азат кылу, фикеремә истикълал (бәйсезлек, иркенлек) бирү юлында мәңге бурычлымын. Болар минем фикри тәкаммелемнең (камилләшүемнең) үткән бер баскычында иң кирәкле мөәссир (тәэсир итүче, йогынты ясаучы) булдылар. Бер мин генә түгел, үзләренең үткәннәреннән хисап бирүче күп татар яшьләре дә моны икърар (тану) кыйлачаклар» *(Сәйфи Кудаш. Яшьлек эзләре буйлап.—Казан: Татар. кит.нәшр., 1964.—Б. 404).*

Укучыларның фикерләү һәм акыл сәләтләрен үстерү—«Галия» мәдрәсәсе укытучыларының төп педагогик принцибы булып торган. Үз вакытында остазыннан күп нәрсәгә өйрәнгән, күп гыйлем, сабак, тәҗрибә алган, аның йогынтысында булган Г. Ибраһимов соңыннан үзе дә укыту эшендә шушы принципны үзәккә куя. 1916 елда язылган «Әдәбият дәресләре» дигән мәкаләсендә (1918 елда «Әдәбият кануннары» исеме белән чыга) Г. Ибраһимов, нәкъ остазы Зыя Камали өйрәткәнчә, укытуда тоткан төп максатын болай дип билгеләп яза: «...Шәкертнең рухында аң уяту, шуңа тырышу—иң беренче шартлардан. ...Төп максат: гакылыбыз, шөбһәләр, ялгышлар, аңлашылмаулар табып, үзе эзләнсен. Менә бу эзләнү—мөгаллим тарафыннан шәкерт рухына салынырга тиешле булган иң кыйммәтле, иң җимешле орлыклардандыр. ...Эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү—мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр. Бу—мәңгелек бер нур, һичбер вакыт сүнми, арта барган саен арта, ниһаять, адәмнең рухын бөтенләй яктыртып җибәрә торган нурдыр» *(Г. Ибраһимов. «Әдәбият дәресләре».—Казан: Сабах, 1916.—Б. 6).* Г. Ибраһимов «Галия»дә укыткан чорда З.Камали тәэсирендә гыйльми-фәлсәфи, гыйльми-методик хезмәтләр яза башлый. Билгеле ки, аның 1909 елда «Борынгы ислам мәдәнияте», «Аурупа философы Декарт һәм аның нотыгы» дигән хезмәтләре, сонрак «Татар сарыфы», «Татар нәхүе» (1911) «Әдәбият дәресләре», «Татар телен ничек укытырга?» (1916) һ. б. китаплары языла һәм басылып чыга.

Әлеге хезмәтләрен язу өчен ул бик күп фәнни, тарихи, әдәби, фәлсәфи чыганакларны, шул исәптән төрки, шәркый, рус, Европа чыганакларын өйрәнгән, алардан файдаланган. Тел, әдәбият, сәнгать, тормыш күренешләрен үзара бәйләнештә өйрәнергә кирәклек турында мөһим фикергә килгән *(Хасанов М. Галимджан Ибрагимов.—Казань: 1977.—С. 20).* 1916 елда мәдрәсәдә казакъ теле, әдәбияты белән бәйләнештә казакъ шәкертләре һәм консерватив карашлы татар шәкертләре арасында чыккан бәхәс унае белән мөгаллим Г. Ибраһимов төпле чыгыш ясый, чыгышын «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре һәм мөгаллимнәре алдында лекция итеп укый (соңыннан ул «Телләре төрле булса да күңелләре бер» дигән



*«Галия» мәдрәсәсе укытучылары һәм шәкертләре. (Арткы рәттә сулдан дүртенче— Ш. Бабич.) Икенче рәттә уңнан дүртенче—«Галия»нең оештыручы мөдәррисе З. Камали, бишенче—Муса Бигичев.*

исем белән 1916 елда «Аң» журналында мәкалә булып басылып чыга *(Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. Т. 5.—Казан, 1978. Б. 225-232).* Г. Ибраһимов әдәби телләрнең һәм милли әдәбиятларның барлыкка килүләре турында бик нигезле һәм ышандырырлык итеп аңлата. Төрки халыклар телләренең, милли әдәбиятларының суверенлыгын тирән нигезли. Аерым алганда, теге яки бу халыкның теле, әдәбияты үсеше шул халыкның тарихи үсеше, тормыш дәрәҗәсе, халыкның җитештерү һәм рухи эшчәнлеге ихтыяҗлары белән билгеләнүе турында мөһим фикерне әйтә. Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә педагогика, татар теле, татар әдәбияты, әдәбият теориясен укыткан.

«Галия»дә укыткан елларда Г. Ибраһимов әдәбият программасына дөнья классикасыннан иң әйбәт үрнәкләрне тәрҗемә итеп кертүне дә көн тәртибенә куя. «Безгә мәдрәсәдә әдәбият дәресләрендә фәкать үз кабыгыбызга бикләнеп калырга мөмкин түгел,—дип яза ул 1915 елда «Хәзерләнә башларга вакыт җитмәдеме?» дигән мәкаләсендә.—Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм кешелек офыгына таба юнәлдерергә—бәни адәм хәятенең борынгы заманнардан алып әдәбиятта ничек ингыйкас итә (чагыла) барганлыгы белән танышырга—кыскача әйткәндә, татар әдәбиятыннан үтеп, бөтендөнья әдәбиятының тарихи агымнары белән дә танышырга лазем булачак. ...Гомумәдәбият күгенең Гареб кояшлары Гомер, Данте, Шекспир, Шиллер, Гете, Байрон кебек даһиларның гомуми әдәбият тарихына гаид әсәрләре илә бергә Шәрык даһиләренең Мәгарри, Фирдәүси, Сәгъди, Физули һ. б. хикмәт вә шигырьләре белән дә азыкланырга тиештер... Без, Шәрык балалары, киләчәк көнебезнең яктыруы өчен Гареб мәдәниятен файдалануыбыз никадәрле лазем булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрыкнең үткәне белән дә азыкланырга тиештер... Гареб классиклары илә янәшә утыртып, алларына бердәй тезләнергә фарыз булган Шәрык даһиларын хәтергә ала башларга вакыттыр дип уйлыйм... Боларны тәрҗемә вә нәшер кылырга, шәкерткә, боларны укып, тикшереп, алар илә нык танышыр өчен юл ачуны уйлый башларга бик тиешледер» *(Г. Ибраһимов. Әсәрләр, Т. 5. Казан.—Б. 223-224).* Г. Ибраһимовның әлеге фикерләрен укучысы, фикердәше Г. Нигъмәти дә уртаклаша. Әлеге фикерләр тормышларының, иҗади һәм фәнни эшчәнлекләренең нигезе булып тора.

Г. Ибраһимов Зыя Камали образын үзенең әдәби әсәрләрендә дә җанландырып бирә. Мона «Безнең көннәр» романындагы Гали хәзрәт, Гали мөдәррисне мисал итеп алырга мөмкин. Автор аны «мәдрәсәнең рәсми башлыгы, мәхәлләнең имамы» дип бирә. Әсәрдә сурәтләнгәнчә, Гали хәзрәт тә «үзенең егерме ел гомерен төрле мәдрәсәләрдә гыйлем алу юлына биргән кеше», ул да «Мәккә, Мәдинәгә, Истанбул, Мисырга барып укыган». «Шуннан ул үзе иске, кадим мәдрәсәләргә дошман киселде, монда, Россиягә кайтып, Мисыр, Истанбулның яңа мәдрәсәләре кебек мәдрәсә торгызмак булып эшкә тотынды. Юктан башлады, либерал татар капиталистлары ярдәме белән менә шундый зур биналар салды, акча җыйды, Истанбул, Мисыр күргән яңа тип мөгаллимнәр кертте. Динне, гарәпчәне янача укытты. Тәфсир, хәдис, гарәбият өстенә риазыят (математика), табигыят, татар теле, рус теле дәресләрен арттырды. Ләкин ничек кенә тырышса да, заманны куып җитә алмады» *(Г.Ибраһимов. Сайланма әсәрләр—Т. 4.—Б. 142).* Әсәрдә тагын бер урында Гали хәзрәт авызыннан язучы мондый сүзләрне әйттерә: «Милләт мондый яңа мәдрәсәләргә мохтаҗ, без кулдан килгәнне эшлибез, мөмкин булган барлык ислахны кертергә әзер торабыз» *(шунда ук, Б.146).*

Октябрь революциясеннән соң, «Галия» мәдрәсәсе яптырылгач, Зыя Камали иҗади эш белән шөгыльләнә, 4 томнан торган «Ислам фәлсәфәсе» дигән зур күләмле фәнни хезмәтен төгәлли, башка китапларын *(«Дини тәдбирләр» һ. б.)* яза. Россиядә җәдитчелек хәрәкәтенең лидерларыннан берсе буларак, Зыя Камали совет властеның даими күзәтүе астында була, берничә мәртәбә кулга алына. Бу чорда дини уку йортларын, мәчет-мәдрәсәләрне саклап калуда Зыя Камали мөфти Ризаэтдин Фәхретдин белән зур тырышлык салганнар. 1923 елдан ул Үзәк Диния нәзарәтендә казый була. 1936 елда кулга алына һәм 7 елга төрмәгә озатыла. Сталин лагерьлары вәхшилеген кутәрә алмыйча, Зыя Камали 1942 нче елда Самара төрмәсендә вафат була (гаепләү эше 1956 елда каралып, тулысынча реабилитацияләнгән). Мәшһүр «Галия» мәдрәсәсенең җитәкчесе Зыя Камали гына түгел, анда укып чыккан, аның горурлыгы булган, илнең милли элитасын тәшкил иткән башка бик күпләр дә шундый ук фаҗигале язмышка дучар була (мәгълүматларга караганда, аларның җитмеш процентка якыны репрессияләнә).

Татарстан матбугаты, радиосы, башка мәгълүмат чаралары аша Уфада «Галия» мәдрәсәсенең зур юбилее—ана нигез салынуга 100 ел тулу датасы билгеләп үтелү турындагы хәбәрне ишеткәч тә, миндә бу атаклы мәдрәсәне күрү, аның тарихы, анда укып чыккан шәхесләр турында күбрәк белү максаты белән Уфага барып катнашу теләге туды. Әдәбиятыбыз, фәнебез, мәгарифебез, гомумән мәдәниятебез тарихын, аерым язучылар, әдәбият галимнәренең эшчәнлеген өйрәнүче буларак, миндә моңа кадәр бу уку йортының тарихы белән зур кызыксыну уянган, билгеле бер кадәр мәгълүмат тупланган иде. Бер ай дәвамында барган сөйләшүләрдән һәм байтак кына формаль мәшәкатьләр үтәлгәннән соң, Татар Дәүләт Гуманитар-педагогика университеты ректоры Җәмил Нигъмәтов кул куйган юллама кәгазен һәм Уфадагы Россия Ислам университеты ректоры Ренат Әфраим улы Раевтан алынган чакыру хатын тотып, мин юлга кузгалдым.

Уфадагы мәһабәт Ләлә-Тюльпан мәчете комплексы бик зур территорияне биләп тора, искиткеч матур архитектура үрнәгендә корылган гүзәл сәнгать һәйкәле, гыйбадәт, мәгърифәт сарае! Уфа шәһәрендә ул икенче җамигъ мәчете санала икән. Аның төзелешенә Башкортстан Президенты шәхсән үзе бик зур ярдәм иткән. Мин монда Татарстаннан килгән бердәнбер вәкил булсам да, үземне чит, ялгыз итеп сизмәдем, һәрдаим мөселман кардәшләремнең җылысын тоеп тордым.

«Галия» мәдрәсәсенең 100 еллыгына багышланган тантаналы кичә һәм «Революциягә кадәрге дини уку йортларының халыкны агартудагы роле» дигән темага республика фәнни-гамәли конференциясе М. Гафури исемендәге Башкорт Дәүләт Академия драма театры бинасында үткәрелде. Әлеге чараларны оештыручылар һәм үткәрүчеләр—Башкортстан Республикасы хөкүмәте, хөкүмәт каршындагы дин эшләре Советы, Башкортстан Фәннәр академиясе, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Уфа каласындагы Россия Ислам

университеты.

Театр фойесында «Галия» мәдрәсәсе тарихына һәм анын укучыларына багышланган, Россия Ислам университеты, Башкортстан республикасы каршындагы архив эшләре идарәсе тарафыннан әзерләнгән әдәбият күргәзмәсе, документлар экспозициясе куелган, китаплар, вакытлы матбугат күргәзмәсе, сувенирлар һәм дини әдәбият сату оештырылган. Шулай ук, теләгән кеше «Галия» мәдрәсәсе тарихына кагылышлы материаллар, фоторәсемнәр, иллюстрацияләр, документлар, башка тарихи мәгълүматлар белән компьютер мониторында әйләнеп торган хәрәкәттәге экспозиция аша да танышты.

Театр бинасы халык белән шыгрым тулы: олуг юбилейга Россия федерациясенен төрле төбәкләреннән, БДБ илләреннән, чит илләрдән 500 дән артык кунак килгән. Шунын белән бергә анда Россия, Башкортстан Президентлары Аппараты һәм хөкүмәт вәкилләре, төрле министрлык һәм ведомство житәкчеләре, Уфа шәһәре хакимияте, Башкортстан Фәннәр академиясе, югары уку йортлары житәкчеләре, галимнәре, педагоглары, шулай ук күренекле дин эшлеклеләре, мәгариф, мәдәният h. б. өлкәләрдә эшләүчеләр, Россиянен төрле өлкәләре губернаторлары (күбесе руслар), аларнын вәкилләре, гомумән, кин жәмәгатьчелек катнашты. Юбилейнын тантаналы беренче өлешен Россия мөселманнарынын Үзәк Диния нәзарәте рәисе мөфти Тәлгать Тажетдин ачып жибәрде. Тантанада Россиянен һәм Башкортстан хөкүмәтләре каршындагы дин эшләре буенча совет рәисләре, Россиянен Курган өлкәсе губернаторы кинәшчесе, Чиләбе өлкәсе губернаторы, Төмән, Оренбург h. б. өлкәләр житәкчелеге вәкилләре, Россия Үзәк Мөселман нәзарәтенә караган төрле өлкә мөфтиятләре вәкилләре, Кавказ республикалары, Казакъстан, Төркмәнстан h. б. илләр вәкилләре, Башкортстан хөкүмәтенен премьер-министры урынбасары—Башкортстаннын мәдәният һәм милли сәясәт министры Илдус Илишев (ул тантаналы өлешне алып та барды) h. б. чыгыш ясадылар. Кунакларнын күбесе, сәхнәгә менеп, бәйрәмгә алып килгән бүләкләрен тапшырдылар. «Галия» мәдрәсәсенен олуг юбилеен котлап, чит илләрдән, БДБ илләреннән килгән аерым телеграммалар да укылды.

Кичәнен икенче бүлеге фәнни-гамәли конференция эше белән кушылып китте. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, юбилей чараларында эш һәм аралашу теле буларак рус, татар, башкорт телләре янгырады. Икенче бүлектә Башкортстан Фәннәр академиясе вице-президенты Нияз Мәжитов, Уфадагы Россия Ислам университеты ректоры Ренат Раев, Башкортстан Фәннәр академиясенен Телләр һәм телара мөнәсәбәтләрне өйрәнү үзәге директоры Морат Жәлил улы Киекбаев (атаклы тел галиме Жәлил Киекбаевнын улы), Казакъ милли университетынын кафедра мөдире, почетлы академик Турсунбәк Какишев (казакъ телендә сөйләде), Төньяк Казакъстан университеты профессоры Равил Рәжәпов, «Галия» мәдрәсәсендә укыган күренекле язучы Сәйфи Кудашнын кызы—профессор Сөембикә Кудашева h. б. кызыклы, эчтәлекле чыгышлар ясадылар. Конференциянен программасы шактый зур булганлыктан, бөтен докладларны да тынлап бетерү мөмкин дә түгел иде. Көннен икенче яртысында кунакларны элекке «Галия» мәдрәсәсе урнашкан бинага алып бару (хәзер анда Россия Ислам университетынын административ һәм төп уку бинасы урнашкан), конференция эшен шунда күчереп дәвам иттерү каралган иде. Чернышевский (элеккеге Уфимская) урамындагы тарихи «Галия» мәдрәсәсенен өч катлы, кызыл кирпечтән салынган бинасы тау өстендә, шәһәрнен тарихи, шактый иске өлешендә урнашкан. Чернышевский урамы шул бина белән башланып китә. «Галия» бинасы, XX гасыр башыннан калган иске, бер катлы агач йортлар, тарихи вакыйгаларнын шаһите булган, бик күп шәхесләрне хәтерләгән өйләр бер тарихи комплекс, утрау булып торалар (минем күз алдыма шул урамнардан үтеп йөргән, яшь, дәртле, егетләр—Ибраһимовлар, Бабичлар, Рәмиевләр, Туфаннар, Нигъмәтиләр килеп басты). Дөрес, урам буйлап тагын да өскә күтәрелсән, анда инде бөтенләй башка дөньяга килеп чыгасын, биек-биек заманча йортлары, төзелешләре белән яна

Уфа башланып китә.

«Галия» мәдрәсәсе бинасының урам як стенасында, ян-як тәрәзә уемнары арасында Г. Ибраһимов һәм Ш. Бабичларның монда укыган вакытларын күрсәтеп торган, шактый искерә, тоныклана төшкән язулы ике мемориаль ак гранит такта беркетелгән.

Экскурсия вакытында сөйләгәннәрдән без шуны анладык: «Галия» мәдрәсәсенең нигезе, фундаменты 1908 елның маенда салына башлаган икән (аңа кадәр шәкертләр мәхәллә мәдрәсәсендә укып торганнар). Яңа мәдрәсәнең проектын Зыя Камали турыдан-туры үз җитәкчелегендә эшләткән. 1908 елның октябрендә Уфа каласының калку бер урынында, Уфимский урамында кызыл кирпечтән өч катлы таш бина төзелә. Яңа төзелгән мәдрәсә бинасының өченче катында уку аудиторияләре һәм уку залы белән китапханә урнаштырыла; икенче катында шәкертләрнең йокы бүлмәләре һәм беренче катында ашханә, намаз уку бүлмәсе, ярдәмче бүлмәләр. Уку корпусын төзүгә бай сәүдәгәрләр ярдәм итә. Бүлмәләрне җиһазлау өчен дә акча җәмәгатьчелектән җыела. Әйтик, йокы бүлмәсенә караватлар Закир Рәмиев акчасына алынган, электр уты үткәрү чыгымнары өчен акчаны Муса Бигиев биргән һ. б. Мәдрәсә—«Галия-Диния» дигән исем белән, гимназия курсларын, ягъни дөньяви уку дисциплиналары курсын үз эченә алган югары дини уку йорты буларак ачыла. Мәдрәсәдә әкренләп китапханә туплана башлый: китапларны китап кибетләреннән, аерым кешеләр кулыннан сатып алалар, башка шәһәрләрдән һәм илләрдән кайтарталар. Китапханәгә татар, рус телләрендә күп кенә вакытлы матбугат басмалары яздырып алына. Китапханә киштәләрендә Ислам нигезе буенча күптомлы китап-әсбаплар, гарәп телендә ун томлык энциклопедия, төрек телендә унике томлык «Кешелек тарихы» дигән китап һәм башкалар белән беррәттән, психология, математика, логика, табигать белеме, геология, география дәреслекләре, Пушкин, Гоголь, Чехов, Горький, Тукай, Гафури, Исхакый һ. б. әсәрләре дә булган. Китапханәгә «Шура», «Ялт-йолт», «Вакыт», «Тормыш», «Нур», «Уфимский край», «Русские ведомости» кебек шул еллардагы матбугат яздырып алынган.

Шәкертләр монда югары дини белемгә ия булу өчен алты ел укыганнар; уку өч баскычтан торган: рөшдия (түбән), игъдади (урта) һәм гали (югары). Укытуда төп фәннәр буларак тарих, ислам фәлсәфәсе, Коръән тәфсире, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы укытылган. Шулай ук гарәп, татар теле, рус, төрек телләре укытылган. Традицион предметлардан тыш, психология, педагогика, дидактика, әдәбият, каллиграфия дәресләре дә кергән. Монда алдынгы карашлы укытучылардан Казан укытучылар мәктәбен бетергән Абдусаттаев, Мәскәү университетын тәмамлаган Сабиров, Багдадта физика-математика буенча белем алган Шинаси, Казан университетында укыган Фатих Сәйфи-Казанлы (тарих укыткан), Закир Кадыйри, Әхмәтзәки Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Гыйниятулла Терегулов һ. б. укытучыларның исемнәре мәдрәсә тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Математика, физика, химиядән көчле укытучылар укыткан монда, махсус җиһазландырылган кабинетлар да булган.

«Галия» мәдрәсәсе белемнәр биреп кенә калмаган, анда әдәби, музыкаль түгәрәкләр дә оештырылган. Мәдрәсәдә үткәрелгән концертларга, әдәби кичәләргә шәһәр яшьләре дә йөргән. Аларда Мәҗит Гафури, яшь шагыйрь Шәехзадә Бабич бик актив катнашкан. Бабич җитәкчелегендә айга ике мәртәбә кульязма фәнни-әдәби «Парлак» журналы чыгарылган. Сонрак бу эшкә Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Х. Туфан һ. б. да актив катнашып китәләр. Әдәби түгәрәк белән мәдрәсәнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Г. Ибраһимов җитәкчелек иткән. Мәдрәсәнең үз биючеләре, җырчылары, музыкантлары, мандолиначы, курайчы, гармунчылары булган. Шулай ук, җыр, музыка, драма, фольклор түгәрәкләре эшләп килгән.

Бинаның тарихи стеналары әле дә шул чорның саклый төсле. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында, Сәйфи Кудашның «Галия» мәдрәсәсе турындагы истәлек китапларында язылган күренешләр барысы да күз алдына килеп басты. Дәрес бүлмәләре, зур озын коридорлар, өске катка менә торган киң тимер баскыч,

өченче каттагы зур зал, икенче каттагы канцелярия—элекке «Галия» мәдрәсәсенең эчке ягы бүген дә, нигездә, нәкъ шулай сакланган. Әлбәттә, материаль ягы яхшырган, эчке бизәлеше үзгәргән, янача төзекләндерү үткәрелгән. Мин мәдрәсә китапханәсенә шунда укып чыккан шәхесләр турында язылган китабымны, Казаннан Галимҗан ага Нигъмәтинең балалары биреп җибәргән, әтиләре турында язылган һәм аның истәлегенә багышланган китапларны бүләк итеп калдырдым.

«Галия» мәдрәсәсе 1919 елга кадәр, 13 ел дәвамында эшләп килә. Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр арасында, Ренат хәзрәт Раевның сөйләве буенча, 28 профессиональ язучы, 28 журналист, 8 фән хезмәткәре, 7 Халык комиссары (мәгариф, эчке эшләр, сәнәгать, җир эшләре), агрономнар, зоотехниклар, юристлар, инженерлар һ. б. булган.

1919 елда «Галия» мәдрәсәсе гомуми белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә, соңрак эшче-яшьләр мәктәбе, интернат-мәктәп, 14 нче урта мәктәп буларак эшли. 1906 елдан 1919 елга кадәр «Галия» мәдрәсәсе бөтен эчке Россия мөселманнарының, барлык төрки халыкларның югары дини уку йорты булып торса, революциядән соң да ул мәгарифкә хезмәт итә. 70 елдан соң мәдрәсә яңадан тергезелә, 1989 елда «Галия» мәдрәсәсе янә үз асылына кайта. Хәзерге «Галия» мәдрәсәсе—Россия Ислам университеты да элекке «Галия» мәдрәсәсенең иң яхшы традицияләрен уңышлы дәвам итә. Монда бүген башкорт, татар, казакъ, үзбәк, кыргыз, таҗик, нугай, Мәскәү, Рига, Ставрополь, Самара, Себердән һ. б. җирләрдән килгән яшьләр белем һәм тәрбия ала. Россия Ислам университетында теология, педагогика, квалификация күтәрү факультетлары бар, аларда имам-хатиплар, руханилар, теология һәм гарәп теле белгечләре-мөгаллимнәре әзерләнә. Бирегә Россия, БДБ илләре, Мисыр, Иордания, Төркия һ. б. илләрдә университет тәмамлаган тәҗрибәле белгечләр укытучылар итеп чакырыла икән. Дини һөнәри белем бирү өч баскычта каралган. Алты ел укыгач, шәкертләр югары дини белем үзләштереп, ислам теологы булалар. Уку программасыннан күренгәнчә, дин гыйлемнәре белән бергә, политология, социология, психология, педагогика, культурология, экология, икътисад, хокук, татар теле һәм әдәбияты (112 сәгать), рус теле һәм әдәбияты (32 сәгать) һ. б. фәннәр укытыла. Укыту теле булып рус, башкорт, татар телләре санала.

Россия Ислам университеты студентлары XX гасыр башы «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре рәвешенчәрәк киенергә тырышалар: егетләр заманча тегелгән камзуллар, озын җиңле ак күлмәк белән кара төстәге жилетлардан йөри, башларында җиңел, ак яки кара төстәге кәләпүш-түбәтәйләр, кызлар да заманча, шул ук вакытта тыйнак, матур, озын җиңле кофталардан, өстеннән йә костюм, йә жилет киеп, озынча матур итәкләрдән, башъяулыклардан йөриләр.

**Эльмира ГАЛИЕВА,**
*ТДГПУ профессоры.*

**Редакциядән:**

*Гомумтөрки, шул исәптән беренче чиратта татар дөньясы тарихында аерым урын тоткан бу олуг вакыйгада Татарстаннан бер генә галимә катнашуы күңелләрдә сәер тойгы калдыра, әлбәттә. Бу гали мәдрәсәдә укыткан һәм укып чыккан шәхесләрнең күбесе татарлар, һәм алар татар мәдәниятенә хезмәт иткәннәр... Уфа тарафыннан тиешле чакыру булмаганмы, әллә чакыру булып та Татарстан вәкилләре бара алмаганмы—сәбәпләре безгә төгәл мәгълүм түгел. Шулай да «Галия» мәдрәсәсе тарихы һәм бу юбилей бәйрәме турында журналыбызда беркадәр мәгълүмат биргәне өчен галимә Эльмира Галиевага рәхмәт белдерәбез.*

# XVI-XVII ГАСЫРЛАРДА КАЗАН ТИРӘСЕНДӘГЕ АВЫЛЛАР

Менъяшәр каланың әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән тагын бер ягы бар. Бу—бүгенге башкаланы барлыкка китерүдә төп рольне уйнаган, хәзерге шәһәрнең урамнары, мәйданнары һәм микрорайоннары булып торган, урта гасырларда Казанны чолгап алган күп санлы һәм төрле типтагы авыллар һәм бистәләр.

С. М. Шпилевский, Ш. Мәржани, И. А. Износков, К. Насыйри, И. М. Покровский, М. Г. Худяков, Е. И. Чернышев һ. б. тарихчылар Казан шәһәренең авыл өлеше турында язып карарга омтылсалар да, бу эш системалы һәм тулы башкарылмаган. Мона галимнәребез игътибарында гаҗәеп бай тарихлы шәһәрнең төп өлеше, беренче чиратта Кремль торуы комачаулык итте ахры. Күпчелеге инде онытылып бара торган бу авылларны искә төшереп хәтердә янарту бик мәслихәт булыр дип уйлыйбыз.

Кызганычка каршы, Казанның авыл өлеше турында татар чыганаклары сакланмаган диярлек. Бу язманы әзерләү өчен без Мәскәү архивлары материалларын, Казан тарихчыларының, беренче нәүбәттә, рус галимнәренең хезмәтләрен кулландык. Әйтергә кирәк, аларда күбрәк рус халкының тормышы яктыртыла, авылларның татар чорына караган өлеше бик аз.

Рус елъязмаларында күп тапкырлар телгә алынган Бишбалта авылы Туры Казан дигән урыннан бер ярым, ә Идел елгасыннан 7 чакрым ераклыкта урнашкан. Бу борынгы авылда урман кисүчеләр—балта осталары яшәгән. XIV гасырда ук Бишбалта халкы ханның хәрби һәм сәүдә флоты өчен кораблар төзегән. Авыл янына ук килеп житкән Иделнең киң һәм тирән култыгы монда житештерелгән төрле типтагы корабларны олы су юлына төшерергә җайлы булган. Бишбалтаның табигате дә гүзәл булган—көнчыгыштан мул сулы Бишбалта күле, көньяктан тирән Саф күл уратып алган, халыкның терлеге куе үләнле болыннарда тукланган, йөзъяшәр агачлы кара урманнар авылны явыз кешеләр күзеннән яшергән.

Бишбалта рус документларында беренче тапкыр1551 елның 13 августында телгә алына. Бу көнне Тирән үзән дигән жирдә (Казансуның Иделгә кушылган урыны) татар ханлыгының Тау ягы язмышын фажигале хәл иткән жыелыш була (Тау ягы Рус дәүләте кулына күчә). Бишбалтадан ерак булмаган Патша болыны рус воеводалары һәм сугышчылары белән тула, шулар арасында Иван IV гә армый-талмый хезмәт иткән Шаһгали хан да була. Авыл икенче тапкыр 1552 елның 9 март вакыйгаларына бәйләп телгә алына. Бу көнне Казанда рус яклы хөкүмәт бәреп төшерелә һәм Чапкын Үтәшев житәкчелегендә яна идарә төзелә. Чапкын хөкүмәте белән сөйләшүләр алып бару өчен Бишбалтага рус наместнигы С. И. Микулинский килә. Ике яклы сөйләшүләрдә татар морзаларыннан Ислам, Кәбәк, Галикәй һ. б. катнашулары билгеле. Бишбалта өченче тапкыр 1552 елның дәһшәтле 2 октябрь көнендә искә алына. Рус ельязмасы: «татарлар таралышып урманга таба йөгерделәр. Патша ... аларны эзәрлекләү өчен Бишбалтага боярин С. М. Микулинскийны һәм Л. А. Салтыковны жибәрде... Боярлар һәм воеводалар ... поганыйларны күпләп кырдылар: Казансудан урманга кадәр жир һәм урманның эче... үлекләр белән тулды, бик азлары качтылар, яраланганнар күп булды»,—дип яза.

XVI гасырның азагында Бишбалта авылы янында русларның «йөзү хезмәте» («плавная служба») дип аталган оешмасы барлыкка килә, ул Идел буе елга чикләрен контрольдә тоту өчен кирәк була.

Казан яулап алынганнан соң Бишбалта авылы яна оешкан Елантау монастырена бирелә. Бишбалтадан татар халкы куыла, авыл яшәүдән туктый. Ханлык бетеп, 15 ел үткәч, яңа хөкүмәт авылга рус крестьяннарын күчереп утырта башлый—анда 1565 елда өч йорт булуы билгеле. XVII гасыр урталарында Бишбалтада монастырьнең ат хуҗалыгы, 16 крестьян һәм 13 бобыль (җирсез, ярлы крестьян) өйләре булып, монда ир-ат җенесеннән 94 кеше яши. 1680 нче елларда Бишбалта янында дәүләтнең ипи саклау складлары төзелә. XVII гасыр ахыры—XVIII гасыр башында авыл җирендә Адмиралтейство бистәсе оеша башлый.

Бишбалтага каршы якта, Казансу елгасы буенда, Игумново исемле авыл булган. Авылның татарча исеме билгеле түгел. Рус чоры башлангач авыл озак еллар буш (пустошь булып) тора. Бары тик 1603 елда гына монда 4 өй барлыкка килә. 1623-1624 елларда Казан митрополиты авылны монастырьга бирә, монда 8 крестьян һәм 3 бобыль хуҗалыгы була, алар йорт исәбеннән игуменьга 10 алтын түлиләр. 1646 елда авылда 7 крестьян, 10 бобыль, сигез елдан соң 13 крестьян һәм 4 бобыль, 1677 елда 3 крестьян, 13 бобыль хуҗалыгы теркәлгән.

Казан авылларының күпчелеге елгалар, күлләр һәм чишмә буйларында урнашкан. Шундый урыннарны сайлау халыкка хайван асрау һәм җир эшкәртүне нәтиҗәле алып барырга ярдәм иткән. Түбән Кабан күле буендагы (хәзерге Һади Такташ урамы) искиткеч матур табигатьле урында Колмөхәммәт исемле татар авылы яшәп яткан. Колмөхәммәт—кеше исеме, безнеңчә, дәүләткә күрсәткән хезмәте өчен хан тарафыннан авыл шушы аксөяккә бирелгән. Авылдан ерак түгел Кара инеш дип йөртелгән елгачык аккан, җирләрнең рельефы тигез түгеллеге документларда күп тапкырлар искәртелгән. Казан яулап алынганнан соң татарлар авылдан куылган, уңдырышлы бай җирләргә рус воеводасы П. Булгаков хуҗа булган. 1567 елда Колмөхәммәт авылы архиепископ Герман кулына күчә. Бу елда авылда 1 хуҗалык булып, анда Федька Васильев исемле рус яшәгән. Герман бу авылга бобыльләрне китерә; XVII гасыр башында монда (ул инде авылда төзелгән архангел Михаил исемле чиркәү хөрмәтенә Архангельск дип атала башлый) 12 бобыль хуҗалыгы, митрополит һәм поп йортлары, ике келья (монахлар торагы) булганлыгы билгеле. 1646 елда авылда хуҗалыклар саны 32 гә, ә яшәүчеләр 106 кешегә җитә. Бобыльләр җир эшкәртү белән шөгыльләнмәгәннәр, алар арасында ташчылар, сырачылар, арба ясау осталары, балта осталары, күнчеләр һәм көмешчеләр булган. XVII гасыр ахырына Архангельск авылы бистә статусы ала, монда өйләр саны 58 гә җитә. Халкының кәсебе дә төрләнә—итекчеләр, тегүчеләр, шәм, сабын ясаучылар, тимерчеләр һ. б. осталар үсеп чыга. Рус тарихчысы И. Покровский Казанда промышленностьнең башлану һәм сәүдәгәрләрнең барлыкка килүен Архангельск һөнәрчелек хуҗалыгыннан чыккан, дип ассызыклый.

Нугай юлындагы Әхмәт авылына (Ометьево), татарларны Казаннан руслар куып чыгаргач, Әхмәт исемле кеше нигез салган дип күрсәтәләр татар риваятьләре. Безнеңчә, бу хәбәрләр дөреслеккә туры килми. Авылга нигез салучы булып XIV гасырның икенче яртысында Урда ханы эзәрлекләвеннән Зөя елгасы ярларына килеп сыенган Әхмәт исемле эре аксөяк булуы ихтимал. Шәһәрдән 2 чакрым ераклыкта урнашкан бу авылда 1568 елда 8 рус хуҗалыгы, 1603 елда 15, 1643 елда 52 өй булган. Авылда яшәүчеләрнең күпчелеге крестьяннар булып, 8 генә бобыль хуҗалыгы теркәлгән. Митрополит милке саналган Аметевода (рус чорында авыл шулай дип йөртелә башлый) XVII гасырның икенче яртысында өйләр саны кимүгә таба йөз тота—1678 елда 22 хуҗалыкта 95 кеше яшәгән.

Нугай юлының уң ягында, Нокса елгасы буенда, Казаннан 10 чакрым ераклыкта Салмачы исемле авыл урнашкан. Рус тарихчысы И.Износков авылның исемен «салма ясаучы»дан чыккан дип раслый. 1567 елда авылда (Казанга яңа күчеп килгән рус дворяны О. А. Янев биләмәсе) 15 крестьян хуҗалыгы булып, шулар арасында 6 укчы (стрелец) торган. Салмачы патша фәрманы буенча 1591 елда Казан Преображенск монастыре архимандриты Галактионга бирелә. XVII гасыр урталарына авылда 39 өй булып, анда 150 кеше яшәгән.

Казан шәһәреннән 11 чакрым ераклыкта, Нугай юлында (кайбер документлар Җөри юлында дип күрсәтә) Озын күл (Бәкләр күле түгел микән?) буенда Олы Утар

авылы җәелеп утырган. Олы Утар 1552 елга кадәр хан биләмәсе булган. Казан яулап алынганнан соң авыл рус патшасы биләмәсе, ә 1566 елда князь Ф. И. Троекуровка җир мөлкәте итеп бирелгән. Авылда бу чорда 11 крестьян хуҗалыгы барлыгы билгеле, Иван Москвин һәм Богдашка Васильгородец фамилияләре аларның Мәскәүдән һәм Васильгородец шәһәрләреннән күчереп утыртылганын күрсәтә.

Бүген Атары поселогы дип йөртелгән Урта Утар авылы Казан шәһәреннән биш чакрым ераклыкта урнашкан булган. Авыл белән янәшәдә Озын күл урнашкан. 1566 елда Урта Утарда өч хуҗалык булып, алар О. А. Янов исемле алпавытка бәйле булганнар. 1621 елда авылда 12, 1646 елда 19 йорт исәпләнгән. Бу авылны Сангырау күл (Глухое) буенда, Казаннан 6,5 чакрымда урнашкан Урта Утар (аны рус документлары Ближние, Малые дип тә йөртәләр) авылы белән тәңгәлләштерергә ярамый, чөнки монысына Кокушкино авылыннан чыккан өч кеше 1760 елда гына нигез салалар. Тора-бара бу авылга Царицыно авылыннан берничә гаилә килеп яши башлый.

Казан шәһәреннән 10 чакрымда, Нугай юлының сазлыклы урманы эчендә Дәүләки (Девликеево) авылы яшәп яткан. 1565-1568 еллардагы теркәү кенәгәләрендә авылның исеме Дәүләткилде дип бирелгән. Безнең уйлавыбызча, авылдан татарлар куып чыгарылгач, бу җирләр ун елдан артык буш торган, 1568 елда монда 2 генә крестьян хуҗалыгы барлыкка килә. Авылдан ерак түгел Дәүләки чокыры дип аталган, киңлеге 100 метр, тирәнлеге 20 метр һәм озынлыгы 7 чакрымга җиткән икенче терраса чокыры яткан. Дәүләки авылының борынгы икәнен шушы чокырдан табылган күп санлы татар акчалары раслый дип искәртә И. А. Износков.

Дәүләки авылы икенче төрле Введенское дигән исем белән дә йөртелгән. XVII гасыр уртасында авылдагы хуҗалыклар саны 74 кә җитә, шулар арасында бобыльләр 26 өйдә торганнар. Барысы 284 кеше яшәгән. 1678 елда йортлар саны бары тик 44 кә, халык саны 88 гә кала, мондый кинәт кимүнең сәбәбен 1654 елгы үләт эпидемиясенең нәтиҗәсе дип карарга кирәк.

Дәүләки авылында яшәп килгән сәер гадәтләр турында И. А. Износков язып калдырган. Бу авылда төннәрен үч алу максатында капкаларны дегеткә буяу киң таралган булган. XIX гасырда монда бурлаклар күп яшәгән булса кирәк.

Арча юлында, Казаннан 16 чакрым ераклыктагы Киндерле елгасының Казансуга кушылган җирендә, Олы Колсәет авылы урнашкан. Авылның исемен И. А. Износков «Күлле Сәет» дип тәрҗемә итә, А. Халиков моны «кул», «куллар» социаль категориясе, ягъни коллар белән бәйли, Ш. Мөхәммәдьяров дини исемдәге авылларда (Сәетләр, Дәрбиш, Абыз һ. б.) Казан ханлыгы чорында мөселман руханилары торган дип фикер йөртә. Безнеңчә, авылның этимологиясе Колсәет исемле кешегә бәйле. Колсәет—авылга нигез салучы, йә шушы авылның хуҗасы булырга мөмкин. 1564 елда авылга Григорий Онучин хуҗа булганда Колсәеттә 4 крестьян йорты, 3 буш урын булган. XVII гасыр урталарында авылда йортлар саны 39 га, яшәүчеләр 133 кешегә җиткән. Киндерле елгасы буенда 5 өйле Кече Колсәет авылы да яшәп яткан. Хан биләмәсе булган бу авыл 1565 елда рус князе Дмитрийга поместье итеп бирелгән. XVII гасырның икенче яртысында 36 дисәтинә чәчүлек җире булган авылга алпавыт Ф. К. Шушерин хуҗа булган.

Казаннан 13,5 чакрымда, Киндерле һәм Казансу елгалары буенда, Дәрвиш (Дәрбишгали, Дербышки) авылы урнашкан. А. Халиков авылның этимологиясен мөселман руханиларына бәйле дип карый. И.А.Износков Дәрбиш исемен Әстерханның соңгы ханы Дәрвиш исемле булуын әйтеп үтә. Казан ханлыгында шул исемдәге дәүләт эшлеклесе булуы билгеле. 1552 елга кадәр авыл хан милке була, аннары рус патшасыныкы (дворцовый), 1566 елда ике туган—Мансур һәм Иван Товарищев исемле дворяннарга бирелгән. Ханлык чорында авыл шактый ук зур булса да, 1567 елда монда бары тик 3 йорт, шуның да берсе буш булган. 1617 елда Дәрвиштә 9, 1650 елда 22 хуҗалык була, 41 кеше яшәгән.

Киндерле елгасы буендагы, «Озын күпер» янында, Казаннан 11 чакрым ераклыкта Киндер авылы булган. И. А. Износков авылның исеме «киндер»—конопля исеменнән дип карый. А. Халиков, Пермь өлкәсе Бәрәңге районы татарларының генеологик риваятьләренә таянып, авылга марилар нигез салган дигән фикерне әйтә.

1566 елда Киндер бертуган Гагариннар исемле алпавытларга бирелгән, ә 1567 елда ана Казан воеводасы кенәз Данила Чюлков-Ушатый хужа булып ала. Шушы ук елда авылның бер өлеше (7 хужалык) Четвертак исемле тылмачка, икенче өлеше З. С. Еропкинга бирелгән. 1585 елда Киндер авылы Елантау монастыре игумены Родионга буйсына. 1646 елда монда 52 өй булып, 189 кеше кеше яшәгәнлеге билгеле. XVII гасырның 70 нче елларында авылда 20 хужалыкның унберендә крестьяннар, сигезендә бобыльләр яшәгән, берсе монастырь өе булган.

Казан шәһәреннән көнбатыш юнәлештә, Мәскәү-Галич юлының 14 чакрымында Хужахмәт (хәзерге Куземетево поселогы) авылы яшәп яткан. И. А. Износков авылның атамасыннан чыгып, ханлык чорында бу авылда чуашлар торган, дигән фикер әйтә. Безнеңчә, рус тарихчысы бу очракта ялгыша, Хужа Әхмәт чуаш сүзе түгел, гомумән, чуашларда Әхмәт исеме очрамый. Авылда табып алынган эпиграфик истәлекләр дә Хужахмәтнең татарныкы икәнен исбатлыйлар. Казан яулап алынгач халык авылны ташлап качарга мәҗбүр була, 1565-1568 еллардагы теркәү кенәгәләрендә бу җирләр буш урын (пустошь) буларак билгеле. 1603 елда авылда 10 йорт, шуның икесе буш булган. 1654 елда монда 21 хужалык булып, шуларда 79 кеше яшәгән. Авыл янында Хужахмәт исемле ярыйсы ук мул сулы тирән күл барлыгы билгеле.

Җиләкле Алан (Ягодная Поляна) авылы Казаннан һәм Елантаудан 3 чакрым ераклыкта, Галич юлындагы калку Җиләктау аланында урнашкан. Авылны чолгап алган урманда, аның күп санлы аланнарында төрле җиләк күп булганга, авылның атамасы татар һәм рус чорында үзгәрмичә саклана. Безнең уйлавыбызча, бу авыл ханлык чорында иң дәү авылларның берсе булып хан биләмәсенә кергән. Казан алынгач исән калган татар сугышчыларының зур бер төркеме «Җиләкле яр» юлы белән китте, ди татар риваяте. Авыл 1552 елда рус патшасы әмере буенча П. Булгаковка бирелә. Җиләкле Аланның хуҗасы булып рус алпавыты кенәз В. Чесников-Анбульский торганлыгы да билгеле. 1568 елда авылда 19 крестьян хужалыгы була. Җиләкле Алан 1588 елда Казан һәм Свияжск архиепископы Тихон II гә бирелә. XVI гасыр ахыры—XVII гасыр башында Җиләкле Алан яңа авыллар барлыкка килү (Комаровка, Савиново, Овинище, берничә пүчинкә) өчен терәк пункт ролен уйный. 1603 елда монда 40 йорт булып, шуның 15 өе буш торган. XVII гасыр уртасына авылда 122 хужалык булып, монда 350 кеше яшәгән, бобыль өйләренең саны 75 кә житкән. 1678 елгы авылда 51 йорт кына күрсәтелә. Авыл кешеләре арасында ат караучы, мичкә ясаучы, көймә саклаучы, кирпеч остасы һ.б. һөнәрчеләр булган. XVIII гасыр башында авылда хужалыклар саны бик тиз үсә—500 гә житә. Һөнәрләр дә арта—балта осталары, тимерчеләр, кораб ясау осталары һ. б. күренә. XVIII гасыр урталарына авыл халкының чәчүлек җирләре калмый, Ягодная Поляна Казан епархиясе биләмәсеннән аерылып чыга. Ул 1825 елда шәһәр бистәсе булып китә.

Мәскәү-Галич юлында, Казансу елгасы яр буенда (хәзерге Киров районының элеккеге Адмиралтейская бистәсенә керә) Түгәрәк Алан (Круглая Поляна) авылы урнашкан. 1567 елда авылда 3 хужалык булып, шуның берсе буш торган. 1603 елда авылда 11 крестьян һәм 4 бобыль йорты саналган, 1646 елда өйләр саны тагын икегә арткан, 63 кеше яшәгән. XVII гасырның ахырына авыл юкка чыккан, моңа 1654 елда (бу елда 15 йортта 45 кеше булган) башланган үләт эпидемиясе сәбәпче булуы ихтимал.

Мәскәү юлының Казаннан 10 нчы чакрымында, Хужахмәт елгасы башланган урында Уракчы (хәзерге Аракчино поселогы) исемле татар авылы җәелеп утырган. Авыл беренче тапкыр 1603 елда «Аракчин починок» атамасы белән телгә алына. Монда 10 өй булган, 1624 елда йортлар саны 35 кә житә. XVII гасырның икенче яртысында хужалыклар саны кими—1654 елда 25 йортта 81 кеше, ә 1677 елда 12 йортта 48 кеше кала. Уракчы белән Кече Хужахмәт авыллары арасында, Түгәрәк күл буенда XVII гасыр башында 4 йортлы Тишкин пүчинкәсе барлыкка килә. Авылның үсеше сүлпән бара, 20 елдан соң тагын 3 кенә өй барлыкка килүе моңа шаһит. 1646 елда 8, 1654 елда 6 йорт булуы билгеле. Үләт эпидемиясенең бу авылны да юкка чыгаруы рус документларында чагыла.

Казаннан 8,5 чакрым ераклыкта, күп санлы күлләр арасында Карабай (Караби, Караваево) авылы урнашкан. И. А. Износков авылның атамасын Кара бай исеменнән,

яисә кушаматтан, дип күрсәтә. Марсель Әхмәтжанов Яшел Үзән районының Олы Караужа авылы кешеләреннән язып алынган риваятькә таянып, авылның этимологиясен Караужаның әтисе Караби исеменнән, дип аңлата. Карабай авылының ханлык чорында ук шактый зур авыл булуы турында Ш. Мәрҗани язмаларында күренә. Рус авылы Караваевоның төзелү елы дип 1600 ел санала. 1617 елда авылда 15, XVII гасырның урталарына 51 хуҗалык булган (46 крестьян, 5 бобыль йорты), 95 кеше яшәгән, чәчүлек җире 156 дисәтинә саналган.

Казаннан 6 чакрымда, Җөри юлындагы Дүртөйле елгасы буенда Шәмәсир (Шәмсир, Самосырово) авылы булган. И. А. Износков авылның атамасын чуаш сүзе саман сьир—льготалы җир мәгънәсе белән аңлата. Безнең уйлавыбызча, авыл атамасы Шәмсир исемле (фарсыча «кылыч йөртүче») кеше исеменнән килә. 1567 елда авыл Преображенск монастыре биләмәсе булып, монда 6 гаилә—Шамасыр, Умарча Асанов, Сболга Урманчин, Анагузя Малков, Еманок һәм Аликей (рус документларында шулай бирелгән) яши. Шунысын әйтергә кирәк, Шәмәсир—Казан яулап алынганнан соң татарныкы булып калган бердәнбер авыл («жили ... татаровя на льготе»). 1621 елда йортлар саны 26 га, XVII гасыр уртасында 29 га, яшәүчеләр саны 87 гә җитә, чәчүлек җире 219 дисәтинә була.

Казаннан көнчыгыш яктагы Арча кыры артында тирән чокырлы җирләр җәелеп яткан. Бу урында елга-күлләр һәм чишмә-инешләр юклыктан, яшәү өчен шартлар җитәрлек булмаган. Дошман гаскәрләре дә Казанга шушы яктан торып һөҗүм иткәннәр бит. Шунлыктан, шәһәрдән көнчыгыш юнәлештә без торак пунктлар күрмибез диярлек. Дөрес, хәзерге Горький исемендәге парк урынында Подсеки (Подсекино) исемле авыл булган. Элек хан биләмәсе булган бу авыл, рус чоры башлангач, кенәз Данил исемле феодалга бирелә. Авылда 7 крестьян хуҗалыгы була, монда яшәгән кешеләр исемнәре (Гришка Балахонец, Бориско Углечении һ. б.) аларның рус шәһәрләре Балахнадан, Угличтан икәнлекләрен күрсәтә. Авыл кешеләре арасында тире эшкәртүчеләр дә (Васька Кожевник) булган. Авыл халкы төзелеш өчен агач материалны Киндер урманыннан чыгарган. 1586 елда Подсеки авылы Спас-Преображен монастырена кушыла. 1646 елда авылда монастырьның хайван тоту хуҗалыгы булган, шушы йортта карт-корылар, ат караучылар, ялланып эшләүчеләр, аш пешерүче, су ташучы һ.б. яшәгән.

Казансу елгасының төньяк яр буйларында (хәзерге Мәскәү районы) ханлык чорындагы торак пунктлар турында чыганакларда хәбәрләр юк. Монда киң болыннар, куе кара урманнар һәм сазламыклар булган. Казанның соңгы саклаучылары, Казансудан төньякка таба дошманнан башта «киң болын аркылы атлар үтә алмый торган олы сазлыкка, ә аннан соң зур урманга таба» чигенәләр. Без бу җирләрдә, ягъни хәзерге Мәскәү, Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнары территориясендә ханлык чорында торак пунктлар булуына шикләнмибез. Безнең эрага кадәр VI-V гасырларда ук Казансу елгасының уңъяк яр буйларында кешеләр яшәвен археолог галимнәр исбатлады инде.

Галич юлында, Казаннан 11 чакрымда Кадыш авылы булган. Авылның атамасы кеше исеменнән булырга тиеш. 1549 елның 29 июлендә Казан феодаллары Кадыш Яушев һәм Чура Нарыков, Сафагәрәй ханга хыянәт итеп, рус патшасы Иван IV дән шәһәр өстенә яу җибәрүен сорыйлар. Казан ханы аларны җәзалап үтерергә әмер бирә. Ханлыкны яклап көрәшкән икенче бер Кадышны 1552 елда Шаһгали үтертә. Хан биләмәсе булган бу авыл, рус чорына кергәч, П. А. Булгаков исемле феодал кулына күчә. Авылда 6 өй, Солоница елгасында тегермән булган. Кадыш авылы янында, Казансу һәм Солоница елгалары арасында Выгор һәм Макаровское исемле бушап калган авыл урыннары булган. 1617 елда авылда 26, 1646 елда 41 йорт барлыгы документларда күрсәтелә.

Казан тирәсендә авыллар саны арту рус яулап алулары белән бәйләнгән. Ундырышлы туфраклы, гаҗәеп матур бу урыннарга рус дәүләтенең 40 тан артык төбәгеннән кешеләр агыла. Монда «йомышлылар» гына түгел, крестьяннар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, качкыннар һ. б. да килә. Татарлар яшәгән урыннарыннан куып җибәрелә, кайсылары үзләре кача—алар урынын рус колонизаторлары ала. Татар авылларының бер өлешенең атамалары гына сакланып кала.

Авыллар санын арттыруда барыннан да бигрәк монастырьлар (Спасо-Преображен, Троица-Сергий, Воскресен) тырыша. Иван Грозный православие руханиларына яңа җирләрне кызганмыйча өләшә, чөнки тегеләре дә патшага ханлыкны яулап алуда зур хезмәт күрсәткәннәр. Шуның өстенә, буйсынган халыкны христианлаштырасы да бар бит әле.

Нугай юлындагы Өченче Кабан күле буенда, Казаннан 8 чакрым ераклыкта Борисково (Борисово, Давыдково) авылы урнашкан. Авылның атамасы христиан изгеләре Борис һәм Глеб хөрмәтенә төзелгән часовня исеменнән. 1603 елда авылда 11 крестьян хуҗалыгы була, алар Преображен монастырена бәйле булалар. XVI гасыр ахырында берничә гаилә, Борисководан аерылып чыгып, ике яңа торак пункт—Семибратенников һәм Харин исемле пүчинкәләр төзиләр. Әйтергә кирәк, бу торак пунктларның гомере озын булмый—сазлыклы җир аларга үсәргә мөмкинлек бирми—берничә дистә елдан бу авыллар юкка чыга.

Борисково авылы янындагы таулы-калкулыклы урында «Дунька куышы» дигән тау куышы булып, шунда патша Михаил Федорович чорында юлбасарлар качып яшәгән дип сөйли халык риваяте. 1860 елларда бу куышта идәнле һәм стеналары агачтан булган подвал табылган.

XVI гасыр азагында Нугай юлының Урта Кабан күле буенда, Колмөхәммәт авылы җирендә Шишкин пүчинкәсе барлыкка килгән. 1603 елда анда 12, 1654 елда 14 крестьян хуҗалыгы булган. Үләт эпидемиясеннән соң авыл яшәүдән туктый.

Казаннан 6 чакрымда, Урта Кабан күле ярында Воскресенское (элек Выползово дип йөртелгән) авылы барлыкка килә. Авылның атамасы чиркәү исеменнән. 1616 елда монда 10 хуҗалык булып, шуның берсе бобыль йорты була. Крестьяннар Царицыно авылында дәүләт җирендә эшлиләр, бобыльләр казнага акчалата оброк түлиләр. 1619 елда авылда 20, тагын ике елдан 23, XVII гасырның уртасына 26 йорт була. Воскресенское авылында Копорье шәһәреннән Казанга сөргенгә сөрелгән Семен һәм Мишка Копоренин гаиләләре яшәгән. Бу кешеләргә җир эшкәртү һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнү тыелган булган.

Шәһәрдән 4,5 чакрым ераклыктагы калку урында, 4 чакрымга җиткән чокыр буенда Горки дип аталган авыл урнашкан. 1678 елда митрополит биләмәсе булган бу авылда 15 хуҗалык теркәлгән.

Урта Кабан күле буенда Борисоглебское (Пләтән) авылы яшәп яткан. Борисоглебское—чиркәү исеменнән. Казан алынгач бу авыл һәм аңа терәлеп үк торган Поповка, Никифор Чепчугов исемле феодалга бирелгән, аннары, бик аз вакыт дәүләт җире булып торганнан соң, Спас монастыре биләмәсе булып китә. 1617 елда авылда 15, XVII гасырның беренче яртысында 127 йорт була (120 се бобыль хуҗалыгы), шунда 407 кеше яши. Авыл халкы җир эшкәртү белән шөгыльләнми, монастырь файдасына оброк түли. Борисоглебск кешеләре арасында руханилар, тире эшкәртүчеләр, балта осталары, бакчачылар, тегүчеләр, итекчеләр һ. б. һөнәр ияләре булган.

Казаннан биш ярым, Воскресенск авылыннан 2,5 чакрым ераклыкта Кокушкино (Кукушкино, «деревня Заднего поля») авылы урнашкан. И. А. Износков авыл атамасының бу урманлы урында кәккүкләр күп булуга бәйле дип язган. 1621 елда авылда 11, 1646 елда 13 хуҗалык булган, 52 кеше яшәгән.

Саңгырау (Глухое) күл буенда Казаннан 6,5 чакрымда Урта Атар (Ближние, Малые) авылына 1760 елларда Кокушкино авылыннан аерылып чыккан өч гаилә тарафыннан нигез салына. Бу авылга соңрак Царицыно авылыннан берничә гаилә килеп кушыла.

Шушы ук күл буенда Казаннан 11 чакрым ераклыкта Кече Арткы Атар (Меньшие Задние Атары) авылы яшәгән. 1567 елда авылдагы 3 крестьян хуҗалыгы Г. А. Булгаковка буйсынган. 1646 елда авылда 27 крестьян һәм 18 бобыль йорты саналган. Озын күл буендагы Урта Атар һәм Олы Атар авыллары турында алдарак әйтеп үткән идек.

Эчке (Ичка) Казан елгасы буенда Казаннан 8 чакрымда Нугай юлында Победилово авылы урнашкан. XVII гасыр уртасында халкының күпчелеге балык тоту кәсебе белән шөгыльләнгән бу авылда 28 крестьян, 8 бобыль хуҗалыгы булган, 93 кеше яшәгән.

Казаннан 4 чакрымда, Эчке Казан елгасы белән Источное исемле күл арасында, Пләтән авылы белән янәшәдә Поповка авылы урнашкан. 1621 елда Преображен монастыре биләмәсе булган бу авылда 19, 1646 елда 27 йорт саналган. 1751 елда авыл жирләре, Татар бистәсе кешеләре үтенече буенча, бистә составына кертелә, авыл халкы Урта Кабан яр буена күчереп утыртыла.

Нокса елгасы буенда Казан шәһәреннән 6 чакрымда урнашкан Вознесенск. Казан шәһәреннән 6 чакрымда урнашкан Вознесен авылының исеме чиркәү исеменнән. 1521 елда монда 19, 1646 елда 22 хуҗалык саналган, 77 кеше яшәгән.

Эчке Казан елгасы буенда 15 йорттан торган, Новый дип йөртелгән пүчинкә булган, Дәүләки авылы янында олы чокыр тирәсендә Морковка авылы, Югары Кабанда 15 өйле Новоселкино авылы яшәп яткан.

Казаннан 13 чакрымдагы, Елантау монастырена каршы якта, Казансу елгасы буенда Кызыл Тау (Красная Горка, Никольское) авылы урнашкан. Кызыл Тау рус документларында беренче тапкыр 1602 елда пүчинкә буларак телгә алына. Авылның исеме мондагы текә, балчыклы таудан алынган булса кирәк. Икенче атамасы чиркәү исеменнән. Кызыл Тауны митрополит төзеткән, авыл аның биләмәсе булган. Монда архиерей йорты булган дигән хәбәрләр дә бар. Авыл Иделнең элекке үзәне Воложкадан 1,5 чакрымда урнашкан. XVII гасыр уртасында монда 24 крестьян, 2 бобыль хуҗалыгы исәпкә алынган. 1678 елда Никольское-Красногорское авылында 8 крестьян һәм 9 бобыль йорты булып, шунда 17 кеше яшәгән.

1602-03 елдагы рус документлары Казансу елгасы буенда, Алат юлында Овинища (Отвинища, Кузьминское) исемле, бер бояр йорты, 5 крестьян өе торган авылны телгә алалар. Егерме елдан соң анда Иван Афанасьев исемле бояр хуҗалыгы һәм 1 крестьян өе генә калган. Рус теркәү кенәгәләре авылда йортлар санының кимүен һәм, гомумән, Овинищаның бетүен Жангали ихтилалы белән бәйләп күрсәтәләр. 1646 елда авыл урыны бушап кала.

Казансу елгасы буенда, шәһәрдән 7 чакрым ераклыкта Савиново авылы урнашкан. И. А. Износков авылның атамасын Казан ханы Сафагәрәй исеме белән бәйли. Әмма 1565—1568 елгы документларда бу исемдәге авыл телгә алынмый. Бары тик 1603 елда авылда 11 крестьян хуҗалыгы булып, шуның берсе буш торганлыгы билгеле. 1623 елда авылда йортлар саны үзгәрми. Казансу елгасына ага торган инештә тегермән булса да, буасы юклыктан ул эшләмәгән. Тагын утыз ел вакыт үткәч тә Савиновода хуҗалыклар саны артмаган, ә 1670 елларга монда 2 крестьян, 11 бобыль йорты саналган, ике хуҗалыкта тегермәнчеләр, тугызында тегермәнче ярдәмчеләре яшәгән. Савиново авылы архиерей биләмәсе булып китә, монда Казан митрополиты Вениамин торган. Бу авылдан ерак түгел, Казан һәм Зөя митрополиты Корнилий биләмәсенә кергән 45 дисәтинә чәчүлек жире булган Круглая исемле авыл яшәп яткан.

Нокса елгасына койган Коры елгачыгы (Сухая речка) яр битендә Казаннан 11 чакрымда Коры елга авылы (Сухая река, Сухоречная) урнашкан. Халык риваятендә Алат юлындагы бу авылга Казан воеводасы Мамотин нигез салган дип сөйләнә. Арестантларны башка өлкәләргә озату белән шөгыльләнгән Мамотин, алар арасыннан иң тазаларын сайлап алып, Казан тирәсендәге авылларга тарата торган булган, ә түрәләргә «арестантлар юлда барганда качканнар» дип аңлаткан. 1616 елда авылда 16, 1646 елда 44 хуҗалык (1 монастырь өе, тегермән өе, поп өе, пономарь өе, 31 крестьян һәм 6 бобыль йорты) саналган, монда 126 кеше яшәгән, 384 дисәтинә чәчүлек жир булган.

Коры елга буенда 1600 елда исеме чиркәүгә бәйле Борисоглебское авылына нигез салына. Ул Казаннан 8 чакрым ераклыкта урнашкан. Уңдырышлы жирләргә һәм урманга бай бу авылда 1616 елда ук 23 йорт булып, 1646 елда алар саны 35 кә житә.

Казаннан 13 чакрымда, Киндер авылының басу очында, Казансуның уңъяк яр битендә Щербаков авылы урнашкан. Авылның атамасы русның щерба—уха (балык шулпасы) дигән сүзеннән. Монда озынлыгы 1 чакрым, киңлеге 60-140 метрлы Щербаков күле бар. Ул Казансу елгасына тоташкан, урта гасырларда монда тегермән торган. 1646 елда авылда 11 крестьян, 2 бобыль хуҗалыгы булган, 41 кеше яшәгән. 1670 нче елларда Елантау монастыре биләмәсе булган Щербаков авылы бушап калган, моның сәбәпчесе—үлат эпидемиясе. Исән калган өч крестьян хуҗалыгы Киндер

авылына бирелә.

Кремльнең Воскресен капкасына каршы Комаровка елгасы ярында Комаровка авылы яшәп яткан. Монда бер генә йорт—митрополитның ат хуҗалыгы гына булган, шунда митрополитның ат караучылары һәм башка хезмәтчеләре яшәгән.

Казаннан 6 чакрым җирдә, Нокса елгасының ике яры буенда, Царицыно (Богородское) авылы (хәзерге Азино) урнашкан. 1566 елда авыл кенәз С. Д. Засекинның биләмәсе була, 1567 елда ул Д. В. Ушатый исемле кенәзгә күчә. Царицынода 8 йорт булган, шулар арасыннан Ермолка Мельник (тегерманче) һәм Васька Коломнетин (Коломнадан) яшәгән. 1593 елда авылның хуҗасы булып Андрей Плещеев тора, Царицыно шул ук елда Троицк-Зөя монастырена биләмә итеп бирелгән. 1616 елда авылда Николай Чудотворец чиркәве, 2 рухани йорты, 38 крестьян һәм 8 бобыль хуҗалыгы саналган, 4 өй буш торган. XVII гасыр уртасына авылда 72 йорт булганлыгы (50 се крестьян) билгеле. Царицыно авылы янында ук 8 йортлы (1621 елда) Кузнецы авылы да урнашкан булган.

Дүртөйле елгасы буендагы Коры чокырда (Сухой овраг) Константиновка урнашкан. 1621 елда авылда 13, 1646 елда 21 хуҗалык булган. Дүртөйле елгасының югары агымындагы Камышлы аланыннан авыл халкы печән чаба торган булган.

Арча юлында, Казаннан 10 чакрым ераклыкта, Киндер елгасы буенда Әки (Аки) авылы урнашкан. И.А.Износков авылның атамасын ак (белый) дигән сүздән дип фаразлый. Әки авылы урам юлларына җәю өчен кулланыла торган ак ташлы тау янында утырган. XIX гасыр чиркәве торган тау битендә Казан яулап алынганга хәтле, татар зираты булган дигән хәбәрләр бар. 1621 елда авылда 15, 1646 елда 24 хуҗалык, 76 кеше көн күргән.

Нокса елгасыннан Җөри юлы юнәлешендә Клык исемле ике авыл урнашкан: берсе, «сельцо Клык» дип аталганы (хәзерге Олы Клык), Казаннан 7 чакрымда, икенчесе, Кече Клык (хәзерге Малые Клыки). 1567 елда Олы Клык авылында 2 монастырь йорты, ә 1621 елда 30, 1646 елда 41 крестьян һәм бобыль хуҗалыгы саналган. Кече Клык авылында 1565 елда 6 йорт булып, анда крестьяннар һәм әсирләр яшәгән. 1621 елда йортлар саны 40 ка җиткән. XVII гасыр башында бу авыллар күршесендә Решетников авылы пәйда була, монда 1621 елда 12 йорт булганы билгеле. Шулай ук ул тирәдә Черемхин һәм Некрасов пүчинкәләре дә барлыкка килгән. Некрасов пүчинкәсендә Некраско Кузьмин исемле крестьян гомер иткән. Монда XVII гасыр урталарында 10 йортта 35 кеше яшәгән. 1646 елда Черемхинда 13 крестьян һәм 3 бобыль хуҗалыгы саналган. Олы һәм Кече Клык, Самосырово авыллары Спас-Преображен монастыре биләмәләре булып торганнар.

Рус хөкүмәтенең Казанны яулап алганнан соң үткәргән колониаль сәясәтенең төп юнәлеше—бушап калган күп санлы тирә-як авылларга тиз арада христиан халкын күчереп утырту була. Уңдырышлы, әкияттәгедәй бай җирләргә беренче нәүбәттә рус алпавытлары һәм крестьяннары килә. Патша әмере белән Казанга һәм аның авылларына нинди дер җинаятьләре өчен хөкем итеп сөрелүчеләр дә җибәрелә. Шулай итеп, Казан шәһәре тирәсендә татар авыллары калмый диярлек, мондагы җирле халыкның йорт-мөлкәте җиңүчеләр кулына күчә. Ханлык чорындагы татар авыллары яшәүдән туктый, аның урынына рус авыллары барлыкка килә, кайсыбер очракта гына торак пунктның татар исемнәре сакланып кала.

Бүген Казан мегаполисы территориясен тәшкил итүдә зур өлеш керткән илледән артык авылның күпчелеге ханлык чорында ук яшәгән, тик XVI-XVII гасырларда алып барылган колонияләштерү сәясәте шәһәрнең этнотопографик манзарасын танымаслык итеп үзгәрткән.

**Ринат СОЛТАНОВ,**
*тарих фәннәре кандидаты*

# ГАСПРАЛЫ МИРАСЫ КАЙТА

Төрки дөньяда исеме һәм идеаллары киң билгеле булса да, Исмәгыйль Гаспралының үз әсәрләрен (әдәби, иҗтимагый, сәяси) бүгенге көнгә кадәр кулына тотып бик сирәк кешенең укыганы бар. Үзгәртеп кору чорының шифалы җилләре безгә мәшһүр мәгърифәтче, барлык төрки халыкларның рухи лидеры Исмәгыйль Гаспралының исемен кайтарса да, ягъни әдәби-мәдәни мирасы, һаман да китапханәләрдә, «Тәрҗеман» һәм башка газета-журнал битләрендә кала бирә.

Менә, ниһаять, бу хәл дә төзәтелә башлады: 2005 елда Истанбулда «Өтүкән» нәшриятында Гаспралының «Сайланма әсәрләре» басылып чыгып, кулыбызга килеп иреште. Хезмәтне нәшриятка Измир шәһәрендәге Эгей университеты профессоры Явуз Акпынар хәзерләгән, әдәби текстларны латин әлифбасына күчерү эшенә Байрам Орак, Назым Мурадов, Айшән Услу Байрамлы өлеш керткән.




Олуг мәгърифәтченең мирасы өч саллы китапка бүленгән: беренчесенә Гаспралының әдәби әсәрләре, роман һәм хикәяләре кергән, икенче том «Фикри әсәрләре» дип атала, ягъни публицистикасы, өченче томга «Тәрҗеман»да чыккан язмалары сайлап алыначак (әле басылып чыкмаган). Явуз Акпынар тарафыннан һәр ике томга җитди кереш мәкаләләр язылып, Гаспралының тормыш юлына, иҗтимагый-сәяси, әдәби, публицистик эшчәнлегенә шактый тулы анализ ясалган. Гаспралы мирасының шундый хәзерлекле һәм җитди галим тарафыннан нәшер ителүе бик куандыра: Явуз бәй Акпынар—төрек һәм Россиядә яшәгән төрки халыкларның мәдәни байлыгын тирәннән белүче әдәбият тарихчысы булу белән бергә, вак детальләргә дә игътибар итеп эшли торган текстолог та. Аның белән очрашкан вакытыбызда Я. Акпынарның татар әдәбиятын, аеруча классик чорын, бар нечкәлекләре белән белүенә, ятатуына сокландым.

Әлеге хезмәт өстендә эшләгәндә, галим Бакчасарай, Казан, Истанбул китапханәләрендә саклана торган «Тәрҗеман», «Сыйрател-мөстәкыйм» һәм тагын бик күп газета-журнал төпләмәләрен, китапларны тикшереп чыгу белән генә чикләнмичә, алар арасындагы аермаларны таба, төрле текстологик ачышлар ясый, моңа кадәр азмы-күпме билгеле булган фактларны, даталарны төзәтә. Мәсәлән, «Тәрҗеман» газетасының Рәсәй төркиләре өчен чыккан саннары белән Төркиядәге укучылары өчен хәзерләнгән саннары арасында шактый аермаларны табып күрсәтә, Гаспралының үз әдәби әсәрләре өстендә даими эшләп, үзгәртеп торуын текстлар мисалында дәлилли. Шунысы сөенечле, Гаспралы мирасы өстендә эш алга таба тагын да кинрәк планда дәвам итәчәк, чөнки Явуз бәй «Сайланма әсәрләргә» язган мәкаләләрендә үз алдына тагын да зуррак максатлар куя, эзләп табасы әсәрләрен, мәкаләләрен күрсәтә, Исмәгыйль бәкнең биографиясендәге «ак тап»ларны билгели, аның язмаларының тулы «көллиятен» (җыентыгын) хәзерләргә өметләнә. Аңа бу изге эшендә уңышлар телибез.

Беренче том, шулай итеп, Гаспралыны әдип, роман һәм хикәяләр авторы буларак тәкъдир итә: анда «Франгистан мәктүпләре», «Дарер-рәхәт мөселманнары», «Судан мәктүпләре», «Хатыннар өлкәсе», «Мулла Габбас Франсәвигә тәсадеф: Гөл Баба зиярәте», «Арслан кыз», «Көн тугды», «Әхмәт бәй Ташкентлы һәм Бедрос ага

Каракашйан», «Иван вә Сөләйман», «Бәлаи ислам» исемле әсәрләре бирелгән. Төрки әдәбиятлар тарихын мона каләр Исмәгыйль Гаспралы дигән язучыдан башка күзаллавыбыз, язуыбыз һәм өйрәтүебез хәзер хәйранга калдыра, чөнки мәгърифәтчелек, җәдитчелек хәрәкәтенең башында торган Исмәгыйль Гаспралы, әдәбиятта мәгърифәтчелек реализмы методына нигез салучыларның берсе булып, аның хикәяләре һәм романнары урта гасырчылыктан арынып килүче төрки халыклар әдәбиятына, һичшиксез, көчле тәэсир ясаган. Гаспралы әсәрләренең таралу регионы, башка язучылар белән чагыштырганда, гаять киң булган: башта «Тәрҗеман» газетасында чыгарып, соңрак аерым китаплар итеп бастырып, ул үз әсәрләрен киң катлау укучыга җиткерә алган. Шуңа күрә төрки телле башка язучылар аның әсәрләрен үрнәк итеп алып, оригиналь иҗатка омтылганнар. Әйтик, Риза Фәхретдинов иҗатына, аеруча аның әдәби әсәрләре «Сәлимә яки Гыйффәт» белән «Әсма яки Гамәл вә җәза»га Гаспралының «Франгистан мәктүпләре» белән башланып киткән Мулла Габбас мажараларының тәэсире куәтле булуын Җәмал Вәлиди 1915 елда ук «Ан» журналында язып чыга. Исмәгыйль Гаспралы әсәрләренең язылу вакытына игътибар иткәндә, чыннан да төрки халыкларның мәгърифәтчелек // әдәбиятының (аеруча прозасының) юл башында аның әсәрләре торганлыгы күренә. Хәер, XX гасырның унынчы елларында татар әдәбияты тарихын язу юнәлешендә ясалган беренче адымнарда (әйтик, шул ук Җәмалетдин Вәлидовның «Әдәби хәрәкәт» (Ан, 1915) исемле күләмле мәкаләсе) Гаспралының әдәби иҗатына тиешле бәя бирелә башлый, ләкин совет чорында аның исеме һәм әсәрләре, ни аяныч, безнең әдәбият өчен инде «ят» була.

«Франгистан мәктүпләре», «Судан мәктүпләре», «Хатыннар өлкәсе» һ. б. исемнәр астында басылган парчалары белән бергә тупланып «Дарер-рәхәт мөселманнары» исемендәге тулы бер романны хасил итә, чөнки аларның барысында да баш герой «Ташкентлы татар» Мулла Габбас булып, сюжет корылмасын аның сәяхәтләре тәшкил итә. Әсәр көчле романтизм һәм экзотикага корылган.

Язучы ислам галәмендәге фикердәшләренең игътибарын Көнбатыш Аурупа дәүләтләренең икътисади-иҗтимагый мәсьәләләрдә, мөселманнар белән чагыштырганда, нык алга китүенә юнәлтә. Гаспралы халыкның наданлыгын бетерү юлларын фән-техника прогрессына нигезләнгән мәгарифтә күрә, әмма, шул ук вакытта, бу хәлнең дини мәгънәвияткә, иманга зыян китерергә тиеш түгеллеген дә искәртә. Гасырлар буе үз гыйлеме белән бар дөньяны гаҗәпләндергән ислам дәүләтләренең артта калуын ул дини клерикализмда, мөселманнарның акылын буып-бозып торган «иҗтиһад мөнкарыйз» идеясенең чагылышында күрә. «Мәктүпләрен»дә аурупалыларның мәдәният, мәгариф системасы, хокук-канунннары, үзара ярдәмләшү кебек алга киткән өлкәләре үрнәк итеп алына.

Әдип, үзенең мәгърифәтчелек карашларын аңлату өчен, ул чорда дөнья әдәбиятында аерым бер традициягә әверелгән юлъязма алымын куллана. Кайвакыт артык гади, беркатлы, әмма шул ук вакытта эчкерсез һәм саф булуы белән кешеләрне үзенә тартып торган татар егете Мулла Габбасның Франциягә, Испаниягә, Африкага сәяхәтләре аркылы аның рухи яктан үсеше, дөньяга карашының киңәюе, тәҗрибә туплавы күрсәтелә. Сәяхәтенең соңгы ноктасы: Мулла Габбасның изге урыннарны зиярәт итеп йөреп, үзе өчен (һәм, әлбәттә, укучылар өчен) Дарер-рәхәт илен ачуы бик тә мәгънәле. Романның беренче өлешләре, «Франгистан мәктүпләре» хатын-кыз темасына багышланган булып, Мулла Габбасның француз кызлары Жозефина, соңыннан Маргарита белән булган мөнәсәбәтләре аша ачыла. Жозефинаның сылулыгы һәм тугрылыгы егетне үзенә җәлеп итсә, Маргаританың тирән акылы һәм көчле характерына гашыйк була. Мулла Габбас аларга карата гаять игътибарлы, мөселман Көнчыгышы халыкларына хас булганча, галант, әйтик, үзен нахакка гаепләгәч тә, ул кызның яман исемен-данын чыгармас өчен, хәтта үлем җәзасыннан да курыкмый. Гаспралының хатын-кыз идеалы «Дарер-рәхәт мөселманнары» әсәрендә формалашып бетә: җир асты юлыннан бәхет-сәгадәт иленә Мулла Габбасны Фәридә Бану җитәкчелегендә 12 гүзәл кыз алып чыга. Бу кызлар, аеруча

Фәридә Бану, Жозефина белән Маргаритадагы гүзәл тарафларны гына алып калмыйча, тагын чын мөселман кызларына хас булган тыйнаклык, сабырлык һәм сафлык, бирелгәнлек һәм зирәклек кебек матур характер сыйфатларына ия. Шуңа күрә автор нәкъ менә Фәридә Бану авызыннан гарәп хәлифәлегенең куәтле чорларын һәм җимерелү тарихын бәян иттереп, прогрессның кешеләрдәге югары рухи сыйфатлардан һәм омтылышлардан башка була алмавын әйтә.

Әлеге романда күтәрелгән төп тема, әлбәттә, төрки мөселман халыкларының тормышы, Аурупа милләтләреннән нык артка калуның сәбәпләре һәм прогресска омтылыш. «Дарер-рәхәт» утопиягә корылган. Монда Гаспралыга антик әдәбиятның, Аурупа әдәбиятындагы Т. Мор, Г. Уэльс әсәрләренең йогынтысы сизелә. Әндәлүсиядә 500 ел буена буш торган Әл-Хамра сараенда йөргәндә Мулла Габбас мөселман кызлары белән күрешә һәм алар аны «Дарес-сәгадәт»кә (Бәхет иленә) алып китәләр. Бу мәмләкәттә гаделлек, әдәп, культура өстенлек итә, шуңа күрә халык саны 300 мең булган, 40 зур авыл һәм бер шәһәрдән торган илдә яшәү бик рәхәт: гүзәл тирә-як, чисталык, муллык, алга киткән фән һәм техника... Бу әсәрдәге төп фикерләрнең берсе—аурупалылардан аерым, изоляциядә яшәгән хәлдә дә, мөселманнар тәрәккыятьтән артта калмаганнар: алар трамвай, телефон, электр уты, бушлай почта хезмәте, банк системасы, инкубатор, икмәк пешерү заводлары кебек цивилизация казанышларын үзләре уйлап тапканнар дип күрсәтелә. Чөнки дөньяви мәктәпләр, янача уку-укыту методлары кеше акылына ирек, яңа идеяләргә җирлек тудыра, бары тик яңалыкка мөмкинлек бирелгәндә генә җәмгыять алга таба үсә ала, диелә. Шулай да Мулла Габбас бу бәхет илендә калмыйча, реаль дөньяга, үз ватанына кире кайта, чөнки ул бәхетне бары тик үзе өчен генә түгел, милләттәшләре, диндәшләре өчен дә эзли. Бу геройдагы милли тойгылар, иҗтимагый максатлар алга таба «Көн тугды» романындагы Даниял образында тагын да тулырак ачыла. Исмәгыйль Гаспралының үз әдәби әсәрләрендәге прототибын әдәбият тәнкыйтьчеләре нәкъ менә шушы геройда табалар да инде.

Беренче томда бирелгән хикәяләр арасында «Иван вә Сөләйман» (1897) әсәренә махсус тукталасы килә. Чын мәгърифәтчелек рухында язылган бу хикәядә Гаспралы бер үк авылда, бер үк шартларда житешкән татар һәм рус малайларының язмышын күрсәтә. Иванның әнисе Мария һәм Сөләйманның әнисе Хәлимә балаларына бары тик игелек, тәүфыйк-бәхет кенә телиләр, аларның киләчәгенә зур өметләр баглыйлар. Әмма баласына белем бирү, кәсеп өйрәтү мәсьәләсендә татар хатынының куркаклыгы, хәлиткеч вакытта тиешле карарны бирә алмавы аркасында, Сөләйман авылында торып кала һәм ачлы-туклы тормышка дучар ителә, ә Иван исә Мисыр тарафларында сәүдә эшенә өйрәнә, гарәп һәм французча сөйләшеп, дөнья гизә, сәүдә итә...

«Әхмәт бәй Ташкентлы вә Бедрос ага Каракашйан» хикәясе дә, нигездә, шул ук теманы дәвам иттерә: кайчандыр мул тормышта яшәгән төрки мөселман Әхмәт бәй гаиләсе, аеруча улы Җәват бәй, наданлык, ялкаулык һәм кыюсызлык аркасында, әсәр азагында үзләрендә кайчандыр хезмәтче булып торган әрмән Бедрос ага ярдәменә мохтаҗ хәлгә төшә. Бедрос ага яшь вакытта укымышлы бай кызы Мәрьямгә өйләнә, бу гаиләдә туган балаларга заманча тәрбия һәм югары белем бирү өчен бөтен шартлар булдырыла. Ахырда Бедрос ага һәм аның уллары ефәк һәм мамык сәүдәсе белән шөгыльләнеп, баеп китә. Ул чорларда әрмәннәр һәм төрки халыклар арасындагы вәзгыятьнең гаять кискен булуын искә алганда, үрнәк герой итеп нәкъ менә әрмән милләте вәкилен алып тасвирлавы, Исмәгыйль бәкнең, вак милли мәнфәгатьләрне кире кагып, интернациональ позициядә нык торуын күрсәтә.

Гаспралы дөньяга үзенең фәлсәфи, иҗтимагый, гуманистик карашлары белән танылды. Төрле милләт, дин һәм культура әһелләренең үзара аңлашып, хезмәттәшлек итеп яшәү мөмкинлекләрен эзләде. Россия хөкүмәтендә мөселманнарга, Көнчыгыш халыкларына кимсетеп карау сәясәтенең тамырдан дөрес булмавын, рус халкының башка халыкларны изү хисабына алга китә алмаячагын дәлилләп язылган хезмәтләренең әһәмияте бүген дә югалмаган. Аның

«Сайланма әсәрләр»енең II томын әлеге төр публицистик язмалары тәшкил итә. Монда китап хәлендә басылып чыккан кайбер әсәрләре белән берррәттән, «Тәрҗеман»да нәшер ителгән язмалары тупланган. Әлбәттә, Гаспралының Россия мөселманнары тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларга, иҗтимагый-сәяси, мәдәни проблемаларына кагылышлы язмалары бер томга гына сыеп бетәрлек түгел, шуңа күрә китапны төзүчеләр Исмәгыйль бәкнең өч темага караган хезмәтләренә басым ясап, «Россия һәм Аурупа белән элемтәләр», «Россия төркиләренең-мөселманнарының модернлашу проблемалары», «Россия һәм дөнья мөселманнарының съездлары» дип аталган бүлекләр аерганнар. Беренче бүлектә рус телендә басылып чыккан «Бакчасарай мәктүпләре», «Рәсәй мөселманнары», «Рус-Көнчыгыш анлашмасы» әсәрләренең тәрҗемәләре, «Шәркый Әкбәр мәсьәләсе», «Аурупа мәдәниятенә бер нәзари мөвазәнә», «Социализм яки мәзһәбе иштирәкийүн», «Мәзһәбе иштирәкийүн», «Русиянең сәясәте исламиясе» исемле хезмәтләре урын алган. Бу әсәрләрне укыганда, Гаспралы карашларындагы эволюцияне күрү мөмкинлеге туа. Баштарак Россия империясе эчендә яшәгән төрки мөселманнарның мәнфәгатьләрен генә кайгырткан Исмәгыйль бәкнең соңга таба гарәп илләре, Һиндстан, Кытай регионнарын да үз эченә алган проектлар төзүе, дөнья мөселманнары конгрессы оештырырга кызыксынып йөрүе күренә.

Икенче бүлеккә «Русиядә матбугат вә нәшрияте исламия», «Мәбадие тәмәддең исламийани рус», «Кадимчелек—җәдидчелек», «Хатыннар», «Золым каян килә» исемле язмалары кертелгән. Исемнәреннән үк күренгәнчә, бу язмаларда Рәсәй халыкларының матбугат, мәгариф, дин, хатын-кызларга караш кебек өлкәләрдәге актуаль мәсьәләләре яктыртыла.

Өченче бүлектә «Заманыбыз мәсьәләләре», «Өченче Шураи өммәт», «Гомуми моэтәмәри ислами, ягъни Мөселманнар конгрессы», «Нәдвәи гомуми», «Мөселман конгрессы», «Тарихчаи заман» исемле мәкаләләре урын алган. Бу мәкаләләр тарихчылар, сәясәтчеләр, фәлсәфәчеләр өчен аеруча кызыклы булачак.

Без алга таба Гаспралы әсәрләренең Казан татар матбугатында да басылып чыгачагына өметләнәбез, чөнки моңа ихтыяҗ күптән туган иде инде.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА**

**Редакциядән:**
***Хөрмәтле авторыбызның бу мәкаләсе редакциябезгә тапшырылганнан соң «Исмәгыйль Гаспринский» исемендәге күләмле документаль-биографик җыентык (Казан, 2007) нәшер ителде.***

---

*Алхәбәр*

Рабит Батулла

## МУР КЫРЫЛЫШЫ

ФАҖИГА-ХРОНИКА

Күренекле әдипнең бу драматик әсәре укучыларыбыз өчен һичшиксез кызыклы бүләк булачак. Әсәрдә XIV гасыр вакыйгаларына, бигрәк тә татар тарихына авторның өр-яңа карашы ярылып ята. Биредә фантазия тарихи документальлек белән үрелгән.

*«Мур кырылышы» 10-11 саннарда басылачак.*

## Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ХУР КЫЗЛАРЫ, ХУРИЛАР*** – Гарәпчә *кара күзләләр* мәгънәсендәге сүздән. Аларны *хурелгаен* дип атау да бар ("матур кара күзле кызлар"). Оҗмах кызлары. Алар да, *гыйлманнар* (хур егетләре) кебек үк, нурдан яратылганнар (фәрештәләр дә нурдан яратылган). Хур кызы *нимфа, фея* мәгънәсенә дә ия.

Фәрештәләргә дүрт төрле: ак, яшел, сары һәм кызыл төсләр хас икән. Алар хиләл кашлы, кара күзле, гөл яңаклы, энҗе тешле, мәрҗан иренле, сәрви буйлы, назлы һәм татлы сүзле пакь кызлар. Аларның саны җитмеш мең. Мөселман риваятьләре буенча, тәкъва мөселманнар белән бергә җәннәттә яшиләр. Коръәндә (2:25) алар "пакь хатыннар" дип аталган, ягъни аларның бәдәни вә рухи кимчелекләре булмый. Аларга бер кеше дә, бер генә җен дә кагылмаган була. Әл-Бәйдави тәфсире буенча, җәннәт кешеләре барысы да 33 яшьтә. "Хәбәр" сүрәсенең 33 нче аятендә хур кызлары алар белән "бер яшьтәге" дип сыйфатлана. Җир йөзендә тәкъва тормыш алып барган хатыннар җәннәттә үз ирләре белән торачаклар. Соңгырак риваятьләргә караганда, хур кызлары үтәли күренәләр диярлек, хуш исләләр һәм һәркайсының күкрәгенә Аллаһы Тәгалә исеме һәм хур кызының үзенең хәләл иренең исеме язылган була. Коръәндә (55:72) хур кызларының чатырларда яшәве әйтелә. Алар "күркәм холыклы һәм гүзәл" ("Коръән тәфсире" буенча).

Коръәннең Мәккә сүрәләрендә хур кызлары турында сөйләнсә дә (22,55,56,70-72 сүрәләр), һиҗрәттән соңгы Мәдинә сүрәләрендә алар турында сүз әйтелми.

Суфичылыкта хур кызларына мөнәсәбәт башкача. Суфилар аларга Аллаһ белән кавышу юлында адаштыручы, матурлыклары белән алдаучы затлар дип карыйлар.

Христиан динендә исә "теге дөньяда" кешеләр өйләнмиләр һәм кияүгә чыкмыйлар, бәлки алла фәрештәләре кебек күкләрдә яшиләр дип исәпләнелә (Инҗилдән).

*//Хургаеннәр* – хур кызлары (кара күзләләр).

***ХУР-КЫЗЛАР*** *тар.* – Урта гасырларда Хәрәземдә үзләрен Аллаһка тапшырып, гыйффәтле килеш яшәргә сүз биргән суфия җәмгыятьләре булган. Халык ул пакизә кызларны *хур-кызлар* дип атаган.

***ХУТ СУЫГЫ*** – Казан арты, Әтнә якларында 25 гыйнвардан 6 мартка кадәр була торган салкыннар ("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969). *//Хут суыгы гыйнварның алтысы кала керә – мартның алтысы кала чыга. Хут суыгы кырык бер көн дәвам итә.*

Ләкин иң суык кырык көнлек вакытны (25 декабрь – 5 февраль) халык *кышкы чиллә* дип йөртә.

***ХУТОР*** *тар.* – XX гасыр башында, Столыпинның аграр реформасы барышында, крәстиәннәргә бүлеп бирелгән җир. Отрублардан аермалы буларак, хуторга крәстиан бөтен йорт-җире, утары белән күчеп утырган. Җирле администрация хутор хуҗаларына кредит биргән, дәүләт аларга авыл хуҗалыгы кораллары алуда булышкан. Шул заманнарда төзелгән таш йортларның калдыклары хәзер дә очрый әле. Картлар сүзенә

---

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

караганда, анда "стандарт бетон йортлар салына, түбәсе лайлы салам белән ябыла, идән-сайгаклар нараттан була, мичләре завод кирпеченнән эшләтелә. Һәркайсына тимер сабан, тимер зигзаг тырма, теләгәннәренә атлы чәчкеч, урак машиналары кайтарыла". Октябрь инкыйлабыннан соң хуторлар бетә, ләкин НЭП елларында кабат күренә башлый. Коллективлаштыру елларында алар тәмам юкка чыга. Дөрес, XX гасыр азагында авыл җирләрендә хуторларның торгызылуы да күзәтелә ("Башкортостан" энциклопедиясе).

***ҺАВАЛЫ ТУП*** *тар.* – Таш ата торган сугыш коралы. Кол Шәрифнең "Зафәрнамәи вилаяте Казан" дигән әсәрендә 1550 елның февралендә Казан каласын камап алган рус гаскәре кулында 11 "утлы туп" һәм 4-5 "һавалы туп" булганлыгы әйтелә. Соңгылары катапульта (мәнҗәникъ) кебек булган дип фараз итәргә мөмкин. Әлеге әсәрдә аңардан атылып чыккан зур таш "югарыда бер ноктага җитеп, асманда йөреп хәрәкәт куәте беткәч, соңра табигый рәвештә түбән төшәр иде, каза һәм тәкъдир угыннан тизрәк төшәр," – дип аңлатыла.

Тагын кара: ***УТЛЫ ТУП***

***ҺӘМ*** *ф.* – Вә, янә, да / дә. Кайчагында "белән" / "илә" теркәгече ярдәмендә бирелә. Шунысы кызык, Инҗилнең һәм Псалтирьның (Зәбур) керәшеннәр өчен нәшер ителгән татарчага тәрҗемәләрендә "һәм" теркәгече дә, "вә" (бусы гарәп теленнән) теркәгече дә очрамый. Шул ук вакытта дини текстларында шәрык сүзләре (терминнар) шактый (шөкер, пәйгамбәр, фәрештә, каза һ.б.).

***ҺӘПӘРБАЛӘ*** *г.* – Гипербола, мөбаләга. Бу сүзне, мәсәлән, Г.Газиз дә кулланган (1911) һәм аңа түбәндәге аңлатмасын да биргән: "Әдәбият истияхынча ифрат мөбаләгане әйтәләр. Юнан сүзе." ( Ягъни "Әдәбият терминологиясе буенча гадәттән тыш күпертүне әйтәләр".)

***ҺӘФТИЯК*** *г.* – Коръән-кәримнең кайбер сүрәләрен һәм аятьләрен эченә алган китап. Коръәннең 1/7 өлешен тәшкил итә. Аны электә дәреслек итеп кулланганнар. *Хәфтияк* һәм *һәфтеяк* язылышлары да очрый. Телдә *әфтияк* дип әйтү дә бар.

1800 елда Казанда Азиат типографиясе оештырылгач, 1801 елда анда беренче китап итеп Һәфтияк бастырып чыгарылган. Нәшире Габделгазиз Туктамыш улы Бурнашев, ә цензоры укытучы Ибраһим Хәлфин булган.

***ҺИҖРӘ, ҺИҖРӘТ*** *г.* – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең 622 елда Мәккә шәһәреннән Йасрибка (Мәдинә шәһәренә) сәфәре (күчеп килүе). Кара: *Һиҗрәт кичәсе.*

Мәккәдәге беренче мөселманнарның корәйшләр белән низаглашуы аркасында 615 елда вакытлыча Хәбәшстанга күчеп китүен дә *беренче һиҗрә* дип атыйлар.

***ҺИҖРИ ЕЛ ИСӘБЕ (СӘНӘИ ҺИҖРИЯ, ҺИҖРИ КАЛЕНДАРЬ)*** – Мөхәммәд Пәйгамбәр сәхабәләре белән бергә Мәккәдән Мәдинәгә күчеп киткән көннән башлап исәпләнә. Һиҗрәт, ягъни күчеп китү көне дип 622 елның 20 сентябре кабул ителгән. Мондый мөселман календаре Пәйгамбәрнең вафатыннан соң Гомәр ибн-Хәттаб хәлифәлек иткәндә 637 елның 16 апрелендә, рабигыль-әүвәл аенда рәсми рәвештә кертелгән (637-639 елларда урнашып җиткән).

Терлекчелек белән шөгыльләнгән борынгы гарәпләр Ай хәрәкәтенә нигезләнгән 354 көнлек ел хисабыннан элегрәк тә (мәҗүсилек заманнарында ук) файдаланып килгәннәр һәм үзләренең изге урыннары Мәккәгә хаҗ кылу да аларда Исламга кадәр үк булган.

Мөселманча ел шәмсия (Кояш) елыннан 10-12 көнгә кыскарак: Кояш календаре елы гади, ә Ай календаре елы кәбисә ел булганда аерма 10 көн, Кояш календаре елы һәм Ай календаре елы икесе дә гади яки икесе дә кәбисә ел булганда – 11 көн, Кояш календаре елы кәбисә ел булып, Ай календаре елы гади булганда исә аерма 12 көнгә җитә.

Ай календаре буенча яшәгәндә хаҗ вакыты елның төрле фасылларына туры килгән. "Һәм менә алар күршеләре яһүдиләрдән елга айлар өстәргә өйрәнгәннәр, бу хәл исә

һиҗрәткә кадәр ике йөз ел чамасы элек булган, — дип яза Бируни, — һәм алар айлар белән яһүдиләр эшләгән кебек эшли башлаганнар, ягъни үзләренең ае белән Кояш елы арасындагы вакыт аермасы бер айга тулгач, айларына шул артык вакытны өсти башлаганнар". Өстәмә ай *"наси"* дип аталган (*әйям әс-наси* — өстәмә көннәр). Бу инде асылда үзенә бер төрле Ай-Кояш календаре булган. Бируни сүзләренә карап фикер йөрткәндә, наси аен өч елга бер тапкыр өстәргә туры килгән булырга тиеш.

Бируниның "Мәсъгуд кануннары" дигән китабында борынгы гарәпләр кулланган ниндидер бер календарьдагы ай исемнәре санап күрсәтелә. Менә алар: *әл-Мутамир, Наҗир, Хавван, Суван, Хантам, Забба, әл-Асамм, Адиль, Нафик, Вагиль, Хува һәм Бурак.* Наҗир аеның исеме эсселек мәгънәсендәге сүздән килеп чыкканлыгына игътибар итсәк, бу айның җәйге чорга туры килгәнлеге аңлашыла, ә Ай календарендагы айлар ел фасылларына бәйле түгел. Моннан әлеге хисапның Ай-Кояш календаре булырга тиешлеге килеп чыга. Димәк ки, гарәпләрдә Ай-Кояш календареның тарихы шактый озын булган дип уйларга кирәк.

Гарәбстанда Ислам тамыр җәйгәч, 631 елда 13 нче айны өстәү тыелган. Коръәндә дә: "Аллаһ хозурындагы китапта айлар саны Ул күкләрне вә җирне яратканнан бирле унике... Өстәмә ай фәкать имансызлыкны гына өсти; кяфирләр монда хаталаналар; алар аны бер елны рөхсәт итеп, икенче елны тыялар, Аллаһ тыйган хисап белән яраштырырга тырышалар..." — диелгән (9:36-37; ләкин без бу өзекне тәрҗемә иткәндә Ногмани тәфсиреннән читкә китүне кирәк санадык, чөнки тәфсир мәгънәгә ачыклык кертми).

Мөхәммәднең сәхабәләреннән имам Җәгъфар әс-Садыйк әүвәлге 354 көнлек хисапның дөреслеген түбәндәгечә нигезләргә тырыша: "Аллаһы елны өч йөз алтмыш көнлек итеп яратды да күкне вә җирне хәлык иткән алты көнне аңардан чигерде, шуңа күрә хисапта ул көннәр юк", — дип аңлата имам.

Хәзерге мөселман календарендагы айларның исемнәре түбәндәгечә: мөхәррәм, сәфәр, рабигыль әүвәл, рабигыль ахир (яки рабигыль сани), җөмәдел әүвәл, җөмәдел ахир, рәҗәб, шәгъбән, рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә.

Бу исемнәрдә дә ел фасылларына ишарә аермачык күзгә ташлана: җөмәдел әүвәл һәм җөмәдел ахир айларының исеме туңу, бозлану сүзенә барып тоташа, рамазан сүзе исә эсселек мәгънәсендә. Кыскасы, бүгенге мөселман календарендагы ай исемнәрендә дә борынгы Ай-Кояш календареның эзләре сакланып калган икән (һиҗри ай исемнәренең мәгънәсе сүзлектә үз урынында биреп барылганга, аларга биредә тукталып тормыйбыз). Ләкин кабат Ай календарена кайтканнан соң, елның теге яки бу фасылын чагылдырган ай исемнәре үзләренең мәгънәсен җуйганнар.

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчүе гарәп дөньясы өчен бик әһәмиятле вакыйга булган һәм шуңа күрә һиҗрәттән соң һәр елга махсус исем биргәннәр. Беренче ел — "карар елы", икенче ел — "сугышырга әмер ителгән ел", өченчесе — "пакьләнү елы", дүртенчесе — "котлау елы", бишенчесе — "җир тетрәү елы", алтынчысы — "сорау елы", җиденчесе — "җиңү елы", сигезенчесе — "тигезлек елы", тугызынчысы — "баш тарту елы", унынчысы — "хушлашу елы" (соңгы — 632 елда Мөхәммәд Пәйгамбәр вафат булган).

Ай календареның характерлы үзенчәлеге аның бик төгәл булуында. Мәс., 30 еллык гарәп циклы дәвамында яңа Ай мизгеле 0,0118 тәүлеккә генә күчә, ягъни яңа Ай туу мизгеленең бер тәүлеккә алгарак күчүе өчен 2542 ай елы кирәк.

Күпчелек мөселман илләрендә кабул ителгән классик һиҗри календарьда так номерлы айлар 30 көннән, җөп номерлылары 29 көннән тора. Ләкин кәбисә елларда зөлхиҗҗә аена бер көн өстәлә, ә кәбисә елларның чиратлашу тәртибе шактый катлаулы (бу мәсьәлә *гарәп системасы* һәм *төрек системасы* дигән аерым мәкаләләрдә аңлатылды).

Бу календарьның уңайсыз ягы бар, ул табигать сезоннары, ел фасыллары белән берничек тә бәйләнмәгән.

Мәгълүм булганча, һәр 33,5 Ай елы дәвамында бер Кояш елы "югала" (33,58503 Ай елы 32,58503 Кояш елына тигез). 17 ел үткән саен камәри ай (мөхәррәм, сәфәр h.б.) ел фасылларында нәкъ капма-каршы урынга күчә. Мәс., әгәр рәҗәб ае билгеле бер елда язга туры килгән икән, 17 елдан соң ул көзгә күчкән була. Дини йолаларны тиешле вакытында үтәүгә мондый хисап комачауламый, ләкин, әйтик, игенчелек эшләре өчен Кояш хисабы кулай. Мөселман илләрендә табигать күренешләре, ел фасыллары белән турыдан-туры бәйле дөньяви тормышта, мәсәлән дәүләтнең финанс-хуҗалык эшләрендә, 33,5 ел саен бер "сәер" нәрсә кабатлануын күреп алганнар: бу елны чыгымнар

һәрвакыттагыча була, ә килер-табыш булмый, чөнки иген уңышы 32 тапкыр гына җыеп алына. Беренче тапкыр бу хәл Габбасилар хакимлек иткән чорда (казна саеккан чакта) сизелә һәм хакимиятләрне дөньяви тормышта Кояш календарена таяну зарурлыгына ышандыра.

Йөз ел саен шушындый өч "артык" (килерсез) ел пәйда булуының уңайсызлыкларын Төркиягә дә кичерергә туры килә һәм анда һиҗри 1200 еллар тирәсендә (XVIII йөз ахырларында) башта чик буе тамгаханәләрендә, аннары әкренләп барлык дәүләт оешмаларында шәмсия (кояш) елы хисабын кертәләр, ләкин дини йолаларны үтәү тәртибен һәм мөхтәрәм көннәрне билгеләү өчен камәри (Ай) елы хисабы параллель рәвештә кулланыла.

XIX гасыр азакларында Төркиядә солтан хәзрәтләренең генерал-адъютанты *Әхмәд Шакир-паша* Мөхәммәд Пәйгамбәрнең туган вакытыннан башлап исәпләнә торган һәм кояш хәрәкәтенә нигезләнгән *мәүлид календаре* тәкъдим итеп карый, әмма уңышка ирешми.

Билгеле булганча көн дип кояш чыкканнан алып аның баюына кадәр үткән араны атыйлар. Борынгы Грециядә һәм Римда, Бабилда һәм Мисырда да ул шулай кабул ителгән. Ләкин төп вакыт берәмлеге сыйфатында камәри айлар кабул ителгән календарь системаларда тулы көн итеп бер кичтән (кояш баешыннан) алып икенче кичкә кадәр вакыт алынган (мәс., борынгы афиналылар, йәһүдиләр, германлылар). Борынгы Мисырда кулланылган календарь системасы исә күктәге айга бәйле булмаган һәм анда көн дип ике кояш чыгышы арасындагы вакытны кабул иткәннәр. Заратустрага табынучылар (зәрдәштләр) вакытны күктәге айга карап исәпләүне хата эш дип санаганнар. Алар көнне – ике кояш чыгышы арасындагы вакыт дип исәпләгәннәр. Борынгы римлыларда *цивиль көн* (гражданнар көне) төн уртасында башланган, ләкин шул ук вакытта аларда кояш чыкканда башлана торган *табигый көн* төшенчәсе дә булган.

Болгарларда, аннары татарда һиҗри ел исәбенә кадәр фарси кояш календаре (шәмсия елы) һәм 13 нче өстәмә ае булган ай-кояш календаре дә кулланылган. Өстәмә ай һәр 19 ел эчендә 7 тапкыр кертелгән.

Тагын кара: *ГРИГОРИЙ КАЛЕНДАРЕ, ЮЛИЙ КАЛЕНДАРЕ, УНИКЕ ЕЛЛЫК ХАЙВАН ЦИКЛЫ БУЕНЧА ЕЛ ХИСАБЫ, ШАКИР-ПАША.*

***ҺИЛЯЛЕ ӘХМӘР*** *г.* – Кызыл ай җәмгыяте (оешмасы). Кызыл хач җәмгыятенең мөселман илләрендәге рәсми атамасы.

***ҺИНДИ САННАР*** – Дөньяның күп илләрендә кулланыла торган цифрлар. Рус телендә, мәсәлән, аларны *гарәп цифрлары* дип атыйлар. Ләкин гарәпләр үзләре куллана торган цифр тамгалары аңардан нык аерыла. Гарәп язуында (һәм иске татар язуында) күп урынлы саннар уңнан сулга таба түгел, бәлки гадәттәгечә *сулдан уңга таба* укыла.

***ҺИРУГЛИФ*** – Иске татар әдәбиятында – иероглиф. "Иероглиф" сүзенең грек телендәге мәгънәсе – "изге язма". Төшенчәләрне, иҗекләрне һәм сөйләм авазларын аңлата торган фигуралы тамгалар системасы. Баштарак иероглиф сүзе Мисыр язмаларына гына кагылган, хәзерге вакытта гомумән рәсемле тамгалар белән фонетик тамгалар комбинациясеннән торган язмаларга карата әйтелә.

Геологиядә һәм палеонтологиядә тау токымнарында күзәтелә торган бормалы-сырмалы эзләрне дә иероглифлар дип атыйлар. Бу эзләрнең килеп чыгышы борынгы суалчаннар һәм моллюскларның тереклек эшчәнлеге белән аңлатыла. Мондый "иероглифлар" хәзерге вакытта да хасил булырга мөмкин. Мәс., кайчагында бал кәрәзләрендә очраклы рәвештә үзенчәлекле тамгалар барлыкка килеп, фанатиклар аларда изге сүзләр укырга тырышалар.

***ҺОМАЙ*** – Борынгы төркиләрдә өлкән алла. Һомай (Умай, Ымай, Омай, алтай телендә – Май) турындагы күзаллаулар Себер татарлары мифологиясендә сакланып калган. "Умай – асылда фарсылардан алынган "һумай кошы" образына кайтып кала." "Һумай кошы һавада йомырка салып, һавада бала чыгара дигән гыйбарә бар. Шуңа күрә ул авыр шартларда да бала табып үстерүче ана символы булып киткән." (Р.Әхмәтьянов.) Борынгы төрки рун язмаларында Һомай алиһә телгә алына, гадәттә

ул Тәңренең сөекле хатыны итеп күзаллана. Һомай турындагы күзаллаулар угызларда, телеутларда, шорларда, казакъларда, кыргызларда, төрекләрдә дә яшәп килгән. Бу аллага параллельләрне борынгы һинд язмаларында да табарга мөмкин. Ә кыпчакларда Һомай сабыйларга химая кылучы алиһә булып исәпләнгән, бу алиһәне кулына сабый тоткан кыяфәттә сурәтләгәннәр. *//Умайка тапынса, огул булыр*—берәү Умайга табынса, улы туар. "Диване лөгатет-төрк"

Әдәбиятта Һомайны "изге рух", "күкрәк балаларын саклаучы", "үлем фәрештәсе" дип аңлату да очрый.

**ҺОМАЙ КОШЫ**—Күләгәсе төшкән кешегә бәхет китерүче (патша булачагын белдерүче) әкияти кош, феникс. Шуңа күрә Иран патшаларын *Һумаюн*—"бәхет иңгән" дип тә атыйлар. Һиндстанны яулап алучы мәшһүр Бабурның улы тугач (һиҗри 913, миляди 1505 ел), аңа лаек исемне... хисаплау юлы белән тапканнар. Ул заманнарда исемдә туган елны күрсәтү гадәте булган. Шунда бер шагыйрь, әбҗәд кагыйдәләренә таянып, угылны *Солтан Һумаюнхан* дип атарга киңәш итә. Бу исемгә кергән хәрефләрнең әбҗәд буенча нинди саннарга туры килүен табып, шул саннарны кушсаң, 913 килеп чыга. Дөрес, икенче бер шагыйрь, шундый ук хисап юлы белән башка хәрефләр табып, угылга *Шаһ Фирүзкадер* исеме кушарга тәкъдим иткән (аның хәрефләре суммасы да әлеге 913 санын бирә), ләкин Бабурга беренче тәкъдим күбрәк ошаган.

*Һомай/һумай* сүзе "Төшлек"ләрдә дә очрый.

*//Китсә җәһан вилайәтене ташлап Һомай, Байгыш куләткәсенә кеше килмәке мөхаль (булмас хәл).* Сәйф Сараи. *Дәүләт һомае*—дәүләт кошы, ягъни дәүләтнең дәрәҗәле кешесе.

Рус телендә "һомай кошы"—*гамаюн*.

**ҺӨДҺӨД** *ф.*—*Сөләйман* патша белән аның мәгъшукасы *Билкыйс* арасында хәбәр йөрткән мифик кош, Коръәндә дә телгә алына. Һөдһөд кошын фарсыларда *мөрг Сөләйман* дип атыйлар. Билкыйснең һөдһөде җәннәткә керәчәк икән. Һөдһөдкә гарәпләр һәм греклар ихтирам белән караганнар, аның турында күпсанлы хикәятләр һәм мәсәлләр бар.

Һөдһөд—фарсы сүзе, ә борынгы төркидә һөдһөд кошы *үбүп* дип аталган (рус телендә—*удод*).

**ҺӨНӘР** *ф.*—Кул көче белән нинди дә булса эшләнмәләр ясау өчен махсус күнекмәләр таләп итә торган эш, кәсеп.

//"Һөнәр—фәкыйрьлектән саклый торган калкандыр."

"Адәм баласы нинди генә зур вә бай гаиләдән булмасын, никадәр генә зирәк булмасын, кулы белән бер эш эшләү, тир агызып мал табу һич тә гаеп түгел, бу эш аның дәрәҗәсен аз гына да төшермәс." Ризаэддин Фәхреддин.

**ҺУ, ҺУА** *г.*—Гарәп телендә "ул" мәгънәсендәге өченче зат алмашлыгы. Ялгызы гына килгәндә Алланы белдерә. *Аллаһ, Аллаһы, Аллаһу* сүзләрендә дә шушы алмашлык катнаша. Кайчагында бу сүзне *Аллаһу* дип тәрҗемә итәләр. Мәҗүси гарәпләр табынган *Һубәл* алланың исемендә дә шушы "һу" сүзе катнаша дигән фикер бар.

*//Хәмде әйтәм сиңа, раббым, шөкер, кыйлдың безне мөэмин, Яраттың дине Исламнан, хәмде әйтәм сиңа, йа һу.* "Раббыга мәдхия" мөнәҗәтеннән. *Һу-һу тийү һу кошы, агар күзендин яше, Көйеп эче һәм тышы, гафил торма, һу тигел—"һу-һу" дияр һу кошы, агар күзеннән яше, Көеп эче һәм тышы, белми торма, "Аллаһу" диген.* Кол Шәриф. *Һу кошы*—Аллаһка бирелгән кеше. *Һу сохбәтен кормак*-дәрвишләрнең күмәкләшеп "һу, һу" дип зикер әйтеп утырышуы ("һу зикере"). *Һу эррәсе*—зикре эррә (сулыш чыгарганда пычкы тавышы белән зикер кылу).

*Һу. Бил-гыйнаять раббилгаләмин*—Ул (*Алла*). Галәмнәр патшасының ярдәме илә. (Россиядәге илчелек приказы тәрҗемәчесе Көчекәй Сакаевның дусты Габдулла Байцинга язган хатының беренче сүзләре.) Гомумән "Һу" сүзе рус патшаларының грамоталарына да кергән.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ТАТАР ҖАНЛЫ РУС КЕШЕСЕ...

Милләте белән рус кешесе булган Александр Сергеевич Ключарев күпкырлы якты таланты белән музыкаль сәнгатебездә аерым бер урын алып тора. Гомере буе татар сәнгатенә хезмәт иткән композитор. Ул халык музыкасының бөресе булып халык көйләре торганлыгын тирәнтен анлаган, үзенен эшчәнлеген шушы байлыкны—халык җәүһәрләрен: җырларын, биютакмакларын, уен кораллары көйләрен җыеудан һәм аларны теркәүдән башлап җибәрә. Халык көе анын күңелендә, анын иҗатында яши, ул аны яна сәнгати үрнәкләр белән баета, җырга чын мәгънәсендә җан өрә.



Күп кенә халык көйләрен ул үз әсәрләрендә дә эшкәртеп куллана, башкаручы буларак кайберләрен пропагандалый. Үзенен сәнгатькәр дусларын—татар һәм башкорт композиторларын да бу олы эшкә чакыра һәм аларны халык җырлары белән тәэмин итә.

Татар дәүләт филармониясендә җыр һәм бию ансамбле оешкан көннәрдән алып А. Ключарев бай репертуар булдыруда иң актив эшләүче авторлардан булды. Репертуарын популяр халык җырлары эшкәртмәләре, массакүләм җырлар һәм заманча темага такмаклар, хореографик миниатюралар тәшкил иткән Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен күп әсәрләр языла. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленен барлыкка килүе, анын үсеше һәм яшәеше А. Ключарев исеме белән бәйләнгән.

Татар дәүләт филармониясе каршында хор студиясе оешкач, Зөләйха Әхмәтовага хормейстер вазыйфасын Александр Сергеевич тәкъдим итә һәм ансамбльнен төп яшәеш стиленә нигез салуга булыша.

1939 елда куелган «Сабантуй» вокаль-хореографик сюитасы, лаеклы уныш ка ирешеп, театральләштерелгән ансамбль программасынын нигезен тәшкил итә. Соңрак, әлеге сюитаның «Җырлыйммы?», « Мәрфуга җыры» , «Көрәш», «Яшьләр биюе» номерларыннан алты думбрадан торган ансамбль өчен «Сабантуй» концерт сюитасы туа. Әкренләп композиторнын халык материалы нигезендәге иҗат юнәлеше тәмам ачыклана һәм хор өчен эшкәртү төрләре билгеләнә. Еллар үткән саен композиторнын ару белмәс иҗаты хор сәнгате өлкәсендәге яналыкка алып килә. Халык җырынын бөтен булган милли колоритын, матурлыгын саклап, анын интонацион һәм ритмик үзенчәлекләрен гармоник яктан баетып, татар халкынын кумәк җырларын күп тавышлы, бай фактуралы хор әсәре-монын ачык мисалы. Анын тарафыннан 500дән артык халык җыры һәм инструменталь көй өйрәнелеп, алар ике җыентык булып дөнья күрде. (1941 һәм 1955).

Татар җырларын эшкәртүдә Ключаревнын иҗаты ике юнәлештә үсә. Беренчесе-нинди дә булса канүннардан азат ителгән эшкәртү. Бу төрдәге эшкәртүләр күп очракта хорнын акапелла башкаруына нигезләнә. Әлеге әсәрләр тирән

мәгънәгә ия музыкаль новелланы хәтерләтә. Тулы музыкаль поэтик образ тудыру максатында хор янгырашының барлык төсмерләре чагылыш таба. Шундыйлардан «Энгер–менгер» (Себер татарлары көйләре темасына) хор миниатюрасын атарга мөмкин. Бу эшкәртмә катлаулы формада төзелгән, анда күп кенә татар халык җырларының көйләре бирелә. Салмак, озын, кыска көйләр авторга төрле фактурачылыкны киң кулланырга мөмкинлек бирә.

Омск өлкәсендә язып алынган борынгы аучылар бәете–«Карьят батыр» көе бөеклек һәм ныклык белән аерылып тора. Бу эпик җыр үзенең төзелеше ягыннан урыс риваятьләренә һәм хикәятләренә якын тора–музыка фразалары һәм ритмик бизәлешләренең кабатлануы, көйнең ирләр тавышына хас янгыраштa булуы, алмаш ритм җырны тагын да көчәйтә. Г. Тукай шигыренә язылган «Пар ат» җырының эшкәртмәсе исә хор өчен сюжетлы күренешне хәтерләтә, һәм бу күренеш хор драматургиясе ысуллары белән оста итеп тасвирланган.

Көй эшкәртмәләренең икенче юнәлеше–киң аудитория тарафыннан күбрәк кабул ителгәне–ялгыз башкаруның асыл традицияләрен алгы планга кую, башкаручыга иркен рәвештә көйнең бизәкләрен бозмыйча җырлау. Хор партиясе күпләгән гади, әмма тулы һәм чиста янгыраш биргән тавышлар белән баетыла.Үрнәк итеп халык арасында бик популяр булган «Кара урман», «Фазлуш», «Сарман», шаян җыр «Дим-дим», лирик җыр «Өй артында шомыртым», Себер татарлары җыры «Гармун-гармун»...

Югарыда әйтелгән җырларның иң беренче башкаручысы–Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, әлбәттә, «Кара урман»–фәлсәфи эчтәлекле борынгы озын көйләр рәтенә керә. Аның текст сүзләрендә бик күп халыкларның шигырь иҗатына хас булган сәнгати образларның янәшәлеген күрәбез: ягъни кешенең табигать белән бербөтенлеген рәттән кую... Табигатьнең гүзәллеген аңлаудагы уй-кичерешләр, хис-тойгылар музыкада бөтен барлыгы белән чагылыш таба. Халык көе ярдәмендә барлыка килгән сәнгатьле бизәү чараларының күплеге әлеге тәэсирне тагын да көчәйтә. Көйнең интонация ягыннан сыгылмалылыгы һәм төрле музыкаль бизәкләргә байлыгы белән беррәтгән, автор җырның тирән мәгънәсен дә халыкка оста итеп ачып бирә. Ә «Гармун-гармун»... җырына эшкәртмә исә башкачарак уйланылган. Киң колачлы, салмак темплы күнелле көй характерлы музыкаль картина тудыр. Бик күптәннән татар халкының күңелен яулап алган уен коралын тиешле биеклеккә күтәрү теләге белән, композитор фон итеп хор башкаруында гармунда уйнау имитациясен ала. Баяннар җырны виртуоз вариацияләре белән баетып матурлыйлар. А. Ключаревның эшкәртмәсе бу җырны үзенчәлекле гимнга әверелдерә.

Авазларны охшату элементларын борынгы «Дүдәк» җырында да композитор оста куллана. Хор партитурасыннан татар халык кыска көйләренә, такмакларына хас тормышчанлык, күнелләлек бөркелеп тора. Әлбәттә, тормышчан күренешләрне тасвирлаганда теләсә кайсы классификация дә шартлы булып кала. Кайбер әсәрләрне югарыда бирелгән бер төркемгә дә кертеп булмый. Мисалга сокланырлык шигъри аһәңгә ия лирик «Әллүки» җырын гына искә төшерик. Әлеге җырны беренче төркемгә кертеп булыр иде (хорның бернигә буйсынмый иркен үсешен искә алсак), әмма хор партиясеннән тыш югарыда төп теманы алып барган башлап җырлаучының нәзберәк тавышы янгырый. Бу исә үз чиратында икенче төркем эшкәртүләренә хас һәм «Әллүки»не үзенчәлекле сәнгать эталоны итеп санарга була. «Әрәмәләр арасында» җыры эшкәртмәсе дә әлеге ике төркемнең уртак җимеше булып тора. Үзенчәлекле стильдәге «Агыйдел», «Таштай», «Зөлхиҗә» кебек башкорт җырларының эшкәтмәләре–композиторның бәһалап бетергесез иҗат җимеше. Гомумән, Ключарев башкорт җырларын өйрәнү өлкәсендә дә тирән эз калдырды һәм, профессиональ композитор буларак, иҗатында киң файдаланды.

Хор өлкәсендәге иҗат мирасында А. Ключарев халык җырларын гына эшкәртеп калмый, үл–үзе иҗат иткән әсәрләр авторы да. Иҗатында оригиналь җырлар күп булса да, ләкин хор өчен язылганнары чагыштырмача аз.

Халык көнкүрешендә киң таралган җырлы биюләр, биюле җырлар А. Клю-

чарев иҗатының җырны театральләштерүгә илткән аерым бер өлкәсен тәшкил итә.

Композитор тарафыннан үенлы сюжет элементларын эзләү бик кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Мисалга биюле җыр «Ак бүрек»не, солист белән хатын-кызлар хорының уен-көлкеле диалогыннан торган борынгы көй «Аппакай-алмакай» эшкәртмәсен, «Пар ат» хор күренешен китерергә була.

Композитор иҗатында лирик җырлар аеруча күренекле урын алып тора. «Туган җирем–Татарстан» (Г. Зәйнашева шигыре) җыры республиканың музыкаль эмблемасына әверелде. «Татарстан сәламе» (З. Нури), « Идел дулкыннары», «Яңа Казан» (М. Хөсәен), «Сәрвиназ» (Ә. Ерикәй) кебек популяр җырларны хәтергә төшерик.



*Фәйзулла Туишев белән. 40нчы еллар.*

Композитор иҗат эшен актив җәмгать эшчәнлеге белән бәйләп алып барды. Озак еллар Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе булып эшләде, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен оештыручыларның берсе һәм төрле елларда аның сәнгать җитәкчесе булды ( 1939, 1967-70). Татарстан Композиторлар союзы рәисе урынбасары вазифаларын башкарды. 2006 елның февраль аенда А. Ключаревның тууына 100 ел тулды. 25 февральдә С. Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында композиторның юбилеена багышланган кичәдә Александр Сергеевичның улы–Эмиль Ключарев этисенең тормышы һәм иҗат юлы турында үзе төшергән «Мой отец Александр Ключарев» фильмын күрсәтте, симфоник оркестр, солистлар башкаруында композиторның әсәрләре башкарылды.

Александр Сергеевичны күреп белгән Казан дәүләт консерваториясе профессоры Афзал Хәйретдинов Хәтирәләре: «1939-1940 елларда мәдәният дөньясы Мәскәүдә булачак татар сәнгате декадасына әзерләнгән чорда ул халык уен кораллары оркестры оештырды, һәр көнне репитиция үткәрә идек. Александр Сергеевич көйне тиз генә отып алып гармониялэштерә һәм теләгән тональлектә уйный иде.

1953 елда иң яхшы җырга конкурс оештырылды. Җюрида әдәбият әһелләре, башкаручылар утырды. Бөтен җырларны да конкурска авторларын атамый гына күрсәттеләр. Бик җентекләп тикшергәннән соң 1-2-3 нче урыннарны һәм бүләкләү грамоталарын билгеләп чыктык. Шулай, беренче өч урын да А. Ключаревныкы булып чыкты».

Танылган галим, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов хәтирәләреннән дә менә кайбер юллар. «Минем буынга аның белән якыннан аралашырга һәм хезмәттәшлек итәргә, татар халык темаларына кабатланмас импровизацияләрен тыңларга насыйп булды. Язучылар арасында аның бик якын дуслары булды, ә музыкантлар өчен ул татар халык музыкасы буенча кинәшче-консультант иде. Күп еллар үзешчән авторларның иҗат семинарлары белән җитәкчелек итте. Александр Сергеевичның музыка өлкәсендә генә түгел, ә әдәбиятны, этнографияны тирәннән белүе күпләрне сокландыра иде».

А.Ключарев–композитор, музыкант буларак 1930 елдан 1972 елга кадәр татар музыкасының бөтен борылышларында, тормышында, кадрларын әзерләүдә, гомумән, музыкаль тормышта иң актив эшләгән кеше. Ул–музыкант, татар музы-

ка тарихында тирән эз калдырган шәхес. Татар музыкасының кайсы гына тармагына килмә, Шәрыкъ дөньясында бу дәрәҗәдә тирән, эченә кереп атаклы музыкант буларак эшләгән шәхесләр юк. Ул фольклор буенча татарлар өчен энциклопедия иде.

Солист–музыкант буларак татар музыкасының нечкәлекләренә–ритмикасына, монына, хореографиясына керде. Шуңа да, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен Ключаревтан башка әйбәт музыка язган кеше булмады диярлек. Бу аның оркестр өчен язган музыкасында да сизелә. Мин музыка өлкәсендәге эшчәнлегемне аның белән элемтәдә, дуслыкта башладым. Чөнки ул бөтен татар музыкасының фавориты иде. Иң якын дуслары–Сәйдәш, Хәбибуллин булды. Ключарев белән З. Хәбибуллин дуслыгы турында аерым повесть язарлык. Аларның, кызганыч ки, бик аз язмалары калды, алтын фондка тиешле әсәрләре–импровизацияләре язылмаган. Мондый талант, мондый күренеш Ключаревтан соң булмады дияргә мөмкин, моны эшләрлек кешеләре дә табылмады».

РСФСРның атказанган сәнгать эшшеклесе, Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе композитор А. Ключаревның язмышы һәм иҗаты бик үзенчәлекле. Милләте белән рус булып, рус мөхитендә үсүенә карамастан, ул,–татар һәм башкорт профессиональ музыкасына нигез салучыларының берсе буларак танылган шәхес. А. Ключарев үзенең эшчәнлеге белән музыкаль образлар тудыру өчен халык көйләренең иң яхшы сәнгати нигез икәнлеген раслый. Җыр–аның өчен гомере ахырынача мәңге саекмаган иҗат чишмәсе булып кала.

А. Ключарев–куйган максатына, үз табигатенә тугры калып, халкыбызның әхлакый һәм иҗади традицияләрен дәвам итеп, татар музыкасы тарихында бай мирас калдырган зур музыкант-композитор.

**Филүсә АРСЛАН**

---

*Алхәбәр*

## Карл Фукс

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ

1776 елда Германиядә туып, 1846 елда дөнья куйган бу гаҗәеп шәхеснең кырык елдан артык гомере Казанда үтә. Танылган табиб татарларның тормыш-көнкүрешен өйрәнә һәм 1844 елда «Казан татарлары» дигән мәшһүр китабын чыгара. Алдагы саннарда журналда, беркадәр кыскартылып, китапның татарчага тәрҗемәсе басылачак.

Тәрҗемә авторы—Марсель Галиев.

## Марсель Сәлимҗанов

(1934 — 2002)



Марсель Хәким улы Сәлимжанов—режиссер, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1970), СССРның халык артисты (1984). 1962 елдан Казан яшь тамашачылар театрында режиссер, ә инде 1966 елдан Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры. Бер үк вакытта Казан театр училищесында, Казанның мәдәният һәм сәнгать академиясендә укыта, профессор.

Галиәсгар Камал исемендәге театрда куйган төп спектакльләре: «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе» (Кәрим Тинчурин); «Һиҗрәт», «Миркәй белән Айсылу» (Нәкый Исәнбәт); «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер жыр» (Туфан Миңнуллин); «Өч аршын жир» (А. Гыйләжев); «Бирнәсез кыз» (А. Островский).

Ул—Татарстанның Г. Тукай бүләге (1971), Россиянең К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе (1979) лауреаты. Театр әһелләре берлегенең «Алтын битлек» («Золотая маска») бүләге иясе (2000 ел). 2002 елның мартында Мәскәү хастаханәсендә вафат булды. Казанның татар зиратына жирләнде.

## Нәҗип Җиһанов

(1911 — 1988)



Нәжип Гаяз улы Жиһанов 1911 елның гыйнварында Жаек (хәзерге Уральск) шәһәрендә туа. Бик яшьли ятим калу сәбәпле, байтак еллар михнәт чигеп үсә. Кечкенәдән музыканы ярата. 1928 елда Казан музыка техникумына укырга дип килә.

1930 еллар башында Мәскәү консерваториясендә укыганда татар композиторлары С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Ж. Фәйзиләр белән еш очраша. Бирелә ул шагыйрь Муса Жәлил белән дә таныша.

Н. Жиһанов—СССРның халык артисты (1957), Социалистик Хезмәт Герое (1981). 1941-43 елларда Татар опера һәм балет театрының сәнгать житәкчесе. 1944—1988 елларда Казан дәүләт консерваториясе ректоры, профессор.

Язган әсәрләрен санап чыгу өчен генә дә байтак урын кирәк булыр иде: 8 опера («Алтынчәч», «Жәлил» һ. б.); 17 симфония, увертюра һәм сюиталар, шул исәптән «Кырлай» поэма-әкияте, симфоник новеллалар, романслар, жырлар...

Ул—СССРның Дәүләт (1950), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт (1958) премияләре лауреаты. Төрле чакырылышларда ТАССР һәм СССР Югары Советлары депутаты. 2000 елда Казан дәүләт консерваториясенә аның исеме бирелде.

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ**

# ХАЛЫК КИТАБЫ

Әй, язмышлар, язмышлар! Ачы да, гыйбрәтле дә, моңсу да, якты да һәм кадерле дә. Әйе-әйе, кадерле. Чөнки алар олы бер кадер-хөрмәт белән укучы күңеленә җиткерелә, әле өстәвенә кешенең, бу очракта әдәби геройның, хис-кичерешләренең, уй-фикерләренең кечкенә генә, үзе дә сизер-сизмәс кузгалган нюанслары да, туфанланып, давыллап алган мизгелләре дә автор өчен кадерле, ул шул халәтләрне бөртекли-энҗели һәм күңеленнән ак кәгазьгә төшерә... Әйе, мин әдәби әсәр укыйм, дөресрәге, хикәяләр. Бу хикәяләрне аягөсте генә укырга ярамый, бу хикәяләр—поэзия, шигърият, кеше күңеленең иң тирәнлекләренә төшеп, нәзберек-нечкәлекләренә төшенеп һәм төрелеп язылган әсәрләр. Дөрес, бер карaганда безнең тормышта сирәк була торган күренешләр тасвирланмый анда, вакыйгалар хәзерге көннәрне дә үз эченә ала, сугыштан соңгы еллар, сугыш еллары. Күбрәк авыл тормышы, билгеле, шәһәр дә бар. Әйе, автор яхшы белгән хәл-әхвәлләр. Шул хәл-әхвәлләр әсәрдә җанлана, терелә, сулый, яши, һәм укучыны да үзенең тормышы белән яшәтә башлый.




Әйе, язучы Роза Мулланурова, мин үзем яхшы белгән вакыйгаларны язам, ди. Чынлап та, йөрәктә кадерле урын алган нәрсә турында шулай яратып, сөеп үз күргәнгә, башкалар белән уртаклашырга мөмкиндер. Ягъни китап укучының зәвыгын бозмый торган рухи азык тәкъдим итә. Алдан ук әйтеп үтик, бу хикәяләрне әдәбиятның хасиятен, мәгънәсен аңлаган кеше укымый калса, кызганыч булыр...

Кайвакыт, хикәяләр укыганда—әйбәт хикәяләр укыганда—аһ, бер бәянлек, романлык материал әрәм булган дип тә уйлап куясың. Ләкин бу болай гына уйлау, ничектер күләм чагыштыру кебек кенә бер мизгел, дөресрәге, хикәя олы бер бәян укыгандагы кебек тәэсир иткән. Димәк ки, шул бер кечкенә хикәяне укып, андагы геройларның тулы бер тормышлары белән яшәп алгансың, чын тормышның чын геройлары белән виртуаль дөньяда йөргәнсең. Бер хикәядә романдагы кебек хис, дәрт, кодрәт, омтылыш, максат, нәтиҗә диган илнең бөтен почмакларын йөреп чыккансың... Ягъни автор аз әйтеп, укучының фантазиясен уятырга, кабызырга, очыртырга, канат куярга аз көч салмагандыр... Ләкин шулай да бу фикерләр һич тә хикәяне роман жанрына каршы кую түгел, әйбәт озын романны укыганда күз дә рәхәтләнә, шуннан күңел күзе байый...

Әйе, язмышлар, язмышлар... Әллә ялгышлар, ялгышулар? Катлам-катлам салкын карлармы соң алар, әллә бурабура буралган тирән сулармы?...

Шатлыклары азрак инде, нишлисең, автор тормышны ясалма бизәкләүдән бик ерак тора, аңа дөреслек булсын. Гомумән Роза Мулланурова хикәяләрендә ике үлчәү тәлинкәсе чәбәләнә: әйе, берсенә бәхет, икенчесенә бәхетсезлек тәялгән, яисә берсенә шатлык, икенчесенә кайгы салынган диеп әйтсәк тә була. Шатлык белән бәхет үз ягына басып китәм дип артык каударланмаса

Роза Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2006 ел.

да, тигезлек сакларга тырышса да, юк шул, дөнья андый беркатлылык өчен яралтылмаган... Дөньяда гаҗизлек—аптырау, сынау—сыналу, сыну—сынмау, җину—җинелмәү, сатылу—сатылмау бәһасенә торган фикер хөрлеге - барсы бергә чорналган, бер йомгак. Менә шундый авырлык-читенлекләр чыбылдыгын, ятьмәсен рухны сындырмыйча, әмма кыйналып-сугылып, җәберләнеп-үксезләнеп, җәзаланып-җәфаланып, еш кына соңгы сулышларга калып үтеп чыккан геройлар бу хикәяләрдә. Әгәр дә пафоссыз гына әйтсәк, бу тормыш—безнең халык тормышы, татар кешесенең социализм боламыгын һәм инде янәдән әйләнеп кайткан капитализмның ачы пешкән җимешләреннән авызы пешүе. Халыкка дигән балы-мае читтән агып үтә, хәтта әкиятләрдәгечә дә түгел—мыекка да эләкми...

Әй, Галикәй, әй, Саракай!.. («Галикәй белән Саракаем») Сезме соң бәхетле тормышка лаек түгел? Ә күпме кыйналгансыз, җәберләнгәнсез. Сугыш гарасатыннан бер кулын югалтып, мажаралы хәлләр аркасында гына исән калган Галикәйнең буш күлмәк җиненең ярсыпярсып талпынуы, очып китәргә үрсәләнүе—аның эчендә, җанында аккош тыпырчынуын, аккош җаны ярсуын күрсәтмимени? Әйе, ялгыз аккош ул, Саракаеннан ялгыз калган аккош. Сугыш елларында яшь кыз бала торф чыгаруга куылып, анда ярты сәламәтлеген калдырып кайткан затлы, эчке культурасы йөзенә мөлаемлек булып чыккан Саракае белән шул ярым-ярты гәүдә һәм исәнлек белән эш аты булып тормышны тартканда тукталып уйланырга да, бер-берсенә карашып сокланырга да вакытлары да, чаралары да булмаган икән ич.

Галикәйнең Саракае исәнлеккә мантымыйча иртә китеп бара. Ә ялгыз калган Галикәйне яшьләргәме соң аңларга?.. Җанында аккош тыпырчына , ә тыштан ул үзе яратып асраган усал ата казы кебек. Ата казының ачыргаланып кычкырган соңгы авазында аның өчен бу дөньяда бөтен нәрсәнең тәмамлануын, соңгы чиккә килүен тәне белән дереллэп тоя (чалынган ата каз тырпылдаган кебек), әмма күңел күзендә бер нур уйный: Саракае белән алар барыбер бәхетле булганнар! Менә шуны аңлау бәхетенә ирешә Галикәй. Хикәянең сюжет-композиция сызыгы гади генә кебек, әмма автор әсәрдә бик матур символик алымнар, бизәкләүләр күндереп, укучыны бик тә сагаеп кына, уйланып кына укырга мәҗбүр итә. Галикәй ата казының соңгы авазын ишеткәч (ата казны Галикәй өйдә югында чалалар), «Юлладылар!» ди үз-үзенә. Менә шушы төенләнеш һәм хикәядәге геройларның—Галикәй белән Саракайның—язмышларының драматик булачагын тою укучы күңелен дертләп куярга мәҗбүр итә. «Сизенүе хак булган! Ата каз кырпак кар өстендә гырылдап ята, кияве чалгы пычагын комгандагы су белән юып маташа иде...» Ата каз тавык чебие генә түгел, чалганнан соң да әле җаны чыгып бетмәгән... Монда да символик мәгънә. Әйе, сугыш чоры һәм сугыштан соңгы Галикәйләр буыны ул сәрсән, бирешмәс буын, болар мәгълүм шигырьгә—«...сделать бы гвоздей из этих людей, крепче не было бы гвоздей...»гә экспозиция булып торырлык...

Хикәядә хәтта сугыштагы командир да символик-кинаяле сөйләшә, һөҗүмгә керәсе солдатның—Галикәйнең: «Ичмаса, итегем дә юк», дип көенүенә: «Иртәгә барысы да булыр...», ди. Баксаң, мылтыксыз, итексез, котелоксыз солдат кырылышта исән калса, ана үлгән иптәшенең әйберләре буласы икән... Алга таба хикәя Саракаеннан ялгыз калган Галикәйнең үткән тормышларын күз алдыннан, аңыннан кабат үткәрү булачак сүтелә. Хикәянең башындагы «Юлладылар!» сүзе бер үк вакытта чишелешнең ничек булачагына да ишарәли... Тик әле хикәя ахырында да Галикәй исән, үзенең бөтен уйларын, хәсрәтен-кайгысын, булган каләр шатлыгын да яландагы муртайган өянкегә сөйли. Тагын символик алым, өянке дә символ—ул муртайган, аварга тора—Галикәйнең пары.

Алар бер-берсен ничек аңламасыннар инде...

Авторның хикәяләренә кешеләр арасындагы, хәтта туганнар, ата-ана белән бала мөгамәләсендәге иң нечкә, нәзберек җепләрнең бәйләнешләрен гадәттән тыш сизгерлек, такт, аңлау, аңлату белән тасвирлау хас. Бу сүзләргә куәт итеп: «Юшкын», «Бүре чагасы», «Күктәтәй», «Башсыз балан куагы» һәм

тагын да башка хикәяләрне дә атарга мөмкин булыр иде.

«Туйда» хикәясендә «Зур өметләр, ак хыяллар белән тырышып-тырышып теккән аклы ефәк күлмәге атылган аккош кебек, идәнгә таралып төште дә җансыз, хәрәкәтсез ята бирде. Юк, атылган аккош кыймылдый башлады, бәргәләнергә тотынды. Тик оча алмый—канат очлары киселгән...» өземтәсе Фәйрүзәнең эчке халәтен тулысы белән ача да бирә...

Әй тормышлар-язмышлар! «Әфган сугышы» дип калыпланган, ә чынлыкта басып алу сугышына илтеп тыгылган Ирек, шулай ук маҗаралы хәлләр аркасында исән калып, аннан әсирлеккә эләккәннән соң, җәберләнүләрен үзе генә белә... Берзаман илгә янгын эчендә көеп бетсә дә, янып бетмәгән бер сәер табылдык кебек кайтып төшсә, аны туздырылган туган нигезендә айдан төшкән бер шәүлә итеп каршы алалар... Чөнки ул алып кайтып күптән җирләнгән булып санала икән, ә нигезенә килеп утырган яшьтәшләре елгыр бизнесменнарга, шактый ук кансыз адәм кисәкләренә әйләнгәннәр... Әнисе исә күтәрә алмаслык кайгыдан вафат, сөйгән кызы елгырларның «азыгы» икән...

Роза ханымның әсәрләренең теле матур, нәзберек-нечкә, шул ук вакытта халыкчан бай, тәвәккәл дә. Гомумән дә бу—халык китабы... Бу тәвәккәллек фикер белдергәндә сүзләрне иркен куллана белүдә генә түгел, кайбер диалекталь дип әйтимме, әллә билгесезрәк сүзләрнеме куллануда да чагыла. Мина үземә «чарача» дигән сүз ошады, югыйсә безнең халык һәртөрле кумырык, бүлем, бүлемтек кебек урыннарны предбанник дип әйтеп җибәрергә өйрәнде. Ә андый җирләр—чарача дип атала икән. Нинди матур! Күбрәк иген арасында үсәргә яраткан зәңгәр чәчәкне ничек кенә җайсыз итеп атамыйлар: «буынтыклы» дип тә, урысчалап «василек» дип тә, «зәңгәр» дип тә. Ә ул «күктәтәй» икән ич!

Билгеле, хикәяләрдә кайвакыт тырмалырга теләгән сүз гыйбарәләре дә бар. Шундыйлардан берничә калька куллану бик үк уңышлы түгел кебек. Аннан килеп, тагын: «... Казлар Рим дигән би-и-ик олы каланы саклап калган бит, беләсегез килсә...» дигән әкият гыйбарә дә кереп киткән, ә чынына килсәк исә, Римне Атилланың мәрхәмәтлелеге коткарып калган...

Югарыда әйтелгән сүзләр хикәяләрнең һич тә чынлыгын киметми, болар капылт кына кергән кебек, аларны алып кую да мәшәкать тудырмас иде. Әйтүебезчә, авторның сөйләм-язу күәсен җигәр өчен көчәнүнең хаҗәте юклык болай да күренеп тора.

Ә без исә әсәрләрне укыганда ялгызлык, ятимлек, кардәшлек, туганлык, сөю-сәгадәт, үткенлек, юашлык, сагышсаргаю, тәвәккәллек, читенсенү, читсенү кебек тормыш дулкыннары эчендә тирбәлгән, кайнаган геройларның күбесенең яхшы мәгънәсендә намус колы булган язмышларын йөрәк әрнүе белән кабул итәбез...

**Бикә РӘХИМОВА**

# “МОҢЛЫ ЯДКАРЬ”




Аманулла (Әмир Камалиев)—театр сәхнәсеннән драматургиягә килгән урта буын авторларның берсе. Ул театр сөючеләргә “Әлепле артистлары”, “Әле кичә генә яз иде”, “Кылый Кирам балдагы” пьесалары буенча куелган спектакльләр аша таныш булса, Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән “Моңлы ядкарь” пьесалар җыентыгы (Казан, 2005) әлеге үзенчәлекле иҗат турында җитди сүз алып бару мөмкинлеге бирә. Аерым әсәрләренең сәхнәгә куелышына бәйле рәвештә А.Әхмәдуллин, Д.Гыйймранова, Ю.Сафиуллин һ.б. лар матбугатта үзләренең фикер-карашлары белән уртаклаштылар. Шулай да Аманулла иҗатына беренче җитди бәяне Й.Нигъмәтуллина бирә. Галимә “Җәйге кырау”, “Әлепле артистлары” пьесаларын модернистик концепция кысаларында тикшереп, драматургның яңа, кызыклы эзләнүләр алып баруын билгели *(Нигматуллина Ю. “Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве.—Казань: Фэн, 2004.)*

Җыентыкка Аманулланың сигез пьесасы—биш комедия, ике драма һәм бер трагикомедия туплап бирелгән. Алар белән танышкач, әдипнең бай рухи дөньясы, яшәеш фәлсәфәсе, сәнгати фикерләү үзенчәлеге ачык тоемлана. Ул үзе сайлаган тормыш материалын җентекле өйрәнеп, белеп һәм аны эчке яктан сурәтләргә омтыла. Шуңа да пьесалар тормышчанлыгы, конфликтның ачыклыгы, сюжет-композиция төзеклеге, хәрәкәт динамикасы белән күңелне били. Аманулла татар сәхнә әдәбиятының иң матур традицияләрен дәвам итү белән бергә, һәр әсәрендә яңачалыкка омтыла. Соңгысы аеруча сурәт чараларының күптөрлелегендә, герой характерын ачуның, заман проблемаларын калкытып куюның төрле юлларын эзләүдә чагыла. Драматург әсәрнең төп идеясен ачу максатында метафора булып килгән вакыйгага, образ-символларга, әдәби детальләргә, психологизмның төрле алымнарына, “уен”га һ.б. иркен мөрәҗәгать итә.

Аманулла төрле жанрларда язса да, комедиядә үзен аеруча иркен сизә. Әйтергә кирәк, аның уңышлары Г.Камал, К.Тинчурин кебек әлеге жанр осталарының традицияләрен яңа шартларда, яңа эчтәлек һәм алым-чаралар аша дәвам итүе белән бәйле.

XX гасырның 80 еллар ахыры-90 еллар башында илнең иҗтимагый-сәяси, икътисади тормышында барган үзгәрешләр, аларның кеше аңына ясаган йогынтысы тарихчылар, икътисадчылар, психологлар тарафыннан гына түгел, әдәбият-сәнгать әһелләренең дә “тикшеренү” өлкәсе булып тора һәм киләчәктә дә бу чор вакыйгаларына еш мөрәҗәгать итәчәкләренә шикләнмәскә мөмкин. Аманулланың “**Җоңлы кеше**” сатирик комедиясе үзәгендә—үткән гасырның 90 еллары башындагы татар авылы. Автор аның авыр, кызганыч хәлен тирән борчылу, әрнү белән сурәтли. Вакыйгалар барачак колхоз идарәсе бүлмәсендәге чебен тавышы әлеге хәлне аңлатучы билге-күренеш булып тора. Гасырлар дәвамында сакланып килгән яшәү рәвешенең бозылуы авыл халкының рухи-әхлакый дөньясы үзгәрүгә китергән һәм шул сәбәпле авыл үзе дә югалу, таркалу хәлендә тора. Әсәр геройлары белән бергә укучы-тамашачы да моның сәбәпләре турында уйлана. Бу—иң элек, совет системасының өстән кушканны үтәүне күздә тоткан эш стиленең соңгы чиккә килеп җитүе; аннары колхозның гомум милеккә нигезләнүе һәм беркемнең бернәрсә өчен җавап бирмәве; шулай ук кешедә үз хезмәте нәтиҗәсе өчен тырышу, яхшырак эшләү теләгенең юкка чыгуы, чөнки “эшләсәң дә түләмиләр, эшләмәсәң дә”; тагын бер сәбәп— үзебезнең рухи йомшаклыгыбыз, мәнсезлегебез, кемнәндер, нәрсәдер көтеп яту, кушканны гына эшләүгә гадәтләнү. Әнә шулар авыл-колхозны чарасызлык хәленә җиткергән: яңгыр-кар яуса тор-

мыш сүнә торган авылга ни кереп, ни чыгып булмый, юллар юк; күпер ватык ("машина белән түгел, җәяү дә үтеп булмый"); кешеләрдә иман-әхлак сыйфатлары кимеп бара, авыл хатыннарының кылгән шабашниклар белән "мәхәббәт уены" гадәти хәл санала, эчкечелек яман чиргә әверелгән (тракторист Тәфкилнең яздан бирле айныганы юк). Иң аянычы—кеше күнелендә өмет-ышаныч беткән, ә ул исә кыргый инстинктларның калкып чыгуына, әдәп-әхлак кануннарын таптап үтүгә китерә.

Автор ул чорның аерым вакыйгаларын арттырып, хәтта абсурдка тиң күренешләр аша күрсәтә. Аракы эчүдән Тәфкил кешелек сыйфатын җуя башлаган. Хатыны Фәгыйлә сүзләренә караганда, тавыкларга дигән җимне ашый икән. Элекке партком секретаре Хәнәфи хәзер авыл мулласы вазыйфаларын үти. Аның мәет күмүне башкаруы көлүдән бигрәк аптырау, гаҗәпләнү хисе тудыра. Фәгыйләнең: "Үлгән кешегә "Ясин" чыгалар бит",—дигәненә болай дип җавап бирә: "Орып бирә ул "Аятел көрси" синен "Ясин"ыңны, белдеңме?" Авыл кешеләренә тагы да тулырак бәяне агроном Әхтәм бирә: "Ут төртеп яндырырга гына кирәк бу авылны. Беркемгә бернәрсә кирәкми! Беркем берни эшләми! Крестьян балалары бит сез, каян килгән сезгә шулкадәр ялкаулык?" Болар барысы да авылга гына түгел, бөтен милләткә янаган куркынычны аңлата. Чөнки авыл гомер-гомергә татарның яшәү рәвешен, иң матур гадәт-сыйфатларын, әхлагын саклап килсә, хәзер инде ул әлеге вазыйфаны үтәүдән читләшә бара, икенче яктан, дистә еллар дәвамында яшәп килгән система үзенең хезмәт яратуы белән дан алган халыкны ялкаулыкка өйрәтте, битарафка әйләндерде.

Чит илләрдә йөреп кайткан колхоз рәисе Наил болай яшәп булмауны аңлый: "Хәзер заманалар үзгәрде, (...) безнең өчен беркем бернәрсә эшләмәячәк. Ничек булса да үзебезгә җаен табарга кирәк". Шотландиянең Лох-Несе күлендә әкияти зур кәлтә Несси яшәве турындагы вакыйга Наилгә юл күрсәтә. Шул рәвешле авыл урманында "Җонлы кеше" пәйда була. Бу рольне авыл көтүчесе Мәннән башкара. Биш кеше башлап җибәргән "уен"га әкренләп бөтен авыл кушыла. Чынбарлыкның ямьсез, күңелсез, эчпошыргыч, хәтта фаҗигале яклары әлеге "уен"ны төрләндерә, баета һәм урыны белән кайда "уен", ә кайда яшәеш дөреслеге икәне бутала да. Әсәрдәге вакыйга-күренешләрне, геройларны бер фокуска туплап торучы Җонлы кеше берничә вазыйфа башкара. Берсе—халыкның беркатлылыгыннан ачы көлү. 1990 еллар башында җәмгыятьтә һәртөр шарлатаннар, экстрасенслар күбәя һәм, ни гаҗәп, кешеләр соңгы акчасын түләп булса да аларны карый, тыңлый. Автор, кеше ышанмастай әйбергә ышануларын күрсәтеп, халыкның томаналыгын, маллар көтүе хәлендә булуын ача. Икенчесе—авыл халкының үз асылын, традицион яшәү рәвешен югалта баруын күрсәтү. Җонлы кешене ярымкыргый итеп тасвирлап, автор "Башкалар да шул хәлдә түгелме соң?" дигән сорауны да куя. Читтән кайтканга күрә "килмешәк" дип аталган, урмандагы Җонлы кеше—Мәннәннән алар берни белән дә аерылмыйлар. Өченчесе һәм иң мөһиме—янача уйлауга, үзгәрешләр башлауга этәргеч бирү. "Халкыбызның үзәк тамыры нык, ул үзендәге кимчелекләргә көлеп карый белә һәм шуның белән билгеле бер чистарыну кичерә", ди кебек автор. Ә инде тормыш-яшәешне үзгәртүне үзеннән башла, башкалардан көтеп яту урынсыз. Җонлы кешене күрергә килгән кунакларга бәйле авылда зур эшчәнлек башлана. Әсәр ахырында инде үзгәргән авылны күрәбез: Тәфкил эчүен ташлаган, туган як музее эшли, музыка мәктәбе ачарга йөриләр һ.б.

Аманулла комедия жанрының асылын, көлү эстетикасын яхшы белеп яза. Халыкчан юмор, ирония аның иң яхшы әсәрләрен "сугара". Нәкъ менә халыкның көлү культурасына таянуы әсәрләрен гаять тормышчан һәм эмоциональ янгырашлы итә. Мисал өчен, Мәннәннең "Тимәгез миңа! ГРИНПИСка жалоба язам" яисә "Кышкы буранда эчегез китеп җәфаласын!" кебек репликалары төп вакыйганың гайре табигый булуын тагы да тирәнәйтә һәм аның тәэсирен дә арттыра. Әсәргә немец профессоры кертелү дә сатирик пафосны үстерүгә хезмәт итә. Чөнки ул игътибарга лаек бернинди эш гамәл кылмый һәм авыз ияртеме белән генә сөйләшә: "О-о, йа-йа!", "Гуд-гуд!" Ә инде Тәфкилнең немецка күргәннәрен аңлатуы, татар-рус-немец сүзләрен кушып сөйләшүе авторның җорлыгына, сүз уй-

нату осталыгына мисал булып тора.

Аманулланың "уен" алымы куллану аша халыкчан көлүгә ирешүе "**Әлепле артистлары**"нда кин чагыла. Әлеге комедиядә дә вакыйга 1990 елларда бара. Авыл артистлары колхозчыларга спектакль күрсәтергә телиләр. Моңа әзерлек һәм театр уйнау күренеше—яшәешнең мәгънәсез, хәтта абсурд хәлен ачып сала. Бу пьесада да сәхнәдәге "уен" белән тормыш күренешләре буталып, аралашып бетә һәм ул проблемаларны тагы да калкытып, авыл-колхозның хәленнән, үзебезнең тормыштан ачы көлүгә китерә.

Драматург "традицион" авыл тематикасы белән генә чикләнми. "**Кылый Кирам балдагы**" сатирик комедиясендә инде бүгенге көн аферистлары сурәтләү объекты итеп алынган. Аманулла үзенең остазлары булган Г.Камал, И.Богданов, К.Тинчурин һ.б. лардан килә торган акчага-байлыкка җанын саткан бәндәне фашлау традициясен уңышлы дәвам итә. Пьеса сайланган тормыш материалы, сатирик пафосы, заман типларын мәйданга чыгаруы белән әлеге жанрның иң яхшы үрнәкләреннән санала ала. Әсәрдә уңай герой юк. Әлеге функцияне, драматургның эстетик идеалы буларак, Көлү башкара. Автор, үзе язганча, "кемдер алдарга, кемдер алданырга тиеш" заманны яхшы белеп, тоемлап эш итә. Ул тудырган сатирик типлар берсен-берсе баета, тулыландыра, ахыр чиктә үзгәртеп корулар чорында күбек кебек өскә калыккан, акча өчен намусын сатарга, якыннарын таптап үтәргә, теләсә нинди түбәнлеккә төшәргә әзер бәндәләрнең гомумиләштерелгән образын бирә.

Аманулла яшәешнең авыр, четерекле сорауларына җавап эзләп, башка жанрларда да иҗат итә. "**Әле кичә генә яз иде**" лирик драмасында урта мәктәпне тәмамлаучыларның олы тормышка беренче адымнары сурәтләнә. Әсәр яшьләрнең Идел буендагы дачада мәктәпне тәмамлау көнен билгеләп үтүләренә бәйле хатирәләренә, бүгенге чынбарлыкка мөнәсәбәтләренә һәм киләчәк турындагы уй-хыялларына, өмет-теләкләренә нигезләнгән. Анда үтәли конфликт юк. Ул бәхет, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе кебек сорауларга мөнәсәбәттә үзара фикер каршылыкларында, эчке конфликтларда бирелә. Шуңа да хәрәкәт салмак үстерелә һәм элекке классташлары Әнәс белән каршылыкта иң югары ноктасына җитә. Шактый аз вакыт аралыгында һәм бер урында барган күренешләрдә авторның игътибар үзәгендә яшь геройларның шәхси кичерешләре аша тормыштагы иҗтимагый-социаль үзгәрешләргә караш--мөнәсәбәтләрен билгеләү һәм, иң мөһиме, аларның күңелләрендә барган рухи кичерешне тоемлау, шуны укучы-тамашачыга җиткерү тора. Шуңа да күңел ачу, ял итү мәҗлесе лиризм белән өртелгән хатирә-истәлекләрдән үсеп, тормыш-яшәешнең җитди сораулары турында уйлану рәвешендә фәлсәфи эчтәлек ала.

Әсәрдәге интрига Әлфинурның укытучысы—класс җитәкчесе Альберт Равилевичка булган мәхәббәтенә бәйле үстерелә. Әлеге үзенчәлекле күренеш һәркемгә яхшы таныш. Мәктәп елларында өлкән классларда укыганда бик күпләр укытучыларын хыялында йөрткән идеал кеше буларак кабул итә, гашыйк була, әти-әнисенең, якыннарының, хәтта классташларының эш-гамәлләрен дә шуның белән чагыштыра. Ә Альберт Равилевич уңалты-уңҗиде яшьлек кызларның хыялында йөрткән "принц"ка бик тә туры килә. Укучыларның һәм ата-аналарның тирән хөрмәтенә лаек булган укытучының гаять үзенчәлекле, серле, матур һәм бай рухи дөньясы ачыла. Тормышка романтик күз белән караучы класс җитәкчесенең саф, гөнаһсыз җаны һәртөр түбәнлек-пычраклыктан өстен. Кешеләрнең икейөзлелегенә аның җаны әрни. Романтикларга хас булганча, ул һәртөр шау-шудан, ыгы-зыгыдан качарга омтыла, чынбарлыкта да ике төрле төсне—ак һәм караны гына күрә. Тынычлыкка, ялгызлыкка омтылган укытучы үзе кабул итмәгән чынбарлыкны болай бәяли: "Бары төннәрен... кешеләр ялгыз калгач кына, аларның чын йөзләре ачыла. Ул искиткеч матур да булырга мөмкин, коточкыч ямьсез дә... Ләкин ничек кенә булмасын, кешенең җаны ул вакытта чиста, ана берәүне дә алдарга кирәкми. (...) Көндез кешеләр битлек киеп, төрле рольләр уйныйлар. Өйдә бер төрле, эштә икенчене, урамда өченчене".

Дөрес, Альберт Равилевич хатынынннан аерылган, баласы ятим үсә. Әмма хатынының ямьсезлегеннән, хәтта исеменнән зарланучы Ирдән аермалы буларак, ул начар сүз белән хатынын кимсетергә, дәрәҗәсен төшерергә уйламый да.

Киресенчә, "искиткеч хатын... акыллы, чибәр... өстәвенә ул бит минем кызымның әнисе. Беләсеңме, алар шуның кадәр бер-берсенә охшаганнар. Күзләре, кашлары, хәтта тырнакларына кадәр" дигән сүзләрендә аңа илаһи зат итеп каравы, җылы, кешелекле мөнәсәбәте һәм кызының әнисе буларак зурлавы, хөрмәт итүе сизелеп тора.

Тормыш каршылыкларына әлегәчә очрамаган, киләчәкне китаплар аша ал төсләрдә генә күрүче, серле мәхәббәткә омтылып, ышанып яшәүче Әлфинурның әлеге идеал Ир-атка, яхшы Укытучыга гашыйк булуы табигый хәл. Автор укучы кызның укытучысына мәхәббәтенең вакытлы мавыгу, яшьлекнең бер мизгеле генә булуын шактый ачык сиздерә. "Сезнең белән сулыйм, яшим мин. Сезнең исем белән йокларга ятам, сезнең исем белән уянам",—диючө кызның хатларын француз телендә—гашыйклар телендә язуы да аның китап геройларына охшарга тырышуын күрсәтә.

Билгеле инде, Альберт Равилевич Әлфинур күңелендәге хисләрнең вакытлы гына булуын яхшы аңлый һәм бу турыда кызга да әйтә: "Юк, син уйлаган кеше түгел мин. Бу синең балалык галәмәте генә. Хыял. Мине башыңнан чыгарып ташла, оныт. Син әле үзеңнең чын ярыңны табачаксың. Аңлыйсыңмы? Анда бүтән законнар. Бүтән кешеләр. Геройлар да бүтән. Анда чын тормыш. Синең мәхәббәтең дә шунда. Вакыт узгач, миңа булган хисләреңнән оялачаксың әле син, үзеңнән көләчәксең".

Алдагы күренешләрдә драматург үз хезмәте белән көн күрүче, олы тормышның кырыс кануннарын шактый тулы, әмма берьяклы үзләштергән Әнәснең эш-гамәлләрен алга чыгара. Бензозаправкада эшләүче егетнең "кумирлары" булып, билгеле инде, чит ил машиналарында йөрүче, һәрнәрсәне йә акча, йә көч белән генә хәл итүче, ягъни үз теләкләренә ирешү өчен һәртөр чаралардан файдаланырга әзер "хуҗалары" тора. Аның яшәү фәлсәфәсе дә шуңа нигезләнә. Дөньяны танып белергә ашкынган, әлегә каршылыкларны җиңеп үтәргә әзер, шуңа да киләчәген Иделдә йөзгән ак пароход белән тәңгәлләштереп кузаллаучы Вазыйхка Әнәс болай җавап бирә: "Агымга каршы йөзәргә ярамый, көчеңне генә әрәм итәсең".

Драматург үз геройларының күңел кичерешләрен, эчке халәтләрен оста тотып алган. Укытучы һәм укучы бәхәсендә хисләр бәрелеше дә, яшәеш фәлсәфәсе дә, кеше дигән затның гаять серле, катлаулы булуын белү, шуның сәбәпләренә төшенү теләге дә һәм, ниһаять, үз хыялына, яшәү рәвешенә, тормыш матурлыгына тугры калган, шуның белән хөрмәт уяткан олы җанлы Укытучыны аңлау да бар.

"Әле кайчан гына яз иде!"—ди Сөмбел. Аңа Азат кушыла: "Хәзер җаның ни тели, барын да эшләргә була. Җәй житте. Җәй безнеке!" Язгөлем болай дип дәвам итә: "Без—җәйге күбәләкләр!" Әйе, кичәге мәктәп укучылары һәрберсе үзенең "җәенә"—олы тормышка атлый. Йоклаган Альберт Равилевич янына уенчык кораб белән алма куеп калдыру да символик мәгънәгә ия. Алар, үзенең гадәтитабигыйлеге белән хөрмәт казанган (алма—табигать бүләге), мәктәп елларының хыял-омтылышлары (кораб—хыял, идеал билгесе) чагылышы булган укытучыларын калдырып, яңа тормышка ашыгалар. Киләчәкләре нинди булыр, үз юлларын таба алырлармы, чынбарлык каршылыкларында адашып калмаслармы? Әлеге һәм башка күпсанлы сораулар әлегә ачык кала. Монысы—укучы һәм тамашачы өлеше. Әсәр геройларының эш-гамәлләре, караш-фикерләре һәркемне үзенең үткәне һәм бүгенгесе, хыял-омтылышларының тормышка ашу-ашмавы турында уйланырга, билгеле бер нәтиҗәләр ясарга этәрә.

"**Моңлы ядкарь**" трагикомедиясендә автор төрле яшәү фәлсәфәсенә бәйле тормышчан сорауларны укучы алдына куя. Әйләнә-тирәбездә, балаларның ятим үсүенә, бәхетсез гаиләләрнең һәм әхлаксызлык күренешләренең артуына сәбәп нәрсә? Әлеге һәм башка житди сораулар буыннан-буынга күчеп килергә тиешле рухи кыйммәтләргә мөнәсәбәт-караш белән тыгыз бәйләнештә бирелә. XX гасырның 60-80 еллар татар әдәбиятында гына түгел, соңгы еллар сүз сәнгатендә дә тотрыклы төсмер алган күренеш—әхлакый кыйммәтләрне өлкән буын вәкилләрендә эзләү, төрле буыннар арасындагы рухи бәйләнешне саклау—пьесада төп тема итеп күтәрелә. Шуңа бәйләп драматург гаилә тотрыклылыгы, бәхет һәм бәхетсезлек, гөнаһ төшенчәләрен калкытып куя. Ә инде исемгә үк чыгарылган

"Моңлы ядкарь"—халыкчан жыр—әсәрнең лейтмотивы булып бара. Ата-бабалардан килүче рухи мирас яшәешнең асыл мәгънәсен аңларга, тормышта үз урыныңны табарга булыша, ди драматург.Әсәрдә гаилә, ир-хатын мөнәсәбәте, мәхәббәт, җаваплылык, бәхет төшенчәләренә бәйле җитди бәхәс алып барыла.

"**Җәйге кырау**" драмасы белән Аманулла кеше җанының каршылыклы булуы, аны аңлап бетерү мөмкин түгеллеге турындагы мәңгелек бәхәскә кушыла. Әсәр үзенең психологизмы, кеше бәхете, аның рухи көче, өмет-ышаныч мәсьәләләре турында укучы-тамашачыны җитди уйлануга этәрүе белән уңышлы. Табигать күренеше булган җәйге кырау—көннәр җылына башлагач, кисәктән килгән салкын һава—яшь үсентеләрне, яңа ачыла башлаган бөреләрне юк итә. Әлеге күренеш пьесада Зөфәр язмышын аңлатучы метафора булып тора. Кыю, батыр һәм көрәшче егет үз мәхәббәтендә, үз-үзен тотышында, кешеләргә мөнәсәбәтендә хаталар ясый, шуның өстенә үзе ышанган кешеләрнең хыянәтенә тап була. Зөфәр аларны үтеп чыгарга, тормышын яңадан башларга көч таба алмый һәм үзенә үзе кул сала.

Берничә кеше язмышы аша драматург дуслык һәм хыянәт, мәхәббәт һәм мәкер, яшәү һәм үлем, куркыныч чиргә әверелгән эчкечелек кебек проблемаларны күтәрә. Яшь кешенең гомере өзелү кебек фаҗиганең сәбәпләрен ачыклау, аны булдырмау юлларын эзләү автор белән укучы диалогы рәвешендә дәвам ителә. Аманулла Зөфәр язмышын Ак сөлге символы аша аңлата. Драманы беренчеләрдән булып тикшергән Й.Нигъмәтуллина фикеренчә, ул дүрт төрле символик мәгънәдә бирелә. Зөфәр төшендә әтисенең ак сөлге тапшыруын күрә, ә инде соңрак аңа Сабантуй батыры буларак ак сөлге бүләк итәләр. Берничә ел вакыт үткәч, эчкечелеккә сабышкан Зөфәр сөлгене аракыга алыштыруны сорый. Соңгы күренештә исә ул әлеге сөлгегә асылынып үлә. Күргәнебезчә, ак сөлге башта ата-баба традициясен аңлатса, аннары ул осталык, көч, үз-үзеңә ышану билгесе булып тора. Зөфәрнең сөлгене аракыга алыштырырга омтылуы—бу инде традицияләрдән читләшү, гореф-гадәтләрне бозу, өмет-ышанычны югалту һәм рухи көчсезлек нәтиҗәсе буларак үлемгә бару.

Билгеле, җыентыкка туплап бирелгән пьесалар бердәй уңышлы түгел. "Борын-борын заманда", "Итәкле кияү" кебек комедияләр яналык алып килми һәм алар вакытлы күренеш булып калачак. Драматургның иҗат йөзен билгеләүче, югарыда без сүз алып барган пьесалар да аерым кимчелекләрдән азат түгел. Автор үзен оста психолог итеп таныта да, геройларның үз-үзен тотышы, сөйләмнәре һәрвакыт та мотивлаштырып бетерелми. "Әле кичә генә яз иде..."дә Ир кешенең кинәттән генә үзенең хатынын яманлый башлавы ышандырмый. Альберт Равилевичның укытучыларга кушамат тагылу турында беренче тапкыр ишеткән булып кылануы да шулай. Әнәснең элекке укытучысын бер сәбәпсез (!) "юньсез" диюе, төрлечә түбәнсетүе вакыйгалар барышыннан, геройларның эш-гамәлләреннән үсеп чыкмый. Алларак укытучысын илаһилаштырган Әлфинурның "бик тиз үзгәрүе" дә характер үзенчәлегенә тулысынча яраша бетми. Әйтергә кирәк, хәзерге татар сәхнә әдәбиятына хас бер кимчелек, ул—ясалмалылык. Авторлар, сенсация ясыйм дип яисә укучы-тамашачыны көлдерергә тырышып, еш кына хәл-күренешне, аерым диалогны, герой холкындагы аерым бер сыйфатны, тормышның үзеннән килгән итеп күрсәтүдән бигрәк, «уйлап» табалар. Аманулла да моннан котыла алмый. Аның "Моңлы ядкарь"ендә яшь егет Зиннәтнең үз хисләре турында Гафурҗан карттан сорашып утыруы нәкъ шундый. Әлеге пьесада район мәдәният бүлеге хезмәткәре Флоридның эш-гамәлләре бер яклы бирелгән. Аның Гөлшатны алып китеп "үзенеке" итәчәге укучы өчен алдан билгеле, шуңа да ул көчле тәэсир ясамый. Аерым әсәрләрдә төп идея белән бәйле булмаган күренешләр дә бар. Әйтик, "Җоңлы кеше"дә Фәгыйлә-Тәфкил-Фельдшер "өчпочмагы" характерларны ачуга да, автор позициясен аңлатуга да хезмәт итми.

Әнә шундый фикерләргә урын калса да, Амануллaның пьесалар җыентыгы—җитлеккән, үз стилен, үз юлын тапкан драматургның иҗат җимеше. Аның һәрдаим эзләнүдә булуын, чынбарлыкның яңадан-яңа хасиятләрен аңлавын һәм ачуын күрми мөмкин түгел.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

*Мәгърифәтче галим һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин (1732—1785) XVIII гасырда Казанда тылмач буларак танылган. Казан шәһәренең Иске һәм Яңа бистәләре вәкиле буларак, 1767 елда Екатерина II нең кануннар (Новое уложение) төзү проектын әзерләүдә катнашкан. 1769 елның октябрендә патшабикә фәрманы буенча Казандагы Беренче гимназиягә тәрҗемәчеләр әзерләү өчен татар теле укытучысы итеп билгеләнгән һәм гомеренең ахырынача шунда эшләгән. Пугачев восстаниесен тикшерү комиссиясе эшендә дә тылмач буларак катнашкан.*

*Сәгыйть Хәлфин—татар теле буенча беренче басма әлифба (1778) авторы һәм 23 меңгә якын сүзне эченә алган ике томлык кульязма русча-татарча сүзлекне (1785) төзүче. Аның мәгърифәтчелек эшен улы Исхак һәм оныгы Ибраһим дәвам иткәннәр.*

*Хәлфиннәр турында татар телендә беренче мәртәбә тәфсилле итеп Әхмәтзәки Вәлиди язып чыккан. Аның 1913 елда «Шура» журналында басылган «Хәлфиннәр» исемле күләмле мәкаләсенең Сәгыйть Хәлфин турында язган өлеше хәзерге укучылар өчен дә кызыклы булыр. Текст бераз кыскартылды һәм хәзерге телгә якынайтылды.*

---

Әхмәтзәки
Вәлиди

# СӘГЫЙТЬ ХӘЛФИН

...Бөтен Русиянең гыйлем, фән галәмендә мөһим урын биләгән, ләкин безнең өстебезне каплап алган караңгылык астында күмелеп онытылып калган «тарихи Хәлфиннәр». Бу Хәлфиннәр олуг затлар булганнар һәм безнең Казан татарлары эченнән чыкканнар. Ләкин, ни булгандыр, безнең бу олуг затлар безнең олуг һәм кече кешеләребездән күзгә-колакка эләгеп калганнарын җыюга багышланган 2 нче том «Мөстәфадел-әхбар»да да, мөселманнарның һәр җәһәтеннән мәркәзләре булган Диния Нәзарәте янында торып вә биниһая күп фидакярлекләр сарыф итеп язылган «Асар»да да искә алынмаганнар.

Бик кызганыч хәл! Ни булгандыр, Русиянең төрле тарафларында торып, «Асар»га ярдәм итүче затлар, бу кешеләр хакында бик аз гына булса да сүз табып, Ризаэтдин хәзрәткә бер хәбәр итә алмаганнар. (Чөнки хәбәр иткән булсалар, Ризаэтдин хәзрәт җыентыгында болар әллә кайчан язылган булырлар иде).

Аз мыни безнең берничә гасырлардан бирле Шәрык халыклары, төрки халыклар эчендә үзенең мәдәнияте, сәләте белән дөньяга мәшһүр булып килгән халкыбыз(казанлылар)ның эчендә кирәк сәясәт, кирәк гыйлем, һөнәр, байлык җәһәтеннән бик мөһим урыннарны биләп килгән, тик үзләренең барлык шөһрәтләрен үзләре белән бергә кабергә алып киткән, сәүдәгәрлек, чиктән тыш мәшгульлектәге, үзенең бүгенгесен һәм киләчәген генә кайгырта, үткәнен бөтенләй оныта торган халыкның (казанлыларның) эчендә үзләренең һичбер эзләрен кадырмаган кешеләребез?

Аз мыни? Аз мыни!..

Без бу урында сөйләргә теләгән Хәлфиннәр аталы-уллы өч кеше: Сәгыйть, Исхак, Ибраһим.

Сәгыйть унсигезенче гасырнын ахырларында Екатерина (Әби патша) вакытында

гыйлеме вә милеге зур хезмәтләрдә булган зат. Ул Екатерина тарафыннан халыкларның хажәтләренә карап канун төзү өчен җыелган сирәк депутатлардан. Ул 1769 нчы елдан башлап 1785 елга кадәр Казанның Беренче гимназиясендә татар теле мөгаллиме булган...

Без «Сәгыйть Хәлфин һәм аның хезмәтләре» темасына керешеп, кулдан килгәнчә җыелган материалларны карап, Сәгыйть Хәлфиннең тәрҗемәи хален, аның дәрес җәдвәлен һәм шул вакыттагы Пугачев вакыйгасы мәсьәләсендәге эшен, бу мәсьәләне хәл итү турысында Сембердә оештырылган комиссиягә чакырылып, анда мәшһүр галим Рычков белән танышып, аның билгеле тарихына ярдәм итүе турында язган идек. Боларның һәммәсен «Йолдыз» мөхәррире Һади әфәнде Максуди югалтты. Шул сәбәпле укучыларга ул турыларда сүз сөйли алмадык. Чөнки минем җыйган материалларымның бүген янымда караламасы калмаган һәм ул күп чыганаклардан җыелган материалларның барысы да хәзер Беренче гимназия һәм университет архивларындагы (инде күпчелегенең исемнәре онытылган) китаплар арасында калды. Инде аларны актарып йөрергә төрле киртәләр дә бар һәм озак вакытлар сарыф итәргә инде мөмкинлек тә юк. Шулай итеп бу хезмәтем әрәм булды. Бу мәкалә Казанга мөнәсәбәтле булган өчен үткән яз көне Казан газетасы «Йолдыз»га кертүне мәгъкуль күреп, мөхәррире Һади әфәндегә биргән идем. Иң башыннан берничә сәхифәсен «Йолдыз»га кертте (871 номер), янә тукталып калды. Моннан соң янә басуын үтенгәч, Һади әфәнде аның уртасыннан ун битен югалтуын сөйләде. Хезмәтемнең юкка чыгуы мине борчуга салды. Инде укучылар арасыннан минем бу кайгымны аңлап, мәкаләмнең уртасыннан өзек булуы өчен мине гафу итүчеләр булыр дип уйлыйм.

18 нче гасырда рус халкы эчендә чит кавемнәрнең (бу җөмләдән безнең дә) телләре белән кызыксынырдай һәм эш эшләрдәй кеше булмаган. Бу хакта иң әүвәл яхшы һәм төпле әсәр язучы—Сәгыйть Хәлфин, һәм иң әүвәл Русиядә татар теле буенча басылган әсәр—аның әсәре. Дәрес өчен хаҗәт булганга күрә Сәгыйть кайбер дәрес китаплары язды, аларның кайберләре басылды, кайберләре кульязма көенчә калды.

Россиядә татар теле буенча иң беренче әсәр булып басылган «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов (сочиненная Казанских гимназий учителем Сагитом Хальфиным и татарских в Казани слобод муллами, в оных гимназиях рассмотренная и одобренная)» исемендәге әсәре. Бу китап Мәскәү университетының матбагасында басылды. Басылып тәмам булгач та (1774[1] нче ел 4 сентябрьдә) Казан гимназиясенә йөз нөсхә җибәрелде. Без бу китапның нөсхәсен Казанның университет, академия, гимназия китапханәләрендә таба алмадык. Шәрык факультеты күчерелгән вакытта мондый китапларның Петербурга күчерелгәнен югарыда әйткән идек.

Сәгыйть Хәлфиннең исемен мәңгегә калдырган иң мөһим вә зур хезмәте «Русча-татарча лөгать» исеме белән язган әсәре. Бу олуг китапның Петербургта Публичный император китапханәсендә һәм Азиат музеенда, Казан университетында нөсхәләре бар. Һәммәсе дә кульязма хәлендә. Чөнки китап нәшер ителмәгән.

Сәгыйтьнең бу әсәрен гимназиянең мөдире И.Ф.Лейдеман князь Потемкинга җибәргән (1785 ел). Бу эш князь Потемкин һәм Екатерина өчен бик кыйммәтле әсәр булып табылган. Чөнки Екатерина ул вакыт «инородец» (ягъни рус булмаган халыклар) телләренә бәйле мәшһүр сүзлеген (Сравнительный словарь инородческих племен) яздыра һәм төрле тарафтагы «инородец» телләрен белүчеләргә бу китапларны ничек язу хакында төзелгән планнарын җибәрә иде. Татар теле Казан архиепископы Антон белән Нижегород епископы мәшһүр галим Дамаскинга (бу кеше Геттинген университетын бетергән) тапшырылган иде. Архиепископ Антон гимназиядән бер шәкерт һәм Имангул Чуриков исемле бер татар солдат алып эшләп караса да, зур эш башкара алмаган. Һәм шул вакытта Потемкин Сәгыйть Хәлфиннең грамматика һәм сүзлеген алган. Князь Потемкинга җибәрелгән һәм

[1] «Шура» журналында 1774 ел дип (1779 урынына) ялгыш басылган. Чөнки Хәлфиннең әлифба китабы 1778 елда чыккан.

аның китапханәсе Казан университетына китерелгән вакытта Казан университеты китапханәсенә төшкән. Һәм бүген шунда саклана торган нөсхәсендә авторының исеме язылмаган, бәлки шул гимназия хозурында язылды гына диелгән. Шул сәбәпле кайбер кешеләр: «бу сүзлекне, шөбһәсез, Сәгыйть Хәлфин язгандыр» дип кенә әйткәннәр. С.Булич язуынча, сүзлекнең Азиат музеендагы нөсхәсендә «Авторы Сәгыйть Хәлфин» дигән сүз бар икән. Димәк, сүзлекнең Сәгыйть Хәлфин әсәре булуында шөбһә калмады.

Сүзлекнең Казан университетындагы нөсхәсе олуг китапханәнең «Кулъязма әсәрләр һәм сирәк китаплар бүлеме»ндә саклана. Китапның беренче битенә бу рәвештә язылган: «Татарский словарь, в пользу обучающихся при Казанских гимназиях юношества татарскому языку, сочиненный при оных же гимназиях 1785 году». Китап сәхтиян белән матурлап зиннәтләнеп, ике калын томда тышланган һәм бик яхшы кәгазьдә язылган. (С.Буличның әйтүенчә, бу сүзлеккә 25 меннән артык сүз кергән). Беренче томы 653 бит, икенче томы 876 битле.

Китап русча тәртип белән сулдан уңга таба укыла. Язуы (Сәгыйть Хәлфиннең кулы)—кирәк русча, кирәк татарчасы—бик ачык, матур. Кайбер русча сүзләр русча графада язылган, татарча графада тәрҗемәләре юк. Болар китапта бик аз урында, ихтимал ки, язучы ул сүзләргә татарчада сүз эзләргә авырсынгандыр яки таба алмагандыр. Чөнки мондый сүзләр, күбесенчә, татарчада сүзләр табылып бетми торган русча булмаган чит (иностранный) сүзләр.

Русиядә Сәгыйть Хәлфин әсәренә кадәр татар теле буенча грамматика да, рәтле сүзлек тә булмаган. Сәгыйтьнең бу әсәре басылмый калса кала биргән, аның әсәрендәге барлык хаталары-ниләре белән бергә күчереп, шундый ук зур итеп Тобол побы Гиганов русча-татарча сүзлек язган һәм Гигановның әсәре исеме белән Фәннәр Академиясе тарафыннан нәшер ителгән. Бу китапның ун нөсхәсен 1806 елда Казан гимназиясенә җибәргәннәр икән. Якулин шунда ук эшне сизгән. Ул: «Безнең Сәгыйть язган сүзлекнең нөсхәсе ничек тә бу автор кулына төшкән дә, ул аннан сүзгә-сүз, үзгәртмичә, һәм барлык хаталары белән күчергән һәм шул көенә бастырган» дип язган. Хәлбуки, Гиганов Россиядә генә түгел, бөтен Европада татар теле буенча беренче мәртәбә грамматика һәм сүзлек чыгаручы дип мәшһүр. Сәгыйть сүзлеге булган кебек, Гиганов сүзлеге дә Казан университеты китапханәсендә бар. Кызыксынган кешеләр укырга мөмкин.

Без, ниһаять, шуны әйтәбез: Сәгыйтьнең сүзлеге безнең бу көннәрдә русча-татарча сүзлек язучы әфәнделәр өчен дә зур файда итәр иде. Сәгыйтьнең моннан башка нинди әсәрләре бар һәм нәрсәләр, без бу хакта бер нәрсә белә алмадык. Инде бу эшләр һәм Сәгыйтьнең тормышына бәйле башка тикшеренүләр башка кешеләребезгә калды...

Мин бер ялгызым бу затлар хакында күңелләрне басарлык сурәттә төпле, нигезле мәгълүмат бирә алмадым. Кулымда материаллар шул кадәр генә булды. Бу язганнарым ул хөрмәтле тарихи затлар хакында беренче язулар булу җәһәтеннән бәлки ярап торырлар. Ихтимал ки, тиз вакытлар эчендә безнең халык арасында үзләренең үткәннәре, Хәлфиннәре-фәләннәре белән яхшы таныш кешеләр пәйда булырлар.

*(Әхмәтзәки Вәлиди. Хәлфиннәр // Шура.—
1913.—№ 3.—Б. 67—72, № 5.—Б. 141).*

# ШИФАЛЫ ЙОГЫНТЫ

## ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘГӘН ХАЛЫКЛАРНЫҢ МӘДӘНИЯТЕН, МӘГАРИФЕН ҮСТЕРҮДӘ КАЗАН ҺӘМ АЛАБУГАНЫҢ РОЛЕ

Октябрь инкыйлабына кадәрге Россиядә Казанны «Шәрык гүзәле» дип атаганнар. «Казанны үзе белән көньяк-көнчыгышта чикләшкән губерналарны берләштереп тора торган урын диярге була: алар аның аркылы мәгърифәт, гореф-гадәт һәм мода ала,—дип язган А. И. Герцен 1836 елда «Провинциядән хатлар»ында.—Гомумән, Казанның әһәмияте ифрат зур: ул ике дөньяның очрашу һәм көрәшү төбәге» *(Герцен А. И. Собр. соч. I. I.—М., 1954.—Б. 132).*

Казан Россиянең танылган уку үзәге була. Изге Гурий туганлыгы мәктәбендә, Казан «инородец» укытучылар семинариясендә, Казан университетында һ. б. уку йортларында күп халык вәкилләре белем ала. «Россия өчен Мәскәү нинди үзәк булган булса, Казан да башка халыклар өчен шундый ук үзәк булды»,—дип бәяләгән күренекле лингвист галим, профессор Н. Ф. Катанов.

1842—1902 елларда удмурт, алтай, чуаш, кыр чирмешләре (мари), тау чирмешләре, кыргыз, кумык, башкорт һ. б. өчен беренче әлифба китаплары (азбукалар, букварьлар) Казанда дөнья күрә. Бу халыкларның язучылары, галимнәренең беренче әсәрләре, фәнни хезмәтләре дә шушында басыла. XVIII гасыр башында Казанда архиерей (епархиаль) мәктәбе ачыла. Анда Идел буе халыкларыннан 14 малай укый. Бу мәктәп нигездә руханилар хәзерли. 1732 елда архиерей мәктәбе руханилар (духовная) семинариясе итеп үзгәртелә. 1906 елда әлеге семинарияне беренче мари галиме, танылган лингвист, фольклорчы һәм этнограф профессор В. М. Васильев тәмамлый.

XIX йөзнең икенче яртысында Казанда китап басу эшчәнлеге 1867 елда оештырылган тәрҗемәчеләр комиссиясе карамагында була. Изге Гурий туганлыгының беренче басмасы—И. Кедров тарафыннан төзелгән букварь—1867 елда Казанда чыккан. Ул халык училищелары укучыларына дәреслек буларак тәгаенләнә. 1877 елда кыр чирмешләре өчен Г. Яковлев төзегән букварь басыла, 1892 елда «Тау чирмешләре өчен букварь» дөнья күрә.

Казанда 1847 елда удмурт телендә «Азбука, составленная из российских церковной и гражданской печати букв для обучения вотских детей чтению на их наречии (Глазовском)» дигән беренче кулланма басыла. Алга таба мәктәпләр өчен XIX гасырда 12, XX гасырда 8 исемдә удмуртча азбука һәм букварь дөнья күрә. Күп кенә дәреслекләр һәм уку-методик китаплар күренекле удмурт галиме һәм методисты Иван Михеев тарафыннан языла.

Удмурт, мари мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү вазифасын 1864 елда Н. И. Ильминский нигезләгән Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе башкара. Үзәк мәктәпне тәмамлаган удмуртлардан миссионер Захарий Осипов, Иоанн Васильевларны күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Идел буенда һәм Урал алдында яшәүче рус булмаган халыкларның мәгарифен үстерүдә, авыл мәктәпләренең башлангыч класслары өчен укытучылар әзерләүдә 1872 елда ачылган Казан «инородец» укытучылар семинариясе зур роль уйнады. Ул азчылык милләтләр өчен укытучы миссионерлар әзерләүдә житди өлеш кертеп кенә калмады, киң мәгънәсендә белем һәм тәрбия бирү методикасын эшләүдә әһәмиятле эш башкарды. Үз вакытында бу уку йорты алдынгы педагогик фикер һәм интернациональ туганлык булып саналды. Семинариянең башлангыч сыйныфларында укыту рус, татар, удмурт, мари, чуаш һәм мордва телләрендә алып барыла. Гомумән, бирелә егермедән артык милләт вәкилләре белем ала.

47 ел эшләү дәверендә (1872—1919) бу уку йортын 1500 дән артык укучы тәмамлый.

Шулардан 686 рус, 243 татар, 179 чуаш, 128 мари, 110 мордва, 70 удмурт, 20 казакъ, 10 калмык, 20 пермяк, 12 кореяле, 10 коми, 7 якут, 6 башкорт, 6 зырян, 6 гарәп, 4 алтайлы, 1 абхаз, 1 эстон, һ. б. милләт вәкилләре *(Педагогическая мысль в конце XIX—начале XX века.—Казань, 1979. С. 47).* Казан «инородец» укытучылар семинариясендә И. Шкляев, Г. Прокопьев, Максим Прокопьев, И. Яковлев, Кедра Митрей, З. Осипов, И. Васильев, М. Ильин, А. Сугатов, К. Яковлев кебек удмурт, С. Чавайн, П. Эмяш, М. Васильев, Г. Микай, В. Мухин, П. Глезденев, П. Еруcланов, Т. Семенов кебек мари, А. Юртов, М. Евсевьев, И. Кривошеев, А. Кирюков, З. Дорофеев кебек мордва халыкларының күренекле әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, педагоглары һ. б. белем ала. Казанда аларның дөньяга карашлары, сәяси һәм милли үзаннары формалаша һәм үсә. Күренекле удмурт галимнәре И. Михеев, И. Яковлев, мордва галимнәре А. Юртов, М. Евсевьев, чуаш галиме Н. Ашмарин һ. б. ахырдан күп еллар дәвамында бу семинариядә актив педагогик эшчәнлек алып баралар.

Казан «инородец» укытучылар семинариясендә керәшен татары Роман Давлей рус теле укыта. Ул мари укучылары белән аеруча якын мөнәсәбәттә була. 1909 елда Роман Давлей ярдәмендә А. Романов (Марданов) семинариягә укырга керә. А. Романов ватандашлар сугышы елларында революционер-большевик була. Үзенең яраткан укытучысы хөрмәтенә ул Романов фамилиясен ала. Фамилиясе Давлейның исеменнән (Роман) килеп чыккан.

Казан университеты Идел-Урал төбәгенең мәдәни һәм иҗтимагый тормышында әһәмиятле роль уйный, үзәк функциясен үти. Аның галимнәре инициативасы белән милли мәктәпләр оештыру, университет типографиясендә милли телләрдә мәктәп дәреслекләре бастыру активлаша төшә. 1917 елга кадәр милли мәктәпләр өчен булган барлык әлифба китаплары диярлек Казанда дөнья күрә.

Октябрь инкыйлабына кадәр һәм аннан соңгы чорда Идел буенда һәм Урал алдында яшәүче халыкларның И. Яковлев (чуаш), В. Васильев, Г. Эвайн (мари), М. Евсевьев, В. Хохряков (мордва), Ашалчи Оки (Векшина А. Г.), Т. Борисов, И. Волков (удмурт) кебек күренекле вәкилләре Казан университетында укып белем ала һәм югары квалификацияле белгечкә әверелә.

Казан университеты каршында 1879—1930 елларда эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте Идел һәм Урал буенда яшәүче татар, удмурт, чуаш, мари, мордва һ. б. халыкларның тарихын, рухи һәм матди тормышын, мәдәниятен өйрәнүгә шактый зур өлеш кертте. Бу өлкәдә В. Васильев, М. Евсевьев, И. Смирнов, В. Коршунов, И. Васильев, Г. Потанин кебек галимнәрнең һ. б. хезмәте зур була. Төрле елларда бу җәмгыятьнең «Гыйльми язмалары»нда «Бөре һәм Сарапул өязе чирмешләренең һырлары» (1908), «Чирмеш җырларының характеры һәм төзелеше турында» (1909), С. К. Кузнецовның «Этнограф истәлекләреннән» һәм «Кугу сорта» дигән чирмеш сектасы» исемендәге этнографик очерклары унае белән язылган кыска мәкаләләре (1910), «Чирмешләрнең женси азгынлыкка мөнәсәбәте» (1915), «Мариларның дини карашлары һәм гореф-гадәтләре» (1908), (В. Васильев), «Мордва халык әдәбияты үрнәкләре» (М. Евсевьев), «Саратов өязе вотякларының тормышы» (В. Коршунов), «Вотяклар» (1890), «Чирмешләр» (1889), «Мордвалар» (1890), «Пермяклар» (1891, проф. И. Смирнов) кебек тарихи-этнографик очерклар, «Казан һәм Вятка губерналары вотякларының мәҗүсилек гореф-гадәтләрен, юк-барга ышану һәм инануларын күзәтү» (И. Васильев), «Алабуга өязе вотяклары хакында» (Г. Потанин) кебек хезмәтләр дөнья күрә. Җәмгыятьнең гыйльми язмалары барлыгы 34 томны тәшкил итә.

Чуаш, удмурт театрлары Казанда һәм Чепья авылында (хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районы) туган.

Казанда чуаш, мари һәм удмурт телләрендә беренче газеталар дөнья күрә. 1906 елның 8 гыйнварында чуаш телендә беренче революцион газета булган «Хыпар» («Хәбәр») басылып чыга. Вятка шәһәрендә 1915 елда удмурт, мари һәм татар телләрендә «Война увер», «Войнаысь ивор» («Сугыш хәбәрләре») газетасы нәшер ителә һәм ул 1917 елдан удмуртлар өчен «Удморт» исеме астында чыгуын дәвам итә. «Сугыш хәбәрләре» газетасын оештыруда, чыгаруда бу телләрне яхшы белгән мари халкының мәшһүр заты П. П. Глезденев зур эшчәнлек, тырышлык күрсәтә.

1905-07 елларда Россиядә булып үткән беренче буржуаз-демократик революция мари, чуаш, удмурт, мордва, башкорт халыкларының милли аңын үстерүгә булышлык итте. 1904-09 елларда Казанда удмурт телендә, 1907-12 елларда мари телендә еллык календарьлар басылды. Аларны гамәлгә ашыруда И. Михеев, В. Васильев кебек галимнәр зур хезмәт куйдылар. Бу халыклар әдипләренең беренче иҗат җимешләре шушы календарьларда лаеклы урыннарын алдылар.

XX гасыр башында Казанда беренче чуаш сүзлеге басыла, чуаш теле буенча күптомлы сүзлек нәшер ителә, чуаш халкының этнографиясе, халык авыз иҗатын өйрәнүгә багышланган беренче хезмәтләр дөнья күрә.

Илебездә революцион үзгәрешләр якыная. Казанда 1917 елның маенда Идел буенда яшәүче аз санлы милләтләр вәкилләренең съезды була. Анда мари телендә «Ужара» («Таң», 1917-18) исемле газета чыгару турында карар кабул ителә. 1917 елның 25 августында «Ужара» газетасының беренче саны Казанда басыла. (Мөхәррирләре—А. Адаев, В. Васильев һәм С. Гаврилов).

1917 елның азагында, 1918 елның беренче яртысында Казанда һәм Алабугада удмурт һәм мари халыкларының күпсанлы съездлары үткәрелә.

Революцион бәрелеш елларында Татарстанда күпмилләтле һәм күптелле матбугат барлыкка килә. 1917-20 нче елларда Татарстан чикләрендә 130 дан артык, Татарстан АССР төзелү чорында республикада иллеләп исемдә 8 телдә газета һәм журналлар чыга. Аларның 14 татар, 27 се рус, калганнары мари, чуаш, удмурт, немец, венгр (мадьяр), чех телләрендә басыла. Шулардан Казанда нәшер ителгән журналлар (чуаш телендә): «Ана» («Чәчүлек», 1918-20), «Шурампус» («Таң», 1919-21), мари телендә: «Куралше» («Сабанчы», 1918), «У илыш» («Яңа тормыш», 1922-27), «Юк» («Тавыш», 1920-22); газеталар (чуаш телендә): «Херле ялав» («Кызыл байрак», 1921—1963), «Канаш» («Киңәш», 1918-21), «Сене йал» («Яңа авыл», 1925-26), «Сене пуранас» («Яңа тормыш», 1918-19), «Чухансен сасси» («Ярлылар авазы», 1918-19), «Херле солтак» («Кызыл сугышчы», 1919), «Сувар» (1993 елның августыннан Казанда басыла), 1995 елдан «Шурампус» («Таң») журналын кушымта итеп чыгара.); мари телендә: «Йошкар кече» («Кызыл кояш», 1918-21), «Йошкар солтак» («Кызыл сугышчы», 1919), «Сер еслекен» («Игенче», 1919), «Незеррын шамакшы» («Ярлы сүзе», 1918-19), «Тор» («Дөреслек», 1919-22), 1918 елда Казанда немец телендә «Коммунист», венгр телендә «Коммунист», «Партия губкомы хәбәрләре», 1920 елда венгр телендә «Уй элоре» («Яңадан алга») исемле газеталар дөнья күрә.

Совет властенең башлангыч елларында удмурт һәм мари халыкларының мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүдә Алабуга шәһәре гаять зур роль уйный. 1918 елның гыйнварында Алабугада удмурт конференциясе, ә июньдә удмуртларның Бөтенроссия съезды үткәрелә. Анда Вятка, Казан, Пермь губерналарының 9 өязеннән 78 делегат катнаша.

Мәгариф бүлеге мөдире Т. Борисов инициативасы белән 1918 елның декабрендә Алабугада удмурт укытучылар семинариясе ачыла һәм бу уку йорты шактый гына удмурт интеллигенциясе вәкилләрен тәрбияләүгә җитди өлеш кертте. Удмуртларның икенче Бөтенроссия съезды да 1919 елның мартында бу шәһәрдә уздырыла. 1920 елның июнендә Алабугада Халык мәгарифе институты ачыла һәм ул Вятка һәм башка губерналарда яшәүче милли халыкларга хезмәт итәчәк белгечләр әзерли башлый. Шул ук вакытта Алабугада, удмурт мәктәпләре өчен кадрлар тәрбияләү максатын күздә тотып, кыска вакытлы курслар ачыла. М. Ильин, С. Бурбуров, Т. Борисов, Г. Микай, Я. Ильин, М. Коновалов, К. Яковлев һ. б. күренекле удмурт язучылары, галимнәре удмурт укытучылар семинариясендә, удмурт педагогик курсларында белем алалар яки эшлиләр. Бу шәһәрдә удмурт телендә «Гудыри» («Күк күкрәү», 1918-19), «Кам тулкым» («Кама дулкыны», 1918), («Кызыл сугышчы», 1919), «Виль синэ» («Яңа караш»), «Сюрло» («Урак», 1920-22), «Югыт сюрес» (Якты юл»), («Горд гырлы» («Кызыл кыңгырау», 1920); мари телендә «Марий коммунист», «Тул» («Ут», 1920-21) исемендә газеталар чыгара. 1925 елда Казанда мордва телендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты органы булган «Валда эрямусь» («Якты тормыш») исемле газета нәшер ителә.

1919 елның 1 ноябрендә Казанда беренче эшче яшьләр факультеты ачылу Казан

университеты тарихында билгеле эз калдырды. Күпмилләтле төбәк үзәгендә ачылган эшчеләр факультеты беренче елларыннан ук Идел буе һәм Урал алды милли республикалары өчен белгечләр әзерләү чыганагы булып әверелде. 1920 елның октябрендә эшче факультетта укучы 474 студенттан 117 татар, 74 чуаш, 14 мари, 7 удмурт халкы вәкилләре булды. 1924 елда эшчеләр факультетында удмурт һәм мари бүлекләре, ә 1925-26 уку елында чуаш һәм мордва группалары ачыла. Удмурт, мари бүлекләрендә профессор Н. Никольский, Е. Емельянов, И. Михеев, И. Яковлев һ. б. югары квалификацияле милли кадрлар эшли. 1925-27 елларда Казандагы Көнчыгыш педагогия институтында удмурт (вот) теле һәм мәдәнияте, чуаш теле һәм мәдәнияте, мари теле һәм мәдәнияте бүлекләре ачыла. Ә 1930-31 елларда бу милли бүлекләр базасында Ижау, Чабаксар һәм Йошкар-Ола шәһәрләрендә мөстәкыйль педагогик институтлар оеша.

Төрле халык вәкилләре күп еллар дәвамында Казанда укыйлар һәм Казанда, Алабугада, Чистайда хезмәт итәләр, татар халкы белән якыннан аралашалар. Мордва Республикасының атказанган фән эшлеклесе, педагогика фәннәре докторы, профессор Ф. Ф. Советкинның тормыш юлы һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге татар халкы һәм ул яшәгән төп төбәк белән бәйләгән иде. Ул Октябрь көннәрен Казанда үткәрә, аннан соң Чистай шәһәренә күчә һәм биредә 8 ел эшли. Бу еллар совет властен ныгыту, совет мәктәбен тудыру, торгызу, дәүләтчелекне үстерү еллары булып тарихка керде. 1918 елдан Чистай шәһәре һәм Чистай өязе укытучыларының съезды уздырыла. Съезд рәисе итеп Федр Фролович Советкин сайлана. Бу шәһәрдә Ф. Советкинның зур оештыру һәм педагогик сәләте киң үсеш ала. 1919 елда Чистайда Халык мәгарифе югары институты оештырыла, аның рәисе (ректоры) итеп Ф. Ф. Советкин билгеләнә. Ул бу институтта иҗтимагый фәннәр кафедрасы белән җитәкчелек тә итә, политэкономия, тарихи материализм, экономика, география фәннәре буенча лекцияләр укый.

Татар, мари, чуаш, удмурт, мордва, башкорт язучылары, галимнәре, педагоглары, рәссамнары, композиторлары арасында булган иҗади дуслык тамырлары, үзара бәйләнешләре, йогынты ясашуларының башлангычы революциягә кадәрге вакытлардан ук килә.

Күренекле татар мәгърифәтчеләре Г. Курсави, Ш. Мәрҗани һәм бигрәк тә К. Насыйриларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә чуаш халкына мәгърифәт очкыны кабына. Егерменче гасырның башларында татар мәгърифәтчеләре чуашлар турында ныклап язарга керештеләр. К. Насыйри, чуаш авыллары тарихын, халыкның гореф-гадәтләрен, телен, мәдәниятен, мәгарифен җентекләп өйрәнеп, тарихта калырлык хезмәтләр яза. Бөек фикер иясе үзенең гыйльми язмаларында татар һәм мари халыклары арасында булган гасырлардан килгән дуслыкны да чагылдыра. 1900 елда басылып чыккан «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дигән, П. А. Поляков белән бергә язган уртак хезмәтендә («Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» гыйльми язмалары, XVI том, 2 нче чыгарылыш) мари халкы әкиятләрен тирән анализлыйлар. Татар галиме бу хезмәтне язганда мари әдәбиятчы-этнографы Т. Семенов тәкъдим иткән мари әкиятләреннән дә файдалана.

Сонга табарак башкорт, чуаш, марилар турында «Гореф-гадәт законнан өлкәнрәк» дигән мәкаләсендә Татарстан халык язучысы, Дәүләт бүләге лауреаты Гомәр ага Бәширов бик җылы итеп язды. Тугандаш башкорт халкы турында татар әдәбияты аксакалы болай ди: «Безнең якын күршеләребез һәм туганнарыбыз башкортлар да—ифрат талантлы, шигъри җанлы, батыр һәм музыкаль халык. Башкортның моңлы халык җырларын, Урал тауларының биеклеген дә, башкорт далаларының киңлеген дә, халыкның батырлыгын да чагылдыручы бик үзенчәлекле башкорт музыкасын без рәхәтләнеп тыңлыйбыз. Мин белмим, кунакчыллыкта, бүтән милләт халыкларына хөрмәт күрсәтүдә башкортлар белән тагын кем генә тиңләшә алыр икән». Г. Бәшировның күрше чуаш халкы турында әйткән түбәндәге җылы фикерләре дә игътибарга лаеклы: «Яисә менә безнең иң якын күршеләребез һәм дусларыбыз булган чуашларны алыйк. Аларның тыйнаклыгы, гадилеге һәм эш сөючән булулары мәкальләргә, әйтемнәргә кергән. Дуслыкка, татулыкка тугрылыклы булу, әйткән сүзендә тору мәсьәләсендә алар чын-чыннан

үрнәк була алалар» *(Бәширов Гомәр. Бүген дә, иртәгә дә. 1974.—Б. 16-17.)*. Мәшһүр әдипнең мари халкы адресына әйткән сөю сүзләре дә укучы күңеленә хуш килә.

Татар халкының аерым вәкилләре XX гасыр башларында ук Идел буенда һәм Урал алдында яшәүче башка халыкларга тирән ярату белән хезмәт иттеләр, дусларча ярдәм күрсәттеләр. 1901-04 елларда керәшен татары М. В. Васильев «Казан епархиясенең гыйльми язмалары»нда мари халкының тормыш һәм көнкүрешен тасвирлаган берничә очеркын бастыра. Бу өлкәдә аның түбәндәге мәкаләләре игътибарга лаеклы. «Чирмешләрдә дини бәйрәмнәр», «Чирмешләрдә масленица» (кышны озату бәйрәме), «Чирмешләрдә язгы бәйрәмнәр» һ. б.

1880 елларда Казан һәм Вятка миссионерлар җәмгыяте һәм җирле мәгърифәтчеләр-туган якны өйрәнүчеләр удмурт фольклорын өйрәнүдә житди өлеш керттеләр. Аларның басылып чыккан хезмәтләре арасында Казан миссионеры керәшен татары Борис Гаврилович Гавриловның «Казан һәм Вятка губерналары вотякларының халык әдәбияты әсәрләре, гореф-гадәтләре һәм йолалары» *(Казан, 1880)*, «Мамадыш өязе Үрәс-Уча мәхәлләсе вотякларының иманулары, гореф-гадәтләре һәм йолалары» (1891) хезмәтләре һ. б. фикер тирәнлеге ягыннан аерылып тора. Венгр һәм фин телләренә дә тәржемә ителгән беренче хезмәте бүгенге көндә дә зур фәнни һәм гамәли кыйммәткә ия.

Профессор М. Евсевьевның «Татреспублика мордвалары», «Мордва грамматикасы нигезләре», «Эрзя-рус сүзлеге», «Мордва туе» дигән этнографик хезмәтләр һ. б. Башкорт галимнәренең дә беренче фәнни хезмәтләренең тууы Казан белән бәйле. М. Өметбаев, С. Яхшыгулов, Я. Юмаев, Г. Исәнбирдин, Ә. Тангатаров, Т. Ялчыгол кебек һ. б. башкорт галимнәренең гыйльми хезмәтләре шулай ук Казанда дөнья күрә.

Мари, удмурт язучыларының беренче әсәрләре Казанда һәм Алабугада басыла. 1908-21 елларда В. Мухин, Т. Осып, С. Чавайн кебек һ. б. мари сүз осталарының егермедән артык төрле жанр әсәрләре Казанда аерым китап буларак туган телендә мари укучысына житкерелә. Удмурт язучыларыннан Т. Борисов, К. Герд, М. Ильин, И. Михеев, М. Можгин, И. Яковлев һ. б. шулай ук егермедән артык әсәре Казанда дөнья күрә.

Алабуга шәһәренең удмурт әдәбиятын, мәгарифен үстерүгә керткән өлеше бик зур. 1919-20 елларда гына бу шәһәрдә Т. Борисов, К. Герд, М. Ильиннарның икешәр китабы удмурт телендә басыла. Алар арасында Т. Борисовның «Шигырьләр» (1919), К. Гердның «Якты юлга», «Шәһитләр» кебек пьеса китаплары (1919), М. Ильинның «Шигырьләр» (1920) җыентыгы һ. б. игътибарга лаеклы.

Татарстан Республикасы—интернациональ республика. Бирелә йөзләп артык милләт халкы вәкилләре яши. Республиканың төп халкын татарлар, чуашлар, руслар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ. б. тәшкил итә. Республика мәктәпләрендә укыту алты телдә: татар, рус, чуаш, мари, удмурт, мордва телләрендә алып барыла.

Татарстан—күп кенә чуаш, рус, удмурт, мари сүз осталарын, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренең туган төбәге. Алар арасында 40 тан артык чуаш, 20 ләп удмурт халкы вәкилләре бар. Н. Шелеби, В. Краснов-Асли, Г. Краснов-Казенни, И. Максимов-Кошкинский, П. Хузангай, Т. Педерки, Н. Дедушкин, А. Калган, К. Петров, А. Алга, В. Урдаш, В. Ухли, В. Юдин, М. Сениэль, А. Афанасьев, В. Ахун, П. Афанасьев, П. Егоров, Е. Еллиев, А. Назул, А. Тимбай, В. Чебоксаров кебек чуаш, Г. Прокопьев, М. Прокопьев, И. Васильев, И Михеев, Н. Ошмес, С. Бурбуров, Ж. Очей, Г. Сабитов, А. Ермолаев, В. Кельмаков, В. Романов, М. Можгин, А. Сугатов кебек удмурт, Г. Мекай кебек мари язучыларын, галимнәрен һ. б. тудырып үстерүдә, тәрбияләүдә Татарстан республикасының өлеше гаять зур булган һәм хәзерге вакытта да зур.

Безнең туган якта яшәүче төрле милләт халыклары арасында күптәннән ныклы бәйләнешләр яши. Бу өлкәдә Казан, Алабуга, Чистай шәһәрләре, җөмһүриятебезнең башка төбәкләре башкарган эш әһәмиятле.

Татар халкының сәяси, икътисади, мәдәни үсешендә, тугандаш халыклар белән дуслыгын тирәнәйтүдә дәүләтчелеге, аның идея һәм формаларын эзлекле рәвештә гамәлгә ашырылуы аеруча зур роль уйный.

**Фәнис ИСЛАМОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Борнак

Борнак авылы Балтач районында, район үзәге Балтач авылыннан 18, тимер юл станциясе Шәмәрдәннән—31, Малмыж пристаненнән 27 чакрым ераклыкта урнашкан.

Борнак авылы шактый күп тарихи чыганакларда искә алына. Ул Казан ханлыгын исәпкә алган авыллар исемлегендә дә теркәлгән.

Борнак авылы олы юлдан шактый читтә урнашкан. Авылга керә торган юлны ярып Шушма суы ага.

Олылар сөйләвенә караганда, авылга нигезне Борнак баба салган, ул биредә ящелчәчелек белән шөгыльләнгән. Авылны Борнак иле дип йөрткәннәр. Борнак сүзеннән ясалган фамилияләр Борнак авылында юк. Ә күршедәге Янгул авылында мондый фамилиядәге кешеләрнең нәсел шәҗәрәләре Борнак авылы халкына килеп тоташа икән.

Борнак баба килгәнче авылда чирмешләр яшәгән диләр. Борнак баба житәкчелегендә аларны китәргә мәжбүр иткәннәр. Күчкән марилар хәзерге Кукмара районында яшиләр икән. Авыл янында Кирәмәт елгасы һәм Кирәмәт тавы булу да элек монда чирмешләр яшәгәнлекне дәлилли кебек.

1917 елга кадәр Борнакта 355 хуҗалык булган, шуларның 200гә якыны атсыз, ярлы, батрак хәлендә яшәгән.

Авыл халкы игенчелек, яшелчә үстерү белән, кыш көннәрендә чабата үрү, кап сугу, җеп эрләү, киндер сугу эшләре белән шөгыльләнгән. Халык бик тырыш, булсын дип яшәгән һәм яши. Авыл муллалары Миначев Салих (югары мәхәллә) һәм Мулланасихов Хәбибрахманнар (түбән мәхәллә) булганнар. Алар халыкны динле итү өчен зур көч куйганнар.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң илдә башланып киткән ватандашлар сугышында авылның күп кешеләре—Закиров Әхмәтгали, Закиров Нәби, Зарипов Хафиз, Мифтахов Кәрим, Галимов Габдрахман, Галимов Фәйзерахман катнашканнар.

1918 елның көзендә авылда советча мәктәп оештырыла. Балаларны ике укытучы укыта. Авылның беренче укытучылары булып Юнисова Бану һәм Миначева Сажидә эшләгән. 1920—1932 елларда мәктәптә Габделхәй Зарипов белән Фәйзерахман Фазлыев укыткан.

Минлемуллин Нәби авылның беренче шоферы буларак билгеле. Ул Ватан сугышында һәлак була. Беренче тракторчылар Зарипова Мөкәррәмә, Кәримова Факия, Әухәдиева Нәсимә һәм беренче комбайнчы Мөхәммәтшин Гали булганнар.

Сугыш елларында, бөтен илдәге кебек үк, тормыш авырлыклары хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Гафикамал Гафарова, Хәтирә Нәҗипова, А.Чернова балаларга тәрбия бирүдән тыш, фронт өчен җылы киемнәр әзерләү, колхозга ярдәм итү, гомумән, халыкка культура хезмәте күрсәтү эшләрен оештыралар. Нәфисә Сабирова колхозда, Зарифа Габидуллина агротехник булып эшли. Башка хатын-кызларга да җаваплы эшләр тапшырыла.

1945 елның язы илебезгә җиңү шатлыгы алып килә. Тик авылдан сугышка киткән ирләрнең 136 сы кире әйләнеп кайтмый, сугыш кырында батырларча һәлак була.

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Ватан сугышыннан соң җимереклектән чыгу өчен көрәш башлана. Терлекләрнең баш саны арттырыла, яңа сортлы орлыклар чәчелә, торак йортлар салына.

Сугыш бетеп исән калган ир-атлар авылга кайткач, тормыш бераз җайланып китә, халык иркенрәк сулап җибәрә. Яңа мәчет 1996 елның 21 февралендә ачылган.

1995-96 елларда авылның барлык хуҗалыклары да үзәкләштерелгән газга тоташтырыла. Авылда матур мәдәният йорты бар, аның янәшәсендә генә агач йортта китапханә урнашкан. Бу китапханәдә авылның тарихи музее оешып килә.

Башлангыч мәктәп, балалар бакчасы эшли. Элемтә бүлекчәсе, авыл халкын тәэмин итәрлек ипи пешерү цехы һәм шифаханә бар. Шушма күмәк хуҗалыгының үз ашханәсе эшли.

Борнак авылы олы юлдан читтәрәк урнашкан, ләкин асфальт юл авылга кереп, мәчет янына кадәр сузыла.

Авылда ике зират бар. Берсе—иске зират, ул тулган инде. Яңа зират иске зират каршына урнашкан. Иске зират турысында сугышта ятып калган авыл ир-атлары истәлегенә куелган һәйкәл тора. Бу һәйкәлнең ике ягына урнаштырылган ташларга һәлак булган сугышчыларның исемнәре уеп язылган.

Авыл янындан Көшкәт суы агып уза. Аңа Кәрим елгасы (елга ярында Кәрим чишмәсе дә бар), Кәлтә елгасы, Вәли таш казыган елга, Наси елгасы исемле суинешләр кушылган. Инде югарыда әйткәнебезчә, авыл янында Кирәмәт елгасы бар, ул суны Инешкә китерә. Авыл урынында элек яшәгән чирмешләр шушы елга янында гыйбадәт кылганнар диләр. Кәрим инеше шулай ук Инешкә ялгана. Кәлтә елгасы, Вәли таш казыган елга, Насыйр елгасы, Көшкәт суы шулай ук Инешкә тоташалар. Авыл янында тагын Кәрим чишмәсе, Ком тавы, Кирәмәт тавы, Чүлмәк таулары бар. Авылның Түбән очында Нәҗип коесы һәм Бай коесы булган. Хәзер Нәҗип коесы кипкән, ә Бай коесы әле дә исән, аннан халык су ала.

Авылда Әлтаф күле дип йөртелгән күл бар. Юл буенча авылга килгәндә ул күренеп тора. Хәзер аның суы саеккан һәм чисталыгы да чамалы. «Балык үрчетеп зур табыш ала башлыйбыз»,—дип, күлне тәмам бозганнар. Бетермәскә иде бу күлне...

Смәел авылына барган вакытта юлда бер чишмә кала. Аны халык Изге чишмә дип йөри.

Авыл Түбән оч һәм Югары оч дигән ике өлешкә бүленгән. Түбән очны икенче төрле Ачы дип тә йөртәләр. Түбән очта Мәче тыкрыгы, Фаек урамы дигән атамалар бар. Мәче—кеше кушаматы, ул кеше шул тыкрыкта яшәгән. Фаек урамы дигән атама да шунда яшәүче исеменнән.

Авылның Югары оч дип йөртелгән өлеше тагын икегә бүленә. 3-4 өйне башкаларыннан Инеш аерып тора. Аларны Аргы яклар дип атыйлар.

Авылда 170 ләп хуҗалык бар. Йорт салып башка чыгучылар саны ел саен артканнан-арта.

## Борнаш

Борнаш авылы Апас районында, район үзәге Апастан 23 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Борнаш борынгы авыл. Моның чынлап та шулай булуы аксакаллар сөйләгәнне тарихи чыганаклар белән чагыштырганда ачык күренә. Авыл атамасы Казан ханлыгы чоры документларында, XVI йөз мәгълүматларын эченә алган Зөя өязенең теркәү кенәгәләрендә, башка тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш кулланыла.

И. П. Ермолаевның «Казанский край во второй половине XVI—XVII вв.» дигән хезмәтендә 1686 елның 11 июль датасы белән татар авылы Борнаш искә алына.

XVIII йөздә Борнаш авылында ясак түли торган татарлар саны 139, йомышлы татарлар—20, керәшен татарларыннан 8 кеше яшәгән. А. Артемьев китабында (1866) күрсәтелгәнчә, Борнаш авылында 135 йорт булып, анда 375 ир-ат һәм 293 хатын-кыз исәпләнгән. 1898 елда чыккан хезмәттә Борнаш авылында татарлар яшәгәнлеге әйтелә. К.П.Берстель авылда 1175 татар кешесе яшәгән дип күрсәтә.

Борнаш авылы халкы тирә-юньдәге 30 лап авыл кешеләре белән июль башларында Чабыр исемле җыен үткәргән.

Борнаш авылында яшәгән Сафиуллин Хәбибулладан язып алынган «Борнаш» дип аталган риваять игътибарга лаек.

«Хәзерге Зөя янында Борнаш дигән урыс авылы бар. Иске заманда мөселман авылы булгандыр. Болгардан килгән ике агай-эне бар икән. Берсе Борнаш баба, берсе Сәед дигән кешеләр. Шул Борнаш баба дигәне анда килеп утырган—бер авыл булган икән. Зөя каласы урыс кулына кергәч, алар Тәтеш өязенә күчеп киткәннәр. Хәзердә Тәтеш өязендә Борнаш дигән мөселман авылы шул Зөя яныннан күчкән Борнаштыр. Янә Сәед ага дигәне тагы үз алдына бер авыл булып утырган. Борындыктан килгәндә Сит дигән станса шул Сәед ага авылыдыр. Төхфәтулла мулла үзенең Әтнүк бабасыннан риваять кылган сүзләрдер».

Авыл аксакаллары сөйләве буенча, авылда керәшен татарлары да булган. Бу тарихи документлар белән дәлилләнә. Ләкин вакытлар үтү белән алар янадан ислам диненә кайтканнар. Заманасында алар мәетләрен гомуми зиратка күмә алмаганнар, халык рөхсәт итмәгән.

Элек авыл тирәсе калын урман булган. Авылны нигезләүчеләр урман эченә килеп утырганнар. Ышна басуы Дәүләки урманы ягында урнашкан.

Гадәттә күрше авыллар берсен-берсе кушамат белән атап йөртәләр. Күршедәге Әлмәндәр һәм Әҗем авыллары халкы борнашлыларга «мукшы» кушаматы такканнар. Әлмәндәр һәм Әҗем авыллары аксакаллары Борнашта мукшы нәселләре булуы турында сөйлиләр.

Авылның тирә-юненә игътибар итик. Авыл инеше Үләмәгә сул яктан килеп кушыла. Басу тирәләрендә тагын Каз-Хаж, Яу, Абдулла качкын, Аракы елгасы, Олы Каз һәм Кече Каз елгалары, Ишкенә солдат, Гыйззәт ермаклары, Котлы, Ибраһим бабай сызаларын һ.б. атап әйтергә мөмкин. Борнаш тирәсе күлләргә дә бай. Чуаш куагы, Якты яз, Нури һ.б. күлләре, Буралы, Батыр кизләве, Әдел, Салкын чишмә-чыгышлары, Котлы, Тимәшкә, Шәйхетдин мулла, Бармаксыз, Шәрәф мулла, Хажи, Шиһаплар коесы яисә Сиртмәле, Гыйбадулла бабай коелары һ.б. авылга ямь өстәп торалар. Авыл тирәсендәге басуларның күптәнге исемнәре дә халык хәтерендә саклана: Җәмәки, Шәккә солдат, Чирәм жир, Атау яисә Баба кырлары һ.б. Атау басуы яки Баба кырын халык Алып бабаның чабатасын каккан урыны дип саный. Тирә-юнь авылларга бара торган юлларның да үз исемнәре бар: Урта, Ибрай, Биккол, Кияүләр, Баба юлы, Әдел юлы, Җәмәки басуы юлы, Печтеки юллары һ.б.

Авылда Булат бабай бакчасын Булат бабай карап, чистартып, агачлар утыртып тора. Бакча эчендә чишмәләр дә, күл дә бар, бик матур.

Борнаш авылында мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы, медпункт, кибет һәм мәчет эшли.

## Борындык

Борындык авылы Кайбыч районында, район үзәге Олы Кайбыч авылыннан 24, Коланга тимер юл станциясеннән 6 чакрым ераклыкта утырган.

Борындык авылы Казан ханлыгы чоры авыл атамалары исемлегенә кергән. Авыл атамасы Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә (1565—1567 елларны эченә ала) теркәлгән. И. П. Ермолаевның «Казанский край во второй половине XVI—XVII вв.» дигән хезмәтендә 1674 елның 23 декабрь датасы белән Борындык авылы искә алына.

Д. А. Корсаков белешмәсендәге мәгълүматларга караганда, XVIII йөздә Борындык атамасы алган ике авыл була: Олы Борындык һәм Кече Борындык. Бәрле суы ярына утырган Олы Борындыкта 240 йомышлы, 19 керәшен татары; Кече Борындыкта ясак түли торган 14 татар кешесе яшәгән. А. Артемьев (1866) тарихи белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Бәрле суы ярына утырган Олы Борындык авылындагы 137 хуҗалыкта 492 ир-ат һәм 482 хатын-кыз яшәгән, гыйбадәт кыла торган йорт, элемтә станциясе булган. Кече Борындык авылындагы 12 хуҗалыкта 33 ир-ат һәм 35 хатын-кыз көн иткән. 1898 елгы белешмәдә күрсәтелгәнчә, Борындык авылында татарлар яшәгән. Монда авыл Олы Борындык һәм Кече Борындык дип бирелмәгән, Борындык дип бер авыл билгеләнгән. К. П. Берстель җыеп чыгарган тарихи белешмәдә Борындык (телеграф һәм элемтә бүлеге) авылында 1689 татар кешесе яшәгәнлеге искәртелә.

Борындык авылы турында Каюм Насыйри мондый мәгълүмат бирә: «Борындык Исмәгыйль мулла риваять кыладыр Хәмит карттан: элегрәк Борындыкта Хәмит дигән карт бар икән, йөз яшьләргә житеп вафат булгандыр. Ул Хәмит карт үзенен бабаларыннан ишетеп сөйлидер икән: Болгар харап булган вакытларда Арыслан дигән бер адәм бар икән: үзе Болгарда вафат булгандыр. Анын ике угылы Болгардан күчеп, Зөя янына күчеп килгәннәр. Бер угылына Борындык баба диерләр икән. Икенче угылы Чулпан баба дип мәшһүрдер. Борындык исемле угылы килеп, Зөя суы янына, Бәрле суы тамагына урман эченә урын ачып утыргандыр. Борындык авылы дип исем шуннан калган икән. Чулпан дигән угылы янә урман эченә, бер чишмә янына килеп урнашкандыр. Чулпанка дигән шул Чулпан баба ихъя кылган (салган) авылдыр. Борындык—бик күптәнге иске авылдыр һәм иске заманда бик бай авыл булгандыр. Фабрика һәм завод тотучы байлар күп булган. Зур мәдрәсәләр булып, дәрес әйтүче мөдәррисләр, галимнәр була килгән. Әмма ахыргы гасырларда голәма беткән; байлары бөлеп беткәннәр...».

Өлкәннәр авыллары оешуны болай сөйлиләр.

Болгар дәүләте жимерелгәннән сон, Арыслан исемле бер кеше Болгар жирләреннән китеп Зөя ярына килеп утыра. Анын ике улы булган. Бер улы Борындык исемле, икенчесе Чулпан атлы булган. Анын Борындык исемлесе Бәрле тамагына, урман эченә йорт салып нигезләнгән, ә Чулпан исемлесе Зөянен икенче ягына чыгып калкулыкка йорт салган, шунда яшәп киткән дип сөйлиләр.

Авылга якын гына Чулпан таулары сузыла. Анын яныннан гына мул сулы Кирәмәт чишмәсе ага. Зөя һәм Бәрле ярларында чишмә-чыганаклар шактый күп.

Авыл кырыеннан ук урманнар башланып китә. Исемнәре үзенчәлекле, матурлар. Тулбый урманы, Руща урманы, Нарат тавы, Чулпан асты, Имәнсәр, Пристән һ.б. Урманнар киселгән саен яна үсентеләр утыртылып торганлыктан, урман байлыгы кимемәгән биредә. Урманнар шаулап-гөрләп үсеп утыралар.

Бик матур аланнар бар: Тирмән арты, Түгәрәк каш, Умарталык һ.б. Исемнәре дә жисемнәренә туры килеп тора.

Борындык Бәрле елгасынын Зөягә коя торган урынына утырган. Якыннан гына Гөбенә суы агып уза. Авылнын тирә-юнендә Урыс күле, Чуаш күле жәелеп ята. Авыл сакчылары кебек Нарат тавы һәм Чулпан тавы калкып тора.

Авыл елгаларга бай булганлыктан, күперләр дә шактый: Зөя күпере, Бәрле күпере, Гөбенә күпере, Асылмалы күпер, Таш күпер һ.б. Авыл зур һәм анын кырлары да күп: Зөя арты, Кобла тау, Нарат бue, Гөбенә буе, Сири тау, Парк арты, Имәнсәр буе, Бортак кыры һ.б.

Авыл халкы эшчән, күмәк хужалык эшендә дә, шәхси хужалыкларында да куллары алтын. Хәлимуллин Рәфкать, Гарифуллин Барый Социалистик Хезмәт Герое дәрәжәсе алганнар, ә Әбрар Жәләлиев Советлар Союзы Герое. Дәминова Дәйлибәдәр һәм Габитов Рәхим—атказанган колхозчылар.

Авыл элек-электән зур булган. Анда 2 мәчет һәм мәдрәсә эшләгән. Яманаты чыккан утызынчы елларда мәчет манаралары киселгән, мәдрәсә ябылган. Авылда мәчет хәзер янадан торгызылган.

Борындыкта туып-үскән мелла Мансур бине Габдеррахман бине Әнис әл-Борындыкый турында Шиһабетдин Мәржани мондый сүзләр яза.

«Тумышы белән Жәбәлстандагы Зөя өязенен Борындык исемле карьясеннән, мелла Мөхәммәджан мөфтинен бабасы. Башта мелла Мортаза әфәнде шәкертләреннән булып, сонынннан, әйткәнемчә, ана каршы чыккан һәм дошманына әйләнгән булган. «Мансур әфәнде» һәм «Мансур хафиз» дип танылган. Күп шәкертләр жыеп, зур мәдрәсә тотып, дәрес әйткән. Ахыр гомерендә бер байнын кызына күзе төшеп, яучы жибәртеп соратып караса да, тәкъдиме кабул ителмәгән...».

Борындыкта хәзер якынча 360 хужалык исәпләнә. Урта мәктәп, клуб, балалар бакчасы, медпункт, кибетләр, элемтә үзәге эшли.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга. Мәктәптә тарих музее бар. Күп йортларга телефон кертелгән.

Авылдан ерак түгел Иске зират курты дип йөртелгән урын бар.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Күренекле әдәбият һәм тел галиме, әдәби тәнкыйтьче, педагог һәм журналист Җәмалетдин (Җәмал) Җәлалетдин улы Вәлидинең (1887—1932) тууына октябрь аенда 120 ел тула.*

*Җәмал Вәлиди элекке Казан губернасы Тәтеш өязенең Апас авылында дөньяга килгән, данлыклы «Иж-Бубый» мәдрәсәсендә белем алган. 1911-18 елларда Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә әдәбият укыткан. Шул чор татар вакытлы матбугатында (башлыча «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында) үткен публицист һәм гадел, таләпчән тәнкыйтьче, дәреслекләр авторы, Габдулла Тукай иҗатын иң башлап өйрәнүчеләрнең берсе буларак танылган. 1919 елдан башлап Казандагы төрле югары уку йортларында һәм фәнни оешмаларда педагогик, гыйльми эшчәнлек белән шөгыльләнгән, татар теленең диалектологиясе һәм терминологиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән.*

*1931 елда Җәмал Вәлиди нахакка гаепләнеп биш елга ирегеннән мәхрүм ителә һәм 1932 елда һәлак була. Үлеменнән соң аклана.*

*Исеме күптәннән галимнәрнең игътибар үзәгендә булса да, Җәмал Вәлидинең киң кырлы иҗади һәм фәнни эшчәнлеге хәзергәчә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Һәрхәлдә, әлеге вакытка кадәр мәкаләләре һәм фәнни хезмәтләре тупланган бер җыентык та дөнья күрмәде.*

*Укучыларыбыз игътибарына Җ.Вәлидинең милләт һәм дин мәсьәләсенә багышланган, хәзер дә актуальлеген югалтмаган бер мәкаләсе тәкъдим ителә. Авторы 1912 елда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан чагында язылган бу мәкаләнең теле, үз өслүбен саклаган хәлдә, хәзерге әдәби тел кагыйдәләренчә бирелде. Анда фәкать «төрек» сүзе генә (хәзерге телдә «төрки» мәгънәсендә кулланыла) үзгәрешсез калдырылды.*

Җәмалетдин
Вәлидев

# КАВЕМ ВӘ КАБИЛӘБЕЗ АРАСЫНДА

Без, бу дөньяда милләтләр арасында нинди урын тотарга тиеш? Бу дулкынлы дөньяда адашмыйча, чуалмыйча исән-сау иминлек ярына чыгу өчен көймәбезнең койрыгын ничек вә кай тарафка тотарга кирәк? Менә бу сораулар хәзер безнең бик күп кешеләребезнең башын били. Ләкин бу сорауларга җавап биргәнчегә кадәр «без кемнәрбез, безнең исемебез ничек?» соравы да күнелгә килә һәм теге ике сорауның нәүбәтен болар ала.

Чынлыкта без кемнәрбез? Ягъни, шушы Русиядә тора торган кырган башлы, сырган түбәтәйле, чигелгән читекле Нәҗметдиннәр, Бикмуллалар, Әхмәтҗаннарның барысына бердән ничек дибез? Русларга карасак, алар бу халыкка «татар» диләр, әллә кайдагы бер чирмешләрме, кемнәрдер боларны «чуаш» диләр, имеш. Әмма бу халыкның үзенә килсәк, болар үзләрен төрлечә: мөселман дип тә, Мөхәммәт өммәте дип тә, татар, башкорт, мишәр дип тә әйтәләр. Боларга карасак,

боларның асыл исеме мөселман булырга тиеш, чөнки алар житдирәк вә үзенчә әдәбирәк итеп сөйләгәндә шулай, мөселман дип, сөйлиләр. Татар дигән сүз тупас вә наданраклары тарафыннан яки бер түбәнсетү сыман мәгънә белән генә әйтелә.

Мәгълүмдер ки, бездә узган гасырның ахырында юаш кына бер уяну башланды һәм ул уянуның куәте вә йогынты мәйданы бу гасыр башында яхшы ук киңәйде. Бу уяну бездә чирек гасыр эчендә әлегә кадәр булмаган яна бер сыйныф хәзерләде. Бездә әүвәл халык—«мулла», «мужик» исеме белән—фәкать икегә генә бүленә иде. Менә инде, мулла да булмаган, мужик та булмаган өченче бер сыйныф килеп чыкты. Бу сыйныф халыкның йөрешләре, торышлары, өс-башлары, сөйләгән сүзләре, язган нәрсәләре муллача да түгел, мужикча да түгел иде. Болар әлегә кадәр сөйләнми торган әллә нинди сүзләр сөйләргә, әлегә кадәр һичберәү тарафыннан язылмаган әллә нинди нәрсәләр язарга башладылар.

Безнен халыкта әүвәлдән мәктәп, мәдрәсә дигән нәрсә бар иде: аларда әллә кай заманнан бирле укылып килгән китаплар укыла һәм бу китаплар шулай мәңгегә кадәр бара дип уйлана иде. Менә инде бу яна халык үзләре китап чыгара башладылар. Әүвәл мәдрәсәдә—хәлфә дә диләр, суфый да диләр, шәкерт абый да диләр—кулына чыбыркы тотып сандык өстенә ике кат мендәр салып утыра торган берәү була иде. Инде менә бу яңа чыккан халык «алай ярамый, мәктәптә теге яна китапларны укыта белә торган «мөгаллим» дигән бер кеше булырга кирәк», житмәсә тагын «укыткан өчен ана бераз акча да бирергә кирәк» диләр.

Гәзит дигән нәрсә инде ул ят бер әйбер түгел, безнен халыкка әүвәлдән бирле билгеле нәрсә иде... Хәтта «гәжит килгән икән» дигәч, улллары солдат булган әбиләрнен дә «Сугыш хәбәре түгел микән?» дип чәчләре үрә тора. Менә шулай булгач бездә гәзитне яна әйбер дип булмый. Булуын булмый, әмма ул чагында гәзитләр урысча гына була иде. Хәзер татарча да баса башладылар. Тагын ул татарча гәзитләрдә теге сугыш хәбәрләре һәм урам хәбәрләре генә язмыйлар. Халык аңламый торган, ягъни мужикча да түгел, муллача да түгел әллә нәрсәләр язып бетерәләр. Анда языла торган гажәп-гажәп сүзләр арасында «милләт» дигән бер сүз дә бар. Бу татар гәзитләрендә инде тулып ята. Дөрес, «милләт» дигән сүз һәрбер мәктәп күргән вә һәрбер «Иман шарты»н белгән кешенен исендә. Ләкин ул чагында Ибраһим галәйһиссәлам милләтеннән диеп әйтелә иде. Әмма бу гәзиттәге «милләт» дигәннәре ул булмаска кирәк, чөнки аны язар урын гәзит түгел. Соң бу нинди милләт?

Менә, гәзит укыганны читтән тыңлап тора торган һәрбер кара (темный) татар гавамының башына килгән бу сорау—«соң бу нинди милләт?» соравы безнен әлеге уянган дигәнебез, ягъни мулла да, мужик та булмаган сыйныфыбызның да башын байтак чуалдырды. Милләт дигәннән аңланырга тиешле нәрсә Ибраһим галәйһиссәлам нәселеме? Әллә Мөхәммәт галәйһиссәлам өммәтеме? Әллә сөнниләр генәме? Әллә бөтен төрки кавемеме? Әллә Русия мөселманнарымы? Әллә татарлар гынамы?

Чынлыкта, иске китапларыбызның кайсына карасак та, милләт дип бер диндәге халыкка әйтелгәнлеге беленә. Сүзлек китапларында да милләткә, бер диндә булган халыкка исем диеп мәгънә бирелә. Болай булганда, монда мөселманнарның һәммәсе кермичә, сөнни мөселманнар гына күздә тотылуы ихтимал, чөнки күп кешеләр фарсылар (ягъни, шигыйлар) белән бер милләттән булырга риза түгелләр. Бездә бу сүз бөтен төрки кавеменә дә гомуми кулланыла. Шулай ук хосусый Русия мөселманнары яки татарларны гына сыйдыра алырлык урында да килә.

Яшәештә, гадәттә, нәселдә һәм телдә бер охшашлык булмаган Африкадагы гарәп белән, уйлыймын ки, аңлы вә зыялы татар һич үзен бер милләттән санамас. Бездә фикри каршылык бигрәк тә ике маддәдә: «без төрекме? яки татармы?» Безне башкалар (шул җөмләдән диндәш вә нәселдәшләребез госманлы төрекләре дә) татар диләр. Шуна карап безне кайбер язучыларыбыз татар дигәннәр иде, ана каршы икенче берәүләре каләм тотып «юк, без төрекбез» диеп каршы чыктылар. «Тәрҗеман» гәзитәсе госманлылар, татарлар, сартлар вә кыргызларны чын (строгий) мәгънәсе белән бер милләттән санап, боларның язу, әдәбият телләре мотлакан бер булырга тиешлекне дәгъва итте... Риза казый безне һәрвакыт төрекләр вә телебезне дә төрки дип атый, татар дигән сүзне авызына да алмый вә язган вакытында

госманлы вә татар сүзләрен бергә катыштырып яза. «Вакыт» гәзитәсе, башына «төрекчә» дип куя. Мәшһүр Һади Максуди татар телен мөстәкыйль бер тел итеп таный, саф татарча яза вә, бу яктан, тәрҗеманчыларга каршы тора, әмма икенче яктан, Риза казый кебек үк, «татар» дигән сүздән кача, «җаридәи төркия» *(төркичә газета)*, «сарыф вә нәхү төрки» *(төрки телнең морфологиясе һәм синтаксисы)* дип яза. Икенче яктан байтак язучыларыбыз, бер дә тартынмыйча, «татарбыз» диләр һәм татарча язалар. Гомумән караганда, безнең төреклегебезне дәгъва кылучылар—тикшерену һәм өйрәнү әһеле булган тарихчыларыбыз. Әмма татар диючеләребез—әдәбият вә шигърияттәге мәшһүрләребез белән аларга белеп яки белмичә иярүче яшьләребез[1] .

Татар баласына «без татарбыз» дип әйтү бик табигый һәм бик хаклы бер дәгъва. Ләкин безнең яшьләребездән бу дәгъваны исбат итүчеләр күренмәде, бу һаман шул «без татарбыз» көенчә генә кала иде. Үткән ел «Шура» журналында бер «Татар угылы» белән бер «Төрек угылы» бу турыда байтак әрләштеләр. Вә үзләреннән бер нәрсә чыгара алмасалар да, рәхмәт, бу турыда нигезле һәм бик көтелә торган бер мәкаләнең язылуына сәбәп булдылар. Яшь язучыларыбыздан Галимҗан әфәнде Ибраһимов бер-берсен аңламыйча сугышып ята торган ике кешене аерган кебек—боларның дәгъвасын аерып бирде[2]. Галимҗан әфәнде безнең бер үк вакытта төрек тә һәм татар да булуыбызны, төреклек белән татарлык арасындагы нисбәт руслык илә немецлык арасындагы кебек капма-каршылык булмыйча, славян белән руслык арасындагы нисбәт кебек, хосусыйның гомумигә нисбәттә булуын бик ачык бәян итте. Аның бу сүзенә каршы язучы булмады шикелле.

Мөгаен бер исемнең булмавы бер безнең татарларда гына түгел, башка төрекләрдә дә, якынча әйткәндә, шул ук хәл. Без Рум иле вә Анатоли төрекләренә бары тик «төрек» дибез, ләкин алар үзләрен «төрек» диеп бик аз әйтәләр, алар язуда вә әдәбиятта үзләрен госманлы дип атыйлар, телләрен дә «госманлы теле» диләр. Профессор Васильевның әйтүенә күрә, госманлылар якын вакытка кадәр «төрек» исемен кабул итмәделәр, алар хәтта аны үзләрен кимсетүгә саныйлар (малоруслар «хохол» дигән сүзгә шулай карагандай). Төрекчәдә бик күп иске мәкальләр бар, мәсәлән әйтәләр: «төреккә шәһәр төрмә булып күренә», «төрек галим булыр, әмма инсан булмас», «төреккә падишаһлык бирсәң иң әүвәл үз атасын үтерер» һәм «төрек куян артыннан арба белән куа».

Димәк ки, безнең чын төрек диеп йөргән госманлылар да үзләрен чын төрек диеп белмиләр. Төрекләр безне татар диләр: без алар кебек үзебезнең татарлыгыбызны якын вакытка кадәр кабул итмәдек. Без кыргызларга казакъ димез; алар безне нугай диләр. Без үзебез нугай дип әллә кайдагы Әстерхан губернасындагы бер төр татарларга әйтәбез... Башкортлар күп вакытта безнең Казан татарларын мишәр диләр. Без Минзәлә һәм Бәләбәй өязе татарларына башкорт дибез вә алар үзләрен башкорт дип белми, бәлки башкорт дип Чиләбе, Златоуст, Эстәрлетамак өязләрендәге мөселманнарга әйтәләр. Фарсыча сөйләшә торган таҗикларга сарт дибез, төркичә сөйләшә торган Баку һәм Әстерханнардагы азәрбәйҗан төрекләренә «персиян», ягъни «фарсы» дибез. Димәк ки, бөек төрек өммәтенең төрле тармакларына һаман да гомуми һәм дөрес бер исем бирелмәде. Әдәбияты һәм матбугаты тәрәккъкыйдә булмаган, шуңа күрә бер-берсен танымаган вә танырга теләмәгән халык өчен бу хәл бик табигый.

Ярый—без татарбыз. Тагын бер мәсьәлә бар: соң бу татар дигәнгә кемнәрне кертәбез? Мишәрләр, башкортлар татар булалармы? Әллә татар дип Казан татарына гына әйтәбезме? Милләтләрне бер-берсеннән аера торган нәрсә—тел башкалыгы. Әмма башкорт, мишәрләр һәм Казан татарлары арасында бу аерма булганы юк.

---

[1] Әлбәттә, мәрхүм Каюм Насыйри моннан чыгарма. Ул үзенә бер дәвер кешесе һәм бердәнбер кеше. – *Җ.Вәлиди иск.*

[2] 1911-12 нче елларда барган бу бәхәстә «Төрек угылы» псевдонимы иясе педагог Хәсән Гали булганлыгы шул чор матбугатында ук әйтелгән. Бу хакта тарих фәннәре кандидаты Ф.Шәкүров кире каккысыз дәлилләр белән соңгы елларда кабат-кабат язды. Ләкин, шуңа да карамастан, «Төрек угылы» имзасын галим Ризаэтдин Фәхретдингә нисбәт итеп, фән докторларыбыз һаман да ялгыш фаразларын язып киләләр. – *Ред. иск.*

Башкорт һәм мишәр телләренең Казан татары теленнән аермасы фәкать кайбер хәрефләрне ялгыш вә сакау әйтүдән гыйбарәт ки, бу аерма Вятка губернасындагы русларның телләре белән Идел буендагы русларның шивәсендәге аермага караганда да аз. Шуның өчен бу милләтләрне гасырлардан бирле һичбер кыенлыксыз бер мәктәп, бер әдәбият тәрбия итте, болар бер-берсеннән һич ятсынмадылар. Казан татарларының иң сөекле, иң моңлы җырлары башкортның «Агыйдел»е белән башлана, шулай ук башкорт та җырларында Казан каласын үзенең Уфаларыннан, Оренбурларыннан күбрәк искә ала. Кайсыбер авазларның төрлечәрәк әйтелүе вә кайбер кушымчаларның башка булуы белән тел һәм милләт аерылса, дөньяда һичбер әдәби тел, һичбер әдәбиятле милләт барлыкка килмәс иде. «Мишәрләр һәм башкортлар татарга керәләрме?» соравы, бер караганда, бөтенләй мәгънәсез вә урынсыз сорау. Боларның берлеген тормыш күрсәтеп тора. Шулай, әмма боларның төрле исемнәр белән аталулары бик күп кешеләрне, аерым алганда, хөкүмәт әһелләрен вә русларны байтак шөбһәләргә һәм яман уйларга төшерә. Хөкүмәт тә, хакимлек итүче милләт булган руслар да безне бик аз таныйлар. Аларның күбесе татарлар белән башкортларны фәкать дин карендәшләре генә дип беләләр. Иптәшләребездән бер шәкерт пароходта бер студент белән очрашып, ана үзенең дүрт төрле тел (татарча, башкортча, мишәрчә һәм кыргызча) белгәнлеген сөйләп, студентны хәйранга калдырганлыгын сөйли иде.

Этнография һәм тел галимнәре төрекләрне 5 тармакка бүләләр: татар, кыргыз, чыгтай (сарт), якут (якутлар—Себердә ислам динендә булмаган төрекләр), госманлы. Болар арасыннан кыргызлар башка төрекләргә караганда тел җәһәтеннән татарларга бик якын. Сарт һәм госманлы телләре аһәң һәм тавыш җәһәтеннән безнекеннән яхшы гына аерыла: әмма кыргыздан аерма фәкать авазларны сакау яки алмаштырып әйтүдән гыйбарәт. Шуның өчен кыргыз арасында торган татар «мөлдәкәй» (мулла) берничә ай эчендә кыргыз шивәсен тәмам төшенеп житә. Татар мәдрәсәсендә укый торган кыргыз шәкертләре дә шулай ук татарча тиз төшенәләр. Әмма рум, гарәп, фарсы телләренең тәэсирләренә артык бирелгән госманлы һәм сарт телләре болай түгел. Боларда тавышларның физиологиясе башка.

Троицк шәһәрендә «Айкап» исемле кыргызча бер журнал чыга башлаган. Әгәр дә кыргыз теле шулай булса, кыргызча язып маташуда да әһәмият калмый, кыргызларны да, башкортлар кебек, бер татар әдәбияты тәрбия итә ала. «Айкап»ның теле шулкадәр җиңел ки, мин (һичбер кыргыз арасында тормаган кеше дә) тәмам үз телем кадәр аңлап укыдым...

Бу көннәрдә Истанбулда «Төрек йорды» исемле яна бер журнал чыга башлаган. Шуның бер номеры монда, Оренбургка да килеп җиткән. Бу журнал, исеменнән дә аңлашылганча төреклеккә, төреклекнең тереклегенә хезмәт итәчәк һәм җиһанның төрле кыйтгасына таралган төрки кавемнәрне бер-бере белән таныштырачак; төрекләрнең караңгы тарихларыннан кара пәрдәләрен күтәрәчәк.

Журналның теле саф госманлыча. Мөхәррирләре арасында Йосыф Акчура улы һәм Әхмәт Агаев та бар. Без менә шул журналдан мөхтәрәм Әхмәт бәк Агаевның «Төрек галәме» исемле мәкаләсен татарчалаштырып күчерәбез. Чөнки бу безнең югарыда үз тарафыбыздан язган нәрсәләрне байтак ача һәм аларга яхшы эпилог була ала.

Әхмәт бәк җәнапләре төрекләр яши торган җирләрнең чикләрен сызганнан соң болай ди:

«Бүгенге төрек галәме, территориянең киңлегенә караганда, Аурупа һәм Америкадан зур һәм житмеш-сиксән миллион кадәр халкы бар. Фәкать бу төрек галәме, соң заманнарга кадәр, үзенең киңлеге кадәр таркау вә зурлыгы нисбәтендә үз-үзен белми һәм хәбәрсез иде. Бу бөек кавемнең төрле яктагы ыруглары бер-берсен танымыйлар һәм араларында матди һәм мәгънәви бәйләнешнең үзенчәлеген белми иделәр. Госманлы төрекләре Кавказ төрекләреннән, Кавказ төрекләре Казан төрекләреннән, Казан төрекләре Азәрбайҗан төрекләреннән, Азәрбайҗан төрекләре Сәмәрканд төрекләреннән, Сәмәрканд төрекләре дә Колҗа төрекләреннән аерым иделәр. Бу таралганлык һәм таркаулыкның дәвамына өч төрле нәрсә сәбәп була иде: 1) мәзһәбләр каршылыгы, 2) сәяси аерымлык һәм

мохитка иярүчәнлек, 3) халык исемен танытуның юклыгы.

Динлелек—төрекнең табигатеннән. Әлбәттә, бу зур бер әхлакый өстенлек. Әхлакның динлелек белән табылганлыгын һич тә инкяр итеп булмый. Аурупада бу көндә әхлаклары иң нык булган халык—иң динле булган кавемнәр. Фәкать төрек бу сыйфатта югары дәрәҗәгә ирешкән дияргә мөмкин. Төрекнең күнелендә, гүяки, ике мәхәббәт, ике хис берләшми. Төрек бер тапкыр бер нәрсәне кабул иттеме, аңа каршы булган икенче бер нәрсәне кабул иткән кешене ул үз арасыннан чыгара. Монын раслыгына бик күп тарихи мисаллар китерә алабыз: Иранда баби мәзһәбе чыккач та аның өчен үз-үзләрен корбан итүчеләр Азәрбәйҗан төрекләре булды. Хәлбуки бабиларны нигезләүчеләр фарсылар иде. Шулай ук бүгендә дә Иран хөррияте вә конституцион тәртибе өчен тырышып ятучылар төрекләр. Шуның кебектер, ислам галәмендә билгеле булган бик күп мәзһәб һәм тарикатьләрнең башлап чыгаручылары күп вакытта башкалар булган хәлдә, шулар өчен тырышучы, тавыш вә бәхәс куптаручы төрекләр була. Янә шул җәһәттән ки, төрекләр арасына кергән тарикать мәзһәбләре каршылыгы аларның бер-береннән аерылуларына, araларына суыклык вә дошманлык төшүгә сәбәп булды.

Мөселман халкы арасындагы каршылык фәкать безгә—төрекләргә генә хас түгелдер. Мәсәлән, гарәпләр һәм фарсылар арасында да беркадәр мәзһәб белән тарикать каршылыгы бар. Ләкин, шулай да, болар үзләренең гарәп һәм фарсы булуларын онытмадылар. Хәлбуки, без төрекләр болай түгелбез. Бездә иң кечкенә бер мәзһәб каршылыгы һәм хәтта фикер башкалыгы төреклегебезне оныттыра вә хәтта төрек булмаган ят бер кавем белән берләшеп, төрекләргә каршы килерлек дәрәҗәгә җиткерәдер. Бу хәл, әхлак ныклыгының бер дәлиле булса да, халык берлеге һәм миллиятнең яшәве өчен зарарлы.

Төрекләрнең таралып, бер-берсеннән хәбәрсез калуларына бер сәбәп—аларның төрле җирдә һәм төрле мәмләкәттә яшәп, мохитка бик бирелүләредер. Төрекләр көнбатыш Азиягә килгәннән бирле берничә төрле хөкүмәтнең тәэсире астында булып килделәр.

Болар һичбер заман берләшкән бер хөкүмәт оештыруга ирешә алмадылар. Хәтта аерым-аерым булган төрек хөкүмәтләре дә бер-бере белән таныша алмадылар. Без бүген дә исемнәрен ләгънәт белән яд итә торган Чыңгызлар, Тимерләр һәм хәтта Сафавилар—һәммәсе берәр төрек хөкемдарыннан башка бер нәрсә түгел иделәр. Ләкин төрекнең башына бәла боларның бәрелешүләреннән килмәде. Мондый бәрелешүләр бездә генә түгел, башка халыкның тарихында да күп күренә. Французлар, немецлар, инглизләр һәм руслар урта гасырларда үзара вак хөкүмәтләргә кисәкләнеп, бер-берсе белән байтак бәрелештеләр. Ләкин бу сугышулар, бәрелешүләр бу милләтләрне бетермәде, бәлки боларда шул арада бер милләт фикере дә килеп чыкты һәм соңрак шул фикер җинде. Әмма төрекләрдә бу хәл булмады.

Башка милләтләр арасына кереп эрергә, мохитка иярергә төрек кадәр сәләтле бер кавем юктыр. Шулкадәр ки, төрек, үз халкының кавем шәрәфен, тарихының кыйммәтен, әдәбият, тел һәм хәтта ата-бабасыннан калган әсәрләр вә риваятьләрне дә онытырга әзер. Бу хакыйкатьне тарихыбызның һәрбер кәгазе исбат итә: төрекләр, Иран мәдәниятенә нигез салучылар булган хәлдә, милли тел һәм гадәтләрен онытып, бөтен күнелләре белән фарсы гадәте вә теленә ябыштылар. Янә, төрекләр, габбасиларның түбән төшү заманында исламиятнең ярдәменә житешеп, исламиятне асылда коткарган кебек, сүнәргә башлаган мөселман мәдәниятен дә яңарттылар. Һәм фәкать шул заманда гарәп гадәтенә һәм аларның яшәү рәвешенә шулкадәр бирелделәр ки, боларда төреклек әсәре калмады. Төрек тарихында очрата торган гаҗәеп хәлләрнең берсе: шәрык төрекләре (ягъни Иран вә Русиядәгеләр) көнбатыш төрекләрен (госманлыларны) «рум» (византияле) дип вә көнбатыш төрекләре шәрык төрекләрен «гаҗәм» (фарсы) дип атыйлар. Шулай итеп төрекләр, мохитка артык дәрәҗәдә бирелүдән, төрле якта төрле исем белән атала һәм бер-берсен танымый башладылар.

Өченче сәбәп: халык исемен танытуның юклыгы дигән идек. Менә бусы югарыда әйтелгән сәбәпләрнең нәтиҗәсе һәм сәбәбе.

Нәтиҗәсе: чөнки әлеге сәбәпләр төрекнең табигате булганлыктан, болар халыкны таныту казанышына киртә булалар. Мәзһәб каршылыгына бирелгән, мохитка ияргән, шулай итеп бер-берсенә кырын торган халыкның арасында ничек исем танылу алсын?

Сәбәбе: чөнки бу сыйфатлар төреккә бер кимчелек булганлыктан, төрек галәменең төрле дәверендә житешкән ирләре, фикер ияләре моңа каршы торып боларны бетерү чарасын эзлисе иделәр, хәлбуки болай итмәделәр. Киресенчә, бөтен зурларыбыз, фикер ияләребез, шагыйрь, әдип һәм тарихчыларыбыз шул кимчелекне олыладылар һәм куәтләделәр. Соң заманнарга кадәр төрек сүзе бер хурлау һәм кимсетү сүзе булып йөрде, язучыларыбыз гарәпчә һәм фарсыча язуны үзләренә бик зур дәрәҗә саныйлар иде. Төрек теле онытылу дәрәҗәсенә житте. Әдипләребез, шагыйрьләребез соң заманнарга кадәр төрек ышанычы, төрек идеалы исеменә бер нәрсә эзләмәделәр, тапмадылар. Хәтта кайберләре бу соң айларда, бер мактанган рәвештә, госманлы мәмләкәтендә солтаннар нәселеннән башка бер төрек гаиләсе булмавын дәгъва кылдылар. Табигый, мондый кавемдә исем таныту булачак түгел. Бер төрле өмете, идеалы булмаган бербөтеннең төрле кисәкләре арасында матди, мәгънәви нинди бәйләнеш булсын. Шиллерсыз, Гетесыз, Гердерсыз, Гегельсез бер Германия яки Пушкинсыз, Карамзинсыз бер Русия оештырыла алыр идеме? Бер халыкны үз-үзенә таныттыручы—шул халык житештергән әдип һәм шагыйрьләре, фикер вә зиһен ияләре. Болар һәр кавемнең йөзен күрсәтә торган көзгеләр болар. Халыкларның ышанычларын, идеалларын тәгаен итүче, аларның матди һәм мәгънәви куәтләрен билгеле бер юлга салып, мәгълүм бер ноктага тугры юнәлдерүчеләр».

Агаев җәнапләренең сүзе шунда тәмам. Мин дә, артык үз тарафымнан бер сүз кушарга хаҗәт күрмичә, сүземне шунда тәмам итәм.

*«Шура» журналы. 1912.—№ 1.—Б. 8—12.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклангап кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз иде! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр кишт-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГАРУЗ** (аруз), гарәп классик поэзиясендә барлыкка килгән метрик системадагы шигырь төзелеше. Гарәп, фарсы һәм төрки телле поэзияләрдә кулланыла. Гарәп фонетикасы кануннары буенча сүзләрдә озын һәм кыска иҗекләрнең аерым бер тәртиптә чиратлашу үзенчәлегенә нигезләнгән. Теоретик яктан нигезләүчесе - гарәп галиме Хәлил ибне Әхмәд (700-786). Г.ның төп үлчәмнәре бәхер дип атала. Алар барлыгы унтугыз: тавил, мәдид, басыйт, камил, вафир, һәзаҗ, рәҗәз, рәмәл, сәригъ, мөнсәрих, хәфиф, мозаригъ, мокътәзаб, мoҗтас, мөтәкәриб, мөтәдарикъ, җәдид, кәриб, мөшакил. Һәр бәхер үзе берничә төрдәге вәзенгә ия. Төрки телле шагыйрьләр Г. системасын үз телләре хасиятләренә буйсындырып кулланалар: аларда сонор тартык (р, л, м, н) һәм чыжылдавык тартык (ч, ж, ш,) авазларга беткән иҗекләрдән кала барлык ябык иҗекләр озын иҗекләр булып саналалар, ә сузык авазларга беткән иҗекләр, буынның, ритм калыбының (тәфагыйльнең) кайсы урынында килүенә карап, йә озын, йә кыска иҗекләр булып саналырга хаклылар. Татар телендә сузык авазлар озынга-кыскага бүленмиләр, шунлыктан иҗекнең озынлыгы-кыскалыгы сүзнең язылышы б-н түгел, ә реаль яңгырашы, сүзләр тезмәсендәге ритмик әйтелеше б-н аерымлана. Мәс.:

*Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,*
*Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.*

Беренче юлдагы башлангыч ике сүз телдән кычкырып укыганда баш-лый-гале рәвешендә яңгырый, ягъни вәзен калыбының «фагыйләтен» (- U - -) схемасына туры килә. Тулаем поэманың (Г.Тукай, «Печән базары ...») вәзене, ритмик төзелеше – рәмәле мөсәддәси мәхзуф калыбына (- U - - - U - - - U - -) таңгәл (фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт). Татар шагыйрьләре Г.ның нигездә ике бәхер үлчәмен – һәҗәз б-н рәмәл вәзенен кулланалар. Мәс., «Кисекбаш китабы»нда, Утыз Имәни, Г.Тукай һ.б. шагыйрьләрнең иҗатларында бу ике бәхернең тулы яки кыскартылган шәкелдә әлеге ике вәзене ешрак очрый.

Әд.: Табрз В. Джам-и мухтасар. Трактат о поэтике. М., 1959; Хамраев М.К. Основы тюркского стихосложения. А.-А., 1963; Фролов Д.В. Классический арабский стих. История и теория аруда. М., 1991; Курбатов Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. К., 1984.

*Х.Р.Курбатов.*

**ГАСРЫЙ** Нәҗип (Мәүләбирдиев Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы) (1886, Әстерхан губ. Казый а. - 1937), әдәбият тәнкыйтьчесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар әдәбияты укыта. «Ил», «Идел», «Йолдыз» ж-лларында басылган, 20 йөз башы татар әдәбияты һәм татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган, Г.Тукай, М.Акъегетзадә, Г.Ибраһимов, Гыйффәт Туташ иҗатларына караган күпсанлы мәкаләләр авторы.

**ГАТАУ** Макс (Гатауллин Гайнетдин Зәйнетдин улы) (1913, хәзерге Курган өлкәсе, Әлмән р-ны Тозау а. - 20.11.1941), шагыйрь. 1931-34 тә елларда балалар йорты директоры, 1934-37 дә Чиләбе шәһәрендәге татар мәктәбендә завуч, 1937-40 та директор. Бер үк вакытта Казан пед. ин-тында читтән торып укый. Беренче шигырьләрен «Социализм юлы», «Урал большевигы», «Коммунист» г-таларында бастыра. 1939да «Урал мәхәббәте» исемле беренче шигъри җыентыгы чыга. Аерым шигырьләре «Үсү җыры» (1934), «Очкыннар» (1940) исемле күмәк җыентыкларга кергән. Бөек Ватан сугышында катнаша. Калинин өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган сугышта һәлак була.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

## Сафуан Мулла Галигә 80 яшь



Бездә шигъри романнар, шигъри повестьлар бик тә сирәк языла. Бу айда үзенең 80 яшен тутыручы шагыйрь Сафуан Мулла Гали үткән гасырның туксанынчы елларында «Биздерсәләр туган жиреннән» исемле һәм шактый күләмле шигъри повесть бастырып шигъриятебезнең әнә шундый сирәк авторлары арасына керде. Аның бу әсәре туксанынчы елларда азатлык яулаган татар халкына саллы шигъри куәт булды.

*Тарихыңнан искән*
*Гөлләр исе*
*Әйтеп тора синең кемлекне.*
*Вакыт җитте —*
*Үз хакыңны белеп*
*Яшә, халкым, булып иреклe!*

Вакытлы матбугатта Сафуан Мулла Галинең әнә шундый ялкынлы шигырьләре дә еш басылды. Хәзер инде ул «Сәлам бирәм!» (1986), «Күзгә балкыш» (1988), «Мәңгелек йөрәк» (1989), «Биздерсәләр туган жиреннән» (1993), «Йөрәктәге төеннәр» (1997), «Ераклардан киләм» (2003) исемле алты шигъри китап авторы.

Сафуан Галәүтдин улы Муллагалиев 1927 елның 12 сентябрендә Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Чаганлы авылында туа. 1941 елда шул авылда җиленче сыйныфны тәмамлагач ул колхозда эшли башлый. 1944 елда армиягә алына, ләкин бераздан сәламәтлеге какшау сәбәпле армиядән азат ителә.

1947 елда урындагы түрәләр белән килешә алмыйча Сафуан Мулла Гали ерак Үзбәкстан якларына чыгып китә. Андагы Маргелан шәһәрендә озак еллар буе төзелештә эшли, рәссамлык һәм бизәү эшләре белән дә шөгыльләнә.

1982 елда шагыйрь Казанга кайта, бераздан Татарстан Язучылар берлегендә комендант булып эшли башлый. Бер-бер артлы шигъри китапларын бастыра. Аның иҗаты турында С. Хәким, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов һ. б.лар матбугатта әйбәт фикерләр язып чыктылар.

Өлкән каләмдәшебезне олы юбилее белән кайнар котлыйбыз һәм аңа ныклы сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

## Урамга чыгып кычкырыйммы?

Үзем алтынчы дистәне тәмамлап килгән кешемен. Гомерем буе диярлек механизатор булып, авыл кешесенә хас булганча җирдә казындым. Мине Башкортстанда яшәүче татарлар язмышы борчый. Дөресен әйткәндә, гади башкорт халкына карата бернинди дәгъвам да юк, киресенчә, кардәш халык буларак аның телен-мәдәниятен ихтирам итәм. Мәктәптә татар телендә укысам да, башкорт басмаларын бернинди авырлыксыз укый алам. Аллага шөкер, җиребез дә җитәрлек, бүлешәсе юк.

Әле берничә ел элек кенә Башкортстанда миллионнан артык (1 млн. 120 мең. — ред.) татар яши иде, гомумән, руслардан кала сан ягыннан икенче урында идек. Соңгы халык санын алу вакытында, төрле куркыту, мәҗбүр итү, фальсификация, алдашу алымнарын кулланып, ярты миллионлап татарны башкорт диеп яздырдылар. Әгәр тагын да халык исәбен алу үткәрелсә, без барыбыз да башкортка әйләнеп бетмәбезме?

Соңгы елларда татарны башкортлаштыру сәясәтен хөкүмәт үзе планлаштыра. Бу мәҗбүри ассимиляция сәясәте бернинди хокук кысаларына да сыймый. Сүздә республикада барлык милләт кешеләре дә үз туган телендә белем алырга хокуклы диелсә дә, бу өлкәдә тагын да оятсызрак, астыртын, мәкерле эш алып барыла. Республикага исем биргән халык теле, дәүләт теле исеме астында безнең татар балаларын, оныкларыбызны балалар бакчасыннан алып, мәктәпләрнең башлангыч сыйныфыннан башлап башкортча укырга мәҗбүр итү, татар балаларын үз туган теленнән ваз кичтерүне максат итеп куялар. Шул юнәлештә Башкортстанның мәгариф өлкәсендә даими эш алып барыла. Мәгариф хезмәткәрләре татарлар яшәгән район мәктәпләрендә әледән-әле тикшерү үткәреп торалар. Аз гына ризасызлык белдергән район мәгариф җитәкчеләрен законсыз рәвештә эшеннән алалар. Яңа туган балаларны хәтта әти-әнисеннән дә сорамыйча башкорт итеп язу очраклары да күп. Үзегез дә аңлыйсыздыр, монда яшь буынны тоташ башкортлаштыру идеясе ярылып ята.

Шушындый күз алдында кылынган гаделсезлек хакында кычкырып әйтүче юк, чөнки һәркем эшеннән куылудан курка. Менә шулай итеп яшь буынны көчләп башкорт ясау башкорт милли интеллигенциясенең төп максатына әйләнде. Дәүләт теле дию бер сылтау гына ул. Нигә соң алай булгач корылтай утырышлары башкорт телендә алып барылмый? Хәтта авыл җирендә бер гариза кисәге язарга туры килсә дә рус телендә язарга кирәк.

Абруйлы зыялылар, Башкортстанның татар телле язучы-шагыйрьләре, журналистлары, Башкортстан татарлары, татар яшьләре оешмалары! Сез бу хәлләрне белмисезмени? Киләчәк буыннар, милләт язмышы сезне борчымыймы? Бу олы гаделсезлеккә каршы монда, бәләкәй генә татар авылында урамга чыгып кычкырыйммы?

Татарстанда чыгучы абруйлы «Казан утлары» журналында Башкортстаннан килгән бер хаттан мондый шигырь юллары бирелгән (2005 ел, 5 нче сан):

*Татар, башкорт гомер буе туган булып яшәде,*
*Бергә чәчте, бергә урды, бер казаннан ашады,*
*Көтмәгәндә ил өстенә килеп туды бер каза—*
*Башкортстан татарларын «чукындыра» Мортаза.*

Мин президентыбыз Мортаза Гобәйдулла улын зур шәхес һәм оста җитәкче буларак хөрмәт итәм, ләкин милли мәсьәләдә аның белән килешмәвемне белдерәм, чөнки әлеге хәлләр ул җитәкчелек иткән чорга туры килә. Әгәр игътибар белән радио-телевидение тапшыруларын тыңласаң, син татар булсаң да, Башкортстанда яшисең икән, башкорт буласың, диеп аңга сеңдерергә тырышу сизелә.

Башкортстан татарлары үзләренең милли мәркәзе булган Казан радиотелевидениесеннән, шактый дәрәҗәдә хәтта матбугат басмаларыннан да мәхрүм булып яшиләр. Монда Татарстан хөкүмәтенә дә үпкә сүзләре әйтергә була, чөнки ул безгә мораль яктан булса да ярдәм итәргә бурычлы дип исәплим. Әнә бит, Башкортстан хөкүмәте күрше өлкәләрдә яшәүче башкортларга хәтта матди ярдәм дә күрсәтә...

**Ралиф НУРИСЛАМОВ**
*Борай районы, Бакалы авылы.*

## Наилә Краева



Наилә Фәрит кызы Краева 1949 елны Казан шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Башкалабызның 131нче мәктәбен тәмамлаганнан соң Казан университетының тарих-филология факультетында югары белем ала. Профессиясе— рус әдәбияты укытучысы.

Хезмәт юлын Казан вертолет заводының күптиражлы «Знамя Труда» исемле газетасында редактор буларак башлап җибәрә. Бер үк вакытта «Комсомолец Татарии» газетасында хезмәттәшлек итә, күп санлы очерклар, мәкаләләр бастыра. Н. Краеваның әдәбиятта чынлыклап эшли башлавы үткән гасырның 90 нчы елларына туры килә. Рус һәм татар телләрен камил белгәнлектән, ул тәрҗемә эшенә алына. Дөрес, 70 нче елларда ук аның кайбер тәрҗемә үрнәкләре матбугатта басылып чыккан була инде («Рассказы 1971 года. ТКН). Н. Краева рус әдәбияты һәм тәрҗемә секциясе эшендә актив катнаша башлый. Аның тәрҗемәче булып формалашуында күренекле әдип-тәрҗемәче Кыям Миңлебаевның роле зур. Соңгы елларда ул—Мөсәгыйт Хәбибуллин, Айдар Хәлим, Кыям Миңлебаев, Гариф Галиев, Гарәфи Хәсәнов, Ләбибә Ихсанова, Марат Закирларның кайбер әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итте һәм алар төрле нәшриятларда басылып та чыктылар. Шулай ук, рәссамнар Илдар Зарипов, Канафи Нафыйговларның рус һәм татар телләрендә нәшер ителгән альбомнарында да Н. Краеваның хезмәте кергән.

Ире хәрби кеше булу сәбәпле, Н. Краева гаиләсе белән илнең төрле төбәкләрендә яшәп ала: Германия, Украина, Кыргызстан… Ул кайда гына яшәмәсен, педагог укытучы буларак, әдәбиятка якын булырга тырыша. Аның әдәбият укыту, стажы гына да 30 елга якын. Соңгы елларда Н. Краева Татарстан бизнеска булышлык итү институтында (ТИСБИ) өлкән укытучы булып эшли. Табигате белән актив, күңел җегәре ташып торган язучы-педагог татар әдәбияты казанышларын укучы-студентлар арасында пропагандалауга зур көч куя. Аның фәнни-методик хезмәтләре институт басмаларында еш дөнья күрә.

2007 елның 28 маенда Кабул итү коллегиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр: Кыям Миңлебаев, Саимә Ибраһимова, Лилия Газизова) язучылар берлеге идарәсе Краева Наилә Фәрит кызын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.



*СССР язучыларының IV съездында катнашучылар. Сулдан уңга—Хәй Вахит, Ләбибә Ихсанова, Әхмәт Саттар, Михаил Львов, Зәйнәп Биишева, Мирсәй Әмир, Җәмил Мостафин, Леонид Соболев, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким. 1967 ел.*



*Әдәбият галимнәре Ибраһим Нуруллин (уңда), Флүн Мусин. 1980 ел.*



*Шагыйрь Эдуард Мостафин (1945—1997).*



*Әлмәт язучылары Башкортстанда. Сулдан уңга—Гамил Афзал, Вәзих Исхаков (Уфа), Эдуард Касыймов, Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова. 1966 ел.*



*Шагыйрь Сәйфи Кудаш (1894-1993). 1988 елда төшерелгән фото.*



*Замандашлар. Сулдан уңга—Мәдинә Маликова, Флүс Латыйфи, Әсгать Салах. 2006 ел.*

## ШАРТНАМӘ ГАМӘЛДӘ!

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ

**ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОН**

**Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамәне раслау хакында**

*Дәүләт Думасы тарафыннан 2007 елның 4 июлендә кабул ителде*
*Федерация Советы тарафыннан 2007 елның 11 июлендә хупланды*

2007 елның 26 июлендә Мәскәү шәһәрендә кул куелган Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамәне расларга.

**Россия Федерациясе**
**Президенты** **В. ПУТИН**

Мәскәү, Кремль, 2007 ел, 24 июль, № 199-ФЗ

## КАЗАННЫ ТӘКЪДИМ ИТҮ

Премьер-министр Р. Миңнеханов Бангкокта (Таиланд) Казанны 2013 елгы Бөтендөнья җәйге универсиаданы үткәрүгә кандидат сыйфатында тәкъдим итүдә катнашты.

Татарстанның рәсми делегациясе, Халыкара студентлар спорт федерациясе (FISU) Генераль ассамблеясе башкарма комитетының яна составын сайлау тантанасында катнашып, FISU әгъзаларын Казан белән, республика башкаласының Бөтендөнья студентлар уеннарын үткәрү мөмкинлекләре белән таныштырды.

## МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ФЕСТИВАЛЕ

Июль уртасында Казанда Татар яшьләре көннәре һәм аның кысасында Мөселман яшьләре фестивале булып узды. Татар яшьләре көннәре инде унҗиденче тапкыр узса да, мона кадәр анарда бу кадәр санда мөселман егет-кызлары катнашканы булмады. Чарага Россиянең 44 төбәгеннән җыелдылар. Тантаналы ачылышка килгән республика Президенты Минтимер Шәймиев Мөселман яшьләре фестивале оештырылуны зур кыюлык дип атады. «Россиядә яшәүче һәр халыкның үз йөзен, традицияләрен саклап калып кына без бердәм, демократик дәүләт булып үсә алачакбыз, башкалардан аерылып торачакбыз, — диде ул. — Татарстан — дөнья буйлап сибелеп яшәүче татарларның мәккәсе, тарихи туган җире. Бөек Болгар ханлыгы чорында безнен бабаларыбыз бирédә Россия җирендә беренчеләрдән булып Ислам динен кабул иткән. Бүген безгә үз милләтебезне торгызу, динебезне кайтару мөмкинлеге туды. Ә сезгә, яшьләргә, шушы байлыкны — тел һәм динебезне киләчәк буыннарга тапшыру бурычы йөкләнә».

Фестиваль ачылышында Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Александр Коновалов та катнашты. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: мөселман яшьләрен берләштерү идеясен беренчеләрдән булып тәкъдим итүче кеше — ул. Дин һәм замана турында сүз чыккач, ул: «Бүгенге мөселман яшьләре дин тәгълиматларын гына өйрәнеп, үз-үзләренә йомылып яшәүче егетләр һәм кызлар түгел, алар заманча, ачык, кызыксынучан яшьләр, дин аларга уңышларында ярдәм генә итә», — диде.

Биш көн буена яшьләр түгәрәк өстәлләрдә, төрле секция эшләрендә катнашты. Алар, шулай ук, «Борис Полевой» теплоходында су юлы буйлап сәяхәттә дә булдылар.

Яшьләр Исламның яшәебездә тоткан урыны, мөселман яшьләренең киләчәге турында фикер алышты. Фестиваль кысаларында гына түгел, алга таба да аралашу, элемтәне югалтмау максатыннан махсус концепция төзергә карар кылдылар.

## ТАТАР БАСМАСЫНЫҢ ЧИШМӘ БАШЫ

Милли китапханәдә «Татар китабының чишмә башы» дигән күргәзмә ачылды. Ул беренче төрки-татар басма китабы чыгуның 285 еллыгына (кайбер галимнәр татар китабы бер гасыр алда ук дөнья күргән дип исәпләләр) багышлана. Ай ахырына кадәр эш-

ләячәк экспозициядә татарларда китап басу тарихын һәм үсешен чагылдырган әдәбият тупланган. Алар арасында бик кыйммәтле борынгы басмалар да, милли матбугат тарихын яктырткан заманча тикшеренүләр дә бар. Күргәзмәгә килүчеләр хозурына күренекле китап белгече, академик Әбрар Кәримуллин хезмәтләре, 1722 ел манифесты күчермәсе һәм аның татар, рус, инглиз телләренә тәрҗемәсе дә тәкъдим ителә. Искә төшерик: 1722 елның июлендә Петр I нең Әстерхандагы «йөзмә» типографиясендә беренче рәсми татар басмасы дөнья күрә. Бу Петр I нең Фарсы походы уңаеннан язылган манифесты булып, анда сугыш хәрәкәтләренең максатлары аңлатылган. Манифест татар телендә мең данә нәшер ителгән һәм сугышчылар арасында таратылган.

## АЛАБУГА—ЧУЛМАН БУЕ ҖӘҮҺӘРЕ

Алабуганың 1000 еллыгына багышлап, Татарстан Милли китапханәсенең күргәзмәләр залында әнә шул исемдәге китап күргәзмәсе оештырылды.

Алабуга — кабатланмас тарихи-мәдәни мираска ия, горурланырлык бай тарихы һәм үз йөзе булган борынгы шәһәр. Күргәзмәгә шәһәрнең үткәнен һәм хәзергесен чагылдырган төрле басмалар — китаплар, матур бизәлешле альбомнар, открыткалар, харитәләр, журнал мәкаләләре куелган.

Бирелгән басмалар аша Алабуганың чал тарихы, анда булып үткән истәлекле вакыйгалар, шушы җирдә туып-үскән, яшәгән һәм эшләгән мәшһүр шәхесләр турында киң мәгълүмат алырга мөмкин. Шәһәр буенча юл күрсәткечләре исә тарих, мәдәният һәм архитектура һәйкәлләре белән таныштыра. Күргәзмәдә И. Шишкин, Н. Дурова, М. Цветаева музейларына багышланган рәсемле басмалар да урын алган.

## ТУКАЙ БИЕКЛЕГЕ

ТР Президенты матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев исеменә, Тянь-Шань тавының үзәк өлешендәге Сарыджаз сыртында 5063 метр биеклектәге исемсез тау башына менүне оештырудагы ярдәм өчен рәхмәт сүзләре белән Татарстан Республикасы ветеран альпинистлар командасыннан телеграмма алынды. Тау башына тәүге тапкыр менүчеләр хокукыннан файдаланып, альпинистлар биеклеккә бөек татар шагыйре Габдулла Тукай исемен биргән.

## БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ ХӨРМӘТЕНӘ

Мәшһүр шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның туган көне республикада әдәби бәйрәм төсендә билгеләп үтелә. Күркәм традиция быел да дәвам итте.

Әүвәл якташыбызның туган җире — Лаеш районына Казаннан бер төркем шагыйрьләр, Милли китапханә һәм Милли музей хезмәткәрләре, югары уку йортлары галимнәре җыелды. Лаеш сәнгать мәктәбендә оештырылган очрашуда башкалабыз кунакларына район мәктәпләре укытучылары һәм укучылар кушылды. Бәйрәмне кереш сүз белән Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгы урынбасары Илгизә Тимершина ачып җибәрде. Ул Г. Державин исемендәге туган якны өйрәнү музеен яңартуда, шагыйрьнең үзе исән чакта чыккан китапларын юллауда булышлык күрсәткән Мәдәният министрлыгына ихлас рәхмәтләрен белдерде.

Каләм әһелләренә Г. Державин исемендәге бүләкләр тапшыру, мөгаен, әдәби бәйрәмнең төп бизәге булгандыр. Җиде ел элек Татарстан Язучылар берлеге һәм Лаеш районы хакимияте тарафыннан булдырылган әлеге премиянең дәрәҗәсе быел тагын да үсте: гамәлгә куючылар арасына ТР Мәдәният министрлыгы да өстәлеп, ул республика күләмендәге әдәби бүләк статусын алды. Бу хакта бәйрәмдә катнашучыларга Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов хәбәр итте. Лауреатларга махсус таныклык һәм истәлек медале бирелә.

Быел Г. Державин исемендәге әлеге премиягә татар шигъриятенең күп кенә әсәрләрен русчага тәрҗемә иткән күренекле шагыйрь Николай Беляев («Помню. Слышу. Люблю» исемле китабы өчен) һәм шагыйрә Ольга Левадная («Из крика птиц растут воспоминания» дигән җыентыгы өчен) лаек булды.

Лаеш районында башланып киткән бәйрәм Казанда, Г. Державин һәйкәле янында дәвам итте. Шигырь сөючеләр хозурында сәламләү сүзе белән ТР Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов чыкты. ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Айдар Гайнетдинов яңа лауреатларны котлап, аларга саулык-сәламәтлек һәм иҗат уңышлары теләде.

Җыр-музыка белән аралашып барган бәйрәмдә шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Николай Алешков, Михаил Тузов, Борис Вайнер, Салават Юзеев, Альбина Әпсәләмова, Флера Тарханова, Александра Кашина һ. б. чыгыш ясады. Шигъри җыенны шагыйрә Лилия Газизова алып барды.

## ЧИРАТТАГЫ ФЕДЕРАЛЬ САБАН ТУЕ АСТРАХАНЬДА УЗАЧАК

«Киләсе елда Россиянең төп сабан туе Астраханьда үтәчәк»,—дип белдерде Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров «Интерфакс» агентлыгындагы матбугат очрашуы вакытында.

Киләсе елда Астрахань шәһәренә 450 ел тула һәм федераль сабан туе шушы юбилей уңаеннан оештырыла торган чараларны башлап җибәрәчәк Р. Закиров сүзләренчә, Астрахань өлкәсе губернаторы Александр Жил-

кин Татарстан Президентына 2008 елгы федераль сабан туе эстафетасын Астраханьга тапшыруны сорап мөрәҗәгать иткән.

«Киләсе елда сабан туена гына да менгә якын чакырылган кунак килер, дип көтелә. Без бу чарага ел буена әзерләнәчәкбез»,— диде Ринат Закиров.

## УРТАК ТАМЫРЛАРНЫ БАРЛАУ

1-6 июль көннәрендә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында Даими халыкара алтаистик конференциянең сессиясе эшләде. Инде 50 нче тапкыр узучы бу сессия быел «Казан һәм Алтай цивилизациясе» дигән темага багышлап үткәрелде. Ул ТР Министрлар Кабинеты, Казан шәһәре хакимияте, Россия Фәннәр академиясе, ТР Фәннәр академиясе, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү һәм Тел белеме институты, Россия Лингвистика фәннәре академиясе белән берлектә оештырылды.

Даими халыкара алтаистик конференция — төрки һәм монгол халыкларын өйрәнү буенча тәҗрибәле һәм дәрәҗәле халыкара оешмаларның берсе.

Конференция тантаналы төстә ачылып китте. Премьер-министр урынбасары — мәдәният министры З. Вәлиева конференциядә катнашучыларга Президент М. Шәймиев котлавын ирештерде. Котлауда: «Алтай белән безне борынгы тарих бәйләп тора. Татарлар — алтайлылар белән этник тугандаш халык. Узган елның июль аенда без Алтай Республикасында «Алтай — Евразиянең йөрәге» истәлек билгесен урнаштырдык», — дигән юллар бар иде.

Даими халыкара алтаистик конференциянең 1962 елдан бирле генераль сәркатибе булган Денис Синор әфәнде (Индиана университеты профессоры, АКШ), авыру сәбәпле, сессия эшендә катнаша алмады. Аның котлавын һәм рәхмәт сүзен Берлин Ирекле университетының тюркология институты директоры, профессор, Даими халыкара алтаистик конференциянең генераль сәркатибенә кандидат Барбара Кельнер-Хейнкель житкерде.

Сессиядә дөньяның 14 иленнән килгән танылган галимнәр катнашты. Алар арасында Сиэтл шәһәренең Вашингтон университеты профессоры Ч. Карлсон (АКШ), Эгей университеты профессоры М. Акиф Эрдофу (Төркия), Эчке Монголия университеты профессоры Ху Гецзилету (Кытай), Венеция университеты профессоры Д. Стэри Энрико (Италия), Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты профессоры К. Бичелдей, РФА академигы Н. Бекмаханова, РФА академигы Н. Нарбаев, РФА Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург филиалы профессоры С. Кляшторный, Россия Лингвистика фәннәре академиясе президенты, Мәскәү чит телләр институты ректоры Э. Володарская, Археология һәм этнография институты профессоры Ю. Худяков (Новосибирск), Калмык дәүләт университеты профессоры В. Рассадин (Элиста), Татарстан Фәннәр академиясе академиклары М. Госманов һәм М. Зәкиев, ТФАның Тарих институты директоры Р. Хәкимов һ. б. бар.

Биш көн дәвам иткән сессиядә «Алтаистика: үткәннәре һәм бүгенгесе», «Тарихи лингвистика», «Фонология. Морфология. Грамматика», «Тарих», «Дөнья халыклары илләре. Тел һәм мәдәният», «Лексикология. Сүзьясалышы», «Әдәбият белеме», «Стилистика», «Культурология. Социология. Социолингвистика» дигән секцияләр эшләде. Кунакларны Ратуша бинасында Казан мэры И. Метшин кабул итте. Галимнәр Казан Кремлен, Кол Шәриф мәчетен, Благовещение соборын, Казан дәүләт университетын, аның тарих музеен, Шәһри Болгар шәһәрен карадылар.

## «СӘЛӘТ» СӘЛӘТЛЕЛӘРНЕ БАРЛЫЙ

12-15 июльдә Биләрдә XI «Сәләт» яшьләр фестивале «Фестиваль сәләтле балалар һәм яшьләрне барлау, аларның талантын ачу өчен тиешле шартлар булдыру максатыннан уздырыла», — диде Казан дәүләт университеты профессоры, «Сәләт» проектлары житәкчесе Жәүдәт Сөләйманов.

10 ел эчендә «Сәләт» фестивале хәрәкәтендә 10 меңнән артык мәктәп укучысы, студент, педагог һәм ата-аналар катнашкан. Моннан тыш, 100дән артык галим һәм сәясәтче, журналист һәм язучы, рәссам, актер һәм жырчы, композитор һәм спортчы, балалар белән очрашып, аларның дөньяга карашын кинәйтергә булышкан. Жәүдәт Сөләйманов сүзләренә караганда, әлеге фестиваль балаларны татар мәдәниятенең чишмә башына кире кайтара, туган тел традицияләрен яңарта. Моннан тыш, талантлы һәм максатчан укучылар бер-берсе белән танышу, Татарстанның башка шәһәрләре турында күбрәк белү мөмкинлеге ала.

Быелгы фестиваль кысаларында дистәләрчә иҗат лабораториясе эшләде, белгечләр сәләтле балалар өчен мастер-класслар үткәрде, аларның иҗатларын тәкъдим итү кичәләре, спорт-сәламәтләндерү һәм туристлык чаралары узды, брейнринг, музейларга һәм казу эшләре алып барыла торган урыннарга экскурсияләр, иҗат концертлары оештырылды.

Быелгы фестивальдә Татарстанның барлык районнары һәм шәһәрләреннән диярлек һәм Россия Федерациясенең дистәләгән төбәгеннән 1000нән артык бала һәм яшүсмер катнашты.

## ТӨРКИЯДӘ ТАТАР БӘЙРӘМЕ

Июль аенда Төркиядә яшәүче милләттәшләребез өчен зур вакыйга булды: мон-

нан 100 ел элек Себердән бирегә күчеп килгән Бөгередәлек авылы үзенең бер гасырлык юбилеен билгеләп үтте.

Бәйрәмгә Анкарадан һәм Истанбулдан, Иске Шәһәрдән һәм Көтәхиядән, Коньядан һәм Аланиядән, шулай ук Германия, Дания, Финляндия, Швеция, Норвегиядән дә күп татарлар килгән иде. Тантаналарда Татарстаннан да зур делегация катнашты, алар арасында Мәдәният министрлыгы белгечләре, тарихчы-галимнәр һәм артистлар бар иде.

Президент Минтимер Шәймиевнең котлау хатын Татарстанның Төркиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле Радик Гыйматдинов укып ирештерде, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закировның тәбрикләү сүзләрен язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова җиткерде. Котлау сүзләре белән шулай ук Төркиядә яшәүче татарларның милли оешмасы житәкчесе Атилла Көндуз һәм Казаннан тарихчы-галим Гүзәл Сөләйманова-Вәлиева чыгыш ясады.

Татарстан делегациясе Бөгередәлек авылына бүләкләр белән килгән иде, алар тантаналы рәвештә халыкка тапшырылды. Язучы Фәүзия Бәйрәмова исә үзенең яна гына басылып чыккан «Күчем хан» китабын бүләк итте. Соныннан Татарстан артистлары авыл халкына һәм килгән кунакларга зур концерт бирде, анда яшь жырчылар Айгөл Хәйри һәм Фәрит Фәйзрахманов, Зәйдән килгән «Мирас» вокаль ансамбле катнашты. Ә кичен милләттәшебез Гөлтан Ураллы һәм Төркиянең мәшһүр җырчысы Вуниямин Аксунгур Бөгередәлек халкын милли җырлар белән сөендерде. Арча районының Өчиле авылыннан килгән Фәргать һәм Айрат Зыятовлар, Конья шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Фәнис Зыялының чыгышлары да авыл халкы күнеленә хуш килде.

## ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛ

С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы быел унынчы тапкыр немец композиторы Иоһан Себастьян Бах музыкасын сөючеләрне җыйды. Композиторның туган көненә тәгаенләп оештырыла торган бу конкурс гаять үзенчәлекле. Аның тарихы да гадәти түгел—ул эшмәкәр һәм химаяче, классик музыкага гашыйк Рөстәм Латыйпов акчасына үткәрелә. Конкурсны оештыруда аның хатыны, пианист, композитор Разыя Еникиева зур тырышлык куя. Алар конкурска республиканың музыка мәктәпләре һәм училищелары укучыларын, ә жюрига Казан һәм Мәскәү консерваторияләренең танылган музыкант-профессорларын җәлеп итә. Бүгенге заманда яшь талантларны ачу гына түгел, аларга вакытында ярдәм итү дә бик мөһим.

Быел конкурста фортепиано, скрипка, альт, виолончель төрләре буенча 24 яшь музыкант катнашты һәм Бах музыкасы белән бергәттән танылган татар композиторы — Рөстәм әфәндене әтисе Мәсгут Латыйпов әсәрләре дә яңгырады.

Яшь музыкантларның чыгышын Россиянең халык артисты, профессор Р. Абдуллин, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклеләре — профессор Ә. Әхмәтова, композитор Р. Еникиева, доцент А. Михайлов, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Э. Бурнашева, Казан музыка училищесының фортепиано кафедрасы мөдире Ә. Сәйфуллина, Россиянең халык артисты, Мәскәү консерваториясе профессоры З. Шаһморзаевадан торган жюри бәяләде. Бәйге нәтиҗәләре буенча пианистлардан II премияне Р. Сәүбәнова һәм Р. Сафиуллина, I премияне В. Моратов һәм З. Фәхрәзиев бүлеште. Кыллы уен коралларында башкаручылардан I премияне скрипка буенча Ә. Габәши, виолончель буенча С. Пономарев алды. Композитор М. Латыйповның «Юмореска»сын иң яхшы башкарган Э. Хужина, И. Бахның «Ноктюрн»ын оста башкарган Д. Ерминская, «Ариоза»сын уйнаган С. Пономаревка диплом һәм махсус приз бирелде.

## ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕ БОЛГАРДА

20 июнь Татар ПЕН-үзәге өчен истәлекле дата дип санала: чөнки оешмага бу көнне 10 яшь тулды. Шул уңайдан Татар ПЕН-үзәге әгъзалары Идел буйлап Изге Болгар җиренә сәяхәт кылды.

Билгеле булганча, 1997 елда Бөтендөнья язучыларының Мексикада узган конгрессында Татар ПЕН-үзәге рәсми төстә теркәлә. 10 ел эчендә Татар ПЕН-үзәге химаясендә дистәләгән китап инглиз теленә тәрҗемә ителде һәм дөнья күрде. Болар арасында Г. Тукайның «Шүрәле», Р. Фәхретдиновның «Татар тарихы», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», Ш. Галиевнең «Кыек көзге», шулай ук «Татарский путь: права народа и политкорректность», «Татар әдәбияте антологиясе» һ. б. китаплар бар. Татар ПЕН-үзәге вәкилләре ел саен Бөтендөнья язучылар конгрессында катнаша, делегатларга әлеге китапларны тәкъдим итү була. «Бүген татарларны дөньяда беләләр, рухи кыйммәтебез дип саналган иң яхшы әсәрләребезне инглиз телендә укыйлар. Без бөтендөнья әдәбиятына күпер салдык»,—дип горурланып сөйли Татар ПЕН-үзәгенең башкаручы директоры Әхәт Мушинский.

Борынгы Болгар җиренә килеп житкәч, иң әүвәл мәйданда шигырь бәйрәме уздырылды. Аны алып барган шагыйрь Гәрәй Рәхим болай диде: «Бүген бирелә татар шигыре яңгырарга тиеш! Бу изге җирдә безнең табышыбыз бабаларыбыз яткан туфракка инәр һәм алар омтылган күкләргә барып ирешер». Шигъри митингта шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев,

Мөхәммәт Мирза, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Лилия Газизова, Ләбиб Лерон һ. б. катнашты.

«Болгар җиренә килү өчен 10 еллык юбилей бер сәбәп кенә, — диде Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин. — Әлеге изге җиргә сәҗдә кылу үзебезнең кем икәнлегебезне тагын бер кат аңларга ярдәм итә. Бүген бирегә күпләр балалары белән килде: күрсеннәр, кем булганнарын истә тотсыннар, дигән нияттән эшләнде бу. Үзем бирегә килгән саен дөнья турында уйланам, яңа хисләр белән кайтам. ПЕН-үзәк мәсьәләсенә килгәндә, аның оешуына сөенеп туя алмыйм. Бу эшнең кирәклеген отыры аңлый барам. Чөнки татар халкы хакында рус тарихчылары тарафыннан иң начар сүзләр таратылган. Без, әдипләр, моны төзәтергә алындык. Бик кирәкле эшләр башкарабыз. Киләчәккә дә планнар зурдан. Иң беренче чиратта, татар китапларын турыдан-туры инглиз теленә тәрҗемә итүче яшь кадрлар әзерләү ягын карарга иде. Эшебезгә яшьләрне тартырга тырышабыз, бездән соң хезмәтебезне дәвам итүчеләр дә кирәк бит. Язучылар берлеге белән дә дусттанә мөнәсәбәттә яшибез, кулга-кул тотынып эшлибез».

Изге Болгар җирендә язучылар берничә сәгать кенә булсалар да рухи баеп, илһами дәртләнеп кайттылар. Киләчәктә Татар Пен-үзәге турында документаль фильм чыгачак, сәяхәтнең аерым эпизодлары анда да чагылыш табачак.

### ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының җитәкчесе итеп Рамил Равил улы Хәйретдинов билгеләнде. Ул 1997 елдан бирле РФ территориясендә татар халкының мәдәниятен һәм тарихи һәйкәлләрен табу, өйрәнү һәм паспортлаштыру экспедициясе җитәкчесе һәм әгъзасы вазифаларын башкарды.

### УЙГЫР ШӘҺӘРЛЕГЕНӘ СӘФӘР

Казан дәүләт университетының 50 студенты һәм берничә галиме Тывада булып кайтты. Алар Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Красноярск университетлары вәкилләре белән бергә Тере-күлдәге Пор-Бажын утраунытытмасында археологик казу эшләрендә катнаштылар. Максат—кирмән-ныгытманың төгәл күчермәсен торгызу. Проектның идеясен Тывада туып-үскән, Россия гадәттән тыш хәлләр министры Сергей Шойгу тәкъдим иткән.

Уйгыр шәһәрлеген торгызу комитетының иганәчеләр советына Борис Грызлов, Николай Патрушев, Юрий Лужков, Минтимер Шәймиев, Валентина Матвиенко һәм башка күренекле шәхесләр керә. Утрауга экспедицияләр 2007-2009 елларда да җибәреләчәк. С.Шойгу фикеренчә, утрауда «Россия Шаолине» ясап булачак. Анда фәлсәфә, тибет медицинасы, сыбай йөрү, шәрекъ көрәше өйрәтеләчәк һәм теләгән һәркем кабул ителәчәк.

2007 елның 11 нче августында шагыйрь, прозаик, журналист **Нияз Акмал** (Акмалов Нияз Рәшит улы) вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Алтын көз.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Дания Гайнетдинова**.


# Яңа китаплар




**М. И. Махмутов (Мирза Мәхмүтов).** Мир ислама. —Казань: Центр инновационных технологий: 2006. —616 б. Тиражы—1000 данә.

Мәшһүр галим-педагог, җәмәгать эшлеклесе, академик Мирза Мәхмүтовнең фундаменталь бу хезмәте ислам дөньясын өйрәнүчеләр өчен үзе бер хәзинә. Китапта мөселман илләренең тарихи үткәне, бүгенге хәле чагыла; ислам динендәге халыкларның дөнья цивилизациясенә керткән өлешләре күрсәтелә. Гарәп теле белгече буларак, автор гарәп илләрендәге хәлләрне тарихи аспектта аеруча дәлилле итеп бәян кыла. Гарәп белән Шәрык дөньясы арасындагы каршылыклар, глобализация дәверендә диннәрнең роле, дөнья җәмәгатьчелегенең исламга тенденциоз мөнәсәбәт һ. б. бик тә мөһим проблемаларга ачкыч табып була бу хезмәттән. Китапның ахырында гарәп-мөселман илләре турында тәфсилле белешмә дә бирелгән.

Шунысын да әйтеп узыйк: киләсе елда бу уникаль хезмәтнең кайбер өлешләре белән журналыбыз укучыларын да таныштырырга җыенабыз.




**Эрот Зарипов.** Заман көзгесе: Альбом. —Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. —155 б. Тиражы—2000 данә.

Күренекле рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зариповның иҗаты бай һәм күпкырлы. Эшчәнлегенең төп максатын үз халкына хезмәт итүдә күргән останың һәм графикада, һәм нәкыштә яулаган үз биеклекләре бар. Альбомда, рәссамнарның төрле сюжетларга корылган график эшләре белән бергә, йөзләгән күренекле шәхесләрнең сурәтләре тупланган. Борынгы һәм хәзерге заман язучыларының портретлары гына да сиксәннән артык. Дистәләгән артистлар, композиторлар, рәссамнар, галимнәр, хуҗалык җитәкчеләре, якташлары... Альбомның исеме җисеменә бик туры килә: рәссамның иҗат көзгесендә—заман рухы, безнең мәдәни яшәеш.

Альбомга кереш сүзне шагыйрь Марат Закир язган. Кереш сүз татар, рус, рәсемнәргә аңлатмалар—татар, рус, инглиз телләрендә бирелгән.



Дания Гайнетдинова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)